
# КАЗАН УТЛАРЫ

6.1990



# 1990 ЕЛГЫ ТУКАЙ БҮЛӘГЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ



М. Мәһдиев,



С. Садыйкова,



И. Салахов.

**КПССның Татарстан өлкә комитеты,**
**ТАССР Министрлар Советы,**
**Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре комитеты**
1990 елда Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләрен бирү турында карар кабул иттеләр.

Премияләр:
язучы **Мөхәммәт Сөнгать улы Мәһдиевкә**
— «Кеше китә — җыры кала» (1979 ел), «Торналар төшкән җирдә» (1983 ел), «Бәхилләшү» (1989 ел) повестьлары өчен;
композитор **Сара Гариф кызы Садыйковага** — җырлары өчен (үлгәннән соң);
язучы **Ибраһим Низам улы Салаховка**
— «Колыма хикәяләре» (1989 ел) романы өчен бирелде.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ЖУРНАЛЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

1990

6

(812)

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН


## *БУ САНДА*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР


Ф. ЯРУЛЛИН. **Нәсел агачы.** *Поэма* . . . . . 3
З. ХӨСНИЯР. **Каешлану.** *Повесть* . . . . . 12
Я. ИГЕНӘЙ. **Ышандырып кара, Заман!** *Шигырьләр* . . . . . 55
Т. ӘЙДИ. **Елан угы.** *Роман* . . . . . 58


БЕЗДӘ КУНАКТА — КЫРЫМ ТАТАР ШАГЫЙРЬЛӘРЕ


Б. ЧОБАН-ЗАДӘ. **Дунай ташы.** *Шигырьләр* . 128
Ә. СӘЛАМӘТ. **Имә, шагыйрь, башыңны.** *Шигырь* . . . . . 129
ҖӘВӘҺИРӘ. **Анам.** *Шигырьләр* . . . . . 130
Ш. АЛЯДИН. **Кара кыз.** *Шигырь* . . . . . 131
С-Г. ӘМИН. **Өч аршын җир.** *Шигырь.* . . . . 132
Б. МАМБЕТ. **Яшәү өчен...** *Шигырь* . . . . . 133
ЧЕРКЕЗ-АЛИ. **Гафу ит мине.** *Шигырьләр* . . 134
Ә. ВӘЛИЕВ. **Кораблар.** *Шигырь* . . . . . 136
Р. ФАЗЫЛ. **Нинди гүзәл бу яз...** *Шигырь* . . 136
Д. ОСМАН. **Ах, татарлар, татарлар...** *Шигырь* . 137


ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ


Ү. МАТТЕУС. **Җыр.** *Хикәя* . . . . . 138


ПУБЛИЦИСТИКА


**Ил кала, халык кала...** *(Туфан Миңнуллин белән әңгәмә)* . . . . . 142
Ә. ӘМИТ. **Үлемне җиңгән халкым турында** . . 150
А. САДЫЙК. **Афәрин, адаш!** . . . . . 157


ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ


**Ярыш һәм әдәбият** *(Түгәрәк өстәл янында әңгәмә)* . . . . . 162


КИТАП КҮЗӘТҮ


Ф. ГАЛИМУЛЛИН. **Шагыйрь иманы** . . . . 172
Ш. ФАРИДОВ. **Роман хроникада ниләр бар?** . 175

З. ЗӘЙНУЛЛИН. Эстәрлебаш мәдрәсәсе . . . 178

ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕ

Тугызынчы дәрес . . . . . . . . . . . 183

Гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку күнекмәләре . . . . . . . . . . . . 186

Котлыйбыз! . . . . . . . . . . . . . 189
Мәдәният тормышы көндәлеге . . . . . . 190
Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*

РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН

*Редколлегия*

ГАРИФ АХУНОВ
МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
ФЛҮС ЛАТЫЙПОВ
*(җаваплы секретарь)*
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
МАРАТ МӨЛЕКОВ
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
РАШАТ НИЗАМИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*
ГӘРӘЙ РӘХИМ
КОЯШ ТИМБИКОВА
*(бүлек редакторы)*
МӘХМҮТ ХӘСӘНОВ
МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ
ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ
*(бүлек редакторы)*
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066,
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары — 53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-09.

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать, хатлар — 53-07-63
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: продолжение романа Т. АЙДИ «Жало змеи», повесть З. ХУСНИЯРА «Отупение». Поэма Ф. ЯРУЛЛИНА, стихи Я. ИГЭНЭИ.
«У нас в гостях — поэты крымских татар»: стихи Б. ЧОБАН-ЗАДЫ, А. САЛАМЕТ, ДЖАВАГИРЫ, Ш. АЛЯДИНА, С-Г. АМИНА, Б. МАМБЕТА, ЧЕРКЕЗ-АЛИ, А. ВАЛИЕВА, Р. ФАЗЫЛА и Д. ОСМАНА.
«Дружба литератур — дружба народов»: рассказ эстонского писателя У. МАТТЕУСА «Песня».
«Публицистика»: Беседа писателя М. Галиева с народным депутатом СССР, драматургом Т. МИННУЛЛИНЫМ.
Статья Э. ЭМИТ «Народ, победивший смерть» рассказывает о трудном пути возрождения крымских татар.
Очерк А. САДЫКОВА «Браво, тезка!» посвящена чемпиону мира по боксу казанцу А. Хаматову.
«Литературная критика»: «Возрождение и литература» (Беседа за круглым столом о проблемах современной литературы).
«Библиография»: Ф. ГАЛИМУЛЛИН рецензирует сборник воспоминаний о Х. Туфане. Рецензия В. ГАРИПОВА на книгу А. Гилязова и А. Литвина «До шестого августа».
«К истории культуры»: Статья З. ЗАЙНУЛЛИНА «Мәдрәсе Стерлибаша» знакомит читателей с постановкой народного образования среди татар в XVIII и XIX вв.
Уроки татарского языка.
Навыки чтения на основе арабской графики.
В номере отмечается 60-летие писателей М. Файзуллиной и М. Хасанова.
Хроника культурной жизни.
На наших обложках: башня Сююмбеки; известный татарский писатель Н. Фаттах.

*Бүлек редакторлары* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин.
*Редакторлар* Нияз Акмалов, Шамил Маннапов, Җәүдәт Миңнуллин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техредакция:* Р. Вафина, Л. Гатауллина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Т. Сибгатуллина.

Производствога бирелде 6.04.1990 ел. Басарга кул куелды 29.05.1990 ел. ПФ 05265. Офсет ысулы белән басылд.
Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 83044. Заказ Д-180. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1990 ел.

**Фәнис Яруллин**

# Нәсел агачы

ПОЭМА[1]

## 1

Барган идем авылым зиратына,
Йөрәгемне чолгап ут алды:
Янам, янам — бәргәләнеп янам,
Көнем белән төнем буталды.

Йөгереп карыйм йөзне җилгә куеп,
Ут ялмаган ләкин җилне дә.
Кычкырмакчы булам — тавышым чыкмый,
Сүзләр яна минем телемдә.

Әллә инде тәмуг утларының
Бер катрәсе төшкән ярама:
Янам, янам — күз яшьләрем яна,
Кабер өсләренә тама да.

Яна уйлар, яна зиһен дөрләп,
Тамырларда кайнап кан яна.
Үлгәннәр шул кире кайтмый диеп,
Әрнеп-әрнеп эчтә җан яна.

Яна ташлар, яна баскан эзләр,
Яна дөньям — барсын ут алган.
Яна хәтер, яна истәлекләр,
Кошлар хәтта җырдан тукталган.

Ялкыннарга кабат керә-керә
Эзлимен бер нәсел агачын.
Яфраклары аның кая төшкән,
Кәүсәләре аның кая соң?

Эзлим, эзлим, яфракларын эзлим,
Күмерләрен эзлим мин аның;
Һәрбер агач — бер терәге бит ул
Фаҗигалар тулы дөньяның.

---

Фәнис ЯРУЛЛИН (1938) — *шагыйрь, прозаик, драматург, татар, рус телләрендә дөнья күргән егермегә якын китап авторы. Ул — Татарстан Комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты. Казанда яши.*

[1] *Әсәрнең кыскартылган журнал варианты.*

Дөнья кинәт упкыннарга чумар,
Сирәкләнсә әгәр терәге.
Эзлимен — бер нәсел агачының
Кайнар көлен эзлим җирдәге.

Мине монда Хәтер алып килде,
Мәңгелек тик Хәтер агачы.
Кайта-кайта үткәннәрдән эзли
Киләчәген адәм баласы.

2

*Берәүләрнең ялгышларын*
*Бары тик бер иң күтәрә.*
*Берәүләрнең ялгышларын*
*Күп миллионлы ил күтәрә.*

Сиксәненче еллар башы —
Моннан бары ун ел элек,
Калай табут белән кайтты
Армиягә киткән егет.

«Әфган» дигән сүзне ул чак
Сөйләү әле тыела иде...
Чит җирләрдә кирәксезгә
Күпме җаннар кыела иде.

Сүз — авызда үлә иде,
Телләр бикле, ябык иде.
Хөр сүз өчен безнең авыз
Нык ябылган табут иде.

...Ачтырмадылар табутны,
Саклап торды ике солдат.
Йөрде алар итек белән
Гүя йөрәкләрне таптап.

Өзгәләнде ата-ана:
«Соңгы тапкыр күрик йөзен.
Әйбәт итеп юып күмик,
Гореф-гадәт шундый безнең.

Чиста кием кидерербез,
Гүргә үзебез индерербез.
Ачыйк, зинһар, бу табутны,
Зыян күрмәс һичберегез».

Юк, солдатлар ишетмәде
Эндәшкәнне инрәп-инрәп.
Ашыктырды алар барсын:
«Кыймшанығыз тизрәк, тизрәк!»

Бирде алар хушлашырга
Нибарысы ике сәгать.
Алар бары әмер үти,
Аларга ни гореф-гадәт?

Әмер төшә югарыдан
Охшап тәгәрәгән ташка.
Төшкән саен кызулый да
Килеп бәрелә безнең башка.

Коела ташлар, ярыла башлар,
Упкын йота сөякләрең.
Ташлар белән, башлар белән
Күмелә изге ниятләрең.

Сүнә өмет, үлә хыял,
Җаннар оча җәһәннәмгә.
Хыялыннан аердыңмы —
Бер табутка сыя бәндә.

Күпме куллар үрелә дә
Безнең изге хыялларга —
Йөрәк белән умырып алып,
Ата упкын-кыяларга.

Тели алар сыйдырырга
Һәммәбезне бер калыпка.
Әмер булса, дөньясын да
Тыгарлар иде табутка.

Әмер, әмер! Өйрәндек без
Уйсыз әмер үтәүләргә.
Әмер әйбәт — аударасың
Кансызлыкны бүтәннәргә.

Ә без әйбәт, без бит бары
Чит кулларда корал гына —
Үзебезнең кол икәнне
Белми йөргән коллар гына.

Гел тыңлаучан, күндәм булдык,
Үрмәләдек, түштә шудык.
Шик-шөбһәләр килсә — кудык,
Якты уйлар туса — будык.

«Ат!» дисәләр — тотып аттык,
«Ват!» дисәләр — тотып ваттык,
«Сат!» дисәләр — тотып саттык,
«Яп!» дисәләр — тотып яптык.

«Ас» дисәләр — тотып астык,
«Кач!» дисәләр — кереп качтык,
«Тот!» дисәләр — барып тоттык,
«Сыт!» дисәләр — барып сыттык.

Әмер булды — утка кердек,
Чит җирләрдә башлар салдык.
Баш хакына калай табут
Һәм кабергә ташлар алдык.

Башлар кими барган саен
Зиратларда ташлар артты:
Җыерылган кашлар артты,
Җиргә тамган яшьләр артты...

Хәер, минем бу уйларым
Читкә китте бугай алып.
Әнә өйдән чыгып килә
Кайгы тавы — кара табут.

Ай-һай авыр табутлары —
Сыгылганнар таза ирләр.
Катырак итеп бассаң ялгыш,
Батып керер кебек җирләр.

Кайгы диңгезе өстеннән
Кара табут йөзеп бара.
Хыял-өмет чәчәкләрен
Берәм-берәм изеп бара.

Кара кайгы диңгезенең
Дулкыннары тынга бәрә.
Чайкала җир. Кайнар җилләр
Уңга бәрә, сулга бәрә.

Йөзә табут, ә табутта
Рифнең улы — Рәмизләре.
Ул бу өйдә һәммәсенең
Бердәнбере, газизләре.

Бердәнберләр язмышында
Юләрбашлар уйнап тора.
Ә зиратлар корбаннарны
Берәм-берәм җыйнап тора.

Корый нәсел агачлары,
Ташта кала исем генә.
Йолдызларга күчә бары
Җаның гына, төсең генә.

3

*Язмыш диләр, язмыш диләр,*
*Кем язмышын кемнәр яза? —*
*Бирәү өчен язмыш — бүләк,*
*Берәү өчен язмыш — җәза.*

...Кайгы — кара ут, кайнар күмерле,
Күзләргә керә аның сөреме.

Күзләргә керә, битләргә йога,
Кайгыдан кеше каралып чыга.

Елый алганнар үз яше белән
Шушы сөремнең карасын юа.

Һәм җанындагы кайгыдан калган,
Әрнеп йөрүче ярасын юа...

Елады ана ачынып, әрнеп,
Кайгысы чыкты йөрәктән бәреп.

— Әй балам, балам, бәгырь кисәгем,
Нинди илләрдәниләр эшләдең?

Йөрәккәемнең тибеше идең,
Мәхәббәтемнең җимеше идең.

Кемнәр кул сузды бердәнберемә? —
Назлап үстергән иркә гөлемә.

«Әнием» диеп ачылды телең.
Актык сүзләрең ни булды синең?

Әй балам, балам, күзем карасы —
Күзем карасы, күңлем ярасы.

Карынымда йөртеп, сиңа җан бирдем,
Тамырларына кайнар кан бирдем.

Сугышлар да юк, илләр дә тыныч.
Җанны түләрлек юк безнең бурыч.

Кем өчен койдың кайнар каныңны?
Кем өчен бирдең газиз җаныңны?

Ике күз бирдем, күпне күр диеп,
Акны карадан аера бел диеп.

Ике күзең дә йомылган инде.
Җылы тәннәрең суынган инде.

Кыяга баскан бөркетем идең.
Чикләрдән ашкан өметем идең.

Бөркеткәемне харап иттеләр.
Өметләремне таптап киттеләр.

Ике кул бирдем, таза, нык куллар,
Матур дөньяны корыр дип шулар.

Кем мылтык бирде ул кулларыңа?
Төзәдең аны кем улларына?

Әй балам, балам — күзем карасы.
Күзем карасы — күңлем ярасы.

Болын түрендә шат таем идең.
Күңлем түрендә ак аем идең.

Бүреләр буды уйнак таемны.
Болытлар япты ап-ак аемны.

Әй балам, балам — йөрәк парәсе.
Күземнең яше, күңелем ярасы.

Гомер чишмәмнең агышы идең.
Җәйге төннәрнең балкышы идең.

Җәйге төннәрнең сүнде балкышы.
Гомер чишмәмнең тынды агышы.

Әй балам, балам — күзем карасы.
Күзем карасы — күңлем ярасы.

Синең урынга үзем үлсәмче.
Кара гүрләргә үзем керсәмче».

## 4

*Елый алганнарга җиңел,*
*Күз яшендә кайгы эри.*
*Еламасаң, кара кайгың*
*Күкрәгеңдә мәңге йөри.*

Риф күзеннән яшь чыкмады —
Янды бәгъре, көйде бәгъре.
Бәргәләнде ир йөрәге:
«Бер бөртек яшь бирче, тәңре!»

Каты йодрык җирне төйде:
«Ник соң болай, ник соң болай?
Нигә җирдә һәрчак үтереш,
Әгәр булсаң, әйтче, ходай!

Үләр өчен генәмени
Туа кеше дөньяларга?
Кайгыларым ташка бәйләп
Атыйм нинди елгаларга?»

Риф дустымны юатырлык
Сүзләрне соң алыйм каян?!
Әйтер идем, көчле булсам:
«Иңнәремә минем таян!»

Ләкин минем иңнәрдә дә
Язмыш салган авыр капчык.
Ташлый алмыйм аны җиргә,
Гомер буе йөрим асып.

Без бит, дустым, синең белән
Бер туфракта шыткан идек.
Язмыш дигән таш астыннан
Үлән булып чыккан идек.

...Ләкин безнең язмышларда
Нindидер көч уйнап торды.
Бераз калка башладыкмы —
Түбәбезне кыйнап торды.

Иң беренче мин егылдым
Давыл бәргән имән кебек.
«Ха-ха-ха»лап көлде язмыш,
Барыбер сезне җиңәм диеп.

Бераздан син яздың миңа
Хезмәт иткән якларыңнан:
«Мине дә давыл алып атты
Яшьлекнең ак чаптарыннан.

Мин дә хәзер элекке түгел,
Тик кыяфәт шул ук калды.
Ракеталар сынаганда
Нindидер җил өтте җанны.

Ярый, дустым, өйләнгәнмен,
Шөкер, минем малай үсә...»
Күпме җилләр исә җирдә
Бәгырьләрне кисә-кисә.

Истә әле өйләнүең —
Язның гүзәл көне иде.
Синең кәләш шушы язның
Иң-иң күркәм гөле иде...

Кем уйлаган синдәй ирне
Кайгы бәреп егар, диеп.
Нәселегез агачларын
Яшен килеп сугар диеп.

Дустым, дустым! Каберең ташы
Бик басмыймы күкрәгеңне?
Кай йолдыздан эзлим икән
Синең керсез йөрәгеңне?

## 5

*Җидегән йолдыз сүнгәндә дә*
*Нуры күктә каладыр;*
*Җиде улын җуйган ана*
*Җиде утта янадыр.*

...Зур бер нәсел агачында
Җиде алма үскән иде.
Алмаларның җидесе дә
Матур булып пешкән иде.

Тәгәрәтте алмаларны
Язмыш җиле төрле җиргә:

Кайсыларын ачлык йотты,
Кайсын сугыш тыкты гүргә.

Бары берсе — Вагыйз абый
Кайтты сугыш мәхшәреннән.
Чүлдә гөл дә исән кала
Дым алса күз яшьләреннән.

Кайтты, ләкин күкрәгенә
Орден-медаль тезеп түгел.
Кайтты киеп өстенә ул
Погонсыз бер иске шинель.

Шау-гөр килде авыл халкы:
«Ул «тегендә» булган, имеш.
Нигә кайткан инде мескен,
Табар иде шунда бер эш».

Әйе, кайтты Вагыйз абый —
Кайтырга бар иде хакы:
Чөнки Зәйнәп әбиләрнең
Соң өмете аны тартты.

Тартты аны туган туфрак,
Хатынының кабере тартты.
Тартты ятим калган улы —
Кайтты, Рифне сагынып кайтты.

Риф йөгереп безгә килде,
Күзендә яшь — сөенечтән.
Чыгып чаптык. Зәйнәп әби
Бәлеш ала иде мичтән.

Әй ул бәлеш — тәмле бәлеш!
Кайнар иде, олы иде.
Ул көн безгә бөтен дөнья
Матур иде, нурлы иде.

Бәхет өчен күпме кирәк! —
Үлчәүләре бармы икән?
Сөенә белмәгәннәр җирдә
Фәкыйрь икән, ярлы икән.

Вагыйз абыйның кайтуы
Миңа да зур терәк иде.
Үскән чакта мондый терәк
Бик еш кына кирәк иде.

...Каядыр алып киттеләр
Вагыйз абыйны бер төнне.
Ишекләрне япкан җилдән
Янып торган чыра сүнде.

Чыра түгел, Җидегән йолдыз
Сүнде Зәйнәп әби өчен.
Җиде тармаклы агачның
Җил аударды җиденчесен.

6

*Ир йөрәге сабыр була,*
*Түзә ул барчасына.*
*Кычкыра ләкин телсез дә —*
*Бассалар ярасына.*

Авырттырып, ачыттырып
Таптадылар Рифнең җанын:
Юып, пакьләп күмәргә дә
Бирмәделәр бит уларын.

Кеше җиргә пакь туа бит! —
Һәм китәргә тиеш шулай.
...Ак эшләргә кара төн дә
Кай чагында була кулай.

Төн уртасы. Зират тып-тын.
Әрвахлар да йоклый күптән.
Рифнең нәрсә эшләгәнен
Күзәтә тик фонарь читтән.

Җәйге төннәр тик бер тотам,
Ашыга ул: тизрәк, тизрәк!
Нәрсә анда дөп-дөп итә? —
Әллә җил ул, әллә йөрәк.

Кара кабер туфрагына
Шыбыр-шыбыр тирләр тама.
Якынлаша бара ата
Улына таба, улына таба.

Менә җитә, менә җитә.
Ярты колач ара кала.
Сүнәм-сүнәм дигән кебек
Сүрән генә фонарь яна.

Казыла кабер. Ачыла табут.
Булмый хәтта моны сөйләп:
Фонарь уты сибелә эчкә
Һәм... Ярыла шунда йөрәк.

Ата һәм ул — ике корбан,
Күз яшедәй ачы язмыш.
Кабына-сүнә «эһ» дигәнче,
Кеше гомере тик бер балкыш.

*Язмышлары күтәрмәслек*
*Булсын авыр, булсын ачы —*
*Керә алмый кеше гүргә*
*Таммый торып соңгы яше.*

Зәйнәп әбинең тыңлыйм тавышын,
Тыңлыйм тавышын, әчәм сагышын.

Сулышларыннан ялкын бөркелә,
Якынрак барсаң җаннар өтелә:

— Безне бу кадәр кемнәр каргады? —
Нәселебездә беркем калмады.

Алчы куеныңа, ал мине, кабер.
Ничекләр түзим, өзелә бәгырь.

Табып үстердем мин җиде бала.
Калды йөрәктә тик җиде яра.

Җидесе җиде юл табар дидем,
Җидесе җитмеш ул багар дидем.

Каберләре дә кайдадыр читтә.
Җаннары гына очадыр күктә.

Әй кошлар, кошлар, тыңлагыз мине:
Улларым җаны сездә түгелме?

Кулларым сузам, куныгыз учка.
Әверелде алар нindirәк кошка?

Бер генә тапкыр күрәсе иде.
Тыныч җан белән үләсе иде.

Әй болыт, болыт, миңа сөйләче:
Синдә түгелме алар күз яше?

Күз яше булсаң, там туган җиргә.
Балакайларым әверелсен гөлгә.

Әй яшен, яшен, яшьнәмә, тукта:
Янды улларым нindirәк утта?

Бәлки суларга аккандыр алар,
Әҗәлне шунда тапкандыр алар.

Туктап тор, елга, ярсыма, акма.
Дулкыннарыңнан сөйләт шул хакта.

Сиңа эндәшәм, җиһан, киң җиһан:
Улларым җанын, әйт, кемнәр кыйган?

Нәселем агачын кемнәр корытты?
Соңгы яфрагын кемнәр йолыкты?

Әй, язмыш, язмыш, әҗәл бир инде.
Дөнья барыбер салкын гүр инде.

Йөрәк урынында кара күмердер.
Иң яман нәрсә — озын гомердер.

Барсына түздем, барсына көндем,
Оныклар белән өметне күмдем.

Көнелләремнең бетте кәгъбәсе.
Җирдә яшәүнең бетте мәгънәсе.

Алчы куенына, ал мине, кабер.
Газизкәйләрем анда көтәдер...

## 8

Ауды беркөн корыган бу агач та,
Җил-давылсыз чакта, тын гына.
Бетте нәсел. Искә төшерергә
Көнелләрдә калды моң гына.

Шул сагыш-моң килеп сарыла да
Каеннарның яшел иненә,
Әкрен генә кыйсса сөйли миңа,
Кушылып талгын шәфәкъ җиленә.

Сорый җилләр Зәйнәп әби булып:
«Бу дөньялар кая бара соң?
Киләчәктә, алгы көннәрендә
Нәрсә көтә адәм баласын?

Нәрсә көтә? Җавап сорыйм сездән,
Барыр юлларыгыз еракмы?
Я әйтегез: гавәм язмышының
Киләчәге әллә зиратмы?»

Җавап эзлим шушы сорауга мин,
Көнел төпкелләрен актарам.
Үз-үземне юатмакчы булам,
Ә көнелдә тынгы юк һаман.

Дөнья бит ул тик бер бакча гына,
Кеше анда бары бер алма.
Алмаларның бөтенесен әле
Өзеп бармый ласа бер алла.

Үрелә аңар, әллә кемнәр үрелә —
Әгәр инде буе җитмәсә,
Ботарлыйлар гомер агачыңны,
Андыйларга гомерең ни-нәрсә?!

Җилләр коя, кортлар тишеп керә,
Хәвеф-хәтәр тора гел көтеп:
Суларыннан исән калдым дисәң,
Яшеннәре ала бер өтеп.

Яфракларын җил-давыллар коя,
Күтеп тормый алар күзләрне.
Һаман безгә мылтык көпшәсеннән
Карый әле заман күзләре.

Әле һаман төрле биеклектән
Явып тора күпме әмерләр.
Явыз әмерләргә шаһит булып
Зиратларда калка каберләр.

...Мин зираттан кайтам. Чү, нәрсә бу?
Ишетәм соң нинди өннәрне?
Әллә инде шулай җилләр елый,
Үксеп утыра әллә гөлләрме?

Сискәндерде җанны нинди тавыш,
Әллә юкса берәр баламы? —
Каеннарның шаулавына кушылып
Киләчәккә аваз саламы?

Ишетелә авыл ягыннанмы,
Йолдызлардан әллә килгәнме?
Әллә инде Зәйнәп әби оныгы —
Феникстай — туган көлдәнме?

Ишетәм аны, ишетәм, бу тавышны
Торган саен ныграк ишетәм.
«Кешелекнең киләчәге мин!» — дип,
Дәшә бугай бала бишектән.

*1989*

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

**Зиннур Хөснияр**

# КАЕШЛАНУ

ПОВЕСТЬ



ичә тәгәрмәче бар икән соң бу поездның? Ничәләп вагоны булыр икән? Вагон саен сигезәр тәгәрмәч булса...

Тәгәрмәчләре белән бер көйгә рельсларны келтер-келтер сөйләштереп барган поезд кинәт тартылып куйды да шуннан соң тизлеген сизелерлек киметә башлады. Озын-озын итеп сигнал бирде. Карәхмәт, берәр станция күрергә теләп, тәрәзәгә капланды. Караңгы. Әллә кайда, бик-бик еракта, тычкан уты кебек кенә сүрән ноктalar шәйләнә.

Поезддан сикереп төшеп, аны узып алга чабасы килә. Тизрәк, тизрәк, тизрәк инде! Ник болай акрын мыштырдыйсың соң?

Хәер, ашыкма әле, поезд! Тагын ел ярым буе бар да бар, төп-төгәл ел ярым...

Янәшәсендә йокымсырап утырган Панасенкодан: «Синеңчә ничек, бу поезд ашыксынмы, әллә акрын барсынмы?» — дип сорыйсы килде Карәхмәтнең. Ул иңсәсе белән Панасенкога кагылды. Тегесе, фуражкасын тез өстенә куйган да, башын артка ташлап, черем итә иде, дәшмәде: төшендә үзенең ефрейтор булганын күргәндер әле, югыйсә, уяныр иде, йокысы сак бит.

Аннары ул каршысындагы сәкедә сузылып яткан Дроздовка эндәште:

— Дроздь! Бу поездда ничәләп тәгәрмәч булыр икән, ә?

Дроздов мыегын да селкетмәде. Ул да йоклый бугай. Ерак Украинасында калган Наташасын төшендә күрә-күрә онытылып, изрәп, бик тәмләп йоклый.

Сало да әллә кайда йөри ичмаса. Тавышы вагонның теге башында ук ишетелә. Никрутларга һаман хәрби тормыш әлифбасын өйрәтә торгандыр. Медер-медер нидер сөйли. Ара-тирә шаркылдап көлеп тә җибәрә. Карәхмәт ирексездән елмаеп куйды. Моңарчы Салоның көлгәнен күргәне юк иде аның. «Карале! — дип уйлады ул.— Сало да көлә беләме икәнни?..»

---

Зиннур ХӨСНИЯР (1961) — *прозаик, «Таң ата да кич була» китабы һәм «Кара эт баласе» повесте авторы. Узган ел СССР язучылар союзы членлыгына тәкъдим ителде. Казанда яши.*

Тәгәрмәчләр келтер-келтер килә. Аңларга иде шуларның телләрен, ә! Телләре юк булмаса да, үзенә күрә барыбер нindidер мәгънәсе бардыр әле?

Поезд «пу-у-у-ууу! пууу!» итеп тагын бер мәртәбә кычкыртып алды.

Вагон эчендә медер-медер сөйләшәләр. «Сөйләшегез, сөйләш,— дип уйлады Карәхмәт.— Гражданкының тәмен татып калыгыз!..»

Алар Мәскәүдән Минскига ике йөз ун никрут алып кайталар. Әле үзләре дә кайчан гына шул никрутлар кебек иделәр. Узган, ярты гына ел булса да узган икән, ә!..

Шул чаклар кабат егетнең күңеле аша берәм-берәм узды...

* * *

Казан артындагы бер авылның Карәхмәт атлы егетен язның елак бер көнендә солдат хезмәтенә озаттылар.

Иртәгә юлга дигән көнне никрутның туган йортында озату мәҗлесе ясалды, әлбәттә. Аңа кадәр нәкъ бер атна колхоз эшенә чыкмады ул: әнисе пешергән кабартма, корт бәлеше, гөбәдия, өчпочмак, пәрәмәчләр белән сыйланып, «мич башында» ятты, урманга кереп, андагы таныш куяннары, пошилары белән саубуллашып йөрде.

Мәҗлесне бик зурлап ясадылар, бөтен авыл халкы рәхәтләнеп сыйланды.

Урман эчендә утырган җиде йортлы Алан авылында солдатка каралучылардан Карәхмәт үзе генә иде. Яшьтәшләре өч кыз, аларның икесе күрше авылдагы урта мәктәпне тәмамлауга, шәһәргә тайдылар. Өченчесе — Нәзирә камыт аяклы иде, аның авылдан китәсе килмәде, гомер буе шәһәр корымын иснәп яшәгәнче, авылда калуың мең өлеш артык, диде. Карәхмәтнең әнисенә мәҗлес табынын әзерләргә менә шул кыз булышты. Рәхмәт яусын аңа, әйбәт кияүгә тап булсын!

Алан авылының җиденче йортында яшәгән Карәхмәткә җизни тиешле кеше Мөсәгыйть бу көннәрдә баскан җиреннән ут чыгарып, очып-очынып йөрде. Тегесен тапты, монысын юнәтте Мөсәгыйть җизни, озату кичәсен зур мәҗлес итү өчен бә-ә-әк күп тырышты инде. Капка-койманы буяды, каралты-кураны тазартты, өй уртасына нарат такталардан озын өстәл сукты. Каенесенең армиягә китүен Мөсәгыйть җизни җиде йортлы Алан тормышында зур вакыйга итте. Өч көн алдан, өй борынча үзе йөреп, олысын-кечесен кунакка дәште.

Күрше Камышлы авылына мәктәпкә барудан гайре урман арасыннан чыгып карамаган, әнисе яныннан бер карыш җир дә китмәгән Карәхмәт менә солдат хезмәтенә алына. Хупҗамал карчык әйтмешли, кая эләгер дә бу бала,ниләр күрер аның башы?!

Һай ул Хупҗамал карчыкны! Шундый чакта гына булса да телен тыеп торсын иде инде. Юк шул, теле һич тә үзенә буйсынырга теләми. Җир шарында, Казанда, күрше авылда ни барын, ни булганын җиде йортлы Алан халкына түкми-чәчми җиткереп торганы өчен, хезмәтенә күрә хөрмәте дигәндәй, аланлылар аңа «ТАСС хәбәрчесе» дигән кушамат тактылар. Авылча «Тас хәбәрчесе».

Карәхмәткә повестка килгән көнне үк «ТАСС хәбәрчесе» күңелләргә шом салды: «Татар малайларын туп-туры Әфганстанга алып китәләр икән! Болары да мөселман, тегеләре дә мөселман, шуңа күрә татарларны җыялар, ди. Исән кайтсалар да, гарип калалар, ди».

Авыл халкының күңеленә тәки шом салды авызына шайтан төкергән карчык! Җитмәсә, үзе олы кеше...

Карәхмәткә дә килеп ирешә бу сүзләр. Егет көлде генә: «Тас хәбәрчесе» ни сөйләмәс!

Озату мәҗлесе иң кызган, кунаклар ишегалдында ду килеп биегән чагында Нәзирә, Карәхмәтнең чабуыннан тартып, бер кырыйга дәште, мунча артына киттеләр. Нәзирә «ә» димәде, «җә» димәде, аңа үзенең тыгыз, тулы тәне белән сыенып, иреннәреннән үк үпте дә, егетнең учына кулъяулык төртеп, кире өйгә таба йөгерде.

Әле бүген генә ягылып, суынырга да өлгермәгән мунчадан чыктымы бу эсселек, әллә кызның тәне электрланган идеме, егетнең гәүдәсе аша кайнарлык үтеп, аяк бармакларына хәтле төште, битләре, колаклары ут булып кызышты. Иртәгә ахырзаман икән дисәләр, ышаныр, әмма Нәзирә сине кочаклап үбәчәк әле дисәләр, ышанмас, ю-юк, мәңге ышана алмас иде. Менә ниләр яткан икән классташ кызның күңел түрендә, менә нинди уй-өметләр белән яши икән бу тыгыз тәнле, озын толымлы, матур йөзле, камыт аяклы кыз! Ул гынамы әле! Шушы көнгә, шушы мизгелгә кадәр Карәхмәтнең бер генә тапкыр да хатын-кызга якын килеп караганы, кыз кешенең кайнар сулышын тойганы булмады, булмады!

Егетнең хәзер үк Нәзирәне эзләп табасы, бу кешеләрдән, әлеге шау-шудан аерылып, аның белән урманга чыгып китәсе, таң атканчы шул кыз белән каеннар арасында адашып, серләшеп йөрисе килде.

Ул ишегалды ягына таба томырылды. Биючеләр арасында да, карап торучылар янында да Нәзирә күренми иде. Кыз биючеләр яныннан ерак йөри шул, биетмәсеннәр дип. Карәхмәтнең әнисе яныннан китмәде, гел аңа булышты, алъяпкычын салмады. Кызның бик биисе килсә дә, уртага чыгып басып кешеләргә, Карәхмәткә тагын бер тапкыр үзенең камыт аякларын күрсәтәсе килмәгәндер инде.

Карәхмәтнең иренендә кызның кайнарлыгы калды, тоз тәме калды. Солдатка китеп хезмәт итә башлагач, хәлләр булыр әле: аның авызын сугып канатырлар, ирене ярылыр. Әмма шушы татлы тоз тәме, Нәзирәнең кайнарлыгы бетмәс тә, китмәс тә ул иреннәрдән...

Ерак Белоруссиянең танклар, БТРлар һәм башка сугыш техникасы казып, актарып, ертып бетергән комлы юлларыннан хәрби уеннар вакытында бертуктамый унар-унбишәр чакрым юл үткәндә ул иреннәр кибеп, яргаланып бетәр, әмма Казан артындагы бәләкәй генә бер авылда яшәп яткан Нәзирә атлы кызның иреннәреннән күчкән тәм һаман сакланыр...

Карәхмәтнең солдатка китүенә иң сөенгән кеше аның туганнан туган энесе Йосыф булгандыр, мөгаен. Ары чапты, бире чапты малай, Алма апасының (Карәхмәтнең әнисе аңа «Алма апа» тия) һәр кушкан йомышын җиренә җиткереп үтәде. Очып кына йөрде малай. Абыйсы Армиягә китә бит. Озакламый ул солдат хатлары ала башлар. Тиздән аңа Карәхмәт абыйсы автомат тотып төшкән фоторәсемен җибәрер! Аларның авылында андый абый беркемдә дә юк! Ләкин иртәгәсен, чәчен бабасының чалгы пәкесе белән кырдырып алган такыр башлы абыйсы капкадан чыгып киткәндә, аңа да моңсу, бик ямансу булыр. Тик Йосыф балавыз сыга торган малай түгел, җебеп төшмәс, мәлҗерәмәс. Капка төбендә күзләрен яулык чите белән сөрткән Алма апасына, күзләренә яшь килеп бөялгән өлкәннәргә карап торыр-торыр да, аларга кушылып җылап җибәрмәс өчен, койма башына сикереп менәр. Бигрәк тә, өлкәннәрдән күреп, Карәхмәт абыйсы да елап җибәрер шикелле аңа. Еласа — бетте! Йосыфка көн булмаячак аннары! Абыең белән юкка мактанасың, ул солдатка киткәндә акырып елап китте бит, дип үчекләячәк авыл малайлары.

Йосыф койма башында басып торган килеш каты итеп тамагын кырып алды да, абыйсына таба карап, такмаклый башлады:

Әтәч киткән армиягә
Чабатага төялеп.

Карәхмәт әнисенең артында капка баганасына сөялеп торган Нәзирә җырдагы тавыкны үзе дип хис итте, ахрысы, йөзе комачтай кызарды, колак алкалары алсуланып янды, озын кара керфекләре аска салынып төште. Озатучылар Йосыфның бу кыланышыннан кайсы эчен тотып, кайсысы буыла-буыла көләргә тотындылар.

Җырның эчтәлеге белән Нәзирә күңелендәге бар сүзләрне әйтеп бетерде бит ташбаш малай. Шушы мизгелдә кызның чынлап та тавык буласы, Карәхмәтне этәч итеп күрәсе килде. Шулай булсамы? Әй җырлар иде кыз, сузып-сузып, бар авылны, бөтен урманны яңгыратып кытаклар иде ул...

«Китмә, Карәхмәт, китмә инде, Карәхмәт»,— дип кычкырыр иде. Кычкыра алмый шул: ул — тавык, Карәхмәт этәч түгел...

Күзләренә яшь килеп тыгылган Карәхмәт, шаян энесенең бу такмагыннан соң рәхәтләнеп бер көлде дә үзен көтеп торган трактор арбасына менеп утырды. Читтән караганда трактор арбасы чынлап та чабатага охшап тора иде.

Казан артындагы бер авылның Карәхмәт атлы баласы солдат хезмәтенә әнә шулай китеп барды. Әнисе елый-елый капка баганасына, камыт аяклы гүзәл Нәзирә койма буенда үскән «эрекмәнгә сөялеп» калдылар...

* * *

Шул ук көнне Украинаның Белая Церковь шәһәреннән Иван Панасенконы да армиягә озаттылар. Бик күп кызлар елап калды Ваня артыннан. Бик күп кызлар хат язып торырга вәгъдәсен алып калдылар бу мут егетнең. Елый-елый әнисенең күзләре күгәреп бетте. Өч кыз арасында берданбер малай иде Ваня. Иркә малай иде ул. Әнисенең итәк астында ышыкланып, апалары тәрбиясендә үсте.

Сигезенчене тәмамлагач, училищега кереп карады, ошатмыйча ташлап чыкты. Аннары этисе, армиягә киткәнче дип, аны үзе эшләгән заводка урнаштырды. Бу эш малайның күңеленә бик хуш килде. Беренче хезмәт хакыннан әнисенә, апаларына бүләк алып кайтты. Сөйгән кызларына да өлеш чыгарды.

Биек йортның иң өске каттагы тәрәзәләрендә төне буе ут сүнмәде. Барысының күзе Ваняда булды, барчасының сөйләгән сүзе өстәл түрендә утыручы чибәр йөзле, кыска чәчле егет турында гына иде.

Этисенең шушы уңай белән кайткан энесе шахтер Гена абый, бераз төшереп алгач, энесен кочаклап, үзенең армиядә хезмәт иткәндә күргән маҗараларын сөйләде. Максатың чин-дәрәҗә алу булсын, диде.

Ана кеше, табынга тагын берәр нәрсә өстәргә дип, кухняга кереп китә дә йөгереп чыга, күзләрен дә алмыйча улын күзәтә, аның алдына читтәрәк торган берәр тәм-томны алып куя, үткәндә-сүткәндә кулын малаеның башына, җилкәсенә куеп ала.

Эти кеше күңелендәгесен тышка чыгарырга яратмый. Сизелеп тора, күренеп тора: аңа да малаеннан аерылу җиңел түгел. Әмма улы өчен горурлану хисе барыннан да өстенрәк. Аның малае иртәгә солдатка китә. Кулына автомат тотыпмы, үзенең дәһшәтле танкы беләнме туган илен саклаячак газиз баласы. Ул аны гади бер солдат итеп кенә түгел, киләчәктә генерал итеп тә күз алдына китерә әле.

Эти кешенең бу хакта шахтер энесенә, озату кичәсенә җыелган

кунакларга сөйлисе килә, йокыга талган шәһәрне уятырлык итеп балконнан кычкырасы килә.

Кызып алган кунакларның бүтән нәрсәләр, җыен юк-бар, тузга язмаган гайбәтләр сөйләшергә керешүләрен күргән ана кеше түзми, өстәл кырыена килеп баса да, әүвәл: «Сез монда кеше гайбәтен сөйләшергә дип килдегезмени соң?» — дигәндәй бер караш ташлый, аннары, кыенсынып кына тамак кырып ала да тизеп китә...

— Ваняга дүрт яшь идеме икән ул вакытта, шулай бер чакны атна буе югалып йөргән мәчебез үзе белән өч бала ияртеп кайткан. Шаклар каттык инде. Ваняның шатлыгы эченә сыймады. Мәче балаларының һәрберсенә аерым-аерым исем кушып чыкты, карап кына ашатты, үз янында йоклатты. Гел шулар белән әвәрә килде инде.

Беркөнне шулай өйгә кайтып керсәк, аптырап калдык. Ваняны апаларына калдырып чыккан идек. Кызлар зал якка кереп күзге каршына тезелешеп басканнар да күз буйыйлар, каш тарталар, ә Ваня өйдә юк, мәче балалары да күренми. Таптык — мәче балалары белән бергә ваннага кереп бикләнгән дә, өчесен дә ваннага салып, краннан өсләренә су агыза. «Нишләвең бу, улым?» — дим. «Чыныктырам. Аларның армиягә барасылары бар бит әле, чыныксыннар»,— ди. Кылт итеп исемә төште: узган ялда телевизордан «Советлар Союзына хезмәт итәм» дигән тапшыру караган идек. Солдатларның суда коенганнарын шунда күргән иде.

Кунаклар өйне гөрләтеп көлделәр. Барысыннан да уздырып Ваня үзе көлде.

* * *

Шул ук көнне Белоруссиядәге Гомель шәһәре янындагы бер авылдан армиягә Валерий Дроздов атлы егет тә китеп барды.

Валера озату кичәсен ясап тормады. Югыйсә әнисе: «Ясыйк, дус-ишләреңне чакырырсың»,— дигән иде. Валера кул гына селтәде. Моңарчы алар өендә бәйрәмнең бәйрәм төсле булганы юк әле. Барысына да сәрхүш әтисе гаепле. Салып алса, дөньясын оныта, күзенә кем туры килә, шуңа бәйләнә, савыт-сабаны кыра, ямьсез сүзләр белән сүгенә, аннары үкереп елый башлый.

«Без — сугыш елы кешеләре! Сугыштан исән-сау килеш калдык, Фашистлар тырнагы астында яшәсәк тә, бирешмәдек. Җиңүдән соң да бал-майда йөзмәдек! Сез фашистлар тылында яшәгән, дип күзебезне ачырмадылар, ач булдык, ялангач булдык — түздек, иманны сатмадык! Тормыш ярыйсы хәзер! Мин хәзер бу тормышның рәхәтен күрергә тиеш, минем өчен бу тормыш көн дә бәйрәмнән торырга тиеш»,— дип, кем каршындадыр аклана-аклана елый өлкән Дроздов.

Валера үз урамнарында яшәүче Наташа исемле кыз белән йөри иде. Кич җиткәч, әнисенә чәй хәзерләп торырга кушты да киенеп чыгып китте. Сәрхүш әтисе өйдә юк иде.

Наташа белән бергә дус-ишләрен урап чыктылар, аннары озак кына урамда йөрделәр дә өйгә кайттылар. Шундый көнне инде әтисе айныр, дип уйлаган иде егет. Ләкин ул күптән өйгә кайтып кәеф-сафа корырга керешкән иде. Валера авызын ачып бер сүз дә әйтмәде, Наташаны җитәкләп яңадан чыгып китте. Таң атканчы урамда йөрделәр.

Валера өенә яктырып килгәндә генә кайтты. Эти кеше малаен озату кичәсен бик яхшы үткәргән иде. Өйнең асты-өскә килгән, идәндә чынаяк ватыклары чәчелгән, тәрәзә пәрдәләре суырып алынган. Эти кеше үзе идән уртасында гырылдап йоклап ята. Әнисе өйдә юк. Димәк, кичә кичтән үк күршеләргә чыгып киткән. Валера

өйдә булмаса, гел шулай итә энисе. Исерек ир бәйләнә, кул күтәрә башлауга, аның өстенә кулына эләккән берәр нәрсәне алып тондыра да чыгып кача. Иртәгесен генә әйләнеп кайта.

Валера өйдәге күренешкә аптырап карап торды-торды да кире борылды. Капкада әнисе күренде. Ана белән бала ишегалды уртасында, бер-берсен кочаклап, бик озак басып тордылар. Аннары егет биштәрен асып чыгып китте. Әнисенә озатырга барырга кушмаган иде. Ана кеше баштарак риза булса да, улы күздән югалгач, тиз генә җыенып, клуб алдына йөгерде. Солдатка китүче егетләр төялгән әрҗәле машина инде кузгалып маташа иде. Йөгерә-йөгерә сулышы кысылган ана, туктагыз дигәндәй, кулын югары күтәрде.

Әнисе белән янәшә утырган Валерий Дроздов тагын бер мәртәбә еракта, башка йортлар ышыгына сыенып утырган өйләренә карап алды, клуб янында басып калган озатучылар арасындагы Наташасына кульяулыгын болгады...

• • •

Вагон тәгәрмәчләре «так-тык» килә. «Ничә тәгәрмәче бар икән соң аның?» — дип уйлый Карәхмәт. Аннары үз-үзен тиргәргә керешә: «Башка уең юк ахры синең? Тәгәрмәчләр санын исәпләп утырмасаң!»

Вагонның теге башындагы никрутлар һаман йокламый. Проводник купесыннан да сөйләшкән тавышлар ишетелеп-ишетелеп ала. Проводник үз купесын өлкән лейтенант Швалюкка калдырып, икенче вагонга китте. Купеда өлкән лейтенант Швалюк бригада чәйханәсенең буфетчысы Серафима белән бергә бара.

Серафима, юлдашлар булганда бер җилләнеп кайтыйм әле, дип Мәскәүгә барган иде. Инде хәзер шул ук юлдашлары белән кире кайтып килеше.

«Ник йокламый инде бу малайлар? — дип уйлады Карәхмәт. Ярый, берәр атна хезмәт иткәч, йокының тәмен, кадерен белерсез әле».

Карәхмәтнең үзенә хәзер башы тигән урында йоклап китмәсә дә була. Солдат хезмәтенең иң кыен чагы артка калып бара. Үзенә күрә армия тормышыннан, начармы-яхшымы, хатирәләре дә бар инде.

• • •

Беренче көннәр — бүгенгедәй хәтердә...

КППны[1] узып бригадага аяк басуга, поездда үзләрен инде солдатлар итеп хис итеп, горурланып килгән малайларның барысы да кинәт шым булды. Шаярулар, бер-берсенең такыр башларына күрсәтеп көлүләр бетте. КППда дежур торучы солдат, капканы ачкач, тәртипсез рәтләр белән килүче никрутларның һәммәсенә дә ишетелерлек итеп:

— Хабаровскидан бармы? Кем Хабаровскидан? — дип кычкырды. Аңа каршы җавап бирүче булмады. Ул соравын тагын бер тапкыр кабатлады да, никрутлар арасында үзенең якташларының юклыгына инангач:

— Такыр башлар гаскәре! — дип көлеп калды. Бераздан Карәхмәт артына борылып карады. Әле генә кулын биленә куеп никрутларны каршы алган рядовой, сул беләгенә кызыл тасма бәйләгән сержант каршында үрә катып тора. Карәхмәт, үз янәшәсендә башын

[1] КПП — Контроль-пропуск пункты дигән сүзләр[illegible]кыскартылган.

түбән иеп атлаган Дроздовка терсәге белән төртеп, артка таба ишарәләде. Баягы рядовой, хәзер кулына себерке тотып, тырыша-тырыша КПП әйләнәсен себерә башлаган иде.

Моңа хәтле солдат формасын киярга хыялланган малайлар, үзләрен мыскыллаган рядовойның кулына себерке тотып асфальт себерүен күреп, көлемсерәп куйсалар да, солдатның киеменнән, автоматыннан тыш, аларга билгеле булмаган хезмәтен һәм тормышын күз алдына китерергә тырышып, башларын түбән иделәр, күңелләрен хәерсез шом басты.

Аларны туп-туры мунчага алып киттеләр. Никрутларны Минскидагы туплау пунктыннан алып килгән өлкән лейтенант Швалюк һәммәсенә дә бер сафка тезелергә боерды. Үзе кул сәгатенә карап алды. Эткәләшә-төрткәләшә торгач, малайлар, ниһаять, бер сафка бастылар. Иң соңгы кеше сафта үзенә урын тапкач кына өлкән лейтенант:

— Мунча керү өчен сезгә кырык минут вакыт бирелгән иде. Шуның ун минуты очты инде. Без болай да соңга калдык. Нәкъ сәгать икедә сезне плацта көтәләр. Ә хәзер «Уңга!», мунчага «Адымлап марш!» — диде.

Малайлар этешә-төртешә ишеккә ташландылар, мунча эченә керү генә дә тагын ун минутлап вакытларын алды.

Мунчада сарык көтүе кебек ыгы-зыгы килгән малайларның кайберсе душ астында башын гына чылатып алырга өлгерде, «Солдат киемнәре алыгыз!»— дигән әмер яңгырады.

Карәхмәт яңа киемнәрен кочагына кысып читкәрәк китте дә ашыга-ашыга киенә башлады. Итегенең кунычы озынрак кебек тоелды аңа. Бригадир Әхмәтҗан абзый хром итегенең кунычын гармун күреге рәвешенә китереп кия. Атлаган саен шыгыр-шыгыр килеп тора итекләре. Карәхмәт, шуны исенә төшереп, итек кунычларын балтырдан аска шудырды. Болай матуррак та иде. Ләкин шулчак аңа бер солдат төртеп узды:

— Итегеңнең кунычларын тартып куй тизрәк. Командирлар күрсә!

Карәхмәт ашыга-ашыга итек кунычларын югары күтәрде.

Аларны мунча алдында көтеп торган өлкән лейтенант янә сәгатенә күз төшерде һәм:

— Тезелергә! — дигән әмерен бирде. Бу юлы малайлар, өсләрендә инде солдат формасын сизепме, тизрәк тезелделәр. Башлар әледән-әле як-якка борыла, баягы чуар-чабар киемле малайларны хәзер танырлык та түгел. Һәммәсе дә бер-берсенә су тамчысыдай охшаган кебек. Яңа киемнәре ничектер сәер дә, кызыклы да булып тоелды аларга. Өлкән лейтенантның:

«Үрә кат!» боерыгы да сафта тәртип оештыра алмады. Кемдер пилоткасын төзәтә, кемнеңдер аяк чолгавы итек башында җыелып калган, кемнеңдер каешы бушрак, кыскасы, бар да кием-салымы белән әвәрә килә.

«Йөгереп-марш!» дигән әмер сафны плацка таба куды.

Әллә солдат формасы шулай көч өстәде, алар бер-берсен уздыра-уздыра йөгерергә керештеләр. Әмма кайсыберләре шундук артта калды, чөнки аяк чолгаулары чуалып, титаклый-титаклый йөгерергә туры килә иде. Карәхмәткә бу сарык көтүен хәтерләтте. Сарык көтүе кичен авылга килеп кергәндә шулай була, шикәр шакмагы хәтле генә тояклары белән тузан туздыра-туздыра, баш-күзләрен акайтып, бар көчләренә чабалар.

Күрәсең, мондый тәртипсез йөгерү өлкән лейтенантка да ошамады. Ул:

— Тукта! — дип боерык бирде дә, үзе кырыйга китеп кулын алга сузды һәм: — Бер рәткә тезелергә! — диде. Иптәшләрен узып

алгарак киткәннәр дә кире әйләнеп килделәр. Рәт тынып калды.

— Уң-га! Хәзер бер колоннада гына йөгереп карыйк. Берәү дә үз урыныннан чыкмый. Дистанция саклагыз!

Чыннан да, саф белән йөгерүе җиңелрәк икән, болай хәл дә китми, сөртенмисең дә.

Аларны плацтан казармага алып киттеләр. Яшь солдатлар батальоннарга, роталарга бүленгәнче, ике айга якын «карантин»да буласылар.

Командир «Карантин»ның нәрсә икәнлеген һәм ни өчен кирәклеген аңлатты: «карантин»да яшь солдатларны хәрби тормыш әлифбасына өйрәтәләр икән.

Казармага өлкән яшьләрдәге прапорщик килеп керде. «Карантин» командиры яшь солдатларны прапорщик белән таныштырды.

— Прапорщик Сильванович — старшинагыз. Ул монда атагыз урынына да, анагыз урынына да. Старшина сүзен тыңламаучының башы нарядтан чыкмаячак! Сез хәзер солдатлар инде. Бүгеннән башлап яңа тормыш белән яши башлаячаксыз. Һәркем үзе өчен үзе җавап бирә. Монда сезне иркәли торган әбиләрегез, әниләрегез юк.

Армия тормышы белән кыскача беренче таныштыру шундыйрак булды.

Казармага урнашып, старшинадан көндәлек кирәк-яракларны алгач, һәркем үз тумбочкасын тәртипкә китерде. Аннары старшина карават саен йөреп тикшереп чыкты. Караватлардагы һәм тумбочкалардагы тәртип старшинага ошамады. Ул казарма уртасына бер тумбочка чыгарттырды да, тартмада һәр нәрсәнең үз урыны бар дия-дия, сабын, теш щеткасы кебек вак-төякне тезеп чыкты. Аннан соң уртага бер караватны күтәреп чыктылар. Старшина караватны туздырып ташлады да, һәр хәрәкәтен теле белән сөйләп аңлата-аңлата, аны яңадан җыеп куйды.

Һәр урында, һәр җирдә идеаль тәртип булырга тиеш иде. Малайларның гаскәри тормышы тәртипкә өйрәнүдән башланып китте.

...«Карантин»нан соң яшь солдатларны батальоннарга, роталарга бүлделәр. Бер үк көнне өйләреннән чыгып киткән теге өч малай өчесе дә бер ротага — разведчиклар ротасына эләкте.

Разведрота казармасына плацтан аларны кече сержант алып барды. Сержантның сул беләгенә «дежурный» дип язылган кызыл тасма бәйләнгән иде. Казармага килеп җитәрәк ул үз артыннан килгән солдатларга таба борылып карады да:

— Их, егетләр, эләктегез дә инде! — диде. Разведрота дигәч, үзләренең дә күңелләре күккә сикергән иде малайларның. Сержант шул турыда әйтә дип уйлап, алар бәхетле елмаеп бер-берсенә караштылар. Чөнки иптәшләренең күбесе пехота батальонына бүленде, алар исә — разведкага! Кем уйлаган да, кемнең генә төшенә кергән мондый бәхет!

— Их, егетләр, эләктегез дә инде! — дип кабатлады кече сержант.

Тегеләр, аптырап, кече сержантның йөзенә текәлделәр.

— «Картлач»лар бик әшәке безнең,— дип куйды соңыннан сержант һәм бүтәнчә авызын ачмады, яшь солдатлар да кайтарып сорарга кыймадылар.

* * *

Разведрота командиры өлкән лейтенант Ильинның башына бер сәер теләк килде: «Бу озын буйлы, какча Даниловны чалып егасы иде! Кызык... нишләр иде икән? Якагаябышырмы, йә шаяруга борырмы? Һе... Кызык!..»

Өлкән лейтенант Ильин, әлеге сәер уйларын һәм мәгънәсез кызыксынуын артта калдырырга теләгәндәй, адымнарын кызулата төште. Уйлары да аннан калышырга уйламады, ул кызулаган саен, үртәшкән кебек, өлкән лейтенантның үзен дә узып, аз гына алдарак барган беренче взвод командиры Швалюкның ялык-йолык килгән итек кунычларына килеп чорнала. Швалюк, сөрлеккәндәй, кинәт кенә алга тартылып куя һәм шул мәлне үзенең төркемне, рота командирын узып китүен шәйләп, акрыная да, йөзендә елмаю галәмәте чагыла.

«Менә Швалюкны чалып ексам, аның нишләячәген тәгаен беләм. Егылмас ул, көтмәгәндә чалынса да, егылмаячак, тезләнсә тезләнер, артына утырмас. Анысы шулай да булсын. Мәсәлән, егылды, ди? Егылса, сикереп торыр иде, кан чыкканчы иреннәрен кысар иде һәм үзенең миннән өстенрәк дәрәҗәдә булмавы өчен бар дөньяны каргар иде. Һе... Бу Швалюк максатына ирешәчәк, барыбер ирешер. Быел көзгә рота командиры булырга тора бит: нинди генә кыенлыкларга да түзәр, әмма максатына барыбер ирешер. Ярый ирешсен соң. Күренеп тора, взвод командиры булып йөрү аны да туйдырган дыр инде».

Рота командирының уйлары тагын үз янәшәсендә атлаган Даниловның итекләренә килеп сыланды. «Их, жәлке дә соң бу мескен «двухгодичниклар!» Нигә аларны армиягә алып торырга инде? Барыбер, ике елы үтүгә, койрыкларын сыртка салачаклар бит. Вакыт узсынга гына селкенеп йөриләр. Хәер, син, Данилов, ярыйсы гына командир үзең, артык хисле кеше булсаң да. Ә менә хәзер сине чалып ексам, мөгаен, хурланудан кычкырып еларсыңдыр. Аннары, армиядән киткәч, мине гаепләп, газетага да язып җибәрерсең әле! Ярый, ярый, тынычлан, Данилов. Сиңа сүз әйтеп булмый, рота тормышы турында йә газетага язып чыгарсың, тәки журналистлыгыңа барырсың».

Ильин, мәгънәсез уйларыннан котылырга теләгәндәй, каты итеп тамагын кырып куйды һәм: «Тефү! — диде үз-үзен тиргәп.— Булачак капитан, имеш! Малай-шалай кебек кыланып барасың!»

Рота командиры өлкән лейтенант Ильин ачуы килгән чакта бик еш кына үз-үзен: «Булачак капитан, имеш!» — дип сүгәргә гадәтләнеп киткән иде. Әйе шул, әгәр ротасы сынатмаса, быел көзгә Ильин капитан йолдызын алырга тиеш! Гел шул хакта уйлый өлкән лейтенант, шул турыда гына хыяллана.

Разведка офицерларның разводтан соң бригададан бер чакрым ераклыкта урнашкан хәрби шәһәрчеккә кайтып барышлары иде бу.

Рота командирының кәефе шәптән түгел. Бердән, мәгънәсез уйларына ачуы килсә, икенчедән, бүген аның ротасына яшь солдатларны җибәрделәр. «Карантин»нан, борын аслары да кипмәгән малайларны! Батальонга булса, бер хәл иде әле...

Ильин бу хакта әүвәл бригаданың штаб башлыгына зарланырга уйлаган иде. Ләкин шүрләде, андый вак-төяк мәсьәлә белән Коваль янына бару тагын бер мәгънәсезлек булачак иде.

Ильинның бригадада иң шүрләгән кешесе — подполковник Коваль. Ул моны хәтта үз-үзеннән дә яшерми. Штаб башлыгы — аягыннан алып башына хәтле бары гаскәр өчен генә яратылган кеше, кирәгеннән артык кырыс һәм таләпчән офицер.

Аннан бөтен бригада дер калтырап тора.

...Ильин янә Швалюк ягына күз салып алды. «Бигрәк тә үз сүзле син, взводный! Синең белән ачыктан-ачык бер сөйләшергә кирәк булыр әле, мөгаен. Өлкән солдатларны яклап маташуың юньлегә алып бармас. Күңелем сизенә, яхшыга булмас!»

Рота командиры өлкән лейтенант Швалюк янына карамыйча гына:

— Ничек соң, яшь солдатлар, «карантин»нан килгәннәр дим, ошадымы-юкмы? Ярыйсы егетләр ич, ә?!

Әйтерсең, Швалюк аның бу соравын күптән көтеп бара иде, шундук җавабын да бирде:

— Разведрота хәтле разведротага кем «карантин»нан солдат җибәрә инде!

Рота командиры кабат авызын ачарга өлгермәде, сүзгә Данилов кушылды:

— Безнең ротага кирәкми иде алар.

— Ник?

— Кыерсытачаклар, өлкән солдатлар көн күрсәтмәячәк ул малайларга.

Ильин үзенең командир икәнен исенә төшермәдеме, әллә һаман Швалюкның фикерен беләсе киләдеме:

— Алай булгач, ротада без нигә соң? Сез нигә, Данилов, яшьләрне кыерсыттырырлык булгач, дим?! Анатолий Сергеевич, шулаймы?

Ләкин Швалюк аның фикерен җөпләргә ашыкмады, һаман үзенекен тукыды:

— Разведротага «карантин»нан солдат алаларммы соң инде! Батальонга сыйган булырлар иде әле.

— Монысы башка мәсьәлә, иптәш Швалюк.

Рота командиры тагын тамагын кырып алды.

— Бу төп мәсьәлә, иптәш ротный, күзгә тикшерүләр килеп житкәч, яшь солдатларның ротаны яндырулары мөмкин.

Соңгы сүз рота командирыныкы булды.

— Ярый, аңлашылды, иптәшләр. Швалюк, син бүген ротада дежур икәнлегеңне онытa күрмә!

Шәһәрчеккә кергәч, алар төрлесе төрле якка таралыштылар. «Их-ма! Карын ачкан бит!» — дип уйлады Данилов үзе генә калгач. Һәм тулай торакка кайткач, нәрсә пешерәчәге турында план кора башлады.

Владимир Даниловның армиядә әле тагын бер ел хезмәт итәсе бар. Университетның журналистика факультетын тәмамлады Данилов. Укып бетерүгә, берәр район газетасына эшкә әләгеп булмасмы дигән уе да бар иде күңелендә. Әмма язмышы аны ике елга армия хезмәтенә җибәрде. Баштарак бу хәлгә каушабрак калса да, бәлкем анда да берәр хәрби газетага урнашып булыр әле дигән өмет күңелен тынычландырды. Бу теләген хәрби комиссариатта да әйтеп караган иде. Әмма хәрбиләр, гадәтләренчә, аның теләге белән санашып тормадылар. Язмыш Даниловтан взвод командиры ясап куйды. Ләкин газетага урнашып булмасмы дигән өмете күңелендә һаман яши. Хәрби тормышның кырыс кануннары һәм бары үзенә генә хас булган мәшәкатьләре журналист егетне үз эченә бөтереп алса да, Даниловның аңа иярләшеп беткәне юк әле.

Тулай торагына кайтып җитәрәк лейтенант: «Макарон булырга тиеш бит, макарон кыздырырга кирәк!» — дигән карарга килде һәм ашказаны, шуны сизгән шикелле, макарон «таләп итеп», күңелле генә богырдап куйды.

Иптәшләреннән аерылгач, Швалюк әүвәл икенче якка таба китәргә уйлаган иде. Тик бүген тагын бригадага барасы исенә төшеп, өенә кайтырга булды. Серафимага керсәң, тиз генә чыгып китәрмен димә. Назга сусаган хатын, «тревога» булса да, җибәрмәячәк аны.

Хатыны Василиса, эштән кайтып, аны көтеп утырадыр инде. Өлкән лейтенантның кыек юлда йөргәнлеген әллә сизенә башлады шунда: соңгы вакытта һәр адымы белән дә кызыксынып тора.

Сизә генә күрмәсен! Алайса — бетте! Гүзәл хатыныңнан шундук колак кагарсың, Швалюк! Хәер, хатыннан гына колак каксаң, бер

хәл әле! Хатын аерганың бригадада ишетелсә, рота командиры булу да тәтемәячәк! Монысы — иң куркынычы!

Ильин исә гаиләсен бик яратса да, матур, тигез яшәсәләр дә, алар турында уйларга күнекмәгән. Фатиры бармы — бар, акчасын алып кайтып бирәме — бирә, гомерен бөтенләе белән хәрби тормышка багышлаган офицердан тагын ни кирәк?

* * *

Офицерлар җыйнаулашып кайтып киткәч, казарма җиңел сулыш алды. Солдатларның кайсы караватларына ауды, кайсылары телевизор янына өелеште.

«Карантин»нан килгән яшьләрне ике ярусль караватларның өске катына урнаштырдылар.

«Карантин»да чакта ук гаскәрнең язылмаган законнары белән танышып өлгергәннәр иде. Яңа килгәннәр дә, ярты ел хезмәт итәргә өлгергәннәр дә «әрвах»лар була, аларның берникә дә хокуклары юк, кара хезмәттән башлары чыкмый икән.

Хезмәт вакытлары бер елдан авышканнары — «чүмеч»ләр, болары инде үзләрен кеше итеп сизәләр, турыдан-туры «әрвах»ларга әмер бирү дә алар вазифасында, казармадагы чисталык өчен алар җавап бирә, ягъни «әрвах»лардан тазарттыралар.

Армиядә иң рәхәт яшәгән халык — «картлач»лар. «Әрвах»ларның тыңлаучан, карусыз булуларын яраталар, уйлары — тәмле ашау һәм озаграк йоклау, телләрендә — «гражданка».

Менә шундыйрак бүленеш икән монда. Бу тәртипкә каршы кыл да кыймылдата алмыйсың. Бетте!..

«Карантин»нан килгән солдатларга киемнәре («х. б.») каешланып катып беткән, итек башлары агарып торган, кулларын чеби баскан бер рядовой киемнәр киптерү бүлмәсенә керергә кушты. Әүвәл шикләнеп кенә Панасенко кузгалды, аның артыннан Дроздов белән Әмирханов та иярде.

Аларны дәшкән рядовой юынгычка таба китте. Юынгыч бүлмәсенең каршы ягында өстенә «сушилка» дип язылган ишек күренә. Теге рядовой аларны кулы белән генә ишарәләп үз артыннан әйдәде дә ишек янына килеп җиткәч, әүвәл, колакларын торгызып, бермәл тыңлап торды һәм кыюсыз гына шакып алды. Эчке яктан:

— Кер! — дигән тавыш ишетелгәч кенә ишекне ачарга җөрьәт итте. Аннары малайларны эчкә уздырып җибәрде.

Бүлмәдәге элгечләрдә солдатларның комбинезоннары тезелеп киткән, бер почмакта майга каткан ике матрас ята, түрдә, бу кысан бүлмәнең бердәнбер тәрәзәсе янындагы табуреткаларда ике солдат утыра.

— Килегез, кил, егетләр мондарак,— диде аларның салам көлтәсе кебек сары чәчлесе. Икенчесе, чандыр йөзле, ут янып торган зәңгәрсу күзле, бераз кәкрерәк борынлысы, ишек янында торган баягы солдатка кычкырды:

— Сало! Тәмәке! Тиз бул! Юкса мин синнән колбаса ясыйм!

Шундый тапкыр сүзләр әйтә алуына кәефе килеп, ул ыржаеп көләргә дә керешә. Теге солдатның андый очрак өчен тәмәкесе кесәсендә генә икән, атылып керел. Чандырга сигарет сузды да, тагын ни боерасың, дигәндәй аның йөзенә текәлеп катып калды.

— Бар, булды, тай моннан!

Сало күздән югалды.

— Менә нәрсә,— дип сүз башлады Чандыр тәмәкесен кабызып бер тирән итеп суырганнан соң.— Шәп ротага эләктегез сез. Куаныгыз. Разведрота бөтен бригадага бирү генә, бригаданың йөзек кашы!

Штаб башлыгы безнең ротадан башка бер генә көн дә яши алмый!
Сүзне Салам чәч дәвам иттерде.
— Ротаның үз традицияләре бар, сез дә сакларга тиеш аны,— диде дә ул кычкырып җибәрде:
— Сало!
Ишектән баягы солдатның башы күренде.
— Нәрсә, Сережа?
— Егетләргә табуретка алып кил, живо!
Салоның башы югалды һәм күп тә үтмәде ул, берсен җилкәсенә утыртып, икесен кулына тотып, өч табуретка алып керде. Салам чәч аны янә куып чыгарды һәм идән уртасында аптырап басып торган яшь солдатларга ишарәләп:
— Утырыгыз, утыр, егетләр,— диде.
Тегеләр, бер-бер артлы, урындыкларга утырыштылар.
— Менә сез шәп егетләр күренәсез, гәүдәле, таза егетләр. Алайса ротаны эбер-чебер белән тутыра башлаганнар иде. Комбригына хәтле, берәр төрле эш булса, разведчикларны җибәрә, ә үзләре ротаны җыен боламык белән тутыралар. Әнә, карагыз инде теге имгәкне, бая монда керде бит әле, фамилиясе Сало аның. Оешмаган да инде түлке үзе, аягүрә йоклап йөри, үзе разведротада ике ай хезмәт итә инде.
Салам чәч кулындагы тәмәкесен соңгы мәртәбә суырды да, бармак араларына кыстырып, түшәмгә таба чиерттереп җибәрде. Төпчек, түшәмгә тиеп очкыннар чәчте дә, туп-туры Панасенконың башына килеп кунды. Панасенко, корт чаккандай куллары белән чәбәләнә-чәбәләнә, аны чәченнән сыпырып төшерде. Бу хәлгә бары тик үзен генә гаепле итеп сизгәндәй, башын түбән иде, колак яфракларында утлар кабынды. Моны күзәтеп торган Салам чәч пырхылдап көлеп җибәрде, аңа Чандыр иярде, аларга Карәхмәт белән Дроздов та кушылып көләргә тотындылар. Әмма соңгы икесенең бер дә көләселәре килми иде килүен...
Чандыр көлүеннән шып туктады да кыяфәте кинәт кенә җитдиләнеп, кашлары җыерылып килде.
— Әләкләгән өчен безне нишләтәләр иде, беләсезме! — диде ул һәм, сүзләрен раслату өчен, янәшәсендәге Салам чәчкә таба борылды.— Петя, исеңдәме?
— Әй, хәзер нәрсә ул. Элек без «әрвах» вакытта «картлач»лар монда безнең шикелле генә түгел иде. Әнә курилкага да «картлач»-лар тартып торганда керә алмый идең. Типкәләп кенә чыгаралар.
Салам чәч белән Чандыр каршыларында утырган яшь солдатларга бер-бер артлы «әрвах» вакытта үзләренең күргәннәре турында сөйләргә керештеләр.
Карәхмәтнең дә, тегеләрнең дә чәчләре үрә торды, чөнки алар каршында утырган бу ике рядовой «әрвах» чагында бик күп михнәтләрне башларыннан кичергәннәр иде шул.
— Командирга да әләкләп булмый,— дип дәвам итте Чандыр.— Әләкләсәң, беттең диген сүз, көн дә, төн дә юк сиңа, хезмәтең тулганчы адәм типкәсендә йөриячәксең. Үз иптәшләрең дә яратмый әләкчеләрне.
— Йә, ярый,— дип, Салам чәч урыныннан кузгалды,— Мантана, син бик җәелмә, хәзер лейтенант йөгереп килеп җитәчәк.
Салам чәч бүлмәдән чыгып китте. Мантана дигәннәре дә яшь солдатларны чыгарып җибәрде.
Салам чәчнең фамилиясе Рубевский икәнлеген белделәр. Мантана исә фамилия түгел, Манатов фамилиясенә охшатып ясалган кушамат икән. Манатовка үз кушаматы бик тә килешеп, ябышып тора. Чалбары нечкә аякларына сыланырлык итеп тарайтылган, пилоткасы баш түмечендә генә утыра, изүләре ачык. Аның зәңгәр күзләре,

май урларга җыенган карак мәченеке кебек, берөзлексез хәрәкәттә, гел ялт-йолт килә. Манатовның бер ноктага гына карап уйланып утырганын, күзләренең хәрәкәтсез чагын күргән кеше юк әле.

Рубевскийның кушаматы — Этәч. Кем уйлап тапкандыр, аның кушаматы да үзенә бик туры килә. Тавыклар арасында һәрвакыт үзенең өстенлеген тоеп вәкарь белән йөргән этәч кебек, бүтәннәргә ул гел өстән карый. Караватта ятканда да түшәмгә караганы юктыр аның, карашы һәрчак идәнгә төбәлгән булыр.

...Отбойга тикле бер сәгать вакыт бар иде әле. Карәхмәт тумбочкасыннан кәгазь-каләм алды да, өенә хат язарга дип, кызыл почмакка кереп утырды. Өйдән чыгып киткәннән бирле Йосыф энесенә бер авыз сүз дә язганы юк. «Карантин»да чакта язасы килмәде, роталарга күчергәннәрен көтеп йөрде.

Күңеле әле дә тыныч түгел түгелен. Мондый сөйләшүнең нигә кирәге булды икән соң? Карәхмәткә нәрсәгә ди аларның башыннан кичергәннәре. Ни пычагыма үзләрен яшь солдатлардан кызгандырып утырдылар соң әле? Нигәме? Һе, мөгаен, юньлегә түгелдер инде, яхшыга булмас. Алдан ук кисәтеп куюларыдыр әле. Янәсе...

Өчесенең дә күңеленә бик тирән сеңеп калды: ни генә булса да, командирларга әйтү ярамый икән. Әйтсәң, әләкләсәң — беттең!..

«...Сәлам ерак Белоруссия җирләреннән,— дип башлады Карәхмәт энесенә дигән хатын.— Йосыф энем! Абыеңны разведчиклар ротасына алдылар. Рәсемгә төшәргә җай юк әлегесен, служба бик каты бара.

Авылда ни хәлләр? Мине сорашалармы? Сораганнарга сәлам тапшыр!

Монда караватлар ике катлы, бер-берсе өстенә куелган. Безнең урыннар икенче катта ук.

Ярый, вакыт бик аз, шуның белән тәмамлыйм. Разведчик сәламе белән Карәхмәт абыең.

Әйтергә онытa язганмын: энигә кәҗәне арканнарга булыш. Бик хулиган бит ул. Эни үзе генә тыңлата алмас».

Карәхмәт хатны конвертка салып, адресын язды да дневальный тумбочкасына илтеп куйды. Җыелган хатларны почтага дневальный илтеп сала, диделәр.

Отбойдан соң яшь солдатлар икенче каттагы караватларына үрмәләделәр. Менеп кенә җиткәннәр иде, алар янына бер сержант килеп басты да:

— Аякларыгызны юдыгызмы? — дип гөрелдәде калын тавыш белән. Анысын онытып җибәргәннәр иде шул, кире сикереп төштеләр дә, итекләрен кулларына тотып, яланаяклары белән агач идәнгә чапчоп баса-баса, юынгычка йөгерделәр.

Карәхмәт аякларын юганнан соң караваты янына килде. Аның астындагы икенче караватта бер солдат сузылып ята. Ул итекләрен салып маташкан Карәхмәткә таба борылып та карамыйча, тумбочкасы өстеннән йомарланган газета кисәге алып, аңа ташлады.

— Бу кәгазьне чүплеккә атып кил.

Карәхмәт каушап төште, аннары, иелеп, идәндә яткан кәгазьне алды да, кулында тоткан килеш тегеңә карап тора башлады. «Әгәр дә беренче көннән үк баш бирсәң — беттең! Бер ел буе теләсә кемнең кубызында бииячәксең. Беренче көнне үк каршылык күрсәтсәң, кемлегеңне аңларлар, адым саен бәйләнмәсләр».

Бу — «карантин»да алган әлифба иде.

Карәхмәт кулындагы кәгазьгә янә бер мәртәбә күз төшерде дә аны тумбочка өстенә илтеп куйды. Үзе авыз эченнән генә:

— Минем чүп түгел бит ул,— дип мыгырданды.

— Нәрсә?

Шулчак үз караваты янына Панасенко да килеп җиткән иде. Теге, авыз эченнән нәрсәдер сөйләнә-сөйләнә, Карәхмәткә таба кизәнде дә Панасенкога кычкырды:

— Кәгазьне чүплеккә илтеп ташла! Тиз бул!

Панасенко «ак» димәде, «кара» димәде — кәгазьне алып чүплеккә китте. Карәхмәт, шуннан файдаланып, тиз генә караватына үрмәләде. Мендәргә башын гына төрткән иде, астагы солдат Карәхмәтнең карават сеткасына тибеп алды. Карават кырыена ябышып өлгермәсә, икенче ярустан идәнгә мәтәләчәк иде малай.

...Сәгать төнге берләр тирәсе булдымы икән, куркыныч төш күреп, Карәхмәт йокысыннан уянды. Казарма эче тып-тын иде.

Бераздан күрше караватларның берсе шыгырдап куйды, кемдер, күн башмакларын чыш-пыш өстерәп, бәдрәфкә барып килде дә, янә карават сеткасы тартылды — теге урынына ятты. Ул берара әйләнгәләп ятты-ятты да, яңадан йоклап китә алмады, ахрысы, шырпы сызган тавыш ишетелде. Карәхмәтнең борынына тәмәке исе килеп бәрелде. Ул одеялын башына ук тартты. Шулвакыт казарма эчен яңгыратып тәмәкече ягыннан сәер тавыш килде:

— Әрвахлар! Сезнең тормыш бүренекедәй, бүреләрчә улагыз!

Карәхмәт, монысы ни булыр икән инде тагын дигәндәй одеялын ачып, башын күтәрде. Астагы катта ятучылардан кемнәрдер чышын-пышын сөйләшә, көлешә башладылар.

— Әрвахлар!..

Казарма уянды. Карәхмәт йөрәгенең дөп-дөп типкән тавышына хәтле ишетте. «Монысы ни булыр инде тагын?..»

Панасенко караваты астында яткан Рубевский, үрелеп кенә бер итеген алды да, яланаягына киеп куйды һәм үзенең өстендә бүлтәеп торган карават ятьмәсенә тибеп җибәрде. Аңкы-миңке яткан Панасенко идәнгә дөпелдәп төште дә «ай» дип кычкырып җибәрде. Рубевский Панасенконың кабыргасына типте.

— Марш урыныңа!

Түбәндәге караватлардан тагын берничә кеше идәнгә мәтәлде. «Монда әрвахлар без генә түгел икән»,— дип пышылдады Карәхмәт үзалдына һәм нәкъ шулчак ул да аска таба очты. Идәнгә мәтәлүчеләр үз урыннарына урнашып бетүгә, янә теге әмер яңгырады:

— Әрвахлар!..

Бу юлы җавап озак көттермәде, почмак яктан кемнеңдер чын бүре тавышына охшатып улавы ишетелде, аңа икенчесе кушылды, өченчесе. Берничә минуттан казарма эче карурманга охшап калды.

Астагылар буыла-буыла көлде, өстәгеләр тырыша-тырыша улады. Берәр «бүре»нең тавышы тынып калса, аңа шундук астан төртеп алдылар, тавышлар янә көчәйде.

Карәхмәт, карават тимеренә чытырдап ябышып, тыңлап ятты-ятты да, астагы солдатның төрткәләвенә карамастан, «бүреләр»гә кушылмады, урманы, андагы чын бүреләр исенә төште һәм ул эт булып өрергә кереште. Бүре барын сизгән Алан этләре бөтен авылны күтәреп өрә башлый иде.

Дневальный «шуба»[1] дигән куркыныч аваз салмаса, тагын уласылар иде әле. Аның тавышын ишетүгә, «бүреләр» шым булды, берара казарма эчендә карават тимерләре шыгырдаганы гына ишетелеп торды.

Бригада буенча дежур офицер итекләре белән дык-дык басып, казарма эчен әйләнде дә чыгып китте.

Карәхмәт иреннәрендә тозлы тәм тоеп, авызын тотты, борыныннан кан ага иде. Ул, борынын кыскан килеш, җәһәт кенә идәнгә

---

[1] «Шуба» — «Офицер» (жаргон).

төште дә, яланаякларына итеген киеп, юынгычка йөгерде. Дневальный тумбочка янында басып тора, Карәхмәтләрне плацтан ротага алып килгән сержант ишек янында йөренә иде. Йөзе-борыны канга буялган Карәхмәтне күреп, ул аның янына килде һәм кулыннан тотты да тиз генә юынгычка алып кереп, кранны ачты.

— Кем сукты? Кем кыйнады? — диде сержант.

— Ы-ы-ы...

— Кем сукты, дим?

Салкын суда кан оешып катты, ахрысы, тукталды.

— Сукмады берәү дә, үзе каный.

Сержант башын чайкап куйды.

— Идәнгә егылып төштеңме соң?

— Ие. Тик мин барыбер бүре булып уламадым.

— Егет икәнсең! Башка көнне дә улама!

— Аларга каршы сугышырга инде әллә?

— Кирәк тә бит... Тик алар бергә-бер чыкмыйлар, эт көтүе кебек һәммәсе берьюлы ташлана.

Кече сержант — Матусов фамилияле белорус егете иде. Бу ротага моннан ике ай элек өч сержант килде алар. Армиядә тугызынчы айларын хезмәт итсәләр дә, язылмаган законнар буенча ул да, иптәшләре Хафизов белән Нападовкин да «әрвах»лар чутында йөри.

Бу өч егет күптән түгел генә үзләрен Әфганстанга җибәрүләрен сорап гариза яздылар. Әлегә бернинди хәбәр дә юк, разведрота «картлач»лары белән көрәшә-көрәшә хезмәт итеп яталар. «Тизрәк моннан башны алып качасы иде»,— дигән уйлары көннән-көн көчәя бара.

Баштарак Хафизов иптәшләренең бу теләкләренә каршы төшеп:

— Без моннан китсәк, «картлачлар» тагын да котырачаклар гына бит,— дигән иде. Аның бу сүзләренә каршы Нападовкин кул гына селтәде:

— Син нәрсә, Солтан, командирлар үзләре дә бу хәлгә күз йомып торганда нишләп мин монда «картлачлар» белән сугышып ятарга тиеш ди әле. Әфганстанга барып дошманнар белән сугышуың хәерлерәк!

— Әфганстанда хезмәт итеп кайтканнарга фатир бирәләр икән,— дип куйды Матусов.

— Анысы ерунда! Тизрәк бу мәхшәр оясыннан котыласы иде,— диде Нападовкин.

Шулай итеп, мәсьәлә хәл кылынды: өч кече сержант, үзләрен Әфганстанга җибәрүләрен сорап, гариза яздылар.

* * *

Башын, муенын, терсәгенә кадәр бер кулын ак бинтка ураган «картлач» Манатов караватында яткан килеш тә, кызыл почмакка кереп тә, дневальныйның пычагын суырып алып, аны авызына капкан сурәттә дә, пычакны «исән» кулына тоткан кыяфәттә дә ярты сәгать буе фоторәсемгә төшеп йөрде. Аннары үзен рәсемгә төшергән Салоны киемнәр киптерү бүлмәсенә алып кереп:

— Таң атканда фотолар әзер булсын! — дигән кисәтү белән тышкы яктан ишекне шартлатып бикләп куйды.

Аннан соң киемнәрен үтүкләп маташкан Панасенко белән Дроздовны кызыл почмакка чакырып кертте.

— Кәгазь-каләм алыгыз!

Үзе тәрәзә төбенә менеп кунаклады.

— Мин әйткәнне язып барыгыз!

Панасенко белән Дроздов, авызларын ачып, Манатовка төбәлделәр. Шулчак ишектән старшина урынбасары сержант Иванов кү-

ренде. Алыптай гәүдәле бу сержант, офицер һәм прапорщиклардан кала, ротада беренче кеше иде. Бик аз сүзле ул, беркайчан да чәчрәп чыкмас, акрын гына тик үз дигәнен эшләп йөрер. Старшина урынбасары булуыннан бигрәк, бала башы хәтле йодрыкларыннан шүрлиләр аның. Яшь солдатларның котын алып торган Манатов та, Рубевский да, сержант Михайлов та аның белән чамалап сөйләшәләр.

— Мантана! Төш тәрәзә төбеннән! Штаб тәрәзәсеннән күренеп торасың бит,— дип гөрелдәде Иванов.

Манатов урындыкка төшеп утырды да үзенең әмерен көтеп торган яшь солдатларга ымлап:

— Хат язабыз,— диде.— Кайсыгызның язуы матуррак, шунысын мин әйткән адрес буенча почтага илтеп салырсыз. Башлыйбыз: «Дөньядагы иң якын кешем минем».

Манатов шулай диде дә, тиз генә урыныннан сикереп торып, ишеккә китте һәм башын чыгарып:

— Телескин! — дип кычкырды.

Ишектә тәбәнәк буйлы, йөзе атныкына охшаганрак бер солдат күренде.

— Телескин! Кил монда, утыр, миңа матур сүзләр эзләшерсең.

Телескин да армиягә Манатов белән бергә алынган, ул да хезмәт итү вакыты буенча «картлач»лар чутында йөрергә тиеш. Ләкин Телескинның мондый бәхетне татып караганы юк һәм эләкмәс тә инде ул аңа.

Телескин өчен хәрби хезмәт разведротада түгел, батальонда башланган иде. Ротада алар бары да бер чакырылыштан. Һәммәсе дә үз ишләре иде. Бервакыт бригада хәрби уеннары вакытында Телескин взводы белән разведрота взводы солдатларына уртак палаткада яшәп алырга туры килде. Манатовларның «әрвах» чаклары иде бу. Палатканың комсыз тимер мичен ягарга утынны алар ташый, поход кухнясыннан аш алып килергә алар йөгерә. Разведрота «картлачлары» бик тә таләпчән, кырыслар. Вакытында утыны салынмыйча, мич суына башласа, Манатовка, Рубевскийга, Ивановка, Михайловка эләгә.

Телескин хезмәт иткән взвод солдатлары барысы да бер иш булганлыктан, бер-берсенә куша алмыйлар, алар да разведрота «әрвах»ларына аркаланып, тегеләр ташыган утын җылысында яталар. Ә башка рота «картлач»ларының икенче бер рота яисә батальон «әрвах»ларына тешләре үтми, шуңа күрә ни булса да кылырга талпынып та карамыйлар.

Ай, шул чакта ничек кызыккан иде Манатов батальон солдатларының тормышына! Үзләре Манатов белән бер үк вакытта гаскәргә алынсалар да, ничек рәхәт яшиләр! Һай, кызыккан иде разведрота «әрвах»лары аларга...

Язмыш диген, нәкъ бер елдан соң Телескинны батальоннан разведротага күчерделәр. Менә шуннан соң аның өчен икенче төрле тормыш башланды. «Син тиешле вакытында «әрвах» тормышын күрмәдең»,— дип аның хезмәт вакыты нәкъ бер елга чигерелде һәм рядовой Телескин чып-чын «әрвах»лар белән беррәттән үз тиңдәшләренә хезмәт итәр көнгә калды.

— Наташа җиңгәңә хат язабыз, Телескин, йә, ничек дип башлыйбыз? Ә сез, бая язганнарны сызыгыз, чиста кәгазьләр алыгыз!

Телескин эшкә кереште:

— «Күктәге иң якты йолдызым», дип башласак, ә? — диде.

— Менә-менә, шәп бу. Язгыз. Йә, тагын?

— «Күктәге иң якты йолдызым! Сиңа солдат сәламнәре җибәрүче Александрның дип белерсең...»

Манатов аны бүлдерде:

— «Кайнар солдат сәламнәре» диген!

— Ие, «кайнар солдат сәламнәре... Наташа! Сиңа бик озак хат язмый тордым, ачулана күрмә зинһар, сәбәбе бар. Ул сәбәп хәрби сер инде. Наташа, аны хатка язарга ярамый. Мин сиңа госпитальдан чыкканнан соң төшкән фоторәсемнәремне җибәрергә булдым. Шуннан соң аңларсың. Бармаклар әле һаман бөгелеп җитми, каләм тотып язып булмый. Шуңа күрә бу хатны да әйтеп кенә яздырам...»

Казарма эченнән:

— Мантана! Телевизордан Аннаң җырлый, Анна Герман! Күрмичә каласың! — дип кычкырдылар.

Манатов атылып урыныннан торды.

— Үзегез язып бетерегез. Карагыз аны, матур итеп языгыз! Хатны кем шәп яза, шул бүген бәдрәф чистартудан азат булачак!

Манатов чыгып барышлый Телескинга таба борылды.

— Ә син әниемә хат язып сал. Фәлән-тегән, диген. Шура командировкага китте, миннән хат язарга үтенде, диген.

Манатов киткәч, Дроздов каләмен куйды да, кул аркасы белән маңгаендагы тирне сыпырып алды. Бер айдан бирле үз әнисенә дә хат язып салганы юк. Вакыты тими, иртәдән кичкә кадәр аяк өстендә, инде бераз бушадым гына дигәндә, «Картлач»лар бирәр эш таба.

«Әни ничек яши икән? — дип уйлады Валера.— Әти һаман эчә микән? Мин булмагач, тагын да иркенәйгәндер инде. Их, тизрәк үтеп китсен иде бу айлар, бу еллар... Наташасы да сагындырды. Кара, бу Мантананың да йөргән кызы Наташа исемле микәнни? Наташа шул. Хатка шулай яздырды бит...»

Валера каләмен кулына алды. «Наташа! Сагындым сине, бик тә сагындым. Инде менә өченче аемны хезмәт итәм, тик бер генә минутка булса да исемнән чыксаң икән. Беләсеңме, Наташа, кайчак мин болай уйлыйм: әгәр бу дөньяда син, Наташа атлы гүзәл булмасаң, миңа армиядә хезмәт итүләре бу кадәр үк кыен булмас иде, дим. Чөнки сагыну дигән нәрсә бик үзәккә үтә шул. Син булмасаң, бәлки, авылны да бу хәтле үк сагынмас идем. Аннары тагын уйлыйм да үз-үземне сүгәм: тиле, дим, әгәр Наташаң булмаса, син армиянең кырыс тормышына бер генә көн дә түзә алмас идең бит, дим. Бер көн үткән саен: «Инде кайтырга да күп калмый»,— дип, үз-үзеңне юата алмас идең, дим.

Минем хезмәт яхшы гына бара, Наташа. Һәммәсен дә язып бетереп булмый инде, ачуланма, хәрби сер, ярамый.

Наташа! Син безгә кереп йөри күр инде, әнине ташлама. Мин дә булмагач, аңа бик авырдыр. Әтигә дә әйтеп кара, эчеп йөрмәсен. Синең сүзеңне тыңлый бит ул, Наташа.

Наташа, шуның белән хатымны тәмамлыйм. Вакыт бик тар, служба. Сине үбеп: Валераң».

Ә Панасенко хатны ни дип тә дәвам итәргә белмичә, аптырап утыра иде. Ярдәм өмет итеп Дроздовка сүз кушып карады — тегесе ишетмәде дә, Телескин ягына күз ташлады, ул да маңгаеннан тир агызып мышный-мышный Манатовның әнисенә хат яза иде, башын да күтәрмәде.

Анна Герман җырлап бетерде, ахрысы, ишектә Манатов күренде.

— Барамы? — диде ул кирә-керешкә. Дроздов куркуыннан куырылып килде, әмма бу халәте озакка сузылмады, тирән итеп бер сулыш алды да өстәл астында кулын йодрыкка йомарлады һәм: «Кагылып кына кара, Мантана»,— дип тешләрен кысты. Үзенең йөзе комач кебек кызарды.

Манатов, бинтларын чишеп, кулына йомарлаган иде. Үзе берөзлексез нindидер әчпошыргыч көй сызгыра. Ул әүвәл Панасенко янына килде.

— Яле? Тфү! Берни язмагансың бит, аңгыра!

Манатов күп сөйләшеп тормады. Панасенконың чәченнән тотып башын күтәрде дә яңагына чалтыратты.

— Бүген төне буе лезвие белән казарма идәнен кырачаксың!

Манатов Телескинның кәгазен тартып алды.

— Молодец, Телескин, шәп язгансың.

Чират Дроздовка килеп җитте. Манатов аның алдындагы кәгазьне алды да авыз эченнән бытырдатып укырга кереште. Укып чыкты. Аннары, кашларын җыерып, яңабаштан укырга тотынды. Бу юлы ахырына барып җитәргә түземлеге калмады:

— Син! Салага! Әрвах! Мине мыскыл итәсеңме?!

Дроздов аягына торып басты да, башын аз гына ия төшеп, каш астыннан Манатовка карап тора башлады.

— Бир хатны, синеке түгел ул. Мин аны... мин аны үз Наташама язганмын.

Манатов Дроздовка сукмады. Өстәл өстенә менеп басты да хатны мыскыллы тавыш белән кычкырып укырга кереште. Дроздов ни кылырга да белмичә, аптырап, яңакларын чәйни-чәйни басып торды, торды да Манатовка таба бер адым атлады.

— Бир.

Ишектән урынбасар Иванов күренде.

— Мантана! Төш өстәл өстеннән. И шулкадәр акырма. Тавышың бөтен бригадага ишетелә.

Манатов идәнгә сикереп төште.

— «Сине үбеп: Валераң», имеш. Ярый, үбәрсең, әрвах! Бүген унитаз белән үбештерермен мин сине. Төне буе ялап чыгарсың!

Ул шулай диде дә, иптәше сизмәгәндә генә Дроздовның эченә китереп типте.

— Рота дежурные, тышка чык!

Казармага өлкән лейтенант Швалюк керде. Ул кәнсә ишеген ачып япты да, анда кеше булмагач, кызыл почмакка үтте. Дроздов эчен тотып, өстәл артындагы урындыкта утыра, Манатов күзләрен зур итеп ачкан да курка-курка әле аңа, әле ишек ягына карап ала.

— Дроздов, ни булды? — дип сорады өлкән лейтенант.

Дроздов башын күтәрде, әмма җавап кайтармады.

Манатов, керүченең Швалюк икәнен күргәч, Телескинга карап күзен кысты да кулы белән нидер ишарәләп күрсәтте. Телескин урыныннан купты һәм:

— Эче авырта аның, иптәш өлкән лейтенант, бүген боткaны күбрәк ашаган иде, ди. Эче сыекланган,— дип кычкырды.

Һәммәсе берьюлы шыркылдап көлергә тотындылар. Бары Дроздов үзе генә көлмәде.

Швалюк, көлеп туктагач, Манатовка борылды:

— Ничек, Шура, эшләр барамы?

— Әйе, әйе, әйбәт, иптәш өлкән лейтенант, әйбәт...

• • •

Юләр түгел бит өлкән лейтенант Швалюк, кызыл почмакта ни булганын сизенде. Тик сизенеп нишли? Манатовны йә шунда кызыл почмакта ук, йә кәнсәгә чакырып тирги, эттән-эткә салып сүгә ала. Шуннан ни? Манатов үзгәрерме соң? Юк, үзгәрмәячәк... Яшь солдат вакытында элеккеге «картлач»лар аның үзенең дә җелегенә төштеләр. Шуның үчен кайтара ул хәзер. Гаскәрдә бөтен нәрсә кабатланып тора. Форма башка, ә эчтәлек шул ук. Йә, ярый, Манатовны үзгәрттең ди, шуннан ни файда? Манатов һәм аның кебек башка өлкән солдатлар ротада ныклы тәртип саклыйлар. Рота эчендә ни генә булса да, ул тышка чыкмый. Моңа кадәр шулай булды.

Данилов шуны аңларга теләми. Имеш, яшь солдатларны мәсхәрә итүгә юл кую — җинаять. Шалкан башлар! Данилов булып Данилов шуны төшенми: өлкән солдатлар ротаның ныклы терәге бит. Менә тиздән хәрби уеннар башланачак. Шунда күрербез кемнәргә таянырга кирәк икәнен. Яшьләргәме, Манатов кебекләргәме? Яшьләрдән әлегә он да, йон да юк. Иң төз атучылар — өлкән солдатлар, иң шәп механиклар — өлкән солдатлар. Сержантлар Әфганстанга китәргә гариза биргән. Китсеннәр. Алар анда бик җиңел дип уйлый торганнардыр.

Манатовка тиеп кара син. Аңа инде өенә кайтып китәргә дә ярты ел гына калып бара. Бер киреләнсә, уеннар вакытында гел киресен эшләп йөриячәк. Автоматтан да юри начар атачак. Башкалар да шулай итәчәк. Яшь солдатларны да кисәтеп, куркытып куярга мөмкиннәр. Разведрота артта калачак. Рота командирына да эләгәчәк моның өчен, взвод командирларының да башларыннан сыйпамаслар. Хәер, анысы пүчтәк. Армиядә берәү дә берәүнең башын сыйпамый. Тик менә аннан соң Швалюкка рота командиры булу тиз генә тәтемәячәк инде. Аны шул хәрби уеннардан соң танк бригадасына рота командиры итеп куярга тиешләр иде. Корпусның штаб башлыгы моны үз авызы белән әйтте. Ләкин Швалюк гаскәрдә беренче көн генә түгел ич, белә, яхшы белә: барысын да хәрби уеннарда ничек катнашуы хәл итәчәк. Взводның күрсәткечләре яхшы булса, берсүзсез рота командиры итәчәкләр өлкән лейтенантны, начар икән, бигайбә, үзеңә үпкәлисең. Теләсәң, терсәгеңне тешлә, теләсәң, борыныңны тешләп кара — үз ихтыярыңда булачак. Армиядә мәсьәләне вакыт ягы да хәл итә. Йолдызлар саны вакыттан артта калса, отставкага чыкканчы өлкән лейтенант булып йөрүең бар.

Швалюк бригадага Манатовны алырга дип килгән иде. Манатов — менә дигән рәссам. Взвод командирының фатирын бизи ул. Эш башлаганына инде икенче атна, мөгаен, менә бүген ахырына чыгар, әллә ни күп калмады.

Монда күченеп килгәч, Швалюк ел саен фатирын бер мәртәбә ремонтлатырга гадәтләнеп китте. Алай бик зурдан кубып түгел түгелен. Бары стеналардагы чәчәк-бизәкләрен генә яңарта. Солдатлар арасында рәссамнарны исә һәрвакыт табып була. Әлегесен Манатов булыша. Ел саен сурәт-бизәкләрне яңартып тору бигрәк тә хатыны Василисаның күңеленә хуш килә иде.

Бая кызыл почмакта ни булганын Манатовтан юлда кайтканда да сорап тормады взвод командиры. Акылсыз егет түгел, артыгын кыланмас, дип уйлады.

Манатов взвод командиры артыннан ашыга-ашыга атлады. Бу йөрәгенең дөпелдәве кызу барганнанмы соң? Күкрәк читлекләрен җимереп чыгардай булып ник шулай тибәсең инде, йөрәк? Хәзер, хәзер күрерсең, күп калмады. Әле ярый бу Швалюгы сүз кушмый, сөйләштерми. Шәп командир ул шәбен. Разведротада Манатовның иң нык таянычы. Әй лә, кадалып китсенсәнә роталары. Хәзер, хәзер, йөрәк, бик ярсыма, җитәбез.

Надан син, йөрәк, аның өстәвенә сукыр да әле. Аңлыйм, аңлыйм, сукыр булганга надан да инде син. Күрсәң иде син аны менә. Экият гүзәле кебек ул.

Ярый әле, бу взвод командиры сүз кушмый.

Син, йөрәк, бәргәләнгән буласың инде. Чөнки дөм сукыр син. Болай дөпелдәвеңнән ни файда? Ярый, берәр мәртәбә, бәлкем елмаеп та куяр әле безгә. Халат итәге ачылып китсә, башка җирләренә күз салырга да насыйп булыр, бәлки. Шуннан ни? Сине боза гына бит ул, йөрәк. Беләсең килсә, йөрәк бозгыч кына ул. Дөпелдәмә син, дөпелдәмә. Хәзер җитәбез...

Килеп җиттеләр. Швалюк йозакны үз ачкычы белән ачса да, бусаганы атлар алдыннан ишек кыңгыравына басып алды.

Василиса кухнядан килеп чыкты. Бүген өстендә халат түгел, изүе шактый ук мул ачылган зәңгәрсу күлмәк киеп куйган.

Әкияттән чыктыңмы әллә син, Василиса? Җитәр, Мантана, кеше хатынына нәфесеңне сузма. Килгәнсең икән, эшеңне эшлә дә отбойга кадәр казармаңа кайтып җит!

Сәгать ярымлык эше калган. Манатов буяуларны әзерләп куйды да эшкә кереште.

— Толя, ашка бәрәңге генә турап саласы бар. Мин монда булышам.

Манатов буяу савытын тотып торган Василисага каш астыннан гына карап куйды да, савытны үзенә алып, өрәңге яфрагы төшерергә керешге.

Манатовларның авылында, Наташаларның капка төбендә, өрәңге агачы үсә. Шул өрәңгенең яфракларын взвод командиры фатирында да калдырып китсен әле юри, үч итеп. Тик менә кемгә үч итеп икән? Үзенәме? Швалюккамы? Хәер, бу турыда уйлаганы булмады. Ярый, теге кирәксезгә дөпелдәгән йөрәккә үч итеп булсын, ди. Бүтән дөпелдәмәсен! Шул кирәк аңа!

Манатов ара-тирә Василисага да күз салып ала. «Иреңнең буфетчы Серафима белән типтергәнен беләсеңме соң син, мескен хатын? Син генә гүзәл түгел, Серафима да чибәр. Швалюкның зәвык шәп, хатыннарны сайлый белә, каһәр. Берүзенә — икәү. Комсыз! Җитмәгәнмени аңа шушы Василисасы гына? Ә Серафима янына әнә Данилов йөрсен. Барыбер ялгыз башы. «Йә, ярый, Мантана, анысы синең эш түгел!»

— Шура, син мондый осталыкка кайда өйрәндең, кайда укыдың? — дип сорый Василиса.

— Тракторчылар курсында. Ике ел.

Василиса көлемсерәп куйды.

— Рәсем ясарга, дим?

Манатов стенага янә бер бизәк төшерде.

— Рәсемгәме? Бабайның бабасыннан.

Аңлап бетереп булмый Василисаны. Кызык хатын ул. Һәр кыланышы саен көтелмәгән ягы белән ачыла да куя, ачыла да куя. Манатов аны юри үрти. Болай гына, кызык өчен генә, билгеле. Швалюк күрмәгәндә генә.

— Бабаңның бабасы?

Манатов хатынга күз төшерде. Матур йөзендә аз гына аптырау галәмәте бар. Чибәр хатын, бал кашыгына салып сусыз-нисез кабып йотарлык!

— Бабамның бабасы шул. Безнең авылдагы чиркәүне бизәгән ул. Кулы алтын булган. Малайларының, оныкларының кулыннан бу эш килмәгән, миңа җиткәч кенә эш пеште. Рәсем ясарга беркайда да укымадым үзе.

Василиса янә көлеп җибәрде: авызыннан гүя, көмеш тәңкәләр сибелде, ике як битендә борчак сыярлык кына чокырлар хасил булды.

— Чү! Бу яфрагың кыек төште түгелме соң?

— Шулай тиеш ул,— дип куйды Манатов һәм нигә шулай тиешлеген дә аңлатты: — Табигый булсын, дим. Яфраклар агачта төрлечә асылынып тора бит.

Швалюк, савыт-саба шалтыратып, кухняда бәрәңге әрчи иде, ахрысы.

«Кит әле, Василиса, әнә ашыңны кара, син болай карап торсаң, өрәңге яфрагы урынына ялгыш иманнекен төшереп куярмын тагын».

— Армиядән соң художество училищесына керергә кирәк сиңа,

Шура. Табигать биргән сәләтне юкка чыгарырга ярамый.

— Әле бу армиядән кайтканчы! Дөнья йөзгә төрләнер.

— Нигә? Сиңа күп калмады бит инде, ярты елдан да азрак.

Манатов, Швалюк ишетмиме икән дип, кухня якка күз салып алды.

— Ул ярты ел монда ярты гасыр кебек шул.

Василиса аның хәленә кергәндәй башын чайкап алды.

Бер елдан артык вакыт эчендә яфраклар белән шактый эш итәргә туры килгәне бар. Берәр зуррак тикшерү киләсе булса, штаб башлыгы разведротаны тревога белән аякка бастыра. Бер заманны Мәскәүдән генераллар килде. Разведротаны клуб каршындагы газоннарны тәртипкә китерергә чыгардылар. Рота командиры өлкән лейтенант Ильин агачлардагы саргая башлаган яфракларны җыю буенча взводлар арасында ярыш оештырып җибәрде. Сары яфраклар агачларның ямен алып торалар кебек иде. Разведчиклар, җылы якларда яшәгән бик борынгы бабалары сыман, агач саен менеп саргайган яфракларны җыеп йөрделәр.

Клуб нигезеннән бераз читтәрәк үсеп утырган бер яшь кенә, бәләкәй генә каенның да кайсыбер яфраклары саргая, төссезләнә башлавын күрделәр. Яфракларын йолкысаң, каен бөтенләй шәрәләнеп калыр дип, Манатовка яшел буяу алып килергә кушылды. Газон читендәге үләннәр дә каралган, пычранган иде. Манатов аларны да беррәттән яшелгә буяп чыкты. Ике көн эчендә разведрота клуб тирәсен ялт иттерде. Шул хезмәте өчен штаб башлыгы ротаны алдагы якшәмбедә Хатыньга экскурсиягә җибәрде.

Менә стенага соңгы яфрак та төште. Эш бетте, пумалаларны җый да бригадаңа ычкын!

Василиса бик кыстап караса да, табын янына утырмады Манатов. Взвод командиры:

— Әйдә, Манатов, озатып куям мин сине,— дигән иде, тегесе башын селкеде.

— Кирәкми, иптәш өлкән лейтенант.

— Патруль очрамасмы?

— Кәҗә сукмагыннан гына мин.

— Син нәрсә, Толя, Шураны болай гына җибәрмәкче буласыңмы әллә? — дип Василиса Манатовның беләгеннән тотты: — Ю-ю-юк, болай гына булмый! Тырыштың, рәхмәт, яле, кил әле монда. Әйдә.

Швалюк Манатовны кухняга алып керде. Василиса суыткычтан башланган шешәле коньяк алып рюмкага салды. Өлкән лейтенант, эш тапкан булып, кухнядан чыгып китте.

— Әйдә, әйдә, аннан гына берни дә булмый.

Манатов гаепле кеше сыман кыенсынып кына өстәл янына килде һәм рюмканы кулына алды. Тәлинкәдәге тозлы кыярга үрелеп маташкан солдатка хатын шоколад тоттырды.

Взвод командиры солдатын бригада капкасына кадәр озатырга булды.

* * *

Бүген Карәхмәт Йосыфтан тагын бер хат алды. Өйдәгеләр саусәламәт дип язган. Сабан туе булган икән. Шәһәрдән бик күп кунаклар кайткан. Җиде йортлы авылда ул көнне җиде йөзгә якын кеше булгандыр, дигән Йосыф. Сабан туенда укытучы Борһан абыйны күргән икән. Йосыфтан Карәхмәт турында сорашкан.

«Һы, бер хат язып саласы бар әле Борһан абыйга»,— дип уйлап куйды Карәхмәт. Борһан абый мәктәптә башлангыч хәрби эш дәресләре укыта. Үзе дә алты-җиде ел элек кенә гаскәрдә хезмәт

итеп кайткан. Карәхмәтләрне укытканда старшина дәрәҗәсендә иде. Аннан соң укыды, хәзер лейтенант ди бугай.

Әй сөйләп тә карый иде инде армия тормышы турында. Дәрестә бер төрле итеп сөйли иде, тәнәфескә чыккач икенчерәк итеп. Инде дәрескә мәктәп директоры да кереп утырса — бетте, автоматтан аткан кебек китап буенча гына тыкылдата. Имеш, сез булачак солдатлар, туган илне сакларга тиешле кешеләр. Менә сезгә Калашников автоматы төзелеше, менә сезгә атом бомбасыннан саклану чаралары һәм башкалар, һәм башкалар...

Ә тәнәфестә? Тәнәфестә малайларны противогаз киертеп мәктәп әйләнәсе буенча куа торган иде. Ял иткән арада ничек итеп үзе хезмәт иткән полкның хәрби уеннарда катнашуын сөйли, әллә нинди кызыклы да, аяныч лы да вакыйгаларны исенә төшерә.

Тәнәфестә башка нәрсә сөйләп, директор алдында китапта язылганнардан бер җөмлә дә читкә тайпылмаган укытучыны малайлар кайчак үртиләр дә иде.

— Борһан абый, солдатка әдәбият фәнен белү кирәкме, юкмы?— дип куя берәрсе һәм нигә мондый сорау бирүен шундук аңлата да: — Алайса Зөләйха апа гел ачулана, шигырь дә ятлый алмагач, солдатка ничек барырсыз соң, ди.

Әдәбият укытучысы Зөләйха апа классны ике юнәлештә тәрбияли, малайларны армиягә барырга, кызларны кияүгә чыгарга әзерли иде.

Борһан абый авыз ачарга да өлгерми, икенче малай кулын күтәреп:

— Абый, абый, үзем җавап бирим әле шуңа,— ди.

— Йә, йә, аңлат әле Кашапов.

Кашапов бик җитди кыяфәт белән урыныннан торып баса.

— Армиядә хезмәт иткәндә, булачак солдат кешегә инде, туган илен саклаучы кешегә әдәбият фәнен белү аеруча мөһим. (Кашапов мәктәп директорына охшатырга тырышып, җөмләсен катлы-катлы сүзләрдән төзи). Чөнки, мәсәлән, син пограничник ди. Шунда берәрсе чикне бозып керде ди. Кулыңда автомат булса да, ата алмыйсың. Ялгышуың мөмкин...

Класс та, Борһан абый да, хәтта һәрвакыт җитди чырайлы мәктәп директоры да тын да алмыйча кызыксынып Кашаповны тыңлый.

— Йә, йә, шуннан? — ди мәктәп директоры, моның үзе өчен дә кызык икәнлеген белдереп. Кашапов тамагын кырып ала да дәвам иттерә:

— Бәлкем ул кеше дошман түгелдер? Бәлки ул шул илнең президенты малаедыр? Эче пошып йөргәндер-йөргәндер дә совет солдатыннан хәл-әхвәл сорашырга килүедер. Атып үтереп кара син аны менә. Ә син әдәбият фәнен яхшы белгән кеше буларак, тегеңә тәмәке бирәсең дә китәсең сөйләп Муса Җәлилнең төрмәдә язган шигырьләрен. Аннары куркып калачак президент малае. Чү, болар мине дә төрмәгә тыгарга уйлыйлар, ахрысы, дип, тәмәке өчен бөгеләсыгыла рәхмәт әйтеп, үз иленә сыптырачак. Президент малае булса инде әгәр.

— Әгәр дә мәгәр президент малае булмаса?

Директорның тавышы бик тә ачулы. Кашапов, уеннан уймак чыгардым, ахрысы, дигәндәй, югалып кала, тез буыннары җиңелчә генә калтырый башлый. Шулчак янәшәдә утыручы аның ботыннан чеметеп ала, Кашапов аңына килә. Һәм иптәшләренең «сөйлә», «сөйлә инде» дигән ялварулы карашларын тоеп, дәвам иттерә:

— Шпион булса, мәхәббәт шигырьләрен сөйлисең. Аның да йөрәге бар бит. Сокланып тыңлап торыр-торыр да онытылып китәр. Ә син шул арада шалт кнопкага — заставага хәбәр итәсең. Килегез, тикшерегез.

Сөйли торгач үз сүзләренә үзе чын-чынлап ышана башлаган Кашапов беркавым бер ноктага карап уйланып торды. Класс әлегесен түзә, әлегә көлми. Кашаповны фаш итәсе килми; югыйсә, һәммәсенең дә көлке капчыклары тулып, шартлар дәрәҗәгә җиткән. Директорның йөзе бер зәңгәрләнде, бер кызарды. Борһан абый елмая. Әлегә барысы да директорның сүзен көтә. Борһан абый, бу киеренкелекне йомшатырга теләп, ахрысы, инде парта артына утырган Кашаповка сорау бирде:

— Ә шпион татарча белмәсә?

— Шпионнар әллә ничә төрле тел белә алар.

Класс «пырх» итте. Директор сикереп торды да кызу-кызу атлап ишеккә таба юнәлде.

— Кашапов, дәрес бетүгә минем кабинетка! — дигән сүзләре генә ишетелеп калды.

Класс гөр килде. Борһан абый да көлә. Тик дәрес беткәч, Кашаповның әле елыйсы да бар. Чөнки директор аның өенә хат җибәрәчәк. Ажгырып торган үги әнисенә исә шул гына кирәк, ул сылтау гына эзләп йөри.

Соңыннан ишетелде, директор Кашаповны:

— Син безнең хәрби көчләрдән көләсеңме, маңка! — дип сүккәнсүккән дә чынлап та өенә хат җибәргән.

Шушы вакыйгадан соң Борһан абыйны мәктәптә башлангыч хәрби эш дәресен укытудан тыйдылар. Дәресне яңа гына Казан пединститутының татар теле һәм әдәбият бүлеген тәмамлап кайткан яшь егет укыта башлады.

Карәхмәт Йосыфтан тагын бер хат алды. «Хупҗамал карчык беркөнне почта өләшеп йөргән Нәзирәне очратып: Сөембикәнең малаеннан хат-хәбәр киләме соң? Бигрәкләр дә шүрәле каргаган нигезгә килеп утырдылар бит, исән-сау гына йөриме икән?» — дип сораган. Нәзирә апа әйткән тегеңә: «Карәхмәттән көн саен бер хат килеп тора, хаты булмаганда лимон тутырып посылкалар җибәрә, ул хезмәт иткән җирдә лимонны бәрәңге урынына ашыйлар, терлеккә дә шуны гына бирәләр икән»,— дигән. Хупҗамалның сүзсез калган. Нәзирә моны Алма апага да кереп сөйләгән, көлешкәннәр рәхәтләнеп. Икенче көнне «ТАСС хәбәрчесе» Алма апаны урамда очратып: «Чәйгә берәр лимон бирмәссеңме икән, авызымның тәме юк, лимон капсам, бәлки күңелем ачылып китәр ие»,— дигән. Алма апа да аптырап калмаган: «Җибәргән берсен ашап бетереп барабыз шул. Хәер, берәр калгандыр әле»,— дип, кемдер күчтәнәчкә алып килгән соңгы ике лимонын «ТАСС хәбәрчесе»нә биреп чыгарган».

Бу юлларны укыгач, Карәхмәт әүвәл эче катып көлде, аннары, әнисен уйлап, күзләренә яшь тыгылды. «Хатларны гына булса да ешрак язып торырга кирәк»,— дип карар кылды ул.

Тик хатка нәрсә дип язасың? Һаман шул бер үк балык башы инде. «Әйбәт ашаталар, туйганчы йоклыйбыз, хезмәт бара, инде менә ике ай узып китте». Яки шаярткан булып, «кайтырга да күп калмады», дисең. Исәп-хисабы яхшы солдатның: вакыт узуга карап һәр көнне дә киметә бара. Тагын ничә айданмы, атнаданмы хезмәт вакытын тутырып өенә кайтасын, башын мендәргә төртүгә, җиде кат саный, исәпли. Аннары нарядта торасы булмаса, шул көнен төшендә күрергә өметләнеп, тәмле йокыга китә.

Кичә Карәхмәтне «велосипед»та йөрттеләр. Отбойдан соң атналарны, айларны тагын бер тапкыр бик җентекләп санап, йокыга гына киткән иде, берзаманны, аягы авыртканга түзә алмыйча, уянып китте. Хәйран вакыт аңкы-миңке килеш уң аягын селкеп ятты. Янәшәдә шырык-шырык көлешә башладылар. Карәхмәт күзләрен ачты. Уң аягының ике бармак арасына кыстырылган гәҗит кисәге инде янып бетеп бара иде. Ул аны тиз генә сыпырып төшерде дә: «Ай»!—

дип кычкырып, пешкән аяк бармакларын капшарга тотынды.

— Ничек, велосипед шәп чабамы соң? — дип сорый Карәхмәтнең караватт очында торган Манатов.

Карәхмәтнең күзенә яшь килеп бөялде. Аяк бармаклары сулкылдап, сулкылдап сызлый. Күрәсең, «велосипед» шәп чапкан иде.

— Нигә авызыңа су каптың? Ник дәшмисең? Ярый алайса, иртә белән мин уянуга, бәдрәф идәнендә ничә шакмак барлыгын әйтерсең.

Манатовның авызыннан нинди дер ят ис килә, «гражданка» исе бугай.

Төнге сәгать икеләр тирәсендә Карәхмәт уянып китте. Кылт итеп бәдрәф идәнендәге шакмакларны санарга кирәклеге исенә төште. Ул кабалана-кабалана өстендәге одеялын алып атты да, тумбочка өстенә басып, идәнгә сикерде.

«Тукта! Нишлим соң әле мин? Нишлим? Шакмак санарга барам ич. Иртәгә Манатов сораячак. Юк... кирәк булса үзе санасын! Санамасаң... Карышсаң? Эләгәчәк, тукмаячаклар бит! Панасенко бер көнне санаган иде, бәлкем, аннан гына сораргадыр? Аннары иртә белән Манатов сораса, әйтәсең?»

Ул яланаяк кына Панасенко караватына таба китте. Көне буе үзенең хәрби хезмәтеннән тыш «картлач»ларның юк-бар йомышын үтәп алҗыган, йөдәгән Ваня, таралып, изрәп йоклый иде. Карәхмәт әүвәл аңа дәшеп карады, уянмагач, кабыргасына төртте. Тегесе селкенмәде дә. Ахырда ул Панасенконың җилкәсеннән тотып селкергә кереште. Ваня башын күтәреп: «Ә?» — диде дә яңадан мендәренә капланды.

— Ваня, Ваня, дим! Тор әле! Бер нәрсә генә сорыйм!

Тегесе тагын башын күтәрде һәм бер күзен генә ачып карап, янындагы кешенең «картлач» түгел икәнен күргәч, янә мендәренә сыгылып төште.

Ваня астындагы караватта яткан «картлач» кымшанып куйды. Карәхмәт акрын гына үз караваты янына китте. Чалбарын, итекләрен киде һәм туалетка таба атлады.

Дневальный тумбочкасы янындагы идәндә шыплап тутырылган өч капчык ята. Дневальный үзе күренми. Казарма ишегенең тоткасына щетка сабы тыгылган.

Карәхмәт юынгычка керде. Тәрәзә янында парад формасыннан өч сержант басып тора, дневальный да шулар янында. Киемнәр киптерү бүлмәсенең ишеге ачык. Андагы киезләрнең берсендә дежурный кече сержант Михайлов йоклап ята.

Барысы да берьюлы ишектән кереп килүче Карәхмәткә таба борылдылар.

— Нәрсә, йокың качтымы әллә? — диде аңа Хафизов.

— Юк, болай гына,— дип мыгырданды Карәхмәт.

— Йә, ярый, егетләр, безгә кузгалырга вакыт. Өченче яртыга штаб янына җыелырга куштылар. Сәгать биштәге Ташкент самолеты белән очабыз,— дип Матусов урыныннан купты.

— Әйдә, якташ, бир кулыңны. Туган якларда күрешергә язсын! — дип, Хафизов та Карәхмәткә кулын сузды. Карәхмәт аларның шушы көннәрдә Әфганстанга китәчәкләрен белә иде. Ләкин, бүген үк тер дип кем уйлаган! Шуңа күрә ул бераз аптырап калды, рәтләп саубуллаша да алмады.

Нападовкин чыгып барганда дневальныйга:

— Уят дежурныеңны, безне озаткач, рота командирының монда да кереп чыгуы бар. Күрсә, иманын укытыр, йоклап ятмасын! — диде.

— Их, егетләр, неужели котылабыз бу җәһәннәм оясыннан! — диде Хафизов, чыгып барышлый, тагын бер мәртәбә казарма эченә

караш ташлап. Аннары: — Син бирешмә,якташ! Нык тор! — дип өстәде.

Өч егет, армиядә инде сигез ай хезмәт итәргә өлгергән өч сержант, кызу-кызу атлап, баскычтан төшеп киттеләр... Дневальный дежур сержантны уятырга кереште, ә Карәхмәтнең әле шакмак саныйсы бар иде...

«Ә санамасам?! Төкердем мин ул Мантанага!» — дип икеле-микеле уйлар эчендә калды Карәхмәт. «Их, син! Нинди көнгә төштең, ә? Бу турыда Йосыф ишетсә, авылдашларың, Нәзирә, әниең?...

Йә, Карәхмәт! Син сызгырып җибәргәч, урман да шул көйгә шаулый башлый иде бит! Ә бүген бәдрәф идәнендәге шакмакларны санарга калгансың. Кыйнасалар ни, кыйнасыннар!..»

Кием киптерү бүлмәсеннән дежур сержант уянып чыкты.

— Нишләп катып торасың монда? — диде ул Карәхмәткә йокылы күзләрен угалый-угалый.— Мантана әйткәнне эшләдеңме әле?

Карәхмәт карусыз гына бәдрәфкә кереп китте һәм ярты сәгатьтән аның идәнендә бер мең дә утыз тугыз шакмак барлыгын белде.

Иртәгесен физзарядкадан кайтып керүгә, аны Сало кием киптерү бүлмәсенә чакырды. Манатов тәрәзә төбендә аякларын селкеп утыра иде.

— Ничәү?

«Әйтсәң, пүчтәк кеше буласың! Әйтмә!..»

— ...

— Ничәү дим?!

— Белмим.

— Ничә?!

— Сана. Үзең... сана.

Манатовның күзләре дүрт булып, маңгаена ук менеп утырды.

— Ничә дидең, ничә?..

— Үзең...

Манатов тәрәзә төбеннән шуып төште дә: «Ничә? Ничә?» — дип тәкрарлый-тәкрарлый Карәхмәткә якынлашты һәм килеп җитүгә үк йодрыгы белән эченә сугып җибәрде. Карәхмәт бөгәрләнеп килде. Сулышы капты, тыны кысылды. Аннары: «Уф!» — дип бер тирән сулыш алды да, мәче кебек сикереп Манатовның күкрәгенә типте. «Картлач» почмакка таба очты. Разведротада мондый хәлнең күренгәне дә, ишетелгәне дә юк иде әле. Яшь солдатның өлкән солдатка каршы әйтүе яки ул кушкан эшне үтәмәве гадәттән тыш хәл булачак кабул ителсә, кул күтәрү исә... бөтен кешелек дөньясына каршы кылынган гаять зур җинаять кебек иде!..

Бүлмәгә бер-бер артлы өч «картлач» атылып керде һәм, почмакта яткан Манатовны күреп, Карәхмәткә дәррәү ябырылдылар. Малайның күз алдында итек табаннары гына күренеп-күренеп алды.

— Рота, үрәкат! — дигән әмер «картлач»ларны эшләреннән аерды. Казармага рота командиры кергән иде. Карәхмәтнең авыртып сулкылдаган колагында дежур сержантның:

— Иптәш өлкән лейтенант! Мин дежур торганда ул-бу булмады. Рота буенча кизү торучы — сержант Михайлов,— дигән рапорты бик озак яңгырап торды.

— Вольно!

Рота командиры кәнсәгә кереп китте.

Бүген полигонга автоматтан атарга баралар. Өч атна рәттән йөриләр инде. Бүген разведротаның ничек атканын бригада командиры килеп тикшерәчәк.

Казармада ук һәр солдатның да автоматын һәм башка сугышчан кирәк-яракларын Ильин үзе тикшереп чыкты.

Рота иртәнге аштан соң полигонга кузгалды.

Карәхмәтнең ике колагы да үтереп сызлый, кабыргалары авыр-

та, сул кулбашы сулкылдый иде. Ул бу халәтен командирларга сиздермәскә тырышты. Иртән рота командиры аның кызарып торган колагын күреп:

— Нишләде? — дип сораган да иде. Ул:

— Җил тигән, ахрысы, авырта,— дип кенә куйды. Чөнки әләкләсәң — бетте!...

— Алайса санчастька барып кайт,— диде рота командиры.

— Юк, уза ул, инде төзәлеп килә,— дип кире какты Карәхмәт.

Ильин артык төпченеп тормады. Югыйсә, элегрәк, казармага килеп керүгә, яшь солдатларның һәммәсен дә күздән кичерә, йөзкыяфәтләрендәге күгәргән урыннарга шундук игътибар итеп, төпченә-сораша, барыбер очына чыга һәм гаепле солдатны җәзасыз калдырмый иде. Бу элегрәк шулай булды. Хәзер инде офицер, вакыт үткән саен, хәрби тормышка җайлаша башлады. Бигрәк тә борын төбендә хәрби уеннар торганда алны-артны карап эш итәргә туры килә. Швалюкның сүзләрендә хаклык бар. Төп максат — алда торган сынаулар. Калганы — соңыннан.

Полигонга бригада командирының да киләсен белгән операторлар атарга өйрәнү урынын алдан ук әзерләп, мәрәләрне көйләпҗайлап куйганнар иде.

Юлда комбриг машинасы күренүгә, Ильин, ротасын күзәтү пункты янына тезеп, рапортка әзерләнде. Взвод командирлары рәтләр буенча йөреп, солдатларның хәрби кирәк-яракларын тагын бер кат барлап чыктылар. Барысы да тәртиптә кебек иде.

Комбриг, рота командирының рапортын кабул итеп, солдатлар белән исәнләште дә каршыга ук килеп басты һәм һәр солдатны диярлек күздән кичереп чыкты.

— Кулыңны селкемә! — дип берсенә шелтә дә ясады. Сафның иң очында ук, сул җилкәсен бераз күтәрә төшеп, Манатов тора, шелтә шуңа иде. «Кулын имгәттем микән әллә?» — дигән уй Карәхмәтнең эчен жу иттерде. «Әгәр шулай булса, бетте баш, җелекне суырачаклар!»

Күзәтү пункты өстендәге флаг ак ягы белән әйләнде, атуларны башларга мөмкин дигән сигнал бирелде.

Карәхмәтнең хәле бәйгегә чыгарга әзерләнгән чабышкыныкы кебегрәк иде. Автоматка тиз өйрәнде ул өйрәнүен. Бүген генә сынатмаса ярый ла! Кул башының авыртканы да онытылып торган сыман, йөрәге генә тасырдый менә...

Әллә рота командиры берәр нәрсә сизенеп, махсус шулай эшләде, әллә очраклы хәл генә булдымы — Карәхмәт белән Манатов икесе бергә туры килде: берсе — сул як оборона сызыгыннан, икенчесе уң яктан атарга тиешләр иде.

Манатов беренче булып уң як сызык турысына килеп басты. Команда яңгырауга, икесе дә үз түмгәкләренә атылдылар. Автоматлар корылды, гранаталар алдагы окопка таба очты, алда граномемәрә күренде. Икесе берьюлы диярлек чакмаларына бастылар. Еракта танк-мәрәләр калыкты, аннары башка төрлеләре. Менә бер-бер артлы соңгылары да ауды.

Карәхмәтнең кытыгы басылмаган иде әле. Автомат көпшәсе янәшәдәге түмгәк өстендә сузылып яткан Манатов ягына борылды. Бер пуля... һәм барлык газаплар да юкка чыгачак! Карәхмәт, аңына килеп, автоматын чирәмгә куйды. Маңгаена сап-салкын тир тамчылары бәреп чыкты.

Икенче юлы противогаз киеп аттылар. Монысында да Карәхмәтнең пулялары җилгә очмады.

Рота командиры күзәтү пункты янында атып килгән солдатларга ялгышларын әйтә, күрсәтмәләр бирә. Карәхмәт белән Манатов килеп җитүгә ул Манатовка:

— Их син, солдат! Яшьләрдән үрнәк алыр идең ичмасам! — диде дә, Карәхмәтнең беләгеннән тотып, Сало урынына бастырды.

— Син тагын атасың, Сало өчен. Аңладыңмы? Сине Сало күзәтү пункты артында көтеп торыр, аткач, тиз генә алмашырсыз да, комбригка доклад белән Сало керер.

Карәхмәткә өченче, дүртенче тапкыр атарга да насыйп булды. Комбриг сизмәде, күнегүләр «бишле»гә үтәлде. Иванов та кем өчендер ике тапкыр атып килде.

Соңыннан нәтиҗә чыгардылар: рота буенча гомуми күрсәткеч шактый югары иде. Комбриг ротага һәм командирларга рәхмәт белдерде, алда әле тагын да зуррак сынаулар торганын искәртте.

Карәхмәтнең ярты сәгатьтән казармага кайтасы бары исенә төште. Манатовның йөзе кара көйгән, баядан бирле Карәхмәт ягына усал итеп карап-карап ала. Аның бу карашыннан малайның йөрәге табан астына төшеп киткәндәй була, борын очына тир бәреп чыга, кулбашы һәм кабыргалары тагын да ныграк сызларга керешәләр.

Бригадага кайтканда Карәхмәт гел аяк астына гына карап атлады. «Нишләргә икән соң? Нишләргә? Түзәргәме? Әллә тагын сугышыргамы? Яклаучы юк шул. Үзем генә ни кыра алам? Түзәргәдер, бәлки? Көз көне Манатовлар өйләренә кайтып китәләр бит инде. Чыдармын әле көзгә хәтле генә. Их, кыйныйлар шул. Кыйнамасалар бер хәл иде әле...»

Иңбашындагы автомат көпшәсе авырткан колагына бәрелеп алды. Күзеннән яшьләр атылып чыкты Карәхмәтнең. «Кемнән генә киңәш сорап карарга икән? Бәлкем, сез берәр нәрсә әйтерсез, Борһан абый, ә? Армия хезмәтенә сез әзерләдегез бит безне».

Карәхмәтнең күз алдына укытучысы килеп басты.

«Нишлим, Борһан абый, ә?»

«Кеше булып кал. Соңыннан, бүгенге хәлләреңне исеңә төшереп, үз намусың алдында кызарырлык булмасын. Аннан беркая да кача алмассың!»

«Сезгә шулай дип әйтергә җиңел, Борһан абый. Һаман да сүзләр генә шул. Миңа коры сүз түгел, ярдәм кирәк!»

«Ә син мин әйткән сүзләрнең мәгънәсе турында ныгытыбрак уйла әле, егетем. Аннары калганын үзең карарсың».

«Нәзирә, син дә бар бит әле. Минем урында булсаң, нишләр идең, ә?»

«Миңа синең көчле булуың, нык ихтыярлы, олы җанлы булуың ошый бит, Карәхмәт!»

«Анысы өчен рәхмәт, камыт аягым! Ул ихтыяр көче белән генә Манатовның борынын канатып булмый шул. Ә ул шунсыз туктамас, ахрысы, инде».

«Элекке Карәхмәт булып калсаң иде син!»

«Тырышам инде, Нәзирә».

«Йосыф, синнән киңәш сорап тормыйм да инде. Мине өйрәтергә башың яшьрәк әле».

«Алай димә, Карәхмәт абый! Башым яшь булса да, барыбер синең кебек туалет идәнендәге шакмакларны санап йөрмәячәкмен инде мин!»

«Ярый, әтәчләнмә! Һәм абыеңны мыскыллама да! Санасам да, ничә икәнен Мантанага әйтмәдем ич!»

«Әйтүен әйтмәдең анысы».

«Әни, син ни диярсең? Елама тик, күз яшьләреңне түкмә! Син елый башласаң, минем дә күңел тула. Йә, әнием, нинди киңәш бирерсең?»

«Киңәш дип, хәлең авыр, балам, аңлыйм. Тик әтиең рухын рәнҗетерлек эшләр кыла күрмә инде, яме. Алла хакы өчен дим.

Исән-сау йөре. Исән-сау әйләнеп кайт. Карап торган бердәнбер балам бит син!..»

Карәхмәтнең күзләренә яшь килеп тыгылды. Ярый әле бу дөньяда әнисе бар, киңәш-табыш итүче башка якын кешеләре бар...

Ул башын күтәрде. Бригадага кайтып җитәргә дә күп калмаган иде. Шулчак карашы ирексездән үзеннән алда барган Мантананың автомат көпшәсенә бәйләнгән кулъяулыкка төште. Ул ашыга-ашыга кесәләрен актарды. Нәзирә бүләк иткән чигүле кулъяулык бер кесәсендә дә юк иде. Автомат көпшәсенә бәйләнгән кулъяулык җилдә җилфердәп бара.

Карәхмәтнең күзләренә тагын яшь килеп бөялде. Ул як-якка карап алды. Манатов янәшәсендә генә старшина урынбасары сержант Иванов бара иде. Манатовның иңенче ягында Михайлов атлый. Иванов кулъяулыкның кемнеке икәнен тәгаен белә иде, күрәсең, приклад белән Манатовның җилкәсенә төртеп алды:

— Артыгын кылана башладың, Мантана! Бир тизрәк Әмирхановка кулъяулыгын. Югыйсә!

Манатов кулъяулыкны көпшәдән суырып алды да Карәхмәткә таба ташлады.

Тегесе аны эләктереп алып тиз генә куен кесәсенә яшерде.

Кич белән Манатов Карәхмәтне киемнәр киптерү бүлмәсенә чакырмады.

Карәхмәт кыска гына итеп Йосыфка хат язып салды.

«Йосыф! Хезмәт яхшы гына бара. Әнигә әйт: тамагы тук, өсте бөтен, диген, борчылмасын. Хатны озын итеп язарга вакыт юк, бик каты хәрби уеннарга әзерләнәбез. Үзең язгалап тор, авылдагы хәлләрне әйтеп яз. Минем тормышлар шәп, сиңа барысын да язып бетереп булмый: хәрби сер, шуннан үзең аңла. Нәзирәгә миннән сәлам!»

* * *

Якшәмбе көнне яшь солдатлар казармада чуалырга яратмыйлар. Сәбәп табыпмы, сәбәпсезме — кайсы кая таеп бетә. Гадәттә, барысының да барыр юллары уртак: клуб яки чәйханә.

Клубта берәр төрле җыелыш яки кино булмаса, чәйханә белән кибет кала. Якшәмбе көнне «картлач»лар дембель альбомнары белән әвәрә килә, чәйханәгә барып мәшәкатьләнмиләр, кирәге чыкса, «әрвах»ларны йөгертәләр.

Чәйханә! Солдат өчен ул дөньядагы иң затлы рестораннардан да яхшырактыр.

Чәйханәнең ишеген ачып керәсең, борынга вафли, конфет яки бүтән төрле тәм-том исе килеп бәрелә. Авыздан сулар килә, йөрәк дөп-дөп итә. Бер шешә «Буратино» аласың, аннары бер кап печенье, коржик, стакан тутырып каймак, акчаңның җитәрлеген белсәң, янә йөз грамм ирис үлчәтәсең. Синең үкереп эшләп торган ашказаныңа болар гына аз булыр сыман тоела; киштәләр буенча тагын күз йөртеп чыгасың, аннан соң бүген белән генә көн бетмәгәнлеге исеңә төшә дә, тыелып каласың, акча кызганасың.

Бүген Карәхмәтнең дә, Дроздовның да акчада кайгылары юк иде. Бүген Панасенко яшәсен: ул өеннән егерме биш сум алды. Панасенко бүгенге көннең герое иде! Әүвәл киштәләрдә күренеп торган тәм-томның барысын да санап чыкты, буфетчы Серафима алып бирә торды, малайлар өстәлгә ташыдылар. Панасенко «Буратино»ны һәрберсенә икешәрне алдырды. Менә нишләтә дөнья: «гражданка»да чакта лимонад, печенье ише нәрсәләргә шәһәр малае әйләнеп тә карамагандыр, югыйсә. Бүген аларга күз салуга — авыз сулары кибеп, тел аңкауга ябыша.

Башта сөйләшмичә генә сыйландылар, аннары коры-сарыдан тәмам туеп, «Буратино» да кикертә башлагач, чәйнәү тизлеге акрынайды: әңгәмә башланды. Мондый сый-нигъмәт янында гаскәрнең кырыс тормышы да онытылыбрак торган шикелле.

— Гражданкада рестораннарда йөреп тә карадык соң! — дип куя Панасенко һәм ресторан дигәннәрен ишетеп кенә белгән сала малайларына үз шәһәрендәге һәр ресторанның исеменә кадәр атый-атый аларга характеристика биреп чыга.

Тегеләрнең күзләре Панасенкода, йотлыгып тыңлыйлар. Панасенконың гимнастеркасы каешланган, аз йоклаудан күз кабаклары кызарып тора, яңаклары сулган, сөякчел куллары бөтән беркайчан да чистармастыр кебек инде. Кайчандыр затлы рестораннарда йөргәнлегенә ышанып та бетәсе килми. Юктыр, булмагандыр ул андый хәл, дип тә уйлыйлар. Ләкин малай шул хәтле тәмләп, җентекләп сөйли, ялган түгелдер, түгелдер!

Өстәлдә тагын берәр шешә «Буратино»лары һәм коржиклары бар иде әле. Үзләре дә, күзләре дә туйды инде. Ләкин аларны монда калдырып булмый, жәл. Тагын ике-өч сәгатьтән исләренә төшәсен беләләр, шуңа күрә берәү дә кузгалып китәргә ашыкмады.

Кичке ашка да күп вакыт калмаган инде. Тик анда әллә ашап була, әллә юк — шайтан белсен. Рота өстәлләренә куелган чәйнекләрдәге чәй суынган булса, башкалар ашаган арада, поварларга ялына-ялына, кайнар чәй алып килергә туры килүе бар. Алар шулай әвәрә килеп йөргәндә рота тамак туйдырып та өлгерә. Үз өлешләренә тигән ботканы тиз-тиз генә капкалап, савыт-сабаны урыннарына илтеп куясы һәм, рота ашханә алдына тезелгәнче, чатыр чабып, кире урамга чыгасы бар...

Кайчакта «картлач»ларның күбесе кичке ашка йөрми дә. Аларга тиешле өлешне (гадәттә, кыздырылган балык, ипи, шикәр, флягага салынган кайнар чәй була) «әрвах»лар алып кайта.

Ашарга ташу дигәннән, «әрвах»лар үзара кат-кат бик яратып сөйли торган бер мәзәк хәл дә йөри.

Имеш, бер ротада аңгырарак кына бер «әрвах» булган, ди. «Картлач»ларга каршы сүз әйтү түгел, аларга күтәрелеп карарга да базмаган, ди. Ни кушсалар, шуны эшләгән, зарланмаган, карышмаган, командирларга әләкләмәгән. «Бозау» дип йөрткәннәр аны ротада. Аның шундый карусызлыгы, кирәгеннән артык юаш булуы «картлач»ларның үзләрен дә туйдырган, күрәсең, эчләре поша башлаган. Моны кызык итәргә уйлаганнар. Нишләгәннәр дисез? Әшәкелеккә килгәндә «картлач»ларның башы аеруча шәп эшли, теге йоклаганда берәрсе аның итекләре эченә кечкенә йомышын үтәгән һәм уятып кулына фляга тоттырганнар да ашханәгә чәйгә җибәргәннәр. «Әрвах» итекләрен киеп берни булмагандай чәйгә киткән. Бер көн шулай кабатланган бу, икенче көнне дә, тик сүз әйтмәгән, «ак» димәгән, «кара» димәгән, лач-лоч басып гел йөри биргән. «Әрвах»ның үшәнлеге тагын туйдырган «картлач»ларны. Чакырып китергәннәр дә сораганнар:

— Әйт әле, Вася, нигә шулхәтле үшән соң син? Без көн дә итек эчләреңне юешләп сине чәйгә җибәрәбез, ник дәшмисең, бер сүз дә әйтмисең? — дигәннәр.

Тегесе озак уйлап тормаган:

— Ә сез зарланмыйсыз, сүз әйтмисез ич әле,— дигән.

— Без нигә зарланырга тиеш соң? — дип аптырашкан тегеләр.

— Мин урамга чыгуга ук, итек эчен флягага бушатып, шуңа чәй салып кайтам...— дигән «әрвах».

Шул мәзәкне ишеткәч, «әрвах»лар күзләреннән яшь атылып чыкканчы тәгәри-тәгәри көләләр. Кем катырак көлә, шул «картлач»лардан үч алам, мәзәк белән булса да тегеләргә тибеп алам дип уйлый.

Хәзер һәммәсенең дә үз «картлач»ы бар. Дөресрәге, «картлач»ларның бары тик үзләренеке генә булган, үз йомышларын гына үти торган «әрвах»лары бар.

Салоның «картлач»ы — Рубевский. Сало аңа ашханәдән ризык ташый, аның киемнәрен юа, аның өчен төннәрен дневальный тумбочкасы янында тора, иртән карават кырыена сызык суга.

Панасенко сержант Михайловка хезмәт итә. Карәхмәтне моңарчы Манатов бил бөктерергә тырышкан иде. Моннан соң ничек булыр? Манатов әлегә аңа сүз әйтми әйтүен. Әмма...

Кичә полигоннан кайткач, Ильин ротаны кәнсә алдына тезде. Яхшы атканы өчен Карәхмәткә рәхмәт белдерде. Манатовны эттән эткә алып сүкте командир. «Әгәр яшь солдатларны кыерсытсагыз, карагыз аны!» — дип, «картлач»ларга кисәтү дә ясады.

Шул кичне ялагай Сало Карәхмәтне кием киптерү бүлмәсенә чакыруларын килеп әйтте. Моны сержант Иванов та ишетеп торган икән. Ул Карәхмәткә урыныннан да кузгалмаска кушып, үзе китте. Карәхмәтне кем чакырганлыгы мәгълүм иде.

Дроздов киемнәр киптерү бүлмәсендәге сөйләшүне ишетеп торган.

— Мантана! Ул малайга тагын кул тидерсәң, гаепкә алыштан булмасын! — дигән Иванов.

— Оныттың мыни?! Онытгың дамыни «әрвах» вакытта үзеңнең ничек йөргәнеңне?!! Шкаф хәтле гәүдәң була торып, «картлач»ларның итек астында аунаганыңны оныттың дамыни?! Кем төннәр буе унитаз ялтыратты соң? Оныттың да мыни инде? Ай-һай, бик тиз! Шул маңканы яклап торган буласың тагын!

— Төкерәм «әрвах»ларыңа! Әмма шулар белән ротада берәр «ЧП» ясап кара син! Сөйләшербез аннары! Әгәр дә синең аркада минем «дембель»не бер көнгә, бер генә сәгатькә озайталар икән, сөйләшермен мин синең белән! — дигән аңа үзенең өйгә кайтыр көнен дүрт күз белән көткән, хатынын, кечкенә малаен төшләрендә күреп саташкан студент Василий Иванов.

Рота командиры кулында өлкән солдатлардан үч алуның бик тә нәтиҗәле ысулы бар: ачуы килсә, аларны өйләренә иң соңыннан, адәм актыгыннан кайтарып җибәрә ул. Киләсе приказдан соң «дембель» булачак «картлач»ларга моның тәэсире бик тә, бик тә зур.

Панасенко «картлач»ларның холкына акрынлап ияләнеп, күнегеп бара бугай инде. Ярты ел хезмәт иткәннән соң, мәнә көзге тикшерүләрдә үзен күрсәтә дә алса, рота командиры «ефрейтор» итәбез диде. Аннары бәлкем сержант ук та булып куяр әле.

Шул фоторәсемен эти-әнисенә дә, йөргән кызларына да җибәрер. Дөрес, теге мәзәктәге чәйгә йөргән мескен солдат хәленә төшәсе дә килми. Тик мәнә иртәнге физзарядкада алты чакрымга йөгерүләре үзәккә үтә шул. Йөгерә алса, бәлкем, Рубевский әйткән һәр сүзгә «баш өсте» дип тормас иде дә.

Көн дә, иртән торуга, рота алты чакрымга кросс йөгерә. «Әрвах»лар да, «чүмеч»ләр дә, «картлач»лар да чаба. Панасенконың иң яратмаганы әнә шул инде. Юлның яртысын үтүгә, күз аллары караңгылана, йөрәге тасырдый башлый, аякларына гер аскандай була. Ул, гадәттә, ярты юлда ук егылып кала. Разведротада «сыек» солдат булырга тиеш түгел дигән «картлач»лар аның бу гамәлен һич тә өнәмиләр. Ротадан аерылып, юл читендә егылып хәл җыеп яткан Панасенконы берәрсе якасыннан күтәреп торгыза да кулындагы каешы белән аны алга куа. Панасенко бераз бара да тагын сөртенә, тагын күтәреп торгызалар, тагын. Аркасында, арт санында каеш эзләре ярылып кала.

Шулай булгач, «картлач»ларга каршы авыз ача алмыйсың шул. Кросста йөгерә алмагач, йомышка чабарга туры килә.

Дроздовның исә бүген төне буе дневальный тумбочкасы янында басып торасы бар. Югыйсә, үз чираты кичә үк узды инде. Кичә ул үзе дневальный иде. Таңга кадәр керфек тә какмыйча бәдрәфне, юынгыч бүлмәсен ялтыратты, кызыл почмак идәнен юды.

Бүген дневальный булып Рубевский тора. Кич белән Сало аның өчен разводка барып кайткан иде инде. Төнге эшләр Дроздовка йөкләнде.

Ярый, түзәр әле. Бер елдан соң аның өчен дә кемдер идән юачак бит. Күңел әнә шуны көтеп яши. Шулай да ул: «Әгәр Мантана Карәхмәткә тагын бәйләнә башласа, яклап чыкмыйча булмас. Үзе татар булса да, яхшы малай»,— дип тә уйлый.

* * *

Ротаның ничек атканын үз күзләре белән күргәннән соң Ильинның кәефе кырылды. Бар үчне дә өлкән солдатлардан алырга уйлаган иде. Өлкән лейтенант Швалюк тагын бер мәртәбә күңеленә шик салды. Кәнсәдә алардан тыш Данилов та бар иде. Мондый сөйләшү булды:

— Койрыкларына басам мин ул сөрхәнтәйләрнең! — дигән иде Ильин. Тәрәзә янында урамга карап торган Данилов:

— Иван Григорьевич, безнең ротада атмосфера бер дә сәламәт түгел, күңелем сизә, яхшылыкка алып бармас бу,— дип куйды. Сүзгә Швалюк кушылды:

— Алайса бар, штаб башлыгына барып әйт бу турыда, шулай-шулай, диген.

Бу сүзләр рота командирына ошамады.

— Швалюк, ә нигә штаб башлыгына йөгерергә! Син монда ни өчен куелган? Син монда нәрсәгә?

— Иван Григорьевич, иптәш өлкән лейтенант, мин яшьләрне кыерсытуга юл куйыйк димим бит! Көзге тикшерү борын төбендә генә. Хәзер без Рубевскийларга, Михайловларга каныга башласак...

— Һәм Манатовларга! — дип бүлдерде аны Данилов.

— Әйе, без шуларга каныга башласак, сынауларны ничек тапшырып чыгарбыз? Мин шул турыда уйлыйм. Аннары бөтен ротаны адәм мәсхәрәсе итеп сөйләячәкләр бит. Аннан соң Коваль күзебезне дә ачырмаячак. Менә шул турыда уйлыйм бит мин.

Рота командиры:

— Син, Швалюк, кайчаннан бирле бөтен рота турында да кайгырта башладың әле? Әүвәл взводың хакында уйла, син взвод командиры бит,— дип төрттерде.

— Бусы инде, иптәш өлкән лейтенант, артыграк...

— Йә, йә, ярый, шаяртканны аңла.

Данилов тәрәзәгә арты белән әйләнеп басты.

— Ул кешеләр, ул егетләр, армиядә бары ике ел гына булалар. Шунысын онытмыйк. Аннары алар «гражданка» кешеләре. Аннары үз тормышлары белән яши башлаячаклар. Кемнеңдер типкәсендә йөргән солдат ике елдан соң ничек итеп сөйгән кызының йөзенә күтәрелеп карый алсын?! Шул якларын да уйларга кирәк, минемчә.

— Бу инде синеңчә түгел, китапча, китапта язылган кызыл сүзләр сөйлисең син, Андрюша,— диде Швалюк көлемсерәп.

— Их, Толя, хет китапта язылган буенча гына да уйласаң иде әле син! Бәлкем синнән шәп офицер да чыккан булыр иде.

Швалюк тагын көлемсерәп кенә куйды.

— Ярый, Андрей, артык тәнкыйтьчегә әверелеп китәсең тагын. Әйттем ич инде: мин «дедовщина» яклы түгел дидем. Ләкин бераз мондагы шартларны да чамаларга кирәк, дустым. Шул ук Мана-

товны алыйк. Менә дигән солдат ул. Техниканы биш бармагы кебек белә, «Совет Армиясе отличнигы!» Коеп куйган рәссам да әле. Ә ул менә моннан бер ел элек ничек яшәгән дип уйлыйсың? «Картлач»лар өстеннән килеп зарланмады бит. Тыныч кына хезмәт итеп йөрде, хәрби осталыгын арттырды, менә дигән танкист булып җитеште. Йә, нәрсә әйтеп була аңа?

— Теге өч егет Әфганстанга шул Манатов аркасында гына китте. Үзләрен монда кеше итеп тоярга ирек бирмәде ул аларга.

— Китсәләр ни?! Кемдер барырга тиештер ич ул Әфганстанга да. Мин уйлап чыгармаган ич ул Әфганстанны! Партия чакырды...

— Һы, чакырды шул.

— Шулай булгач! — диде Швалюк, үзенең җиңүен белдергәндәй ике кулын да югары күтәреп.

Ильин да телгә килде:

— Йә ярый, иптәш офицерлар, туктатыгыз бу бәхәсне. Күзге тикшерүләр җитсен, үтсен, аннан соң күз күрер, карарбыз. Шулай да син, Швалюк, взводыңдагы солдатларыңны узындырма. Синекеләр бик сикерә бугай анда. Югыйсә берәр «ЧП» килеп чыкса, рота командиры урыныннан ничек колак какканыңны да сизми калырсың.

Швалюк тагын көлемсерәп кенә куйды...

* * *

Манатов Салоны инде икенче тапкыр почтага җибәрде. Тегесе тагын буш кул белән кайтты. Инде икенче ай Наташадан хат килми иде.

Бу юлы ул почтага үзе китте. Почтаны батальоннан бер яшь солдат ташый иде. Солдат боткасын капмас борын кем аны шундый җиңел урынга урнаштыргандыр, үзен нәкъ «гражданка»дагыча тота. Бәхете, разведротада саналмый ул «әрвах». Югыйсә, хәрби хезмәтнең ни икәнен күрсәткән булырлар иде аңа!

Манатовның борчылуы урынлы, бик тә урынлы иде, чөнки ел ярымнан артык бер дә калмыйча атна саен хат яза торган Наташадан хәбәр юклыкка инде ике ай.

Бер елга чаклы Александр да хатларны еш язды. Аннары хәрби тормыш җиңеләя башлагач, хат язулар ирендерә башладымы, аңа дигән хатны «әрвах»лардан яздыра.

Бер кирегә китсә китә бит ул дөнья! Җитмәсә, матур гына яшәп ятканда, теге «әрвах» белән әллә нәрсә килеп чыкты! Кара син аны, ә! Хәчтерүш! «Картлач» хәтле «картлач»ка кул күтәреп маташа. «Бетте, тормыш булмаячак сиңа мин кайтып киткәнче!» — дип теш кайрады Манатов Карәхмәт Әмирхановка. Үз алдына гайрәтләнде, Әмирхановны нинди җәзага тартачагын да кат-кат уйлады. Тик аны әлегесен бер нәрсә шикләндерә, сагайтып тора. Татарны беренче күрүе аның. Ишеткәне бар барын. Тарих китабында рәсемнәрен дә күргәне бар. Атка атланган, кылыч-сөңге белән коралланган, кысык күзле, камыт аяклы куркыныч кешеләр.

Әйе... ике йөз ел буе юктан гына ярты дөньяны буйсындырып тормаганнардыр! Бу Әмирхановлары кыяфәте белән тарих китабындагы рәсемгә төшерелгән кысык күзле татарга охшамаса да, барыбер чаманы югалтмаска кирәктер?!

Үзенә сәеррәк караш булганын Карәхмәт тә сизенә иде. Әмма йөзенә туры карап мыскыл итүче табылса да, әллә ни кыра алмас иде егет, чөнки кайдан белсен ди ул чын дөресен?! Мәктәптә үк шуны тукыдылар бит аңа! Әгәр белсә: «Мин татар-монгол калдыгы түгел, түгел!» — диясе килер иде аның. Тик моңа каршы дәлил таба алмаудан гаҗизләнеп, язмышына буйсынып, шуңа күнәр иде.

һәм әле татар-монгол варисы булуын үз-үзен сакларга кирәк чакта калкан итеп тә файдаланыр. Тиеп кенә, кагылып кына карагыз янәсе бу татарга!..

Ләкин аңа карап тормадылар: кагылдылар Карәхмәткә, кием киптерү бүлмәсенә алып кереп, Рубевский, Манатов һәм Михайлов өчәүләшеп тукмадылар.

Тагын да шул ук Сало аша чакырттырдылар. Иванов юк чак иде. Карәхмәт иреннәрен чәйни-чәйни киемнәр киптерү бүлмәсенә китте. Рубевский Манатовны сүгеп маташа иде. Карәхмәт ишек янында туктап калды.

— Синең аркада, Мантана, «картлач»ларның ротада дәрәҗәсе төшә. Нигә син шул салагага кул күтәртеп тордың? — ди Рубевский. Манатовның бары тик сүгенгән тавышы гына ишетелә. Карәхмәтне күрүгә, ул аның өстенә ташланды, Рубевский белән Михайлов ярдәмгә килделәр. Карәхмәт бары:

— Йөзенә сукмагыз, йөзенә! — дигән тавышларны гына ишетте. Булдыра алганча, хәленнән килгәнчә, рәхимсез йодрыклардан йөзен, эчен сакларга тырышты. Ни гаҗәп: бу юлы аңарда каршы тору теләге уянмады, бары сакланды, сакланды гына...

Күңелләре булгач, Сало белән Дроздовны чакыртып, Карәхмәтнең башын су краны астына тыгарга куштылар. Карәхмәт буйсынды, иреннәре дә ачудан түгел, бары авыртудан гына кысылды бугай. Йа! Бу язмышка күнегә баруы, шушы хәлләргә ризалашуы түгелме соң?!!

Кич белән Панасенко килеп Карәхмәткә:

— Сине Мантана чакыра,— диде.

Карәхмәт иреннәрен тешләде. Мантана үзенең түрдәге койкасында сузылып ята иде.

— Әйдә, Ваня, бергәләп каршы торыйк әле шуларга,— дип пышылдады Карәхмәт. Панасенконың күзләре зур булып ачылды, берәрсе тыңлап тормыймы икән дигәндәй, ялт-йолт як-ягына каранды һәм акрын гына:

— Син нәрсә? Башың бетәр,— дип куйды.

Карәхмәт аңа кулын селтәп Мантана янына китте.

— Нәрсә? — диде ул, килә-килешкә. Күңеле тагын этлек көтә иде.

— Нәрсә булсын, аркага массаж яса!

— Массаж ясый белмим мин.

— Алайса Салоны алып кил. Ул өйрәтер.

Карәхмәт Салоны эзләп китте. Сало каптеркада кайнаша иде.

— Сине Мантана чакырды.

Сало аңа нидер әйтергә теләгән иде, әмма дәшмәде, эченнән генә: «Ник карышасың шул «картлач»ларга, Карәхмәт? Кирәкми, түз, түз, дустым. Килер бер көн, без дә король булып яшәрбез әле»,— дип уйлый-уйлый Мантана янына чапты.

Армиягә кадәр массаж ясый белгәндерме, юктырмы, Салоның бу эшкә хәзер куллары ябышып тора иде. Ул аның әлифбасын Карәхмәткә дә күрсәтеп бирде. Шулчак казармага рота командиры килеп керде. Карәхмәт җиңел сулыш алды. «Барыбер ясамаган булыр идем»,— дип уйлады ул.

* * *

Поезд «пу-у-у-ууу!» — дип сигнал бирде дә тизлеген киметә башлады. Өлкән лейтенант Швалюк проводник купесыннан чыгып Карәхмәттән: «Ничек, тәртипме?» — дип сорады да, Серафиманы ялгыз калдырасы килмичәме, тагын аның янына кереп бикләнде.

Моңарчы андый уйның килгәне юк иде: бүген Серафиманы үз хатыны белән чагыштырып карады ул. Серафима чибәрлеккә Василисадан бераз калышса да, бик сөйкемле иде. Йомры, тыгыз гәүдәсе, калку күкрәкләре, сихер иңгән зәп-зәңгәр күзләре бер генә ир-атны да битараф калдырмастыр. Серафима бу дөньяга яратыр һәм яратылыр өчен генә туган гүзәл зат кебек. Ни генә әйтсәң дә, сиңа елмаю белән генә җавап бирә торган хатын бүген ничектер башка төслерәк. Анатолийның күзләренә туры карарга оялган шикелле, үзенең зәңгәр карашларын тырыша-тырыша яшерә. Әмма ул бүген башка көннәрдәгегә караганда бик күпкә назлырак, әйтерсең, күңелендә булган бар назын да Анатолийга багышлаган иде.

Серафиманың зәңгәр күзләрендә сагыш төсмерләре дә чагылып киткәндәй.

— Толя,— ди ул нәрсәдер әйтергә җыенгандай һәм кинәт туктап кала. Швалюк аның йөзенә текәлә.

— Әйе.

— Толя, син мине яратасыңмы?

— Сима, нәрсә булды сиңа, үзең дә яхшы беләсең ич инде.

— Юк, син тагын бер мәртәбә әйт.

— Билгеле, яратам.

— Бик каты яратасыңмы?

— Бик каты, Сима, бик каты.

— Алайса ник өйләнмисең миңа?

— Ничек? Бар бит инде берәү.

— Аны аерып җибәр.

— Ярый, Сима, алай бәйләнмә әле, мин сине яратам лабаса, бик каты яратам.

Өлкән лейтенант хатынны үзенә табарак тарта.

— Әйдә, ятыйк инде.

Серафиманың күзләрендә көмештәй яшь бөртекләре. Ул Швалюкның сүзләренә каршы килми, инде бая ук җәелгән урынны кулы белән сыпырып, тигезләп куя да, башка вакыттагы кебек оялып, тартынып тормыйча, ир каршында чишенә башлый. Әүвәл юлда кия торган спорт формасының йозагын төшерә, аннары җиңел хәрәкәт белән генә калку күкрәкләрен тартып торган элмәкне чишә, спорт костюмын сала. Швалюк урыныннан күтәрелеп Серафимага таба тартыла һәм аның күкрәкләре арасына борынын төртеп кайнар пышылдый:

— Гүзәлем минем, фәрештәм...

Серафима Анатолийга әйтергә теләгән серен тагын күңеленә бикләп куя. Сер бүген дә аның үзенеке генә булып кала.

Вагон бала бишегедәй акрын гына, җайга гына тирбәлә дә тирбәлә. Бүтән беркайда да, беркайчан да туктамас кебек бу поезд...

* * *

Ә сер Серафиманың үзенеке генә түгел иде, түгел иде...

Туган көненә кунаклар чакырмаска булды Василиса. Елга бер килә торган бәйрәмендә кеше көен көйләп йөрергә теләмәде. Өлкән лейтенанты белән икесе кара-каршы утырып кына үткәрсеннәр әле туган көнен.

Киләсе кешесе булмаса да, хатын табынны мул итеп әзерләде. Бәйрәм табынын әзерләргә ярата ул. Шуннан тәм таба, җиренә җиткереп, зәвык белән табын ясый белә.

Аның иң бәхетле чагы бәйрәм көннәрендә, ул көнне хатын тагын да гүзәлерәк, чәчәктән-чәчәккә кунып очкан болын күбәләге шикелле хис итә үзен.

Туган көнне икесе генә үткәрергә дигән фикерне өлкән лейтенанты да хуплады. Кунак чакыру кебек мәшәкатьне үзе дә өнәп бетерми Анатолий, шундый гүзәл хатыны белән икәүдән-икәү генә бәйрәм итүне ул да бик мәслихәт күрә.

Хатынның эчемлектән исереп, канатланып, очынып биегәнен күрмәгәненә инде шактый, хатынын шундый чагында яратмаганына да күптән.

Ләкин ул көнне Швалюкның да, Василиса Руслановнаның да башларына күсәк белән суккандай булды: өлкән лейтенантын Минскидагы хәрби комендатурага бер тәүлеккә каравыл башлыгы итеп җибәрделәр.

Разведрота белән каравыл башлыгы булып лейтенант Данилов барырга тиеш иде. Ләкин аны ашыгыч рәвештә округ газетасыннан чакырып алганнар.

Озакламый кайтып җитәрмен, дип чыгып киткән иде Швалюк өеннән. Бригадага барса, шундый хәл икән. Аптырап, каушап калган өлкән лейтенант үзенең хәлен аңлатырга керешкән иде, штаб башлыгы хәтта гадәттәгечә җикеренмәде дә, тыныч кына итеп:

— Рота командиры буласың килмәсә, барма,— дип кенә куйды.

Каравылны Минскига илтүче дежур машина КППдан чыгып барышлый шунда нарядта торган Манатовка:

— Нарядтан соң посыльной жетоны алып өйгә барып әйт, мине каравылга китте диген! — дип кычкырды өлкән лейтенант.

Манатов, нарядны тапшыруга, шәһәрчеккә юнәлде.

Инде тәмам әзерләнеп бетеп, табын янына утырырга өлкән лейтенантын гына көткән Василиса, ишек кыңгыравын ишеткәч, әүвәл каушап калды, аннары йөзендә елмаю кабынды: Толясы ишекне үз ачкычы белән ачмыйча, хатыныннан ачтырып, тантаналы рәвештә керергә чамалый, мөгаен.

Ләкин ишек төбендә иренең солдаты басып тора иде.

— Исәнмесез! — диде егет.— Иптәш өлкән лейтенант...

Манатов сүзен әйтеп бетерә алмады, бәйрәмгә әзерләнгән табынны һәм хатынның гадәттән тыш матур кыяфәтен күреп, каушабрак калды.

— Толя кайда? — дип сорады Василиса түземсезләнеп.

— Иптәш өлкән лейтенант... ни... әйтергә кушты... ул гарнизон гауптвахтасына, Минскига китте, каравылга. Даниловны чакыртып алганнар.

— Каравыл? Минскига?!

Хатынның матур күзләре зур булып ачылдылар, нәфис борыны тирләп чыкты, кыйгач кашлары сикереп-сикереп алды.

— Сволочь! — дип кычкырды ул әллә нинди ят тавыш белән һәм Манатовның борын төбендә генә ишекне шапылдатып ябып та куйды. Стенадагы Манатов ясаган өрәңге яфраклары идәнгә коелып төшкәндәй булды. Ул бермәл фикерләрен җыя алмыйча торды: «Сволочь! Нишләп мин сволочь соң әле?» Аннары бу сүзнең үзенә түгел, командирына әйтелгәнлеген төшенгәндәй булып, акрын гына борылды да баскычка таба атлады. «Нигә сволочь соң әле Швалюк? Ни булган?» — дип уйлады ул, әлеге табышмакны чишәргә азапланып.

Ишек янә ачылды. Идәндә бая «коелган» яфрак-бизәкләр кыштырдап куйгандай булды. Манатов артына борылып карады. Василисаның бит алмасы буйлап яшь бөртекләре тәгәри иде.

— Бүген туган көнем. Кер әйдә, Шура! — диде хатын. Тавышына үтенү белән бергә әмер дә катнашкан сыман.

«Синең туган көнеңдә минем ни эшем бар соң? Мин үз бурычымны үтәдем инде, хәзер менә китеп барам...»

— Әйдә, әйдә, Шура!

Манатов әллә әмергә, әллә гүзәллеккә буйсынды — өйгә керде.

— Уз, уз! Тартынма. Беркем дә юк монда.

Табындагы сый-нигъмәтләргә таба никадәр генә карамаска тырышса да, Манатовның солдат боткасыннан гайре берни күрмәгән ашказаны, татлы һәм ләззәтле эшкә үзенең әзерлеген белдергәндәй, тавышланып богырдап куйды. Ашказанының мондый әдәпсезлегеннән оялган солдат, гүзәл хатынның мыскыллы йөзен күрмәс өчен, итек салу сылтавы белән, аска иелде. Ул бөгелгәч, эчтәге һава янә кысылып, ашказаны тагын тавыш бирел алды.

Бәхетенә, Василиса кухняга чыгып киткән иде. Манатов өч мәртәбә ачу белән эченә сугып алды. Богырдау тынды.

Өлкән лейтенантның нигә «сволочь» икәнлеге аңлашыла башлаган иде Манатовка. «Ярый, Швалюк түзәр. Гражданка ризыклары белән бер сыйланып алу миңа да ярар»,— дип иреннәрен ялмап алды солдат.

Василиса сый-нигъмәтләре янына коньяк китереп утырты һәм:

— Кил әле, утыр әле,— дип сөйләнә-сөйләнә солдатны өстәл янына чакырды. Аннан соң капылт кына нидер исенә төшкәндәй:

— Хәзер, хәзер, Шура, син утыра тор. Мин тиз генә бер җиргә генә барып килим.— диде дә, өстенә плащын салып, ишектән чыгып китте.

Солдатның сүзләренә ышанса да, Василисаның күңелендә барыбер шик бар иде, ул үз күзләре белән күреп инанырга теләде. Иренең буфетчы Серафимага битараф түгеллеген сиздергәннәр иде аңа. Беркөнне кибеттә очрагач, рота командиры Ильинның хатыны шулай дип пышылдады. Василиса ышанмаган иде, рота командирының ирендә берәр үче бардыр дип кенә уйлады.

Хатын Серафима яшәгән йортка таба томырылды. Ул буфетчының кайда яшәгәнен чамалый иде, фатирын да бик тиз эзләп тапты һәм кире урамга чыгып, агач астына сыенды да Серафиманың тәрәзәсенә төбәлде. Тәрәзәдә ут юк, Серафима эштән кайтмаган иде, ахрысы. Василиса, тынычланып, борылды да өенә таба атлады. Үз артыннан икенче бер кеше ияргәнен сизмәде Василиса. Серафиманың үзен бик яхшы таныганын да белми иде ул.

Василиса Манатовка булары чыгып торган кайнар аш салып килде һәм үзе дә утырды. Тегесе, вакытны бушка уздырудан файда булмас дип, солдат ашханәсендәге кебек шупырдамаска тырышып, эшкә керешә. Василисага таба күтәрелеп карарга кыймады, ач бүредәй ашыйсы килүеннән оялды. Василиса ризыкларга орынмады, башын иеп аш соскан солдатны күзәтеп утырды. Шул хәтле дә якын, үз булып тоелды аңа бу солдат, хатын үзен ана итеп хис иткәндәй булды. Менә аның баласы ачыгып кайткан да әнисе пешергән ашны ашап утыра, ашау белән шулкадәр мавыккан, әнисенә күтәрелеп карарга да вакыты юк, бары ике колагы гына селкенгәләп ала.

Василиса үзалдына көлемсерәп куйды. Менә бу солдат урынында аның өлкән лейтенанты утыра, ди. Эштән арып кайткан, сүзсез генә ашый. «Юк, Швалюк болай ашамый, аның ашавы ирләрнеке кебек тә түгел, ашаганда тавыш-тынын чыгармый ул. Җиренә җиткереп кенә, рәвешенә китереп кенә ашый. «Культурный» итеп. «Их, Швалюк та шулай шупырдаган тавыш чыгарып ашый белсен иде ул! Менә бу солдат шикелле...»

Манатов нихәтле генә тавыш чыгармаска тырышса да, булмады, никадәр акрын ашарга тырышса да, тәлинкә төбе мизгел эчендә ялтырап калды.

Василиса коньяк шешәсен Манатовка таба этте?

— Ач әле, туган көндә берәүгә дә гаебе булмас.

Манатов бераз иләшә башлаган иде. Карусыз гына коньяк шешәсенә үрелде һәм бөкесен гадәт буенча теш белән ачарга дип, авызына китерде. Аның һәр хәрәкәтен күзәтеп утырган Василиса:

— Чу! Тукта! Мә! — дип пычак суздЫ.

Манатов колакларына кадәр комачтай булып кызарынды һәм ул үзен-үзе әрләде. Үзен эченнән әрли-әрли рюмкаларга эчемлек агызды, үзен әрли-әрли, Василиса белән чәкештереп, эчеп тә җибәрде.

Василиса да рюмкасын төбенә хәтле бушатып куйды һәм, шоколад тешли-тешли, тагын шешәгә үрелде. Инде бу юлы Манатовка кушып тормады, үзе салды да янә эчәргә тәкъдим итте. Шулай бербер артлы өчәр рюмка эчтеләр.

Манатов җиңелчә генә башы әйләнүен тойды һәм моннан тизрәк китәргә кирәк дигән уй аны урыныннан торгызды.

— Мин кайтыйм инде, рәхмәт сезгә, Василиса Руслановна!

Эчемлек тәэсиреннән оеп китә башлаган хатын, уянып киткәндәй, җәһәт кенә торып басты:

— Юк, юк, тукта, ашыкма! Минем үземә генә күңелсез.

Аннары шкаф алдында торган проигрывательне кабызды.

— Миңа кайтырга кирәк, Василиса Руслановна.

— Юк, юк, хәзер минә бер биеп тә алыйк инде!

Манатов кире урынына утырды. Хатын бию рәвешен китереп, бүлмә буенча бер-ике очып әйләнде дә почмактагы диванга барып сыланды.

Күлмәк итәге тартылып, йомры тез башлары ачылды. Ул кулларын ике якка сузып җибәрде һәм, башын чак кына артка ташлап, озын кара керфекләрен йомды. Күлмәгенең изүләре ачылып, ялангач тәненнән сирпелгән яктылык, түшәмдәге люстраның да нурларын басып китеп, Манатовның күзләрен чагылдырды.

— Гафу ит, Шура, бераз исердем, ахры,— диде хатын назлы тавыш белән.

Солдат ниндидер эчке боеруга буйсынгандай, урыныннан торды да хатынга таба сак кына адым ясады.

«Нишләвең бу Мантана! Башыңны үзең бетерәсең ләбаса! Мантана!» Миенең эчемлек тәэсире барып җитәргә өлгермәгән күзәнәкләре әнә шулай дип тәкрарладылар.

Манатов, капылт кына борылды да кызу-кызу атлап кухняга кереп китте, кранны ачып, чүмечкә салкын су агызды да бер сулышта эчеп тә бетерде. Бераз суынды шикелле. Аннары кире Василиса утырган бүлмәгә чыкты. Хатынның күлмәк итәкләре тагын да катырак тартылган һәм ап-ак, шәп-шәрә аягы бөтен матурлыгы белән күренә иде.

Солдат үзендә булган бар көчен җыеп:

— Миңа китәргә вакыт, Василиса Руслановна. Рәхмәт сезгә!— диде.

Хатынның озын кара керфекләре ике якка аерылды. Ул аз гына башын күтәрә төшеп:

— Әйдә, тагы бераз эчик тә,— диде һәм бер кулы белән кирәгеннән артык күтәрелгән итәген аска таба тартты да, кулын кире алганда, итәк баягысыннан да күбрәк күтәрелде. Манатов чатырдатып күзләрен йомды. Каяндыр, ерактан, тирән караңгылыктан:

— Әйдә, Шура, эчик! — дигән тавыш килде. Чәкештерделәр. Василиса күзләрен йомып эчемлекне йотты. Аннары, үрелеп өстәлгә куйыйм дигәндә, кулындагы рюмкасы төшеп китте. Манатов солдатларча бирелгәнлек белән рюмканы алырга дип Василисаның аяк астына ташланды.

«Түзә алмыйм мин бүтән, түзә алмыйм. Кичер мине, Василиса, кичерә күр!»

Үзе: «Кит» дия күрмә, әйтә күрмә, зинһар»,— дип, хатынның йомык күзләренә текәлде. Хатын дәшмәде, ул йоклаган кебек иде. Манатовның түземлеге төкәнде, ул Василисаның кулын тотып, шаша-

шаша үбәргә кирәкте. Хатын селкенмәде дә!

Манатов, каршылык күрмәгәч, кул үбү белән генә канәгатьләнмичә, астан өскә таба хатынның күлмәк төймәләрен чишәргә тотынды. Бирсен чишә, икенчесенә үрелгәндә, куллары тагын да катырак дерелдәде, чишә алмыйча азапланды, онытылып китеп, теше белән тартып өзәргә дип талпынганда гына Василиса пырхылдап көлеп җибәрде.

Манатовның табан астына утлы шарлар тәгәрәде.

— Төймәне өзәсең бит,— диде Василиса, баягыдан да назлырак тавыш белән һәм, Манатовның кулын читкә этәреп, күлмәк төймәләрен өстән аска таба үзе чишә башлады. Манатовның колагында черт-черт иткән тавышлар гына ишетелде, аннары тар ояга гына сыя алмыйча бөселеп чыккан ап-ак күкрәкләрне күрүгә, күзе чагылып, сукырайгандай булды һәм, өнемме бу, төшеммe, дигән кебек кулын сузды да, өн икәненә тәмам ышанып җиткәндә генә, һуштан язды.

«Уф! Дөньяда шундый рәхәтлек тә булса булыр икән!» — дип пышылдады ул. «Гафу итәрсең инде мине, зинһар, иптәш өлкән лейтенант!»

Гүзәл хатынның кайнар сулышы рядовой Александр Манатовның аңын эретте...

Василиса Руслановна, хатын-кыз буларак, иреннән әнә шулай туган көн үчен алды...

Өлкән лейтенантның фатирында ни хәтле рәхәт булса да, Манатовка бригадага кайтырга кирәк иде. Ул тиз-тиз генә киенде дә әле һаман да диванда назланып яткан хатын янына килеп кыяр-кыймас кына:

— Гафу итә күрегез инде, Василиса Руслановна,— дип пышылдады. Хатын, бер кулы белән үрелеп, аны үзенә таба тартты да башыннан сыйпады:

— Ярый, солдат, бар кайт инде, начар итеп искә алмассың мине,— диде.

Әле генә кичергән ләззәтле минутлар өлкән лейтенант фатирында бикләнеп калды. Манатовның уйлары яңадан үзе яшәгән дөньяга кайтты. «Нинди төш булды соң бу?» — дип сөйләнде ул үзалдына һәм, шул «төшне» янә бер мәртәбә күңеле аша уздырырга теләгәндәй, артына борылып карады: Василиса Руслановнаның тәрәзәсендә ут балкый иде. Манатов, туктап бер мәл якты тәрәзәдән күзен дә алмыйча карап торды да, кызу-кызу атлап китеп барды.

Итек дагасының асфальтка тиеп чак-чак иткән тавышы аңындагы томаннарны сыеклап җибәрде, үз адымнарының тавышы бар дөньяга да ишетелеп торадыр сыман тоелды. Ул газонга сикерде. Аяк тавышларын ярсып-ярсып типкән йөрәк дөпелдәве алыштырды.

Юл кырыенда рәт-рәт булып тезелгән баганалардагы лампочка утлары, аны әзәрлекләгән кебек, яктылык сиптеләр.

Бригадага кайтып җитәм дигәндә генә аның каршысына патруль килеп чыкты. КПП күренгәч, күңеленә беркадәр тынычлык иңә башлаган солдат, өлкән лейтенант фатирында калган әкияти дөнья турында уйларга керешеп, уяулыгын югалтты: офицер белән солдатларны күрми калды.

Шәһәрчекнең бер өендә калган ләззәт тә, коньяк пары да әле һаман үз көченда иде, патруль башлыгының:

— Кайдан киләсең, солдат? — дигән соравы аны тәмам куыштатып, теленнән яздырды. Патруль башлыгы солдатның каршысына ук килеп басты һәм куркуыннан еш-еш сулаган Манатов авызыннан килгән ят истән иманеп китте.

— Хәрби билетың!

Манатов хәрби билет урынына посыльный жетонын сузды.

— Посыльной мин, иптәш капитан!

Капитан жетонга күз дә салып тормады, тагын:

— Хәрби билет! — дип боерды.

Манатов каршы тора алмады, хәрби билет артыннан, патруль башлыгы җәһәт кенә Манатовның бил каешын салдырып алды да күршедәге разведчиклар батальонына алып кереп китте.

Манатовны «гөнаһлы» тагын дүрт солдат белән гарнизон гауптвахтасына алып киттеләр.

Гауптвахтада каравыл начальнигы булып өлкән лейтенант Швалюк торуы исенә төшкәч, Манатовның борыныннан шаулап кан китте...

* * *

Бу поезд бер дә туктый белми, ахрысы. Тәгәрмәчләре һаман такы-токы килә, вагон һаман тирбәлә дә тирбәлә.

Мәскәүгә китәр алдыннан Карәхмәткә Йосыфтан хат килгән иде. Ул куен кесәсендәге хатны тагын кулына алды. Йосыф авыл хәлләрен язган-язган да, аннары хатының ахырында гына: «Карәхмәт абый, беләсеңме, Нәзирәнең аяклары турайды бит! — дигән. Имеш, бу күренешкә иң элек «Тас хәбәрчесе»нең күзе төшкән. «Һай, балакай, ике авыл арасында хат ташып йөреп аякларың турайган бит!» — дигән Хупҗамал карчык.

Нәзирә бу хәлгә әүвәл үзе дә ышанмаган, почтасын өләшеп бетергәч, тиз генә өенә кайткан да урындыкка басып көзгегә караса — аяклар шәм шикелле туры ди!

Менә сиңа мә! Бөтен авыл халкы шаккаткан бу хәлгә. Шул турыда ишетүгә, Йосыф тизрәк абыйсына хат язып җибәргән.

Хатны укыгач, Карәхмәт ярты ел эчендә беренче мәртәбә рәхәтләнеп, озак итеп, онытылып көлде дә: «Ну, Йосыф!» — дип эченнән генә аны шелтәләп куйды.

Тик үзенең бу хәлгә бик тә ышанасы, чын күңеленнән ышанасы килде.

Бик тә авылын сагынды шул чагында Карәхмәт. Их, бер генә сәгатькә кайтып киләсе иде анда, аннары кеше күзенә күренмичә генә, читтән генә күзәтеп йөрисе иде. Кичен җиде йортлы авылның уртасыннан тузан туздырып тугыз кәҗәсе, утыз тугыз сарыгы, биш сыеры кайтып кергән чакта, урам уртасында басып, шул тузан эчендә күмелеп каласы һәм: «Һәй! Авылдашлар! Мин сезне нинди сагындым! Мин сезне шулкадәр яратам! «Тас хәбәрчесе» Хупҗамал карчыкны да, әнә теге аксак ата казыгызны да, шәлперәйгән кикрикле кызыл әтәчегезне дә яратам! Әнием, Нәзирә, Йосыф, авылдашлар, борчылмагыз — мин сезнең тынычлыкны саклар өчен көн-төн керфек тә какмыйм!» — дип кычкырасы иде.

Соңгы сүзләрен, билгеле, авылдашларын тынычландыру өчен әйтер, бәдрәф идәнендәге шакмакларны санаганын белми бит авылдашлары...

Төн уртасында тревога белән күтәрелеп чыкканнарын да белмиләр. Бигрәк тә бәйрәм көннәрендә еш була андый тревогалар.

Йөзе агарынган дежур сержант сулышына каба-каба:

— Рота! Трево-о-о-га-а-а! — дип аваз салуга, казарма сикереп тора да посыльнойлар офицерлар артыннан чабарга әзерләнә, сержантлар, солдатлар, яттан белгән сугышчан исәп-хисап буенча, үз эшен башкарырга чаба.

«Әллә сугышмы?!!» дигән хәвефле уй миләрне актарып үтә. Кызулыктан берәү дә күрше казармада тыныч кына йоклап яткан инженер-саперлар ротасына игътибар итми. Йөрәкләр дөп-дөп тибә, борын тишекләре киерелгән, күңелдә шомлы уйлар. Бәхеткә, шулчак

казармада бригада буенча дежур офицер пәйда була.

— Разведчиклар! — ди ул һәм тамагын кырып алганнан соң: — Ашханәдә бәрәңге әрчи торган машина ватылган, бригаданы коткарыгыз, юкса, иртәнге ашсыз калабыз. Анда барыгызга да пычаклар әзерләп куелган! — дип үтенә, боермый, нәкъ менә үтенә.

«Шөкер, сугыш түгел икән!» — дип, рота җиңел сулыш ала.

Бригада янәшәсендә утырган авылга койма аша гына төнге сәяхәткә йөрүчеләрне тотарга да разведрота җиде төн уртасында тревога белән күтәрелә.

* * *

Бу поезда ничә тәгәрмәч булыр икән соң? Әүвәл ничә вагон икәнен белергә кирәк. Шуннан исәпләп чыгарырга була инде.

Карәхмәт үзалдына елмаеп куйды. «Җитте инде сиңа, җыен тузга язмаган нәрсә турында уйлап баш катырып утырырга!» — дип шелтәләде ул үзен.

Дроздов та, Панасенко да мыш-мыш килеп йоклыйлар. Поезд беркайда да, беркайчан да туктамыйча шулай барса да, тормаслар иде кебек алар.

Карәхмәтнең күзләренә дә йокы эленә башлады. Һәм ул үзенә ятарга урын җайларга кереште. Теге очтан Сало да килеп җитте.

— Карәхмәт, станция кайчан була икән? — дип сорады ул киләкилешкә. Карәхмәт, белмим дигәндәй, иңбашларын сикертте дә:

— Нәрсәгә ул? — диде.

Салоның күзләре гадәттән тыш ялтырыйлар иде.

— Тс-с-с,— диде ул борын очына бармагын китереп һәм аннары куен кесәсенә тыгылды.

— Швалюк сизә күрмәсен тик. Дүртебезгә бүләрбез, биш йөз сум булды.

Салоның кулында егерме бишлекләр, унлыклар, бишлекләр, өчлекләр күреп, Карәхмәт телсез калды.

— Кайдан болар?

— Малайлар җыеп бирде.

— Поезд билетлары өчен түләргә кирәк, өлкән лейтенант кушты, дидем.

— Син нәрсә, Петя?!

— Акрын, акрын, тавышланма, Швалюк ишетмәсен. Берәр станциядә кибеткә кереп чыгасы иде. Станциягә ерак микән әле?

— Бар тизрәк, кире илтеп тарат, җүләр!

Сало Дроздовның аякларын читкәрәк этеп, үзе шунда утырды.

— Кире илтеп тарат дим мин сиңа тизрәк, кеше күргәнче!

— Илткән ди менә! Сиңа кирәкмәсә — алмассың, өчкә дә бүлә алабыз без аны.

Тавышка Панасенко да күзләрен ачты. Дроздовны Карәхмәт үзе уятты һәм икесенә дә әлеге хәлне сөйләп бирде. Панасенко исе китмәгәндәй кыяфәттә генә:

— Ә нәрсә булган? Безнең үзебездән дә шулай җыйдылар, ике сержант, үзбәк малайлары иде,— диде дә авызын зур итеп ачып иснәргә кереште.

Карәхмәт аптырап Дроздовка карады.

— Чыннан да, кире таратырга кирәк,— диде Валера.

— Син армиягә барганда сездән җыймадылар мыни? — дип сорады аннан Сало.

— Җыйдылар җыюын. Тик мин бирмәдем, акчам юк иде.

— Әй, егетләр, сез нәрсә? — диде Сало.— Һаман да шул элеккеге мокытлыгыгызны куасызмы. Бетте, бетте ул тормыш, хәзер

безнең өчен яңа тормыш башлана. Нәрсә, сез шул маңка малайларны яклап торган буласыз. Акча ерунда ул алар өчен. Аларның күрәселәре алда әле!

Карәхмәт Салоның мондый гадәте барлыгын элек тә сизенә иде. Бу ялагай Сало акча өчен җанын бирергә әзер. Солдатларга тиеш булган җиде сум айлык акчаны алган саен ул: «Шушы җиде сум өчен мин кеше атарга тиеш буламмы инде, йә! Җиде сумга кеше хәтле кешегә автомат терә инде син, ә!» — дип ярым шаяртып, ярым чынлап сөйләнеп колакларны сасыта. «Кем сиңа кешегә автомат терәргә куша әле?» — дигәч, аңа да җавапны тиз таба: «Ник, әгәр дә мәгәр сугыш була калса! Дошманнарга атырга кирәк булачакмы, булачак!..»

Карәхмәт, шуларны исенә төшереп, иреннәрен кысты һәм ачу белән:

— Илтеп бир кире, Сало! Илтмәсәң, үзеңә үпкәлисең! — диде. Дроздов та, Панасенко да сүз әйтмәделәр.

— Сез нәрсә, егетләр, оныттыгыз мыни, елый-елый: «Яшьләр килгәч, аларга тырнак белән дә чиертмәс идек!» — дигән вәгъдәләрегезне оныттыгыз мыни?

Дроздов Карәхмәткә таба күтәрелеп карады да акрын гына урыныннан торды һәм Салоның җилкәсенә кулын салды.

— Әйдә, Петя, киттек. Тарат акчаларын үзләренә.

Бу хәлдән каушабрак калган Сало, ярдәм эзләгәндәй, Панасенкога төбәлде.

— Алар безнең рота «әрвах»лары түгел ич!

— Бар, бар, Петя, кире илтеп тапшыр!

Панасенко да шулай дигәч, Сало ирексездән урыннан торды.

Өлкән лейтенант Швалюк, уянып, башын күтәреп карады, вакытны белергә теләде, әмма сәгать таккан сул кулына Серафима башын куеп ята иде. Швалюк сак кына кулын тартты. Серафима күзләрен ачты.

— Килеп тә җиттекме әллә?

— Юк, юк, Сима, йокла, иртә әле.

Ләкин Серафима да торып утырды һәм иркәләнеп шундук Анатолийның күкрәгенә башын төртте.

Поезд тәгәрмәчләре такы-токы килеп рельслар белән серләшеп бара, вагон бала бишеге кебек салмак кына тирбәлә дә тирбәлә.

— Толя, әйдә, кайткач, миңа күченеп кил. Теләсәң, башка җиргә күченербез, мин синең белән җир тишегенә дә китәргә риза.

— Хатын барлыгын беләсең бит, Сима.

— Булса соң?

— Ю-юк-юк, Сима, без синең белән алай сөйләшмәгән идек. Нишләп хатын аерыйм ди мин? Без синең белән болай гына бит. Сине яратам мин яратуын, бик каты...

— Ул бала да таба алмый торган хатын белән кайчанга хәтле яшәмәкче буласың?

— ...

— Толя, беләсеңме...

— Әйе, Сима.

— Ул сиңа хыянәт тә итә бит әле.

Вагон бер якка чайкалып куйды. Швалюк, тотынып кала алмыйча, үзенә сыенган хатынны стенага кысты.

— Нәрсә сөйлисең син?

— Үзем күрдем. Син ул көнне каравылда идең. Хатының нигәдер безнең йорт янында йөри иде, мин эштән кайтып килә идем. Артыннан күзәтеп бардым. Сәгать унынчы яртыда хатының яныннан бер солдат килеп чыкты.

— Солдат?!!

— Солдат. Шикәр капчыкларын ташырга кирәк дигәч, бер көн чәйханәгә үз ротаңнан өч солдат җибәрдең бит әле. Теге озын, чандыр солдат.

— Манатов.

— Шул бугай. Хатының артыннан озата чыкты. «Патрульгә эләгә күрмә, башымны бетерәсең»,— дип әйтеп калды.

— Юк, юк! Юк!!! Шул сасы солдат беләнме?

— Бик шук егет күренә ул.

— Әгәр шулай булса! Әгәр шулай булсамы?!! Үтерәм, икесен дә үз кулларым белән атып үтерәм!

Серафима: «Тс-сс..» — дип учы белән Анатолийның авызын каплады.

— Акрын, Толя, акрын. Ишетмәсеннәр.

Хатын шәрә тәне белән офицерга сыенды. Әмма Швалюк аны дорфа рәвештә читкә этәрде һәм, урыныннан торып, ашыга-ашыга киенергә кереште.

— Уу, Василиса! Уу, Манатов!

Швалюк күзен-башын алартып коридорга чыкты да бар көченә:

— Подъем! Всем подъем! Живо!!![1] — дип кычкырды. Бу көтелмәгән әмердән каушап калган вагон бер мәл тынсыз калды, аннары шау-шу килеп уяна, җанлана башлады. Өлкән лейтенант һаман бар көченә кычкыра иде:

— Подъем! Подъем! Живо!!!

Тик никрутлар торып беткәч, аларга нәрсә әйтәчәген дә, ни кылачагын да белми иде әле өлкән лейтенант.

Поезд «пу-у-уу» итеп сигнал бирде. «Мәскәү-Брест» поезды Минск шәһәренә якынлашып килә иде.

* * *

Никрутларны тиешле кешеләренә тапшыргач, өлкән лейтенант Анатолий Швалюк туп-туры казармага кайтты. Үзе белән барган солдатларны алданрак җибәргән иде.

Ул казармага кергәндә рота кәнсә каршында тезелеп тора иде. Нигәдер барысының да башлары аска иелгән, өлкән лейтенант Ильин рота алдында әрле-бирле йөренә, лейтенант Данилов бер почмакта иреннәрен чәйнәп тора. Швалюкка игътибар итүче дә булмады, хәтта дневальный тумбочкасы да ялгызы гына кукраеп утыра. Өлкән лейтенант аптырап, гаҗәпләнеп рота командиры янына килде. Ләкин тегесе аны бар дип тә белмәде, йөрүеннән туктады да, ротага карап:

— Сез монда маегызга чыдаша алмый ятасыз! Сез монда азып беттегез! Бетегез котыра! Ә Әфганстанда сезнең кебекләр кан эчендә ята! Моннан соң... моннан соң...

Рота командиры күз яшьләренә буылып туктап калды. Швалюк тәмам аптыраган кыяфәттә Данилов янына килде.

— Ни булды?

— Тегендә, Әфганстанда, бездән киткән өч егет, Хафизов, Матусов, Нападовкин, өчесе берьюлы, өчесе дә беренче сугышта ук... гранатомет белән...

Өлкән лейтенант Швалюк рота каршысына ук килеп басты да

---

[1] Торырга! Барыгыз да торыгыз! Тиз!

күзләре белән ашардай булып, кемнәрнедер барлап, эзләп чыкты, аннары кыргый тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Кайда Манатов?! Кайда Рубевский?! Кайда Иванов?!! Сез гаепле! Сез көн күрсәтмәдегез аларга... Сезнең кыерсытуларга түзә алмыйча китте алар Әфганстанга! Кайда Манатов, Михайлов, Рубевский? Кайда Иванов? Чыгып басыгыз монда!

Рота командиры аның туктаганын көтеп торды да тыныч тавыш белән генә:

— Сезнең үтенеч буенча Манатовны беренче партия белән үк өенә кайтарып җибәрдек. Тегеләре дә шунда әлакте,— диде.

Швалюк бүтән сүз әйтмәде. Каты итеп тешләрен кысты да алпан-тилпән атлап казармадан чыгып китте...

* * *

Разведрота командиры Ильинга үз вакытында капитан йолдызын бирделәр. Өлкән лейтенант Швалюкны шуннан соң ук танк бригадасына разведрота командиры итеп күчерделәр. Ул Серафима белән яши башлады. Василиса Руслановна, ире Мәскәүдән кайтып кергәч башланган гаугаларга чыдый алмыйча, туган шәһәре Новгородка кайтып киткән иде. Лейтенант Даниловны округ газетасына хәбәрче итеп алдылар. Тиздән Карәхмәт ниндидер өмет һәм сөенеч белән аның «Яшь солдатларны яклыйк!» — дигән мәкаләсен укыды. Аны әле алда тагын елъярымлык солдат хезмәте көтә иде.

*1989.*

# Ямаш Игәнәй

## Ышандырып кара, Заман!

Ни газаплар кичермәдең, Илем,
Җаннар иңри — үткәннәргә баксаң...
Тарих-дәрья ярларыннан ашкан
Асыл улларыңнан аккан ал кан.

Ә син һаман, затлы мирас булып,
Тираннарга күчкән тираннардан.
Җирең, халкың күпме гомер кичкән,
Ыңгырашып зынҗыр-богаулардан,

Һәм барын да челпәрәмә ватып,
Изге Азатлыгын яулап алган.
Тик, юлбашчы булып... кем уйлаган,—
Тираннан да Залим адәм калган.

Ил агасы булыр асылларны
Әйләндереп «халык дошманына»,
Үтерткән ул, кырган. Үзе түгел,
Куштаннарга бары кушкан гына...

Кемдер аның исеменә — алдан
Даһи дигән сүзне өстәп язган.
Халык исә кабул иткән хуплап,
Асылын кем аның абайлаган?

Җәллад калкан иткән аны шулай,
Халык мактап көн-төн җан җырлаган.
Олы-кече бар да кабатлаган,
Әнә шулай Чынны җиңгән Ялган...

Ул бүген дә кабатланыр иде,
Уятмаса Акылларны Заман.
...Залимнәрнең «эше» күз алдында,
Ничә миллион, ничә миллион корбан!

Кемдер әйтер миңа: «Болар — узган,
Һәм аңарга Тарих нокта куйган.
Киләчәккә әйдә кешеләрне,
Үткәннәрне язып торма, туган...»

---

Ямаш ИГӘНӘЙ *(Ананий Малов) — шагыйрь, 1938 елда туган; «Сәфәр чыгам», «Йолдыз булып ян», «Хәзинәләр иле» һ. б. китаплар авторы. Чаллыда яши.*

Язмас идем, тынгы бирми Вөждан,
Ил үч ала мени каберләрдән?..
Тик үткәннең канлы фаҗигасе
Җуелмаска тиеш Хәтерләрдән!

Ни аерма бүген кичәгедән,
Ни үзгәртте бу Яңарыш җиле?
Үткәннәрнең кабатланмавына
Ышандырып кара мена мине.

Чынга ашмас диеп яңа Ялган?! —
Син ышандыр бүген Илне, Заман!

*

Эт ялкавы алар, эшлексез, дип,
Капиталистларга исем тактык.
Без аларны әллә кайчан уздык,
Диеп, бар дөньяга сөрән салдык —
Октябрьдә җиңгән бөек халык...

Зур посттагы мөртәт адәмнәрнең
Татлы ялганыннан гипнозланып,
Хыялдагы затлы сыерларның
Биш тапкырга күбрәк «сөтен савып»,
Чәйне эчтек аерткан сөт салып...

Без дөньяда, диеп, иң бай халык! —
Йөри торгач, сүздән киләп сарып,
Ярыйсы ук хәерчегә калдык:
Кием-салымнарда булмаса да,
Җаныбызда кырык бер ямаулык...
Менә шуны бүген хет аңладык!..

Үткәннәрдән нинди гыйбрәт алдык,
Ни үзгәрде бүгенге көн Илдә?..
Төшәр күлен җуйган Аккош сыман,
«Демократия» сүзе бөтерелә
Баш очында. Ә күл, бәлки, корыган?!

«Демократия» сүзе Ил өстендә
Бөтерелә ялгыз Аккош сыман...

## Экология һәм без

Казан уртасында Болак ята череп.
«Көзгесендә» язмышыбыз чагыла кебек.
Кайсы чорда шушы хәлгә җиттек килеп?
Кичәгебез? Бүгенебез? Иртәгәбез?
Шомлы бер өн тора җанны тетрәндереп...

## Без

Бүген, бәлки, якты
Көннәр кичерәбез...
Үткәннәрне, әрнеп,
Искә төшерәбез.

Гыйбрәт алыр өчен
Бу бик кирәк, дибез.
Ни күрсәтмәс тагын
Алдагы көнебез?!

Заманында безне
Ай-һай, алдаганнар,
Ил байлыгын кемнәр,
Ничек талаганнар?

Залим булган алар,
Ә без кем булганбыз?
Шундый мәсхәрәгә
Ничек юл куйганбыз?

Түрәләрнең татлы,
Затлы сүзеннән без
Һушыбыздан түнеп,
Тәмам эрегәнбез.

Шуның хөрмәтенә
Хәмер чөмергәнбез.
Башка киткән, ләгънәт,
Шактый исергәнбез.

Әмма үзебезне
Аек дип белгәнбез,
— Сез — аек,— дигәнне
Туган күк күргәнбез.

Дөресен әйткәннең
Авызын җимергәнбез,
Куштаннарның сүзен
Сүз итеп йөргәнбез!

Уйлап баксаң, шунсы
Зиһеннәрне ала:
Илдә арткан — күпме! —
Мие сыек бала...

Бүген, ахры, якты
Гомер кичерәбез.
Үткәннәрне, әрнеп,
Искә төшерәбез.

Гел кушканны үтәп
Яшәгәнбез бары.
Янартау күк кайный
Илнең зарлы җаны...

Трибунадан чәчкән
«Уңыш» үстергәнбез,
Кабар ризык сорап,
Күршегә кергәнбез.

Бер тарыдан ун кат
«Ботка» пешергәнбез.
Һәм күр, шуны ашап
Ничек симергәнбез!

Түрә майлы калҗа
Капса — кикергәнбез.
Илне шулай «тук»ка
Әверелдергәнбез!

Кемгә орден таккан
Пинҗәк кидергәнбез?! —
«Затлы» илнең «асыл»
Улы иттергәнбез!

Намуска, Вөҗданга
Битлек кидергәнбез.
Күңел күзен илдән-
Көннән яшергәнбез.

Әни түгел, «Ани»
Дип төшендергәнбез.
Туган телне — милләт
Шәмен сүндергәнбез...

Аяк өсте мәрткә
Китеп йөрегәнбез.
Ничә еллар рухи
Йокы симерткәнбез!

Динне генә түгел,
Денне бетергәнбез.
Кемгә соң без шулай
Каза китергәнбез?..

Кәүсәбезме корган?! —
Тамырдан чергәнбез?..
Шундый түгелме соң
Әле бүген дә без?
...Нишләрбез иртәгә
Һәм берсекөнгә без?!.

## Чәчмә әсәрләр

# Тәүфикъ Әйди

# ЕЛАН УГЫ

РОМАН

### 32



Чеканың яшерен-оператив бүлеге мөдире Юлтай Симиниев, үзендә Шиһабетдинов хаты табылгач, яхшы ук пошаманга төште. Әминев белән Байкучатовның аңа кереп нәкъ менә тентү ясауларына ул тамчы да икеләнмәде. Димәк, шикләнәләр. Байкучатов кына аңа ышанмаса: төкермәс тә иде. Чека рәисе дә аңа кушылса, җитмәсә, шул хат аркасында шиген ныгытып та куйса, эш зурга китәчәк!

Юлтайның хәрби комиссар хатын кулга төшерергә тырышуы аңлашыла. Анда Бохараның асыл егетләренә кара ягарлык анык хәлләр һәм исемнәр телгә алынса, соңгы көннәрдәге вакыйгалар турында берәр хәвефле хәбәр яки зыянлы ишарә теркәлсә һәм йомгак очын тоттыра торган мәгълүматлар Фарукҗан кебек кызыл әтәчләр кулына килеп эләксә, терсәкне тешләргә соң булыр иде. Ул чакта Симиниевкә дәү абзыйларның ышанычы бик тиз кимиячәге ап-ачык. Шуңа күрә хатны вакытында кулга төшерүе егетлек булды. Дөрес, анда аһ итәрлек бернәрсә дә язылмавы беленде. Ләкин менә шуның ачыклануы инде үзе генә дә бик әһәмиятле иде. Төрле ыгы-зыгы эчендә кайнап, хатны юк итәргә дә онытмаган булса кана. Чека председателенә көне-сәгате белән үзе алып кереп күрсәтсә, бигрәк тә отасы икән!

Дөрес, Әминев ятсыту галәмәте сиздермәде. Әллә, Байкучатов шикелле, каударланып утка керү, капчык төбен селкү гадәте юклыктан гынамы бу? Итәк-җиңен җыеп йөри белмәүчене тәшвишкә сала торган зобаный, ахры, бәдбәхет. Тефу!

Хәвеф-хәтәр янавы хакында киңәшер өчен, хат вакыйгасын ул агентура бүлеге башлыгы Латыйфхан Нурморатов белән Ревком рәисе урынбасары Габделхәмит Гариповка сөйләп бирергә ашыкты.

— Фарукҗан казынулары нәтиҗәсе бу! — диде Латыйфхан.— Чекадан тизрәк олактыру кирәк егетне.

— Байкучатовны арагызга тыгып ялгыштым, ахры,— диде Габделхәмит.— Әзрәк көтик инде. Кабаланып берәр мөгез чыгармасларымы. Әминев белән икесен дә дер селкетер идек аннары.

Ахыры. Башы 4, 5 саннарда.

— Исмәгыйль Гаспралы төрки кавемнәрне «телдә, фикердә, эштә берлек»кә күпме өндәде, ә монда без, өч бөртек татар, әле дә үзара аңлаша алмыйбыз, бер-беребезгә баз казырга гына торабыз,— диде Симиниев ачулы кыяфәттә. Габделхәмит аны юатырга да, тынычландырырга да ашыкмады. Эченнән уйланган төсле:

— Һәр татар аңы ягыннан даһи Исмәгыйль бабабыз дәрәҗәсенә күтәрелсә, без әллә кайчан инглиз, французлар янәшәсенә баскан булыр идек инде,— дип җавап бирде.— Вәхаләнки, байтагыбыз, сукыр тавык кебек, кибәккә алдана шул.

— Дөрес. Гаспралы — татарның ничә гасыр буе мең газап кичереп көтеп алган якты йолдызы.

— Ә без, Юлтай, һәр милләттәшебезгә аның яктысын иңдерергә өлгермәдек,— диде Габделхәмит.— Хәзер шуның язгын күрәбез.

Симиниев, тәмәке кабызып, аны еш-еш суыра-суыра Гарипов кабинетында арлы-бирле йөренде һәм ачынган рәвештә:

— Бичара Шәрык! — диде.— Үзенең йолдызларын да танып белми бит ул. Йокыга оеган албастыдай, билләһи. Теләсә нинди кырыкалдарга җилкәсен каезлата да тора.

— Менә шуның өчен дә Йөгнәки бабабыз инде моннан мең ел элек: «Сөяккә — җелек, адәмгә — гакыл кирәк»,— дигән. Гакылсыз адәм хәйван кебек, йөгән кидерүче ихтыярыннан чыга алмый. Шәрыкне уятырга, аңа гакыл кертергә кирәк.

Ишектә кулына зур чынаяк чәйнек, касәләр тоткан үсмер егет күренде. Ул кунак белән итәгатьле кыяфәттә баш иеп исәнләште. Гарипов, хезмәтче күздән югалгач, тәрәзә буендагы кечкенә өстәл янына килеп утырып, Симиниевне дә шунда чәй эчәргә чакырды.

Болай хезмәт күрсәтү Ревком председателе урынбасарының Чека хезмәткәре Юлтайны үз күрүе хакында сөйли иде. Хуҗа кеше тыштан ишек кагучыга: «Сабыр итегез!» дип кычкырды да, касәне кулына алып, кунагына:

— Бераз ял итәргә дә кирәк, без дә хакның бәндәсе,— дип көлемсерәде.— Гозер белән килүче ярлы-ябагай бетмәс.

Байлыгы белән мактана алмаган Симиниевнең кәефен кырырлык иде бу сүзләр. Әмма, малга хирыслыктан, ул Габделхәмитнең кимсетүле мөнәсәбәтенә үпкәләү кайда, хәтта аны хуплап диярлек кабул итте. Көяз мыегын бора-бора:

— Ни хикмәттер, раббебыз дөньяга фәкыйрьләрне күбрәк яраткан,— диде.

— Фетнәгә үзе шулай җирлек бирә дә аннары байларны шәфкатьле булырга өнди.

Алар шулай гәп суга-суга чәй эчеп утырганда телефон шалтырады. Габделхәмит трубканы теләр-теләмәс кенә алды.

— Гарипов тыңлый.

— Чекадан Әминев бу,— диде кискен тавыш.— Каганда афәт: дары төялгән вагоннар шартлаган!

— Дары?

— Әйе. Һәлак булучылар да күп диләр. Мин хәзер шунда китәм. Ревкомнан берәрегез кушылырга теләмиме?

— Көтеп торыгыз, хәзер үзем килеп җитәм. Бергә барырбыз.

Ревком рәисе урынбасары трубканы куеп, канәгать төстә әле берни дә аңламаган Симиниевкә карады. Аннары кулына тагын касәне алып, кайнар чәй уртлады да:

— Ходайның кодрәте киң! — дип елмайды.— Бер каныкса, каныга адәм баласына. Шартлаткан.

— Кагандамы?

— Әйе. Кайгыдан мәй эчсәң дә урынлы бүген. Тик хәзер үк түгел, кичен пылау пешереп.

Симиниев сикереп урыныннан торды. Аңа хәлне бүтән төшендереп тору кирәкми иде. Болай да ачык, бик шәп!

— Чекага элдертергә кирәктер миңа. Бу вакыйганы тикшерергә.

— Үзәгендә кайна.— диде Габделхәмит.— Җинаятьчеләрне эзләү ялгыш юлдан китсен. Бар! Без Чекага аерым-аерым килеп җитик.

Юлтай, Ревкомнан җитез генә йөгереп чыгып, атына атланды да өермәдәй кузгалып китте. Урамда күзенә ак-кара күренмәде — җирән кашкасын куды да куды. Күн фуражкасын батырып кигән, төймәләнмәгән куртка чабулары канат кебек каерылып җилферди, портупеясына тагылган музеры шап-шоп ботына бәрелгәләп ала. Йөрәге дәртләнеп тибә, күңелендә: «Бар да без дигәнчә булыр!» дигән гайрәтле уй. Каршы очраганнар аңа тизрәк юл бирергә ашыкты, тузанга күмелеп калган карт-коры гына бәреләә-сугыла чапкан атлыга, өс-башын кага-кага, сукранып карап, бәддогаларын укыды. Симиниев Чека урнашкан Алмашу базарына якынлашканда гына атын тыя төште. Исемен атап эндәшкәнне ишеткәч, тезгенен кисәк тартып, артына борылып карады.

— Нәзир?

Әбдиев аның янына килеп, сәлам дә биреп тормастан:

— Мин сине монда сәгатьтән артык көтеп торам инде,— диде.

Симиниев тирә-юнен караштырып алды — төенчек күтәргән пәрәнҗәле хатын-кыз, ишәкле олауда барган ике ир-ат, койма ышыгында ашык уйнап чыр-чу килгән бала-чагадан гайре җан иясе күренмәде. Хәвефсез сөйләшергә дә мөмкин шикелле.

— Нәрсәңә ут капты?

— Балҗанны Каганнан шома гына алып сыпыртканнар икән. Аны юлда «урлаган» өч әшнәмнең берсе Бохарага исән-сау әйләнеп кайтты.

— Шуннан?

— Ләкин, әлеге егет аерылып киткәч, иптәшләре ниндидер бәлагә тарыган — элек сөйләшенгән җиргә барып җитмәгәннәр.

— Шуннан?

— Сүз куешкан төрекмәннәрем кәләшне вәгъдәләшкән җирдә төшкә кадәр көтеп торганнар да, түземнәре төкәнгәч, үзләре каршы алырга кузгалганнар. Кәләшнең кайсы тарафтан алып киленәсен беләләр. Кузыбагар тозагына җиткәч, шаккатканнар: әшнәләремнең икесе дә үтереп ташланган, Балҗаннан җилләр искән, ди.

Юлтай әле һаман тынычлана алмаган чаптарын тыеп, бер үк вакыт үзе дә җенләнә башлап, инәле карашын Нәзир Әбдиевкә батырды да:

— Көрәш кан коюсыз гына булмый,— диде.— Син урамнар, мәйданнар буйлап: «Әмир пулы бикәр, әмир акчасы йирмәйде!» — дип оран салып революционер исемен казанмакчы, бөтен хәтәр эшне кешедән эшләтмәкче. Үз гаиләң алыш-бирешләрен дә безгә йөкләмәкче. Булмый ул алай, егетем, булмый!

— Соң мин кулымнан килгәнчә...

— Кулдан күбрәк килерлек итеп тырышырга кирәк! — диде Юлтай, аны бүлеп.— Әмир акчасын әйләнештән чыгару җиңел ул, Бохара мәмләкәтенең яңа акчасын сугу гына авыр. Ансыз исә нинди бәйсезлек турында хыялланырга мөмкин? Ә сезнең берегез тизрәк мамык сатарга ашкына, икенчегез — хатын. Сәүдәгәрләр, имеш!

Нәзир бурлаттай кызарынып чыкты. Тик үзен аклап бүтән бер сүз дә әйтә алмады.

— Нишләргә соң хәзер? — диде ул, күндәмлек күрсәтеп.— Мин әшнәләремне Байкучатов корбаны булмады микән, дип хәвефләнәм. Үз өере белән ул иртән үк Каган ягына чыгып киткән, диләр. Безнекеләрнең серен дә алса...

— Синең Балҗаныңны кайда асрарга тиеш алар?

— Каганда яки туган кышлагында. Атасы янына чүлгә илтеп яшерүләре дә мөмкин.

— Каганга алып кайтмаслар. Димәк, эзли торган җирең икәү. Егетләреңнең ышанычлыларын җый да каршыларына кит. Алар күбәү түгелдер, берсен дә калдырмый юк итегез. Шуннан соң корал китерүче кәрванга юл күрсәтергә ашыгыгыз.

— Зыятдингамы?

— Әйе. Бер генә минутны да әрәм уздырмагыз. Язмышны җитезлек, кыюлык хәл итә.

Юлтай кайтып кергәндә, Чекада ыгы-зыгы көчәйгән, Галимҗан Әминев партия Үзәк Комитеты һәм милиция вәкилләре белән юлга чыгарга әзерләнә иде. Мондый очракта яшерен-оператив бүлек мөдире һәлакәт сәбәпләрен беренче ачыкларга тиеш булганлыктан, Симиниев борчулы төстә шефы янына килеп:

— Иптәш Әминев, афәт чыгуын яңа гына ишеттем, мин бәхетсезлекне шушы минутта ук тикшерә башларга әзермен,— диде.— Оператив төркемгә кемнәрне алыйм икән?

Чека рәисе аңа йөгерек караш ташлады да анык әмерен бирде:

— Сез Чекада кизү торыгыз. Каганга мин үзем барам.

Юлтай үз колакларына үзе ышанмады. Ничек инде мондый җитди һәлакәтне тикшергәндә яшерен-оператив бүлек мөдире катнашмасын икән? Ялгыш ишетмидер ич ул? Хәтта дөрес ишетсә дә, кулай түгел аңа бу әмер. Кичкә таба аның Бохарадан читтә, кеше күз алдында болгануы хаҗәт. Шулай файдалы.

— Иптәш Әминев, сыйнфый дошман кулы уйныйдыр монда,— диде ул.— Ун вагон харап булсын әле!

— Мин дә дуслар тырышадыр дип уйламыйм.

— Шуңа күрә сезнең янда мин дә артык булмам.

— Бохарада кем тәртип саклар соң? Монда да сезнең кебек бер уяу кеше калуы шарт.

Әминевнең «уяу» дип әйтүе сагайтты Юлтайны. Әллә мактап, әллә төрттереп әйтә, белмәссең. Шулай да, үзен барыбер Каганга алып бармаячагына ышангач, станциядәге шартлау хәлләрен ул юри гадиләштерергә омтылып:

— Бәлки кызыл гаскәриләр үзләре гаепледер әле,— диде.— Саксыз тәмәке төпчеге ташлаганнардыр. Дарыны кабызырга күп кирәкмени?

Чека рәисе салкын кан белән җавап кайтарды:

— Шулай икән, андый гади җинаятьне ачуга бөтен көчне туплау да кирәкмәс. Пайтәхеттә күз-колак сизгер булсын, монда да сынатырга ярамый.

Юлтай артыграк борыч сипте, ахры. Әмма эшне төзәтергә соң иде инде. Кәрвансарай ишегалдына Габделхәмит Гарипов атылып килеп керүгә, Әминев иярткән төркем Каганга таба юл алды.

Гарипов киткәч, Каган хәлләре өчен борчылмаска да мөмкин, дип уйлады Юлтай. Ә менә Әминев яшерен-оператив бүлек мөдирен шундый афәтне тикшерүдән читтә калдыруы шикләндерә. Аның күз алдында үзен революция каһарманы итеп расларлык нәрсә эшләргә соң?

Ишекле-түрле йөреп баш вата торгач, тапты: ни тегеге, ни бу якка кушылмый йөргән берәр сәүдәгәрне «кысып», Кызыл Гаскәр файдасына зур салым салырга. Сәүдәгәр карыша, Әминев, Хуҗаевлар бу эшнең гадел эшләнүенә икеләнә алмасын өчен, әлеге акыллы башка берәр гаеп тагарга. Малы кулыннан китә башлавын тойгач, яңа хакимнәргә бик тиз аркан борылыр. Ялгызы гына түгел! Кемне савасын финанс комиссары Булатхуҗаев белән киңәшеп хәл итәргә була.

Симиниев кирәк кешесен телефон аша гына таба алмагач, тагын атын иярләде. Халык Комиссарлары Советына, берничә базарга кагылды, бары шуннан соң гына Булатхуҗаевның өенә юнәлде. Иркен ишег-

алдына килеп кергәч, хезмәтче егет белән исәнләшеп:

— Энем, мин Чека хезмәткәре Симиниев булам,— диде.— Хуҗагызга ашыгыч йомышым бар, өйдәме ул?

— Хәзер белеп чыгамын.

Бераздан егет түгел, ишектә хуҗа үзе күренде.

— У-у, Юлтай уртак, әссәламегаләйкем, килең, килең, боерың! — диде ул ачык йөз белән.— Исән-аман йөрисезме? Әхвәлләрегез яхшымы? Өйдәгез ханәгә узыгыз!

Юлтай аның белән шулай ук, Бохарадагы йола буенча, чуклап-чачаклап исәнләште һәм хуҗаның, аның гаиләсенең сәламәтлеген, мал-мөлкәтенең иминлеген сорашты. Үзе әнә шулай Булатхуҗаевка ияреп кереп хәл белешкән арада кунак бүлмәсен күздән кичерде. Ханә иркен, унике өрлекле түшәме биек иде. Өч зур тәрәзәдән яктылык мул иңә, өч яктагы өч ишекнең һәммәсе нәфис итеп сырланган, бизәкләнгән. Көндез артык эссе булмасын өчен, тәрәзәләр нәфис бизәкле челтәр белән капланган. Агачмы, ташмы шулай челтәрләнгән — монысын Юлтай чамалый алмады. Тәрәзә араларындагы диварга исә күз явын алырлык матур сурәтләр төшерелгән. Геометрик сыннар, үсемлекләр, чәчкәләр. Каршы диварда тәрәзә сыман алты уем — алар да, чиккән намазлык кебек, ямьле, нәфис рәсемләнгән. Уртадагы җиденче уемда китап-дәфтәр, савыт-саба шүрлекләре. Ишек башларында диварга догалар һәм шигырьләр язылган. Алар сурәт кебек матур, бүлмәгә затлылык өстәп тора. Түшәм кәрнизләре умарта кәрәзедәй сырланган. Идәненә түшәлгән калын келәм буйлап атлаганда, үзеңне куе үлән, чәчәкләр каплаган болында йөргәндәй тоясың. Юлтай купшы бүлмәне сокланып тамаша итте. Хуҗа исә түрдәге тәбәнәк өстәл янында урын күрсәтеп:

— Бәрәкалла, хуш килепсез,— ди-ди кунакчыллык күрсәтүендә булды.— Мәрхәбә! Бергәләп чәй эчәргә кем җитми дисәм, сезнең кебек бер зыялыны юксынганмын икән. Табын күрке — кунак, түргә узыгыз, Юлтай би!

— Рәхмәт, тәкъсир. Әгәр бер үтенечем булмаса, мин сезне өегезгә килеп борчырга һич тә җөрьәт кылмас идем, әлбәттә.

— Хафаланмагыз, хәзер барысы турында да гәпләшербез. Сез әле көндез әукатьләндегезме?

— Ары чабып, бире йөгереп, тамак ягы онытылып та китә. Әмма сез, тәкъсир, мәшәкатьләнмәгез, әүвәл эшне хәл итик әле.

— Менә монысы мәслихәт нәмә имәс,— диде хуҗа көлемсерәп һәм башын чайкап.— Лампа янсын өчен, элек аңа май салалар. Кичерәсез, мин хәзер әйләнеп керәм.

Бераздан бая Юлтайны каршылаган үсмер табын әзерләде. Өстәлгә хуш исле пылау, кайнар сумса, кәләвә, аннары алма, анар, алморт, йөзем, өрек кебек җиләк-җимеш килде. Хуҗа кунакны сыйлады.

— Эш хакында сөйләшеп, ризыкны суытмыйк, анысына соңрак та өлгерербез,— дип тукып торды. Бары тик кавын-карбызларны да капкалагач кына, Булатхуҗаев сүзне сәясәткә күчерде.

— Әйе, коммунистлар — диктатор,— диде ул кулларын тастымалга сөртә-сөртә.— Үзләре белән килешмәгән кешеләрне гаепләү, сүгү аларга берни тормый.

— Тәкъсир,— дип елмайды Юлтай,— сез мине шундый сыйладыгыз, хәзер бөтен дөнья күземә хуш күренә, күңелсез нәрсәләрне, валлаһи, телгә аласы да килми.

— Тугры,— дип көлде Булатхуҗаев.— Ашау-эчү, киенү, торак мохтаҗлыгын татып яшәүче адәмнең уе да моңсу була, хыялы да бер кабымлык ризык, ямаулы бер иске чикмән яки кәвеш, төн кунарлык кечкенә бер куыштан ары китми.

— Көче дә шуларны булдыруга сарыф ителеп бетә,— диде Симиниев, хуҗаны куәтләп.

— Тазарту комиссиясе исә әнә шундый ярлы-ябагайны сөттән ак, судан пакь санап, эш башына сайлап куйдыртырга тырыша. Хатыны талак имансызлар! Эчке аң үсеше кая ул югары баскычка күтәрелү, бер җамаяк боткадан да ары китмәгән гидайны Комиссарлар Советына керт, имеш.

— Кул куясы урынга тавык тәпие сырлап утырырга!

— Әйе. Менә шундый бәндәләрне Рәсәйдән килүчеләр җөдә үз күрә. Сезнең милләттәшләр дә, кызганыч ки, булдыксызларны күбрәк яклый.

Бу искәртүне Юлтай шелтә кебек кабул итте. Булатхуҗаевның ачынуы нигезсез түгеллеген белсә дә, якташлары гаебе үзенә дә күләгә төшерүе ихтималлыгын чамалап:

— Тәкъсир, Бохара халкы бердәм булса, читтән кем дә тыкшына алмас иде,— диде.— Әгәр инде Казан татарларын күздә тотасыз икән, без үз язмышыбызны сезнекеннән аерып карамыйбыз.

— Юлтай би, күңелегезгә авыр алмагыз...

Симиниев, үпкә тойгысына бирелепме, хуҗаны бүлеп дәвам итте:

— Нәкъ менә безнең Садрый Максудый җәнапләре Дәүләт Думасы мөнбәреннән: «Дөньяда бер бөек төрек милләте бардыр, булган, булачактыр вә бу милләтнең барлыгына вә киләчәгенә һичбер куәт киртә була алмас!» дип чыгыш ясавын онытмагыз.

— Мин Максудый әфәндене ихлас вә ифрат хөрмәт итәмен. Аның бу нотыгына меңнәр рухланып дога кылды.

— Тәкъсир, татарның хөрмәткә лаек егетләре бер ул гына түгел,— диде Юлтай тагын да үҗәтләнеп.— Фетнәчеләре, мәнсезләре бар икән, алары серле рәвештә һәлакәткә очрый да тора. Серле рәвештә!

Булатхуҗаев, аны аңлавын белдереп, баш какты. Аннары җитди, ихтирамлы төстә:

— Жураларым әйтүе хак икән,— диде.— Сез үтә дә кайнар, тәвәккәл көрәшче.

— Хәзер сүз, буш хыялларны онытып, эшкә, хәрәкәткә күчә торган заман, тәкъсир. Әмма: «Шәрык уяна!» дип күпме сөенсәк, күпме тәкърарласак та, Бохара әһле һаман йоклый бирә. Аның өчен без, читтән килүчеләр, әле теге, әле бу яктан аһ орабыз, хәтта кан коябыз.

— Канә, мәрхәмәт кылыгыз, ризыкка үрелегез,— дип эндәште хуҗа. Аннары, житдилеген саклаган хәлдә, Симиниев касәсенә чәй коеп һәм кунагының салпы ягына салам кыстырып, сүзен дәвам итте: — Гәбегездә мән бар. Сезнең шикелле егетләр җитми безгә, дөрес. Әмма әхвәл өметсез имәс. Каган хәлен ишеткәнсездер. Дуслар да булышса, халык күтәреләчәк әле.

Симиниев, ниһаять, йомышын әйтер вакыт җитүен тоеп, өстәлдәнераграк күчеп утырды. Мул табында сыйланудан бөтен тәненә рәхәт талгынлык җәелгән, маңгаена тир бәреп чыккан иде. Иркен бүлмәдә тыштагы бөркүлек бөтенләй сизелмәгәнлектән, монда сулыш алу җиңел, ял итү тансык. Ләкин хәзер купшы хөҗрәләргә бикләнеп онытылыр чакмыни? Шуңа күрә ул ризыкка ишарәләп:

— Тәкъсир, кунакчыллыгыгызга мең рәхмәт! — диде.— Инде эшкә күчик. Блеккер әфәндене яңа бер үтенече барлыгын беләсез. Йөрәкле егетләр исән чакта, иншалла, анысы да вакытында үтәлер. Ләкин андый егетләрнең үзләрен дә кайгырту мөһим, минемчә.

— Әлбәттә.

— Шул исәптән, мин үзем дә, тәкъсир, тәрәккә, таянычка мохтаҗ,— дип, Юлтай үзенә Әминев күрсәткән мөгамәләне сөйләп бирде.— Госманхуҗа әкә, бу бер дә яхшы фаш түгел. Чекада Байкучатов казынган шартларда...

— Без ул бәндә хакында Гарипов белән киңәш-табыш кылдык инде.

— Кинаштегез, ә? — Симиниев, хөкем иткәндәй, башын чайкады.— Без кайвакыт дошманнарга әнә шулай бәя биреп җиткермибез, аннары бик нык үкенергә туры килә. Мин үзем кискенрәк чаралар да күрә башладым инде. Тик хәзер сүзем ул хакта түгел. Әминев башын әйләндерер өчен минем мондый бер ниятем бар иде...

Булатхуҗаев кунагын игътибар белән тыңлап торды да:

— Мәгъкуль,— дип хуплавын белдерде.— Ишназар әкәгә тукта-гыз әле.

— Кем ул?

— Пайтәхетебезнең Сәлләханә ягында яши булса кирәк. Ерак кышлакларга барып, чәй-шикәр, шырпы, кәтүк, сабын, пәрвәрдә ише нәрсәләр белән сату итә.

— Баймы?

— Кайда инде! Малны бездән бурычка ала да кышлакларда бодай, солы, тары ярмасына, терлеккә алмаштыра. Аннары шул игенне, малларны Бохара базарында саткач, безгә әҗәтен түли. Сәүдәгәр дигән исеме генә бар, гаиләсе көчкә җан саклый, имеш. Әмма гөнаһсы зур — гидайларны кызгана, безгә тел озайта. Шуның өчен аны Хуҗаевлар груһы сәүдәгәрләр исәбеннән корылтайга сайлатты, нотык сөйләтте. Кызыл Гаскәр файдасына дип салым сылавыгыз, чыннан да, шәп булыр. Революция дип сайрап кына йөрмәсен, йөз пот ашлыгын чыгарып салып егетләнсен! Үзенә дә, бүтәннәргә дә акылга утырырга яхшы булыр.

— Байгышны яклый башласалар?

— Кышлакларда малын ике бәягә сатып, кәмбәгальләрне каезлап йөри, диярсез. Берничә шаһит табылыр, иртәгә безнең комиссариатка килеп, исемнәрен белеп китәрсез.

— Төшендем, тәкъсир!

Йомышын йомышлагач, Юлтай китәргә җыенды. Әмма ул, ишек башларындагы диварга язылган догаларны укыган булып, тагын бераз тәрәлеп торды. Булатхуҗаевның, бердән, ата-бабадан килгән бай, икенчедән, Истанбулда белем-тәрбия алган кәттә укымышлы, шактый ел җәдитчеләр юлбашчысы булганлыгын ишеткән, әле хәзер дә Бохара тормышының уртасында кайнап, күп кенә ачык һәм яшерен эшләргә даими йогынты ясап торуын чамалый иде Симиниев. Бер дә юкка гына нәкъ менә аны эзләп өенә килмәде ич. Нигә әле аяк астында кара эшне генә башкарып йөрергә? Нигә дәү абзыйларга якынаеп, югарырак үрмәләмәскә?

Әмма йорт хуҗасы бик үк чишелеп китмәде. Югыйсә кунагының кемнәргә хезмәт итүе аңа һич тә сер түгел иде. Аксөякләнеп маташуымы? Ят кавем санавымы? Шундый сәбәпләр аркасында турыдан-туры аралашырга ашыкмавымы?

Симиниев, ышанычка кереп бетә алмавына кәефсезләнсә дә, күзләрен ишек башыннан алып, тыштан бүтән нәрсәгә сукрангандай итте:

— Төркестан мөселманчылыктан бүтәнне белми шул әле. Бар җирдә дога, дога, дога! Әйтерсең, гареп һөҗүмен шуның белән генә туктатырга мөмкин!

— Атам корган йорт бу,— диде Булатхуҗаев.— Картыбыз диндар. Ә сез шулар урынына ни язып куяр идегез?

— Мин, тәкъсир, Насыйр Бохараиның бер шигырен туган телемә тәрҗемә иттем. Ни әйтсәк тә, без — төрки кавем. Кабинетымны гарәпфарсы теле басмасын әле дидем.

— Хуш.

Юлтай стенага язгандай хәрәкәт ясап, шигырь әйтте:

«Бабайларның алтын сүзен искә алмый ярамый;
Кайбер чакта нәни инә сөңгедән нык яралый».

— Бәрәкалла, Чека өчен махсус чыгарылган шикелле бу, һич тә мең ел элек язылган дип уйламассың! — дип көлеп җибәрде Булат-

хуҗаев. Аннары урта бармагындагы йөзеген салып, кунагына сузды: — Бу бүләк сезгә хөрмәтем билгесе булсын, Юлтай би. Кирәк чакта мөһер итеп тә файдаланырга мөмкин аны.

Симиниев инде мондый юмартлыкны көтмәгән иде. Әмма баш тартып кәнфитләнмәде, йөзен балкытып, рәхмәт яудыруын белде:

— Сезнең ышанычыгыз миңа иң зур дәрәҗә, тәкъсир! Игелегегез үзегезгә, якыннарыгызга, тарафдарларыгызга яхшылык булып кайтсын.

— Амин!

Янып торган якут кашлы йөзек саф алтыннан коелган иде. Юлтай аны шулай ук урта бармагына киде дә:

— Сөбханалла, бу кадәр дә таман, килешле булыр икән! — дип сокланды.

Көннең калган өлешен һәм төнне Симиниев Чекада кизү торып уздырды. Кичке караңгылык куерганда базарларның берсендә янгын чыгу аны гаҗәпләндермәде. Ул бу хәбәрне көтә иде инде. Ә менә иртән шалтыраган телефон йокысын ачып кына калмады, тешләрен дә шыкырдатырга мәҗбүр итте. Ул болай да һәммәсе ачык ишетелүгә карамастан, хәбәр бирүчедән кат-кат:

— Каратауга баручы кәрванмы? Байкучатов отряды кулына? Аны кем таныган? — дип төпченеп сорау алды.— Менә кабахәт, менә җанымнан җөда булгыры имансыз эт! Ә сез, миңгерәү сыер кәлҗемәләре, бу югалту өчен башыгыз белән җавап бирерсез!! — дип янады.

Ул трубканы куйгач та тынычлана алмыйча: «Юк инде, җитәр, йә Байкучатов дөмегә, йә мин Юлтай исемен йөртмәячәкмен!» — дип ант итте. Блеккер, Булатхуҗаевлар алдында хур ителүе җенен чыгарганлыктан, үч алу планын корып зәхмәтләнә башлады.

## 33

Бәрелештән соң әзрәк хәл алгач, кызыл гаскәрләр сугыш кырын йөреп чыгып, һөҗүм итүчеләрнең икесе авыр яраланганлыгын ачыклады һәм аларга беренче ярдәмне күрсәтте. Аннары һәлак булган ике иптәшләрен коедан бер читтәрәк җирләделәр, чәчелеп калган дошман мәетләрен дә җыеп гүргә иңдерделәр. Ашыга иде Байкучатов, әмма кешелеклелек күрсәтүдән үзен тыя алмады. Монда Австрия фронты түгел, дошманның да — үз мөселманың, баксаң, алар арасында кызыл гаскәриләрнең я берәр авылдашы, я берәр танышы да очрап куюы бар. Җирләү дошманга түгел, мәрхүм кешегә хөрмәт күрсәтү. Фарукҗан иптәшләренә дөрес әмер бирүен аларның күзләреннән үк шәйләде: әле яңа гына кәрәк-китмәннән аерылган диһкан-игенчеләр кан коюга һич тә сусап тормый, аларга җир эше, кабер казу булса да, күңелгәрәк шөгыль иде.

Йокләр төялеп, яралылар атларга атландырылгач, сафы сирәгәйгән төркем, боерык көтеп, командирына төбәлде. Байкучатов киңәшкән төстә:

— Әйләнеч булса да, Зыятдинга чүен юл буйлап кайту хәвефсезрәктер, ә? — дип эндәште.— Тау итәгендә дошман посып торып, кинәт һөҗүм итәргә мөмкин. Сахрада без аны әллә кайдан күреп алырбыз. Атыша башласак, безгә ул тирәдә ярдәмне тизрәк күрсәтерләр. Шулай ич?

— Дөрес,— диде Амантай.

Ул монда үзен Фарукҗанга иң якын кеше саный, шуңа күрә командиры янәшәсендә булырга тырыша иде. Таңгы бәрелештә дә ул аның әмерен көтеп кенә торды, үҗәтләнеп атышты. Тидерүе ни чама булгандыр, әмма дошманның алар турысыннан якын килә алмавы хак. Байкучатовның дошманнар куплектән өркеп калмавы, салкын

кан белән кирәкле әмерләрне вакытында бирүе Амантай күңеленә дә ышаныч өстәгән иде. Югыйсә, «эшләр харап, бетәрбез, ахры», дип, белгән догаларын укый башлавын да яшерәсе юк. Әмма бирешмәделәр, җиңделәр. Йөрәкле икән чекист, юкка гына хәтәр җыенаятьнең очына чыгарга алынмаган икән.

Шулчак Байкучатовның икенче ягыннан барган Иргәш:

— Амантай,— дип эндәште,— сез ничек уйлыйсыз, мөселманча булдымы инде бу?

— Нәрсә?

— Кәфенсез генә күму. Моның өчен ходай ормас микән безне? Бичараларның каргышы төшмәс микән?

Сорау Амантайга бирелсә дә, үзенә юнәлтелүен шундук аңлап алды Фарукҗан. Диндар Шәрыкнең бар кайгысы шул булыр инде! Әмма ул, Иргәшнең чынлап хафаланган кыяфәтенә күз йөгерткәч, үзенең дә шиген таратырга теләгәндәй, йомшак кына итеп:

— Тәкъдирләре шул булгандыр,— диде.— Язмыштан узмыш юк.

Иргәш сораудан аның болай җиңел котылуын өнәмәде бугай, пошынулы төстә:

— Мәетләрне якындагы кышлакка гына илтеп тапшырасы булган икән,— диде.— Йола буенча күмәрләр иде. Ясин чыгып.

— Әгәр алар безне тураклап атса, нишләтерләр иде икән? — дип телгә килде Амантай.— Ялчысына ямаулы чапанын да бирергә кызганучы байлардан кәфенлек артыр идеме?

Иргәш дәшмәде. Фарукҗан көлемсерәп:

— Ясин чыкмас өчен исә алар безне кяфер дип игълан итәр иде! — диде.— Күрәш бара, егетләр. Күрмисезмени, кышлак халкы да ике тарафка бүленгән. Фронттагы кебек. Ә фронтта йолаларны бик саклап булмый. Герман фронтында өч ел җәфа чиктем, анда мөселманнар да чебен кебек кырылды.

— Аларны кәфенсез күмдегезме? — дип сорады Амантай.

— Кая инде кәфен эзләргә вакыт?!

Дөяләрнең бер өлеше харап булганлыктан, коралның шактыен атларга астылар. Каракүл тиресен дә кое янында калдырасы килмәгәнлектән, йөк күп җыйналды — барлык гаскәриләр җәяү кайтырга мәҗбүр булды. Багбан коесы инде әллә кайчан артта калды, әмма чуен юл әле һаман күренмәде. Төнлә ни ял, ни йокы татымаган сугышчылар дөя көенә сүлпән генә атлый, көчәя барган эсселек торган саен башны авырайта, миңгерәйтә иде.

Иртәнге иксез-чиксез зәңгәр күктә бүрек кадәр генә бер болыт йөзеп йөрде. Ул Фарукҗан игътибарын тартырлык зур да, кое да түгел иде. Әмма бер заман чүлдә күнегелмәгән ниндидер бер ят тавыш ишетелде. Ул Зыятдин тавы ягыннан ишелеп килде дә минут эчендә, шарлавыктан койган шикелле, тоташ яңгыр агымына әйләнде һәм, ни дә булса уйлап өлгергәнче, чуар кәрванны исәнгерәтеп, җиргә бәреп екты. Тирә-як исә ян-якты, балкып торган кояш та баш очында гына иде. Су ташкыны ун-унбиш минут кына дәвам итте. Әмма ул шулкадәр кинәт һәм шулкадәр кыска вакыт эчендә коелса да, бер генә җеп бөртеген дә коры калдырмады. Гүя, яңгыр яумады, кемдер өстән галәмәт зур кисмәк белән су бушатты!

Фарукҗан шаркылдап көлгән тавышка башын күтәрде. Иргәш лычма су булган гимнастеркасын сыгып маташа һәм тәмам шәрә калганчы чишенеп ташлаган бер иптәшен үрти икән.

— Гомерегездә бер госел коендыгыз, ичмасам!

— Ходайның кодрәте, сөбханалла.

— Мамыкның кирәген бирде бу, бичара диһкан тагын аһ итә инде.

— Әле кайчан болай мунча керер идек?..

Байкучатов сикереп торды да шулай ук чишенә башлады. Һава җылы, дымлы, мунча ташына су тондыргандай, җирдән бу күтәрелә

иде. Амантай сокланып:

— Фарукҗан ага, карагызчы! — дип мөрәҗәгать итте.

Һәр тарафта — эре-эре бөртекле ком диңгезе. Яңгыр аны утырткан, юган, кыздыруын дәвам иткән кояш нурларыннан миллионлаган бөртекләр, бриллиант сипкәндәй, җем-җем килә. Әле яңа гына коеп узган яңгыр сулары бер-берсе белән кушылып, ком өстенә матур буразналар сызган. Тузаннан арынган һава сафлыгы, пакьлеге белән сулап туйгысыз. Сугышчылар, күнитекләрен дә салып атып, юеш җирдә яланаяк йөгерешеп, үзара шаярышып рәхәтләнә. Аларны әле кайчан гына канлы бәрелештә үлем белән чәкәләшкән, йончыган, сүлпәнләнгән хәлдә чүлдән атлаган кешеләр дип күзаллавы да мөмкин түгел, һәммәсе сабый бала шикелле иде. Бары яралылар гына бу күңелле ыгы-зыгыга кушыла алмый кызыгып карап тора, тик алар да атлар җиргә чүңкәйгәндә үзләренең имгәнми котыла алуларына куанган иде.

— Иптәшләр, онытылмыйк. Зыятдин станциясенә тизрәк барып җитүебез хаҗәт!

Атлар, дөяләр торгызылды, йөкләр яңадан асылды, кораллар барланды — кәрван сәфәрен дәвам итте. Бер сәгатьтән алар инде Бохара-Сәмәрканд чуен юлына да килеп җиттеләр. Байкучатов тиздән юл төзәтүче эшчеләрне күреп алды. Шуларның берсе каршы килеп сәлам бирде, кәрванның кайдан юлга чыгуы белән кызыксынды. Эшчеләрнең һәммәсе мылтыклы булуын Фарукҗан ерактан ук чамалаган иде инде. Аларның өлкәне:

— Сәетморат бәк мәлгуньнәре азына, бүген төнлә менә тагын күпме юлны эштән чыгарганнар,— дип аңлатты.— Ярый әле вакытында хәбәр итүчеләр табылды, поездлар һәлакәткә очрамады.

— Коралыгыз җитәрлекме соң? — дип сорады Фарукҗан.

— Бар. Безгә хәзер эшләргә генә түгел, тимер юлны сакларга да туры килә ич.

Байкучатов отряды Зыятдин станциясенә көндезге сәгать уннарда кайтып керде. Гарнизон башлыгы трофейларны кабул иткәндә шатланып һәм Фарукҗанны мактап:

— Явыз карчыгаларның канатларын кискәнсез, рәхмәт! — диде.— Басмачылар кулына төшсә, бу кораллар тагын күпме кешенең башына җитәр иде. Һәлак булган иптәшләребез кызганыч, әмма сугыш корбансыз гына булмый шул.

— Дошман унөч кешесен югалтты, авыр яраланган янә икесен монда алып кайттык әнә. Җиңел яраланганнары да байтак булгандыр, качып котылдылар.

— Аңлашыла. Ә сезне монда Чекадан эзләделәр. Бохарадан иптәш Эминев. Каган госпиталеннән Мартьянов дигән берәү дә үзен күрүгезне үтенде.

Ниндидер мөһим яңалык ишетергә сусаган Фарукҗан, җанланып һәм ашыгып:

— Күптән эзләделәрме? — дип сорады.

— Мартьянов кичә кичтән таптырып маташты, ә Чекадан — бүген бер-ике сәгать элек кенә әле.

— Телеграф эшлиме?

— Эшли,— диде гарнизон башлыгы.— Тик мин иптәш Эминев әмерен язып алдым. Ташкенттан Мостафа Янбулатов Бохарага дип юлга чыккан икән. Баһаветдин иптәш Шиһабетдиновның дусты. Сез аны монда көтеп алырга, аннары бергә Бохарага кайтырга тиеш.

— Поезды монда кайчан килеп җитәчәк?

— Өч-дүрт сәгатьтән. Кызыл Гаскәр командиры икән Янбулатов, хәрби киемнән. Сезне беренче вагон янында көтәчәк. Паролегез — кош исеме, таҗикча кул куючы шымчыгыз атын көйлисез. Янбулатов

шуңа икенче шымчыгыз исемен әйтеп җавап бирергә тиеш.

— Яхшы,— диде Фарукҗан тынычланып.

— Юынып, тамак ялгап, бераз черем итәргә дә вакытыгыз бар. Ятак — күрше бүлмәдә, үзебез уятырбыз.

— Бик әйбәт, рәхмәт. Юлда безне яңгыр шундый итеп коендырды — яңадан тугандай булдык.

Байкучатов егетләрен гарнизон ашханәсенә алып китте. Солдат сые һәммәсенә килеште, суынган дип тормадылар, китергән берсен ялтыратып бардылар. Аннары штаб урнашкан йортның тәрәзәләре томаланган салкынча бер бүлмәсендә киез түшәлгән идәнгә тәгәрәделәр.

* * *

Хәрби эшелон станциясе билгеләнгән вакытта килеп җитте. Ачык платформада туплар тезелеп киткән, алар арасында юлның як-ягына каратып пулеметлар урнаштырылган. Туп көпшәләренә асып тарттырылган плащ-палаткалар эчендә солдатлар бара. Платформа саен кызыл гаскәриләрнең икешәре ачык мәйданнан тирә-юньне күзәтә. Күренеп тора: Бохара хезмәт ияләренә ярдәмгә теләсә кайчан һөҗүмне кире кагарга сәләтле көч юнәлтелгән.

Поезд туктауга, беренче вагоннан да шактый кеше перронга коелды. Барысы да хәрбиләр. Аларның кайсылары вокзалга, станция башлыгы бүлмәсенә кереп китте, байтагы, оеган буыннарын язып, эшелонның койрыгына таба йөгерде. Байкучатов вагон ишеге төбендә укмашып торган төркем яныннан, үзалдына сәйранда йөргән кеше шикелле, «Бум-бум-бум, бум-бум-бум», дип көйли-көйли ашыкмый гына атлап узып китте. Амантай белән Иргәш, ул өйрәтеп куйганча: командирларын бераз читтәнрәк күзәтеп торырга тиешләр иде.

Фарукҗан, як-ягына каранмаса да, төркемнән аерылган бер кешенең үзенә иярүен сизми калмады. Бик әйбәт: «Бум-бум-бум, бум-бум-бум»...

Артыннан җитеп килгән хәрби аның белән тигезләшкәч:

— Бу көй мине «биһуш» итә,— диде — «Биһуш!»

Фарукҗан, көйләвеннән туктап, сүз кушучыга таба борылды. Янәшәсеннән калку буйлы, җитди чырайлы кызыл гаскәри атлый иде. Пөхтә кырынган, әмма кара кучкылланып төк төпләре беленеп тора. Озынча йөзле, калын иренле, шактый юан муенлы ир икән.

— Безгә һушсыз калырга ярамый, иптәш Янбулатов,— диде Фарукҗан.— Юлда ялыгырга мөмкин, тик шуннан арысына рөхсәт юк.

— Мин әле монда тәгаен очрашуыбызга ышанып бетмәгән идем. Сез, Фарукҗан иптәш, хәзер Бохарага кайтасыздыр ич?

— Әйе.

— Алайса вагонга керик.

— Анда командирлар гына барамы?

— Штаб. Әмма сез дә сыярсыз, бик кысан түгел.

— Без анда иркенләп сөйләшә алырбызмы соң? — диде Фарукҗан Мостафа Янбулатовның күзенә карап.— Аулаграк җир кирәкмәсме?

— Алайса эшелонның койрыгынарак китик. Иптәшләрегез монда утыра торсын, сүз беткәч, без дә шушында әйләнеп килербез.

Алар берничә платформаны узарга өлгермәде, арттан Иргәш куып җитте.

— Фарукҗан әкә,— диде ул,— хәзер ышандым инде, сезне ниндидер бер бәндә күзәтә. Мин аны без бая өчәүләп станциядә йөргәндә үк абайлаган идем инде.

— Ниндирәк кеше?

— Озынча йөзле, кыйгач кашлы, кара сакаллы. Чалма-чапан, кәвеш кигән.

Байкучатов Каган вокзалында күргән кешегә охшый икән ләбаса. Тураев сүзләрен дә онытмаганлыктан, ул кинәт артына борылып карады. Перронда поезд килгәндә куба торган ыгы-зыгы: сәфәргә җыенган пассажирлар, карбыз-кавын сатып йөргән кышлак халкы, су эзләп ары-бире чапкан солдатлар — мәйдан гөж килә, бары ул эзләгән әлеге кеше генә күренми.

— Кайда соң ул хәзер?

— Белмим. Шушы тирәдә генә кайнашадыр әле.

— Эшелон монда озак туктап торачакмы? — дип сорады Байкучатов Янбулатовтан.

Нәкъ шул вакыт паровоз сузып-сузып кычкыртты, буферлар бербersенә бәрелде, солдатлар үз платформаларына таба йөгерешә башлады. Фарукҗан Иргәшкә:

— Ул бәндәгә күз-колак бул, шушы поездга утырмады микән? — диде.— Үз вагоныңа бар, поезддан кала күрмә тагын!

Байкучатов белән Янбулатов туплар гына төялгән, солдатлар да, пулеметлар да күренмәгән бер платформага үрмәләп менеп, лафет өстенә утырдылар. Күрше платформадан аларны күзәтеп торган солдатлар, үз кеше булуларына ышаныпмы, аны-моны дәшми үз шөгыльләрендә булдылар — кайсы черем итәргә ятты, кайсы гәп сугуын белде. Поезд йөрешен тизләткәннән-тизләтеп Зыятдин станциясен артта калдыргач, Фарукҗан йомры гәүдәле, кояшта янган йөзле, үз-үзен тотышыннан ук тәҗрибәле командир икәнлеге күренеп торган юлдашыннан:

— Димәк, безгә булышырга киләсез? — дип сорады.

— Юк, мин бу артиллерия дивизионыннан түгел, хәзерге вакытта Җидесуда булырга тиешле кеше. Ташкентка эш белән барасымны белгәч, Икенче полк кызыл гаскәриләре Шиһабетдинов фаҗигасен ачыклап кайтуымны үтенделәр. Баһау язмышы үземне дә пошындырганлыктан, Ташкентта тиешле җитәкчеләргә мөрәҗәгать иттем.

— Үзегезне бу фаҗига нигә кызыксындыра соң?

— Кызыксындыра дию әз, борчый. Баһау танышым, көрәштәшем генә түгел, дустым да иде.

— Ташкентта бу вакыйганы ничек аңлаттылар инде?

— Имеш, ул үзен-үзе аткан. Мин моңа, билгеле, ышанмадым. Ышана да алмыйм, Баһаветдинның ни дәрәҗәдә тормыш сөючән кеше икәнлеген яхшы белә идем мин.

— Кызык.

— Нәрсәсе кызык?

— Юк, мин болай гына әйтәм,— диде Фарукҗан уңайсызланып һәм үзен ялгыш аңлаудан куркып.— Мәзәк, тамаша эзләүдән түгел, фикерләребез туры килүенә шатланам. Иптәш Әминев сезне беләмени?

— Белми. Ташкентта аның яхшы бер танышына тап булдым. Төркестан фронты штабында. Шөбһәләремне сөйләп биргән идем, ул шундук Бохара Чекасына телеграмма сукты. Әминевтән сезнең белән бәйләнешкә керүне киңәш иткән җавап алдык.

— Аңладым, Мостафа иптәш. Тик мин сезне тынычландырырлык ни генә әйтә алырмын икән?

Байкучатов шулай диде дә бер мәл тынып калды. Эшелон кызган һаваны ярып алга чаба, ачык платформада туктаусыз җил өргәнлектән, бөркүлек җанга тиярлек түгел иде. Җанга тия торганы билгесезлек, үз теләгеңә ирешә алмау иде. Кемнең нәрсәгә омтылганын, аның дусмы, дошманмы икәнлеген анык кына белеп тә булмый. Бөтенләй башка хыял, башка максат белән яшәсә дә, кайберәүләр революционер, тормышны үзгәртер өчен көрәшүче булып кылана. Ә ме-

нә бөтен җаны-тәне белән тормышны үзгәртеп корырга ашкынып та, әүвәлгечә яшәргә, иске тәртипләрне сакларга омтылучы ролен уйнаучылар бармы икән Бохара республикасында? Бәлки андый кеше мондагы чын көрәшне, көчләр нисбәтен, кемнәрнең сүзе белән гамәле туры килү-килмәвен ачыграк күрер иде? Бәлки генә түгел, ә нәкъ менә шундый зат чека өчен табыш буласына икеләнмәскә мөмкин. Артык туры, чамасыз беркатлы хезмәткәрнең монда каш ясыйм дип күз чыгаруын көт тә тор. Тик юлбарыс сарык тиресен ябынса, күгәрчен тилгәндәй кычкыра башласа, бүтән тереклек ияләре буталып бетмәсме? Ул чакта көнлекче ялчы-мәрдекәр, уртагыннан җир эшкәртүче — чәйрекәр, фәкыйрь игенче — диһкан гозерен кемгә сөйләр? Ярдәм аласы урында алар бәлагә генә тарымасмы? Юк, хәзер инде Фарукҗан баскан юлыннан чигенә дә, үзен бүтәнчә таныта да алмый. Шуңа күрә, Бохара хәлләрен, Шиһабетдинов фаҗигасенә мөнәсәбәтен Янбулатовтан яшерү кирәкме икән? Исемнәрне атамыйча сөйләргә дә бирергә?

— Әлегә хәрби комиссар фаҗигасе һаман томанлы,— диде ул күзен офыктан алып.— Минемчә, кайберәүләргә: «Ул үзен-үзе аткан икән», дигән хәбәрне тарату файдалырак. Моңа шик белдерүчеләрнең бугазын чәйнәп өзәргә дә әзер алар. Әйтик, минекен.

— Сез Шиһабетдинов мәетен үз күзегез белән күрдегезме? — диде Янбулатов, карашын Фарукҗанга төбәп.

— Әйе.

— Аны чаян, каракорт ише берәр хәшәрәт чакмаган идеме?

Байкучатов гаҗәпләнеп гәптәшенә күз сирпеп алды да:

— Нинди чаян, нинди каракорт ул тагын? — дип сорады.

— Агулы бөҗәкләр. Баһаветдин Тәрмиздә чакта шулардан бик курка иде.

— Ә-ә,— дип көлемсерәде Фарукҗан.— Бохарада кеше кыяфәтендәге чаяннар хәтәррәк шул. Чагарга гына торалар. Сез Рахманколны беләсезме? Хәрби комиссарга ничек килеп тагылган икән ул?

— Баһаветдин ихлас күңелле, кечелекле, ярдәмчел кеше иде. Рахманкол, бәлки, аны шуңа ошаткандыр,— диде Мостафа җавап итеп.— Заманында ул аңа эш табышкан, аннары герман фронтына китәсе егетнең Төркестанда калуына — өлкән яшьтәгеләр тупланган Ташкент халык дружинасына эләгүенә булышкан бугай. Баһаветдин инде аш белән атканга таш белән атучы түгел иде. Аеруча дус итмәсә дә, Рахманколны чит күрмәвен беләм.

— Ә нигә дус күрмәде икән ул?

— Рахманколда революцион рух чамалы була. Дөресрәге, булмый. Октябрьдән соң контрларга кушылмавы гына гаҗәп. Безнең якка инде ул Баһаветдин йогынтысында, аның абруен танып чыккандыр.

— Командирына, дустына хыянәт итә аламы ул?

— Белмим,— диде Мостафа икеләнеп.— Шикләнәсезмени?

Фарукҗанның бу сорауга туры җавап бирәсе килми иде.

— Мин үземә дә ышанмыйм бугай инде хәзер.

— Бохара Чекасы бу җинаятьне ачарга җитди тотындымы соң? Көче җитәрме?

— Ничек дияргә инде? Беренче көннәрдә очрасагыз, мин сезгә, мөгаен, тискәре җавап биргән булыр идем. Хәзер өметләрем артты. Карагыз әле, сез Шиһабетдиновка ачу саклаган берәр хатын-кызны белмисезме? Әйтик, гыйшык тоткан, алданган...

Янбулатов кискен рәвештә:

— Мондый хәлнең булуы мөмкин түгел! — диде.— Баһаветдин, көчле чын шәхесләргә хас булганча, шәфкатьле, миһербанлы кеше иде.

— Шиһабетдиновны тәмам әүлиягә әйләндереп бетердегез инде!

Фарукҗан моны юлдашына ышанмаудан яки аны үртәргә теләүдән әйтмәде. Янбулатов, корт чаккандай, лафеттан кинәт сикереп торды, очлы күзләре белән чекистны бораулап, ачулы тавышын күтәреп:

— Сез аның хакында ни беләсез соң? — диде.— Күренеп тора: якынча да күзалламыйсыз! Бәлки ул мөселман кызыл гаскәриләренең иң сөекле, иң шанлы, иң үткен командиры булгандыр? Иң намуслысы!

Аптырабрак калган Байкучатов та торып басарга мәҗбүр булды.

— Чү-чү...

— Ак полковникларны бер карашы белән көйдерә иде Баһаветдин! Нәрсә ул мифик әүлия? Безнең шикелле кара халык арасыннан чык та син менә, кайчандыр академияләр бетергән, гомер буе сугыш гыйлемен өйрәнүдән бушамаган генераллар эшен — штаб башлыгы вазифасын үтә, аннары атка атланып, кылычыңны болгый-болгый эскадроннарны атакага алып бар яки фетнә күтәргән контрлар оясына өлкә хәрби комиссары төсендә япа-ялгыз килеп кер! Андый тагын кемне беләсез?

— Туктагыз әле, кызмагыз болай!

— Безнең тыйнак, кыюсыз татар кызларының Җәркәнттә Баһаветдинга ничек гашыйк булулары, туйда Шаһикамал белән икесенә нинди теләкләр теләгәнлеген беләсезме?

— Сез үзегез сөйләмәгәч, мин аны кайдан ишетим соң? Әйдәгез, утырыйк әле!

## 34

Балҗан атын ак күбеккә батырып хәлдән тайдырганчы куды да куды. Ниһаять, шомлы кое, аның тирәсендә икесе ике якка мәтәлгән адәм кыяфәтендәге козгыннар шактый артта калды. Яраланган гынамы иде алар, әллә беттеләрдәме — Балҗан бу хакта бөтенләй уй-фикер йөртмәде, бары җил чыгуын теләүдә булды. Җил иссә, чүл күкрәгенә батып кергән ат эзләрен бик тиз ком каплап китәчәк, ул чакта инде аны берәү дә артыннан килеп тота алмаячак иде. Әмма Балҗан күпме генә ходайга ялвармасын, чәч бөртеген селкетерлек тә җил чыкмады. Шул ук вакыт бу тирәләрдә кеше яшәвен белгерткән билгеләр дә шәйләнмәде. Арыган ат алдагы барханнар сыртына күтәрелгән саен ул офыкта сарык көтүе яки дөяләр кәрваны күренмәсме дип күзен талдырды, ләкин тирә-юньдә һаман бертөрле ком диңгезе генә җәелеп ята иде.

Көнчыгышка таба гына барып дөрес эшлиме икән соң ул? Кичә эңгер төшкәндә алар Каганнан төньякка, Гыйҗдуванга юл тоткан иде. Шаһруд арыгын кичәргә өлгермәделәр, димәк, алар күп дигәндә дә ун чакрымнан ары җир узмагандыр. Бәдбәхет җайдаклар, Балҗанны кулга төшергәч, башта шулай ук төньякка таба хәрәкәт итте сыман. Хәер, күзләре бәйләнгән хәлдә булганлыктан, ул инде моны тәгаен генә белми. Шаһруд идеме ул, Зәрәфшән елгасы тармагымы — бер дәрьяны кичүләре генә истә. Аннары янә төне буе өзлексез атларын кудылар. Тимер юл аркылы чыкмадылар шикелле — Балҗан һәр тавышка бик уяу колак салып барды. Төрекмәннәргә икән, димәк, алар Әмударьяга таба юнәлергә тиеш иде. Кәрван йөргән кеше түгел, чүлдә адашып, сусаудан яки ачлыктан харап булуы да ихтимал Балҗанның. Бәлки аңа көньяк-көнчыгышка борылу кирәктер, бәлки ул шул якта берәр җан иясенә тизрәк юлыгыр. Бохара, Каган кайсы якта калды икән хәзер? Аты озакка чыдармы? Берәр кое да күренми ичмаса, кояш төшлектән узды лабаса инде.

Менә такыр башланды. Арыган ат җиңелрәк атлый, аның тояклары хәзер инде җиргә батып керми иде. Артына борылып караган Балҗанның эченә җылы йөгерде. Дөрес, базар мәйданыдай тип-тигез такырда офык киң, ялгыз җайдак анда әллә кайдан күзгә бәрелә иде. Тик, хәрәкәттә бәрәкәт, диләрме әле?

Тагын берничә сәгать атлаганнан соң, бахбай туктады. Балҗан, иярдән сикереп төшеп, малкаенын ялларын тарады, маңгаен сыйпады.

— Түз инде син, җирәнкәем, түз! Сусадыңмы? Үземнең дә авызым бик кипте, ләкин нишлим соң? Чыдарга кирәк безгә. Йә тимер юл, йә елга буена барып җитми калмабыз. Бәлки әле аңа кадәр мөлдерәп торган сулы коега да очрарбыз. Әйдә бергә янәшә атлыйбыз?

Әмма Балҗан аны йөгәненнән сөйрәп алдан атларга мәҗбүр булды — җирәнкәй шунда гына урыныннан кузгалды. Күпмедер баргач, аяк астында көйгән карабаш, кыңгыртбаш үләннәре очрый башлады, тагын бераздан сыек яшел төстәге көйрәвек һәм әрем үсемлекләре дә күренде. Күптән түгел явып узган яңгыр аларга җан керткән иде, ахры. Балҗан үләннәрнең тапканын берсен бахбаена өзеп каптырырга тырышты. Сусаудан хәлсезләнгән ат, телен әйләндерергә бик теләмәсә дә, корыган үләннәргә үзе дә үрелгәли иде.

Көн хәтәр эсселәнде, әмма ял итәргә туктаса, такыр уртасында ятып калудан курыккан Балҗан һаман атлавын дәвам итте. Хәзер инде ул эченнән кое янында атын сугармавы һәм юлына запас су алып китмәве өчен үзен сүгә иде. Куркак ике үлә, дип юкка гына әйтмиләр шул. Ничә чакрым үтте икән инде ул? Әһә, күктә ниндидер кош күренә, димәк, су моннан бик үк ерак та түгелдер.

Нинди гөнаһсы, нинди языгы бар икән Балҗанның? Нигә болай гел җәфа чигә икән ул? Изгеләргә әз табындымы, сәдаканы җитәрлек бирмәдеме? Бервакыт әнисенә ияреп әллә кайдагы Пир төрбәсенә кадәр барды ич инде. Төрбәнең ачык ишеге төбендә бусагага тезләнеп, маңгаен җиргә орды да шул тирәдәге балчык кантарларын, тузанны кулларына, йөзенә ышкыды, иңнәренә тидерде. Ишегалды уртасында үскән изге агач тирәли өч мәртәбә әйләнеп чыкты, аңардан саркып аккан сутны җамаякка җыеп, шулай ук битенә, муеннарына сөртте. Әнисеннән күреп һәм, «Монда бар нәрсә дә изге!» дип чын күңеленнән ышанып, төрбәнең барлык диварларына, почмакларына, ишек яңакларына кагылды. Юл буе үзенә бәхетле язмыш теләп кайтты. Аның хәләл көч белән намуслы, тыйнак тормыш алып баруын раббесы нигә күрми, аны нигә аямый икән?

Хәрби комиссар фаҗигасе кыюландыргандыр инде бу хәшәрәтләрне. Амантай эзли башладымы икән әле Балҗанны? Чекист дусты да булышса, ул инде кул кушырып ятмас, ләкин иксез-чиксез бу Кызылком чүлендә адашкан ялгыз адәм баласын табып алу мөмкинмени? Ышаныч бары үзендә генә, бархannar арасында күмелеп калмаска, ничек тә кешеләргә юлыгырга тиеш ул. Ә кешеләр шундый төрле-төрле...

Калак сөякләре арасын сулык-сулык иттереп ашыйсы килде. Сусаудан авызы кибеп, вакыт-вакыт күз аллары караңгыланды, әмма ул көньяк-көнчыгышка таба һаман атлавында булды. Бары кечкенә якта гына офыкта кое күренде. Аның суы тозлырак, әмма атны сугарырлык иде. Балҗан үзе авызын берничә кат чайкады, бит-кулларын юды. Берничә чиләк суны бахбаенын өстенә дә тондырды. Аннары җирәнкәенә менеп атланды да тагын юлын дәвам итте. Сарык көтүе эзен дә күргәч, хәзер инде тиздән Зәрәфшән яки Әмударья үзәнлегенә килеп җитәсенә шиге калмады. Нужа печән ашата дигәндәй, кичәге һәм бүгенге бәрелештән сабак алганлыктан, ул юл буе кулыннан ычкындырмаган наганын пәрәнҗәсе астына яшерергә булды. Моның өчен Амантае бүләк иткән баш яулыгыннан телем-телем ике тасма ертып алды, шулар белән элмәк ясап, коралны муенына асып куйды. Амантае күрсәтсә дә, наганнан атып караганы юк, ерактан дошманына тидерүе бик икеле, әмма аны үз тырнакларына ансат кына эләгәчәк калҗа санаучы тәкәббер ләгыйньнәргә ник гөрселдәтеп карамаска? Якыннан!

Янә бер сәгать чамасы барганнан соң, Балҗан тоткан юнәлештән беркадәр төньяктарак көтү күренде. Әһә, әнә түгәрәк киез өй дә ерак

түгел. Анысы офыкның кеньягында иде. Кайсы якка борылырга? Көтүчеләрдән кирәкле нәрсәләрне сорашырга, тирмәдә исә бер йотым булса да су табылыр. Бәлки көтүчеләрнең берәрсе шулай ук киез өй тирәсендә калгандыр?

Балҗан ымсынып диярлек тирмәгә таба китте. Кайчандыр алар нәкъ менә шундый сахрада Амантай белән очрашканнар иде ләбаса. Көтеп алсын иде ул аны тагын! Кочагына килеп егылыр да туйганчы елар иде ичмаса. Юк, еларга ярамый. Амантай аны бичара, мескен кеше итеп күрергә теләмәс. Үзе дә тәвәккәл, гайрәтле җанга әверелеп бара ул. Балҗанны да йөрәклерәк, батыррак итеп күрергә ашкына.

Тирмәдә һәм аның тирәсендә бер җан иясе дә юк иде. Балҗан киез өйдә беренче эш итеп чәйнеккә барып ябышты. Касә эзләп торырга сабыры җитмәде, калдык чәйне шуннан гына эчеп җибәрде дә, җиңел сулап, кое янына чыкты. Улаклар буш иде. Ул тире чиләк белән тирәннән су чыгарды һәм татып карады — йә хода, шундый да тәмле! Сап-салкын. Балҗан ниндидер комсызлык һәм дәрман белән ашыга-ашыга тагын берничә чиләк су алып улакка бушатты — җирәнкәен сугарды. Тирмәдә үзенә ризык та табылды, ә атына нишләргә менә? Якын-тирәне сарык көтүе ялап бетергән диярлек — ник бер үлән сабагы күренсен! Юл сорашыр өчен көтүчеләрне күрү кирәк, тик аларны эзләп барыргамы, монда үзләре уралып кайтуын көтәргәме? Хатын-кызның ялгыз башы каңгырып йөреп бәхет эзләве Бохара мәмләкәтендә бәладән бүтән нәрсә китерүе мөмкин түгелдер. Баштан-аяк коралланган хәлдә эзләсә дә! Көтүчеләр әле шәфкать күрсәтүе ихтималрак халык. Таң калсалар да, зыян итмәсләр. Төне буе куллары иягә бәйләнгән килеш атта, көндезен исә юлның байтак өлешен сусаган хәлдә җәяү узганлыктан, аның бөтен гәүдәсе ватылган, изрәгән, йокы һәм ял сорый иде. Улак кимерә башлаган җирәнкәе әнә яңа хуҗасының су белән сыйлавына гына риза түгел, көтүчеләр хәзинәсеннән алып чыгып биргән бер сынык пәтернан аның кече теләнә дә йокмады, билгеле. Балҗан аны ялыннан сыйпый-сыйпый: «Тиздән, малкаем, сусыл үләнле үзәнлеккә дә барып җитәрбез».— диде. Аннары тирмәгә кереп, тагын бер мәртәбә чабаннарның ярмаларын барлады. Ул кеше әйберенә тияргә дә курка, атын да кызгана иде. Әгәр беренче аяк басачак кышлагы яки станциясе әле ерак булып, ач җирәнкәе ярты юлда аяктан егылса? Менә шундый уй Балҗанны тәвәккәлләргә мәҗбүр итте — ул атына ике җамаяк җүгәре чыгарып салды. Шуннан соң тирмәдә көтүчеләрнең урын-җирләренә сөялеп, хәл җыярга утырды. Бахбае җүгәрене ашап бетергәнче генә гәүдәсенә ял бирергә. Төнлеге ябык киез өйдә тыштагы кебек бөркү түгел, рәхәт. Әмма кургашын керфекләр ябылырга гына тора икән...

Балҗан йокыга талуын сизми дә калды. Кое янында яңгыраган тавышларны да башта төшендә сыман кабул итте. Тирмәгә якынлашучы бер ир-ат:

— Ул әллә нималәрне гәперде,— дигәндә генә тынычсызланып күзләрен ачты. Чү, әллә хуҗалар кайткан инде?

Килеп ишек ярыгыннан караган иде — иманеп китте: тирмәгә таба әүвәлдән аңа таныш берәү атлый иде. Көтүче түгел, бу кабартма яңаклы, озынча чандыр буйлы ирнең Бохарада Нәзир янына әллә ничә тапкыр кагылганы бар иде. Нәрсә, Балҗанны эзәрлекләп йөрүеме? Иртән сахрада кабынган бәрелеш эзләрен күрде микән? Хәзер яшеренергә соң инде. Бәлкем пәрәнҗәле хатынны танымас? Үзен дә белмәмешкә генә салынырга кирәк. Көтүче булып кыланырга!

— Өйдә кеше бармы?

— Ирем чүлдә мал багады,— дип аваз бирде Балҗан.

— Бу атның иясе кайда соң?

— Чабаннар янына китте.

— Аты була торып, җәяүме?

— Аны ял иттерер өчен, дөябезгә атланды.
— Көтү хәзер кайсы якта икән?
— Җанубтә булу кирәк.
Балҗан юри көньякны атады. Эзләп китсәләр, озаграк тинтерәсеннәр. Ул арада кабартма яңак, иптәше янына барып, ниндидер шиген белдерергә кереште. Балҗан ике колагын дүрт итеп, аларның сүзләрен ишетергә тырышты. «Аты таныш сыман... Сезгә бер арызым бар... Чабаннардан хакыйкатьне...күрәйлик». «Көтү тиздән монда кайтачак имәсме?» «Ис-һушыгыз җаидамы? Монда көтсәк, кичегәмез...»
Ирләрнең икенчесе атына менеп атлангач, хәйләсе ачылудан курыккан Балҗан, калай чәйнеген күтәреп, тышка атылып чыкты.
— Әкәҗаннар, чәй эчеп алың, хәзер кайнарлатып керәм,— дип эндәште ул юлчыларга. Аларның икеләнеп калганын күргәч, эченә йөгергән дәһшәтне яшерергә тырышып, тавышына кунакчыллык төсмере бирде: — Мәрхәбә, күләгәндә дәм ала торың. Хәзер өлгерәде.
Чүлдә иң әгъла сый — чәй. Бу җайдаклар да сусаган иде, күрәсең, бер-берсенә карашып алгач, атка менеп атланганы кире җиргә төште.
Балҗан учакны тергезеп, чәйнекне ут өстенә куйды. Аннары җил-җил атлап, тирмәдән юылмаган табак-савыт, чынаякларны алып чыкты. Юлаучылар аның болай бөтерелеп табын кайгыртырга керешүенә бик риза хәлдә бераз карап тордылар да, тел асларына тәмәке салып, тирмәгә кереп киттеләр. Балҗанга шул гына кирәк тә иде. Тирмә ягына бер мәл колак салып торды да, ул-бу хәрәкәт сизелмәгәч, сак, елдам рәвештә улак янына йөгереп килде һәм атларның тезгеннәрен казыктан ычкындырды. Йөрәге күкрәк читлеген дөрселдәтеп тибә башлады. Уе елдырымдай зиһенен балкытып алды. «Җирәнкәй таныш имеш, кара син аларны. Кемлегемне, бәладән ничек котылуымны белсәләр моңа болардан рәхим-шәфкать көтәсе юк!» Ике чаптар арасына житәкләп алып кергән җирәнкәенә гаҗәп җиңеллек, житезлек белән менеп атланып, һәммәсенең тезгеннәрен сул кулына чытырдатып кысып тотты да уң кулындагы камчысын өч бахбайның сыртында берьюлы уңлы-суллы уйнатып, тирмәдән мөмкин кадәр тизрәк ераклашу ягын карады. Үзләрен кинәт урыннан кузгатучыга күнәргә теләмәгән ят чаптарлар, пошкырып, кешнәп читкә тартыла-тартыла, Балҗанның кулын каердылар, ул арада киез өйдән атылып чыккан кунаклар:
— Киленхан, туктагыз!
— Иреңнән талак булгыры, атам!! — дип кычкырдылар. Берсе юмалый, икенчесе яный, сүгенә. Балҗан, камчысын уйната биреп, бахбаенның сыртына сарылды. Чаптарлар җирәнкәй җаена төшеп, тизлекләрен арттырганнан арттыра бардылар. Җайдак белән җәяүлеләр арасы ераклаша башлагач, сахраны наган тавышлары сискәндерде. Әмма кунаклар, атларына тидерүдән куркып, форсатны кулдан ычкындырдылар — хәзер инде качак пуля житмәслек арага китеп өлгергән иде. Куучыларның тавышлары тоныклана төшкәч, Балҗан әле һаман көнбатышка таба элдерткән атларын көньяк-көнчыгышка борды. Хәзер инде ул кабаланмады, камчысын кирәгеннән тыш селтәмәде, малкайларның тигез генә юртып барулары да ярар, дип исәпләде. Кунаклар иярләренә сулы солдат флягасы, капчык белән юл азыгы да аскан иде, сәфәрләре еракка булган, күрәсең.
Ком сахрасы тозлы такырга, анысы ак балчыклы үзәнлеккә тоташты. Балҗан берничә коены, алар тирәсенә укмашкан биш-алты тирмәле күчмә авылларны ерактан урап узды. Эңгер төшкәндә сугарулы кырлар, байтирәкләр һәм тут агачлары ышыгында урнашкан кышлак та күренде. Хәзер инде аңа артык атларны шушында калдырырга да мөмкин иде — бахбайларга ия бик тиз табылачак. Ул үзенә көчлерәк кара-туры айгырны сайлап алды.
Балҗан кышлак аркылы узганда күк йөзе караңгыланып, җил

чыкты. Берзаман артында әллә нинди тавышлар ишетелде. Сискәнеп борылса, урам буйлап артык зур булмаган өермә бөтерелеп килә, аның артыннан бер көтү малай-шалай ияргән икән. Кычкыралар, чиныйлар, кулларын болгыйлар, абынып егылганнары сикереп тора да тагын өермә артыннан чаба, тузан баганасына таш, балчык кантарлары, түбәтәйләрен ыргыталар. Балҗан дувалга сыланып, пәри туен уздырып җибәрде. Әгәр кеше шул өермә эченә эләксә, телсез калу ихтималы барлыгын ул бала чагыннан ишетеп белә иде. Тузан баганасына пычак ыргытсаң, аның йөзенә бер тамчы кан куна, диләр. Җен зәхмәтеннән исән-имин котылыйм дисәң, өермәдән ерак кач!

Тузан баганасы кышлак читендәге арык өстендә таралып юкка чыкты. Балҗан җиңгән кыяфәттә шау-гөр килеп кире борылган төркемнән:

— Балалар, алда кандай дәрья ул? — дип сорады.

Төркем бер арыкка, бер тагын да ераккарак карап һәм гаҗәпләнеп:

— Арык кү ул.

— Зәрәфшәнне әйтәсезме? — дип юлаучыны урап алды. Хәзер инде Балҗан аларны таң калдырмаслык сорау бирергә ашыкты:

— Шушы юл станциягә дә алып барамы?

— Әйе.

— Ул алысмы әле?

— Ничек барасыз инде. Ике сәгатьтә дә җитә аласыз кү.

— Өч сәгатьтә дә.

— Апаҗан, атыгызны яхшырак кусагыз, биттә сәгатьтә дә мөмкин, Каракүл якын ул безгә!

Биттә, ягьни, бер сәгатьтә барып җитү ихтималы шатланырлык иде. Балҗан хәзер инде бөтәнен дә ачыкларга булды.

— Каракүлдән Бохара алысмы икән?

Малайларның өлкәнрәге алга чыгып кычкырды:

— Дәдәм поездда дүрт сәгать, дөя кәрваны белән көне буе барады.

— Кара, сез һәммәсен беләсез икән, әй. Рәхмәт, җаныйларым, зу-ур үсегез!

Караңгы төшеп килә, хәзер инде ничек тә ашыгырга кирәк иде. Әмма Балҗан толпарын бик үк кумады. Талчыккан, өшәнгән, Каракүлдә көтеп торган кешесе юк, кайда төн кунасы, аннары Каганга ничек барып җитәсе дә томанлы, шуларны уйларга да кирәк иде. Каракүлдә дә яңа хакимият урнашкандыр, тиешле кешесен эзләп тапса, булышмый калмаслар. Төннең канат җәюе генә эшне харап итә менә. Әмма монда инде ул җебеп тормас. Амантаевның Бохара милициясендә хезмәт итүен дә, үзенең кемнәр кулыннан ычкынып качуын да...

Ул шулай уйга чумган хәлдә Зәрәфшәнне кичте. Күпердән соң юл икегә аерылгач, аларның киңрәген, такыррагын сайлады. Артында тояк тавышы яңгыравын ишеткәч, кара-турысын ашыктыра башлады, әмма артык тәшвишләнмәде, пәрәнҗә астында муенына асылган наганын гына капшап, файдаланырга уңайлап куйды. Артына әйләнеп, аны куып җитеп килүчеләрнең икәү генә икәнлеген ачыклагач, бигрәк тә тынычланды. Монда кышлаклар тыгыз урнашкан, олы юлда кем йөрмәс дисең, дөньяда мәшәкать әзмени? Тумыш бар, үлмеш бар, адәм баласын чир, уен-кызык та ташлап бетерми. Балҗан чәчванын күтәреп, төнге салкынча һаваны рәхәтләнеп сулап, үзен сунарга чыккан аучыга, хәтта әкияти бер каһарманга охшатып, елмаеп куйды. Шулай да камчысын кара-турының сыртына селтәми чыдамады, чөнки артындагы җайдаклар һаман якынлаша килә иде. Берзаман аллыартлы болай бару куышуга охшый башлады. Балҗан атын тизрәк чаптырган саен, арттагылар да чыбыркы белән куыра иде, ахры.

Алда зур кышлак күренгәч, Балҗан иркен сулап куйды. Юл буе җилдереп барганлыктан, инде балалар әйткән Каракүлгә дә килеп ке-

рергә тиеш иде ул, мөгаен. Кызыл гаскәриләр сагы астындагы станциягә. Монда инде аңа хәвеф-хәтәрдән курыкмаска да мөмкин булачак.

Кышлак читенә аяк баскач, ул тезгенне бушатып, чаптарын да үз иркенә атлата башлады. Шул мизгелдә арттагы җайдаклар аңа якынлаштылар һәм, Балҗан исенә килеп өлгергәнче, аның өстенә элмәк ыргыттылар — иярennән җиргә йолкып төшереп, өермәдәй атка сөйрәп алып киттеләр. Тын һаваны әсирнең:

— А-а-а, каравы-ы-ыл! — дип ачыргаланып кычкырган авазы ярып җибәрде. Җайдакларның берсе:

— Бу мордарның авызын томаларга кирәк,— дип киңәш итте.

— Тиздән болай да дөмегәде!

— Юк, ул әле безгә тере кое кирәк. Кое янындагы арысланнарыбыз үлеме өчен җавап бирсен әүвәл.

— Бер аялны җиңә алмаган кандай арыслан булады ул?

Әмма җайдакларның өлкәне туктады. Кулларының элмәктән бушый төшүен тойган Балҗан, соңгы көчен җыеп, шундук хәнҗәрен суырып алды да арканны кисеп җибәрде. Сул кулы әллә сынган, әллә биртелгән — үтереп сызлый иде. Бәхеткә уңы исән, дип Балҗан наганын кулына алды һәм, яткан җирендә катып калып, җайдакларның үзенә якынлашуын көтә башлады. Аннары иярдән сикереп төшкәненә «гөрс» берне!

— Уйнашчы бәдбәхет!

Ирләрнең кайсы кычкырды моны? Җәяүгә калган әзмәвер гәүдәлесе күкрәгеп тотып, киселгән агачтай, җиргә ауды, икенчесен үрә сикергән аты читкә алып чапты. Балҗан анысына да гөрселдәтте, әмма тидерә алмады. Ул арада иярдә калганы үзе дә ут ачты. Әмма ул якынрак килүдән сакланды, җирдә тәгәрәп яткан ике карачкының бергә укмашуын шәйләп, әллә инде иптәшенә тидерүдән дә курыкты, төзәп атмады. Балҗан исә, җирдә кымшанмый яткан ир-ат янына мүкәләп килеп, капшый-капшый аның коралын эзләде, ниһаять, биленә таккан наганын да, хәнҗәрен дә тапты. Моның өчен хырылдап ыңгырашкан дошманын икенче ягына әйләндерергә туры килде.

Иясез калган атлар кешнәп читкә ыргылды, кышлакта этләр өрергә кереште. Ялгыз җайдак, иптәшенең тереме икәнлеген белергә теләп, ерактан:

— Әкә, сез калайсыз? — дип кычкырды. Җавап ишетелмәгәч, карачкыларга төзәбрәк ата башлады. Аны ерактарак тотар өчен, Балҗан да ут ачты. Дошманның үз коралыннан! Шушы бәрелеш кызулыгы белән ул иңбашы яралануын да күлмәге астыннан кан саркып чыккач кына тойды. Кышлак якында гына, хәле беткәнче шунда качып котылырга иде, ир-ат белән атышу хатын-кыз эшемени? Әмма хәрәкәткә килсә, ул, мөгаен, теге җайдакка мәрә генә булачак. Чү, атыннан төште түгелме соң ул мәртәт?

Балҗан, пәрәнҗәсен бөтенләй салып ташлап, дошманы ягына тагын бер пулясын җибәрде. Аннары мүкәләгән хәлдә арты белән кышлакка таба чигенә башлады. Ул инде хәзер көче озакка җитмәячәген белә иде. Күлмәге каннан юпь-юеш, наган тоткан кулы дерелди, сул кулы асылган таяк кебек, бер эшкә дә ярамый.

Балҗан кышлактан унлап җайдак килеп чыгуын күрмәде, үзен эзәрлекләгән дошманның, атына атланып, җәһәт кенә күздән югалуына гына таң калды һәм, киеренкелектән бушанып, җиргә егылды. Сызлану җәфасыннанмы, дошманнар кулына төшмәү шатлыгыннанмы, күзе тулы яшь иде аның.

Атышны ишетеп аякка баскан Каракүл станциясе кызыл гаскәриләре кышлактан кырга атылып чыгуга, ике авыр яралыга юлыгып, ялгыз җайдакны эзәрлекләп тормадылар. Хатын-кыз көрмәкләнә башлаган теле белән:

— Бохара милициясе... Амантай Туктаров... Балҗан...— диде дә

һуштан язды. Җәрәхәтле ирнең дә хәле мөшкел иде. Күп кан югалткан яралыларның икесенә дә беренче ярдәмне күрсәттеләр, аннары иртәнге поезд белән Каган госпиталенә озаттылар.

## 35

Үзенең ярдәмчеләренә Фарукҗан Каган вокзалында гына килеп кушылды. Вак-төяк станцияләрдә туктап тормаган хәрби эшелонга эләгеп, алар гомумән уңды — әле көн кичкә авышкан гына иде. Тизрәк Мартьяновны күрергә ашыккан Байкучатов юлдашларына үзен вокзалда көтеп торырга кушты. Амантай түземсезләнеп:

— Теге хәрби кайда соң? — дип сорады.

— Юлда төшеп калды.

— Ул безнең эш белән йөрмимени?

— Ничек дип әйтергә инде? Хәер, соңыннан сөйләрмен. Госпитальгә генә кереп чыгыйм да...

— Мин дә сезнең белән барыйм әле? — дип үтенде Амантай.— Балҗан хакында берәр хәбәр юкмы икән анда?

Шулчак Иргәш Фарукҗанга терсәге белән төртеп, вокзалдан базар ягына узып барган бер ир-атка ымлады һәм пышылдап:

— Бу — Зыятдинда сезне күзәткән теге шикле бәндә,— диде.— Нинди өлгер!

Байкучатов үзенә иярергә кирәклекне белгертеп башын гына изәде дә, кабыннан унатарын ала-ала, чалма-чапанлы юлаучыга таба кузгалды. Иргәш ялгышмый, алар кичә Зыятдинга китәр алдыннан шушы мәйданда Латыйфхан Нурморатов белән гәп сугып торган ирләрнең берсе иде бу. Маңгаенда яра эзе беленеп торганы. Озынча йөзлесе. Газәли чәйханәсендә әмирне мактап утырган картның үзе түгелме соң әле? Билләһи, нәкъ шул лабаса!

Сиздерми якынлаша алмадылар — шикле карт ялт борылып аларга карады. Качып котылырга да, каршылык күрсәтергә дә соң — аңа таба йөгергән кызыл гаскәриләрнең берсе коралын атарга төзәгән иде инде.

— Тукта! Кулларыңны күтәр!!

Якын-тирәдәгеләр өркеп читкә тайпылды. Иргәш белән Амантай ике ягына килеп баскач, карт телгә килеп:

— Сез ялгыштыгыз, мин дошман түгел,— дип ризасызлык белдерде.

Фарукҗан аны тиз генә капшый-капшый тентеп алды. Чапаны астында каты нәрсә барлыгын тоеп, кулын тыккан иде — билбауга кыстырылган наган тартып чыгарды.

— Гөнаһсыз әүлия, марш комендатурага!

Карт каушау галәмәте күрсәтмәде, йөзенә ачулы кыяфәт чыгарып, алдан барган Фарукҗан белән арттан килгән Иргәш, Амантайлар арасында тыныч кына атлады. Комендатура ишеге биек түгел, шуңа күрә бүлмәгә кергәндә әсирнең кулын төшерүенә егетләр гаҗәпләнмәде. Карт исә шул арада куен кесәсеннән язулы кәгазь чыгарып, «ә» дигәнче авызына капты һәм чәйнәп йотарга тырышты. Фарукҗан шикләнеп артына борылгач, тел астындагы насваен әйләндергән булып кыланды.

— Ач әле авызыңны!

Әсир карт тиз-тиз нидер чәйнәп йоткан хәрәкәт ясады да канәгать төстә телен чыгарып болгады. Насвае күренмәде. Байкучатов башыннан: «Тәмәке капкан булса, йотмас иде, димәк, бүтән нәрсәне...» дигән уй чагылып узды.

— Чишен!

Бу юлы җентекләбрәк тентеделәр, әмма баягы наганнан гайре

картны гаепләрлек бүтән нәрсә табылмады. Баштук кулларын бәйлисе калган икән, дип үкенде Фарукҗан. Язуны кеше кулына төшермәс өчен соңгы чиктә чәйнәп йотуларын ишеткәне бар иде ләбаса. Томана Азия, дип фикер йөртә һаман, тәкәбберләнә, бәлки менә хәзер, дошманына җитди карамавы аркасында, бик әһәмиятле дәлилдән коры калгандыр? Шик уятмыйча гына кулын кайчан төшерергә мөмкинлекне дә алдан ук исәпләп куйган булгандыр әле, явыз!

— Зыятдинда нишләп йөрдең?

Карт Байкучатовка сөзеп карады да исе китмәгән рәвештә:

— Кайчан? — дип сорады.

— Бүген.

— Бүген Каганнан ары киткәнем юк кү.

— Безне сукыр дип уйлыйсыңмы әллә?

— Бүтән кеше белән саташтыргансыздыр.

— Алты күз саташмый,— диде Фарукҗан кырыс итеп.— Дөресен сөйләсәң, үзеңә җиңеллек килер. Нишләп йөрдең анда? — Карт дәшмәгәч, Фарукҗан бүтән яктан басым ясарга булды: — Барлык коралларны Чекага һәм милициягә тапшырырга әмер бирелүен ишеткән идеңме?

— Әйе.

— Алайса нигә наган кыстырып йөрисең?

— Заманы хәвефле, сакланырга кирәк.

— Алтының күпмени?

— Әмир яраннары үчләшеп бәйләнсә, теләсә кем бәлагә юлыгуы ихтимал.

— «Үзе гадел, намуслы әмир»нең яраннары яман була аламыни? Газәли чәйханәсендә галиҗәнапне тагын ничегрәк мактаган идең әле? «Миһербанлы, юмарт, фәлән-фәсмәтән!» Бәлки сиңа наган да әмир хәзрәтләрен яклар өчен кирәктер? Нигә дәшмисең?

Карт кайчандыр үзе әйткәннәрне сүзгә-сүз кабатлагач, кызыл гаскәриләргә пошаманлы карап:

— Журалар, ул көнне мин шулай гәпләшергә мәҗбүр булдым,— диде.— Чәйханәдәгеләрнең серен алырга кирәк иде. Мин чека түрәсе Латыйфханның әмерен үтәдем. Инкыйлабка хезмәт кылыр өчен наганны да Латыйфханнан алдым.

Фарукҗан тимерне кызган чакта бөгәргә ашыкты.

— Мине атып үтерергә дә «Латыйфхан түрә» куштымы?

— Тәүбә диең, нимә гәперәсез? Латыйфхан уртак инкыйлабка җөдә бирелгән адәм.

— Алайса миңа үз ихтыярың белән генә аттың инде?

— Кайчан? Мин сезнең кем икәнлегегезне дә белмим.

— Монда кәмит уйнап маташма,— диде Фарукҗан кискен төстә.— Газәли чәйханәсеннән караңгы тар тыкрыкка минем арттан син йөгереп чыктың, пушкаңнан да син гөпелдәттең. Моңа шаһитлар бар. Шулаймы, Амантай?

— Тугры, юлдаш командир.

— Бикәр, нахак гәп,— диде тәшвишләнә башлаган карт.— Мин чәйханәдә Латыйфхан уртак әмерен баҗарыр, шуны үтәр өчен генә утырдым. Мин бары сер алыр өчен генә...

Фарукҗан аңа кәгазь, каләм сузып һәм өстәл янында урын күрсәтеп:

— Хәзер менә шуны язмача аңлат,— дип боерды.—Кем син, Латыйфхан Нурморатовның нинди әмерен кайчан, ни сәбәпле үтәдең — һәммәсен төшендер!

Байкучатов әсирнең гаепләүне кире кагачагын белә, аңлатманы исә үзенең бүтән бер фаразын ачыклар өчен генә яздырта иде. Бераздан ул чыннан да максатына иреште һәм кәефле елмаеп җибәрде: картның кулы «Бум»ныкыннан аерылмый — икесенең язу рәвешләре тә-

мамысы охшаш иде. Димәк, карт — хәтәр агентның үзе. Фарукҗанны да, Тураевны да, тагын бүтәннәрне дә күздән язмаучы дошман!

— Тикшерү тәмамланганчы син кулга алынасың,— диде ул картка.

— Бу — кәттә гаделсезлек. Минем шушы хәлгә төшүемне Латыйфхан уртак белергә тиеш.

— Кайгырма, белер. Әмма тәүбә итеп, гамәлләреңне булганынча танымасаң, сине зинданнан Латыйфханнан зуррак түрә дә йолып чыгара алмас. Уйла!

Картны, берәү белән дә очраштырмаска кушып, сак астына тапшыргач, Фарукҗан госпитальгә юнәлде. «Бум»ны ачыклау,— ә ул моңа ирешүенә тамчы да икеләнмәде,— аны канатландырып җибәрде. Яшерен дошман ачыгыннан хәтәррәк. Чекадагылары бигрәк тә. Алардан тизрәк арыну яңа корбаннарны булдырмас өчен кирәк.

Мартьянов госпитальдә юк иде. Бохарага киткән, шәһәрдән кайчан кайтып җитәчәген берәү дә белми иде. Фарукҗан шулай да аның фатирына йомышчы җибәрттерде — аймылыш килеп, очрашмый калудан курыкты. Җитди кеше, юкка гына эзләмәгәндер чекистны.

Ул арада янәшәсендә басып торган Амантайны госпитальдә хезмәт итүчеләрдән берәү күреп алып:

— Иптәш Туктаров!— дип кычкырды.— Кайда югалдыгыз сез?

— Ә нәрсә булды? Югалттыгызмыни?

— Югалттык шул. Сез Балҗанны күрдегезме әле?

— Кайда соң ул?

— Их сезне, әйдәгез әле минем белән!

Амантай шатланып һәм ашыгып ак халатлы иргә иярде. Коридорга кергәч, әлеге медик:

— Уянса, күп сөйләштермәгез,— диде.— Авыр яраланган.

— Яраланган? Ничек инде...

— Менә шулай. Хатыныгызны авыр хәлдә Каракүлдән алып килделәр. Каны күп аккан. Үзеннән әлләниләр сорашмагыз, аңладыгызмы?

Амантай бернәрсә төшенмәстән туктап калды. Табип артына борылып һәм Туктаровның тагын нидер белешергә теләвен, ләкин базмый гына торуын чамалап, үзе сүз катты:

— Каракүлдә кардәшләрегез бар идеме әллә?

— Кайсы якта соң ул кышлак?

— Кышлак кына түгел, тимер юл станциясе дә. Чарҗау ягында.

— Белмим, беренче ишетүем.

Табип бүтән сорашып тормады. Амантайны ишекләрнең берсе янына ияртеп килде дә башын иәде.

Палата кечкенә, нәни генә тәрәзәсе ачык икән. Өч караваг сыйдырганнар: аларның ишек төбендәгесе буш күренә. Түрдәгеләрендә ак җәймә ябынган авырулар. Амантай яралы хатынын, стенага карап ятса да, ишектән керүгә танып алды. Иңбашы бинтланганлыгы әллә кайдан беленеп тора иде. Кайда, ничек бу хәлгә төшкән ул? Доктор беләдер, нигә юньләп сөйләп бирмәде инде?

Балҗан кеше керүен сизүдәнме, сызланудәнмы уянды — борылып чалкан ятты һәм ыңгырашып керфекләрен ачты. Бер мәл ул караваты янына килеп баскан иренә мелт-мелт итеп төбәлеп торды, аннары:

— Су!— дип пышылдады.

Амантай тиз генә тумбочка өстендәге кувшинны барып карады. Сулы икән. Шуннан җамаякка агызды да, уң кулы белән Балҗанның башын күтәреп, эчерде. Бер-икене йоткач, хатыны аңа тагын да текәлебрәк күз салды. Хәзер инде каршысында кем торуына инанды булса кирәк, яшьле күзләре белән мөлдерәп карады.

— Амантай!— дип эндәште.— Наганым бар иде...
— Сөйләшмә, сиңа әле ярамый.
— Амантай... син әле монда утырасыңмы?
— Әйе, сәүләм, күз нурым.
— Байсын ягына китмәйсеңме?
— Тынычлан, беркая да китмим.
Балҗанның зәгыйфь тавышы, хәлсез кыяфәте Амантайның йөрәген сыкратты. Соңгы соравы исә күз төбен үк дымландырып җибәрде. Бөтенләй җебеп төшмәс өчен, хатынын башыннан сыйпаган, ябынган җәймәсен төзәткән булды. Хатыны күзләрен йомды да бераздан тагын ачып:
— Каракүлдән... минем белән... китерелгән яралы — дошман,— дип пышылдады.— Аң бул, миңа... ул атты.
Балҗанның тагын нидер әйтәсе килә иде, ахры. Тик Амантай аңа бүтән авыз ачарга ирек бирмәде.
— Соңыннан, ярыймы, сәүләм? — диде ул үгетләгән тәстә.— Хәлең җиңеләя төшсен әле, аннары аңлашырбыз, ә дошманнарыбызның арт сабагын хәзердән үк укыта торырбыз. Йокла син бераз, яме?!
Ишектә Байкучатов күренгәч, Амантай иптәшләрен кисәтминитми үзенең озаккарак югалуын чамалап, караватка — Балҗанның аяк очына утырган җиреннән җәһәт сикереп торды да коридорга чыкты.
— Хатыным табылды,— диде ул.
— Бик әйбәт. Алайса ни өчен болай борчулы соң әле син?
— Аны кемнәрдер авыр яралаган.
Амантай Балҗан хәлен сөйләп, ул әйткәннәрне сүзен-сүзгә кабатлады да:
— Доктор сагайткач, үзеннән җентекләп төпченергә курыктым,— диде.
Байкучатов, иптәшен ияртеп, баш врачны эзләп китте. Тик аларга ачыклыкны бу юлы да баягы медик кертте.
— Әйе, Каракүлдән безгә ике авыр яралыны китерделәр,— диде ул.— Балҗанны без шундук таныдык. Операция ясап, иңбашыннан пуля алдык. Тагын берсе кабырга тирәсен тишеп үткән иде. Дәвалыйбыз. Аерым палатага урнаштырдык, савыгырга тиеш.
— Икенче яралы нинди хәлдә?— дип сорады Фарукҗан.
— Савыгуына өмет аз.
— Озатып килүчениләр сөйләгән иде?
— Яралылар үзләрен эзәрлекләп килгән дошман белән Каракүл кышлагы янында атышкан булган, ахры. Гарнизон отряды күренгәч, басмачылар качкан. Балҗан исә кызыл гаскәриләргә яралы юлдашын дошман дип әйткән. Тик аның сүзен гарнизонда берәү дә чынга алмаган.
— Нигә?
— Соң... монда борын хатын-кыз гына түгел, ир-ат та юньләп корал тота белми иде ич.
— Әйе, ә кораллары кайда соң аларның?— диде Фарукҗан.
— Гарнизонда калган. Кызыл гаскәриләр якынлашканда Балҗан кулында ике наган да булган икән.
— Әлеге яралы ир янына берәр таныш-белеше килмәдеме?
— Юк. Без монда, Балҗан сүзен игътибарга алып, аны шулай ук күз уңында тотабыз. Канлы киемнәрен салырга теләми шаккатырды әле ул безне. Барыбер үләчәк, имеш. Безнең бурыч — савыктыру...
— Салдырдыгызмы соң?
— Бөтенесен түгел.
— Киемнәрен карыйк әле.
— Үзен күрәсегез килмимени?— диде врач гаҗәпләнеп.
Фарукҗан бу искәртүне бик урынлы санап:

— Бик дөрес, әүвәл үзенә күз салыйк,— диде.— Көне-төне чатыр чабып, башыбыз да эшләми инде. Йончыдык.

Балҗан юлдашы эре сөякле ир иде. Таза. Башы тап-такыр итеп кырылган. Түгәрәк сул як бите сыдырылып, кара янып чыккан — аттан егылып төшү билгесе. Хәзер йоклаганмы, һуштан язганмы — хәрәкәтсез ята. Доктор аның беләген кулына алып, кан тамырын тотып карады. Зәгыйфь кенә тибә икән. Аннары өстенә ябылган ак җәймәне ачты. Яралының корсагы марля белән кысып бәйләнгән иде. Ул арада авыруны Фарукҗан да күздән кичерде. Таныш кешесенә охшамаган. Иелеп аның күлмәк якасын, җиң беләзеген, ыштан бөрмәсен капшап карады. Аннары яралының башын күтәреп, муенындагы өчпочмак рәвешендә тегеп асылган бөтиен салдырып алды.

Шуннан соң врачтан:

— Бу кеше хәрәкәтләнә ала идеме?— дип сорады.

— Юк. Аңа борылып яту да читен, көчкә сулыш ала.

Фарукҗан барыбер киез белән мендәрнең җөйләрен тикшерде. Амантай ярдәмендә яралыны күтәреп, аларның астына да күз салгач, канәгать төстә палатадан чыгып китте.

Яралының чапанын, калын чалбарын ул инде врач кабинетында карады. Әүвәл, әлбәттә, доктор һәм Амантай алдында бөтине сүтте. Аның эченнән дога язылган кәгазь генә түгел, кыйммәтле алтын балдак белән ярым ай рәвешендәге бер пар алка чыкты. Алкаларның эчке ягына матур итеп сырлап «һират» дип язылган иде. Табылдыклар Фарукҗанны дәртләндереп җибәрде. Сырган чапан белән чалбарны ул инде икеләтә игътибар белән тентеде. Тиздән чалбар каешы астында яшерен нәни кесә барлыгы беленде. Анда шактый озын хат тыгып куелган иде. Латин хәрефләре белән язылган! Врач аңа бер карау белән:

— Инглиз телендә бу, минем теш үтми,— дип белдерде.

— Кем укый ала?

— Укуын мин дә булдырам, сүзлек тапсам, тәрҗемә дә итәр идем, бәлки.

— Бу хатта язылганнарны Чеканың тизрәк белүе хаҗәт,— диде Фарукҗан.— Зинһар булышыгыз!

Врач госпитальдә эшләүче бер хезмәттәшенә мөрәҗәгать итте, анысы, чекистлар атына атланып, өеннән сүзлек алып килде. Икәүләп тырыша торгач, алар бер сәгать эчендә язуны русчага әйләндереп бирделәр.

«Капитан Блеккергә.

Без бары хәзер генә РСФСР вәкиле Сурицның Әфганстан тышкы эшләр министры Мәхмүт Тарзига җибәргән яңа нотасы белән таныша алдык. Нотада Совет Русиясенең Бохара революциясенә булышуы, ләкин андагы бәрелешләрне үз мәнфәгатендә файдаланырга җыенмавы, БХСРның тулы ирекkә, бәйсезлеккә ирешүенә теләктәшлек күрсәтүе, аның халкы сайлаган теләсә нинди хөкүмәтне танырга әзер торуы хакында әйтелә, шул ук вакытта Русиянең революцион Бохара хөкүмәте җиңүләрен сакларга омтылуы да белдерелә. Нотада Әфганстанның Бохара эчке эшләренә тыкшынуы, тәхеттеннән бәреп төшерелгән әмирне һәм аның тарафдарларын яклавы Амануллахан хөкүмәте игълан иткән сәясәткә — күрше ханлыклар белән дусларча мөнәсәбәттә яшәү, Урта Азиядә инглизләр йогынтысын җую омтылышына туры килмәве искәртелә.

«Хөкүмәтемнең шифрланган ашыгыч хатыннан Бохарада уздырылган тикшерү нәтиҗәләрен белдем,— ди Суриц.— Алар түбәндәгечә:

Әфганстан вәкиле Габделшөкерхан әфәнде Бохарада русларга каршы бөтен үгет-нәсихәткә җитәкчелек итә; Бохара әмире гаскәрен әфганнар өйрәтә; мәгълүм вакыйгалар башлангач: Бохарада әфган отрядлары күп туплана, алар революцион гаскәрләргә каршы барыннан да активрак һәм ахыргача сугыша, әфганнар Әфганстаннан Бохарага корал китерә һәм шул ук максат белән Төркестанда да корал сатып алуны оештыра; алар Төркестанда советка каршы үгет-нәсихәтне киң җәелдерә; Фирганәдә һәм Бохараның шәркый бәкләкләрендә басмачыларга өзлексез ярдәм итеп килә; Әфганстан гаскәрләре Кушка артындагы Чарҗуйга һөҗүм итүдә катнаша.

Ике дәүләт арасындагы дуслык элемтәләрен ныгытырга кайнар теләк белән рухланган РСФСР хөкүмәте барлык әлеге күңелсез нәрсәләрне тирән үкенеч белән искә

ала, лакин. Кабул хөкүмәтенең дуслык хисләренә һаман ышанып, бу аянычлы хәлләр Әфганстанның мәркәзи хакимияте белән аның җирле вәкилләре арасында җитәрлек бәйләнеш урнашмаудадыр, дип фараз кыла».

Менә шуннан соң Русия вәкиле Әфганстан хөкүмәтеннән Бохарадагы вәкилләре эшен тикшерүне, югарыда телгә алынган «тыкшынуларга» чик куюны таләп итә.

Нотада китерелгән барлык гаепләүләр нигезләме, әллә алар Әфганстан хөкүмәтенә басым ясар өчен юри генә саналганмы? Габделшөкерхан чынлап та әмир тарафдарымы? Ул очракта безнең аңа зыян китерүебез яманлык булып кына кайтмасмы? Шушы сорауларның һәммәсенә ашыгыч тәстә тулы җавап бирүегезне көтәм.

Бохарада һәм Төркестанда Русия вәкилләре сафсатасын ачык төшенер өчен, лорд Жорж Керзонның РСФСР тышкы эшләр комиссары Чичеринга җибәргән нотасын истә тоту кирәк. Ул анда: «Бөтен дөньяга тараткан радиотелеграф хәбәрләрендә Совет хөкүмәте аерым эшлекләләре авызыннан һәм матбугат аша Бөекбританиягә һәм Британия империясенә дошманнарча мөнәсәбәтен вәгазьләвен беркайчан да туктатмады. Совет хөкүмәте күптән түгел Бакуда бәхәссез тәстә Британия мәнфәгатьләренә каршы юнәлтелгән Азия халыклары революцион конференциясен үткәрде. Аның Кавказда, Иранда һәм Үзәк Азиядә, Әфганстанда Бөекбританиягә каршы ачыктан-ачык хәрәкәтләре яхшы билгеле»,— диде.

Мондый шартларда без Төркестанда, Хивада һәм Бохарада үз эшләребезне бермәбер көчәйтергә тиеш.

Радиотелеграф аша БХСР хәрби комиссары Шиһабетдиновның «үз-үзен атып үтерүе» билгеле булды. Бик шәп, яклыйм! Банктагы исәбегезгә көне белән түгәрәк сума күчерелде. Шушы хат белән бергә алтын алкалар һәм балдак җибәреләә. Бүләкләрне «Остаз» һәм «Бум» әфәнделәргә тапшырыгыз. Хәрәкәтебездә нәтиҗәле катнашсалар, «Уяу» белән «Маһир» әфәнделәр исеменә тиздән банкта махсус исәпләр ачылачак.

Ике рапортыгыз безнең кулга килеп ирешмәде. Киләчәктә аралашуны тизләтер өчен Радиотелеграфны файдаланырга тәкъдим итәм. Каганда яки бүтән берәр үзегезгә якын телеграф станциясендә ышанычлы кешегезне булдыргач, шифрланган хәбәрләрегезне Дүшәккә, Тарасов исеменә адреслагыз.

Ашыгыч җавабыгызны көтәм. Полковник Штеннел.

Мәшһәд, егерме беренче октябрь».

Хатны укып чыккач, Фарукҗан врачка:

— Яралылардан сорау алырга мөмкинме?— дип мөрәҗәгать итте.

— Юк. Хәлләре әлегә бик авыр.

— Кызганыч. Бер-ике нәрсәне ачыклау безнең эшне шактый җиңеләйтер иде.

— Тиздән сезгә Балҗан ярдәм итә алыр, дип уйлыйм.

— Тизрәк савыктырыгыз үзен,— диде Фарукҗан.— Нинди хатны кулыбызга төшерттe бит. Чека өчен бик кирәкле мәгълүматлар.

— Хәзер инде койрыкларына басарсыз, ә?— дип кызыксынды врачлар.

— Алдагысын алла белә. Тик сез хат хакында кеше-карага ләммим, килештекме?

Госпитальдән ишегалдына чыккач, Фарукҗан гаҗәпләнеп:

— Уһу, кояш та байый икән ләбаса инде,— дип куйды.— Егетләр, бүгенгә җитәр, хәзер ял итегез. Амантайга, бәлки, төнлә хатыны янында кизү торырга да туры килер. Үзем иртәгә иртүк сезне Каганда эзләп тапмасам, сәгать уннарда Бохарада очрашырбыз.

— Кайда?— дип сорады Иргәш.

— Ләби-хәвездә. Чалма-чапан киеп килсәгез яхшырак. Наганны беленмәслек итеп яшерерсез.

Фарукҗан аны-моны дәшми басып торган Амантайның җилкәсенә кулын салып:

— Аңладыңмы, туган?— дип сорады.

— Әрине, төшендем,— диде Туктаров уйларыннан арынып.

Алар инде төрле-төрле якка таралырга җыенганда гына госпиталь ишегалдына тарантаста Мартьянов кайтып керде. Ерак сәфәрдән арып кайтуы сизелеп тора. Тузанга баткан, күн фуражкасы астыннан күзләре генә елтырый. Шулай да ул тарантасыннан елдам төште һәм туп-туры Фарукҗаннар янына килеп:

— Күрәм, барыгыз да исән-сау икән, шөкер.— дип күреште.

— Безгә берәр хәвеф-хәтәр булырга тиеш идемени?

— Кайберәүләр уенча, әйе,— диде Мартьянов.— Кисәтергә соңгарак калдык. Багбан коесы янында сезгә тозак корылуы кичә төштән соң гына беленде.

— Дошман анда үз тозагына үзе килеп капты!— диде Фарукҗан.

— Бик шәп. Ә менә Балҗан бичара йөзе каралар капкынына эләккән — аны Әбдиев яраннары кулга төшергән бугай. Бу турыда сезгә Глафира җентекләбрәк сөйләр. Сез аны бүген үк эзләп табыгыз әле.

— Кем соң ул?

— Балдызым. Партия Үзәк Комитетында эшли. Ул сезне кичә көндез үк күрергә теләгән иде инде.

— Нәрсәгә кирәктем икән соң аңа?

— Теге юлы әйтергә онытканмын сезгә: Шиһабетдиновны ул да яхшы белә иде ич. Верныйда чакта аның йомышларын да үтәштергәләгән әле.

Мартьянов кесәсеннән куен дәфтәрен чыгарды да, аның бер битен ертып алып, кәгазьгә карандаш белән адрес язды һәм Бохара планын сыза башлады. Аннары шуны Фарукҗанга тоттырып:

— Сезгә сөйлисе серләре бар аның,— диде.— Балдыз бик чая минем, башкисәр!

— Рәхмәт, очрашырга тырышырмын.

— Балҗан кызганыч,— диде Мартьянов үкенечле төстә.— Артык беркатлы иде шул.

— Сез госпитальдән күптән чыгып киткән идегезме?

— Төш вакытында ук.

— Алайса сөендерә алабыз: беркатлы Балҗан бәладән котылу гына түгел, менә дигән трофей да эләктереп кайткан әле. Әмма юлда яраланган. Гайрәт кергән үзенә, тизрәк аякка гына бастырыгыз инде!

Мартьянов эшлекле кыяфәттә үз белемәләренә, Амантай кире таныш палатасына кереп киткәч, Фарукҗан ниндидер бер тынычлану, рәхәтлек кичереп, тирә-ягына күз салды. Дөнья матур икән ләбаса! Дувал буендагы куаклар арасында чикерткәләр сайрый, ишегалды уртасындагы чәчәклек өстендә күбәләкләр уйный. Ак канәфер, кызгылт-сары хәтфә, төрле-төрле төстәге кашкарыйлар әле дә чәчәк атып утыра. Купшы флокслардан бөтен ишегалдына тәмле хуш ис таралган. Күләгәләр озынайган, көндезге бөркүлек басылган. Яралылар чәчәк түтәле буена су салынган таба чыгарып куйганнар да хәзер кошларның очып төшеп шуннан сусын кандыруын көлешә-көлешә тамаша кыла иде. Кайберләре кесә төпләрен кагып, ризык валчыкларын сибә, үзләренә якынрак килгән кошларны «менә бусы батыррак икән!»— дип мактап куялар.

Фарукҗан әле һаман янәшәсендә басып торган Иргәшне капкага таба алып китте һәм, бер дә көтелмәгән сорау биреп, аны яхшы ук сәерсендерде.

— Дускай, синең кыз туганнарың әле һаман кышлагыгызда атаанаң белән торамы?

— Апам күптән кияүдә. Сеңелләрем әле яңа гына аякка басып килә.

— Аларга ничәшәр яшь?

— Олысына — унҗиде, кечесенә — унбиш.

Фарукҗан үзен юынырга чакырган Анарны күзаллап, эченнән: «Олысы шулдыр. Үзе матур, кыю икән,— дип уйлады. Карлыгандай кара күзләре өздереп карый, керфекләре, кашлары исә шундый назлы, әсәрле — таң калырлык. Өйдән чыгып килүчеләр өркетмәсә, алар, мөгаен, тагын сөйләшә алган булырлар иде. Ни хакында? Һәй, табылыр иде әле сүз. Бүлдерделәр бит шунда гәпне!»

— Сеңелләрең үзең шикелле чибәрләрдер инде, ә?

Иргәш тагын да гаҗәпләнә төшеп, командирына күз ташлады, әмма аны-моны дәшмәде. Фарукҗан сүзен гүя өзелмәгәндәй дәвам итте:

— Тормышлары да матур булсын иде аларның.

— Амин.

— Тик моның өчен кызларга да көрәшергә кирәк.

— Нимә кылып?

— Һич югы берсе, әйтик, олысы синең янга килеп тора башласа, бәлки укырга керер иде.

Иргәш, командирына итагатьле төстә колак салып торса да, үзенең бөтенләй башка нәрсәләр турында уйлавын фаш итте:

— Фарукҗан әкә, уртак Баһаветдиновны, димәк, инглиз агентлары үтергән, ә?

Бу юлы сүзнең кинәт шулай башкага күчүенә Фарукҗан шаккатты.

— Моны әле ачыклыйсы бар.

— Хатта ачык язылган имәсме?

— Мин алай дип уйламыйм. Үзенең тик ятмавын күрсәтер өчен, агентның юри мактануы да мөмкин. Хәер, без бит әле моны белмибез. Штеннел әфәнде телеграф хәбәренә таянып кына фараз кыла лабаса.

— Ә мөкафәт бүләкләр? Алар ни өчен җибәрелә соң?

— Контрларны рухландырырга, кызыктырырга кирәк ич инде. Син, Иргәш дус, үзең бер соравыма җавап бир әле: Бохара кызлары нинди очракта чәчванын ачып, егеткә йөзен күрсәтүе ихтимал?

— Бездә мөмкин имәс нимә бу,— диде Иргәш.— Егет бертуганы, я калым түләгән ярәшелгән яры булса гына инде. Я шунда кыйшыктан тәкатьсезләнсә... Ай-һай, минем андыйларны берәүдән дә ишеткәнем юк әле.

Фарукҗан иптәшен йотылып тыңлап торды да, күкрәгенә тула башлаган сөенечтән дулкынланып:

— Элек ишетмәгәнсеңдер, хәзер замана бүтән инде,— диде.— Бохара түңкәреше моннан соң тагын да көчлерәк тәэсир ясый барачак. Без шуңа хезмәт итәбез түгелмени?

Иргәш килешкәндәй баш какты. Байкучатов шундук атына менеп атланды да урыныннан өермәдәй дәррәү кузгалып китте. Каганның тар урамнарыннан киң яланга килеп чыккач, кайчандыр хәтеренә сеңеп калган сүзләрне җыр шикелле көйгә салып кабатлый башлады:

> «И күңелнең шаулап аккан чишмәдән сафрак чагы!
> И гомернең нурланып үскән яшел яфрак чагы!..»

Күңеленең кайсыдыр почмагында: «Штеннел бүләкләре Бумның телен ачарга булышыр», дигән уй кузгалып куйгач, Фарукҗан тагын да дәртләнебрәк сузды бу җырын.

## 36

Бүлмәдә җиделе лампа яна, аның саргылт яктысында Глафираның җитен чәчләре алтынсу төскә кереп ялтырый, чыраенда исә эчтән бәреп чыккан ямансулык, үкенечле моң бар иде. Аның сөйләгәннәрен тын да алмый тыңлап утырган Фарукҗан нәүмизләнеп:

— Шуннан соң бүтән очрашмадыгызмы?— дип сорады.

— Очраштык. Ул чакта шундый юләр булсам да, Баһауга юлыкмый озак тора алмый идем. Тик мин аңарда егет кеше, ир заты күрә, аның да миңа кызларга карагандай каравын тели идем. Шулай күз

салмагач, кәефем кырыла иде. Ә Баһау инде ул елларда ук революцион көрәшкә тартылган булган икән, почтада эшләү аңа Ташкенттан җибәрелә торган яшерен әдәбиятны Верныйга ташырга мөмкинлек биргән. Күзәтү астында яшәгән Павелга «күчтәнәч» илттереп, ул мине дә шул юлга бастырды. Ләкин тиздән гаскәри хезмәткә алынып, үзе каладан китеп барды. Хатлар язмады, шуннан соң мин аны югалттым. Яңадан былтыр октябрьдә, ул Верныйга хәрби комиссар булып килгәч кенә очраштык. Баһаветдин тагын да кызыклырак, чибәррәк егеткә әверелгән иде. Элекке басынкылыгының эзе дә калмаган. Шундый дәртле, тынгысыз, сөйли башласа, теле телгә йокмый! Тәҗрибәле, белемле җитәкчегә әйләнүен әйткән дә юк, мыек та үстергән бит әле! Аны күтмәгәндә шундый яшьнәп торган егет, дәрәҗәле командир хәлендә күрү күңелемне әсәрләндереп кенә калмады, йөрәгемне үкенеч, югалту тойгысы да чеметте. Чөнки мин инде берничә ел элек кияүгә чыгарга өлгергән идем.

— Шиһабетдинов белән Бохарада да аралаштыгызмы?

— Көн саен диярлек. Кайбер йомышларын да үтәдем әле.

— Нинди йомышларын?

Глафира Фарукҗанга карап бераз уйланып торды да:

— Менә монысын әйтә алмыйм,— диде.— Мин сезнең бу җинаятьне ачырга алынуыгызга теләктәш дип кенә әйтү әз, мөмкин кадәр булышырга да әзер. Ләкин мөмкин дәрәҗәдә генә.

Фарукҗан бөтен кыяфәтенә салкынлык, кырыслык чыгарып, урыныннан торды. Буш сүз тыңлап утырырга теләге дә, вакыты да юк иде аның. Глафира чекист егетнең чырае сытылуын үзенчә аңлап:

— Мине тиз арада «үзен-үзе үтергән» хәлдә күрергә теләмисездер ләбаса?— дип сорады.— Баһаветдин кушкан йомыш Республиканың беренче җитәкчеләренә кагыла иде. Фаҗигане ишетүгә, мин бөтен белгәнемне РСФСР вәкиле иптәш Куйбышевка барып сөйләп бирдем.

— Соңгы тапкыр хәрби комиссарны кайчан, кайда күрдегез?

— Унтугызында, кичке өчләрдә. Ул партия Үзәк Комитетына көн саен кереп чыга иде.

— Иптәш Шиһабетдинов үзенә хәвеф янавын сизенә идеме?

— Бу хакта уйламаска тырыша, кылыч йөзенә басып йөрергә күнеккән иде ул. Верныйда да, Җидесу хәрби комиссары башы белән, фетнәчеләр оясына үзе барып керде ич. Могҗиза аркасында гына исән калды. Моннан сабак кына ала белмәде.

Ишегалдында нидер доңгырдады — Глафираның ире гәпне түгәрәкләргә ишарәли, ахры. Сәгатьнең унберенче китүен күргәч, Фарукҗан:

— Кара, соң икән инде,— дип гаҗәпләнгән булды.— Хәрби комиссарның Верныйдагы тормышы белән таныштык, Рахманкол турында сөйләдегез, Зөһрәгөлнең Үзәк Комитетта нишләп йөрүен белдек, сезнең фотоларны алдым,— инде нибары җинаятьне генә ачасы калды!

Байкучатовны ир белән хатын капка төбенә кадәр озата чыктылар.

## 37

Кәрвансарайга кайтып җиткәнче, Фарукҗанны ике җирдә хәрби патруль туктатты — Шиһабетдинов фаҗигасенә Кагандагы шартлау, базардагы янгын ише вакыйгалар да өстәлгәч, Бохарада уяулык көчәйгән иде. Чека тәрәзәләреннән берсеннән, ярты төн якынлашуга карамастан, бүген дә якты сибелә — дежур чекист хәвеф-хәтәргә каршы көрәшергә әзер иде. Фарукҗан, үзе кизү торган егерменче октябрь төнен уйлап, күңелсез көрсенеп куйды: әлегә зәгыйфьрәк шул

алар. Сәүдәгәрләр, руханилар мәкерен дә вакытында сизенә, меңләгән Иргәшләрне, Таштимерләрне яңа тормыш өчен көрәшкә күтәрә алмыйлар, фаҗига булып узгач кына, гаепләләрне эзләргә керешәләр. Анда да абына-сөртенә генә. Хәрби комиссарга һөҗүм итүчеләрне ачарга күптән вакыт иде инде, югыйсә!

Фарукҗан, Әминевне очратырга теләп, дежур бүлмәсенә килеп кергән иде, кабинетта арлы-бирле йөренгән Юлтай Симиниевкә тап булды. Чека секретаре туктап калды һәм гаҗәпләнеп:

— Кара әле син, Ташкентта түгелмени?— дип үзе сүз кушты.

— Башым авырта, хәлем дә китте — ярты юлдан кире борылырга мәҗбүр булдым.

Симиниев, аңа ышанмаган төсле караш ташлап, сорады:

— Алай чирләгәч, нигә Багбан якларын айкап йөрдең соң?

— Сызгырып та өлгерделәрмени инде?

— Ни дигән сүз ул «сызгыру»?— Симиниев шактый кырыс эндәште.— Кушмаган эшләргә тыгыласың да, аннары Чекага өстеңнән хатлар ява. Синең аркада безне дә гаеплиләр.

— «Басмачылар планын өзә», дипме?

— Үзеңне генә булдыклы революционер санама!— диде Симиниев коры гына.— Мөгез чыгарырга кем дә оста. Әлегә оператив эшләргә Чекада мин җаваплы. Кирәксә, сиңа да өлеш чыгарырмын. Ләкин, башка бер уй килде исә, теләсә кая китеп барырга түгел. Әмер буенча гына.

Фарукҗан бүгенге сәфәрнең Әминев белән килешенгәнлеген белгертергә теләмәде. Тузынсын әйдә, серне ачып кына Юлтайга үз булуы кыен. Тик... нинди хатларны телгә алды соң әле Чека секретаре? Үзе берәр нәрсә әвәләмәде микән?!

Ул, әле һаман хезмәттәшен тыңлаган кебек басып торса да, бүлмәнең бердәнбер тәрәзә төбенә күз салмый калмады — Чека хезмәткәрләренә килә торган хат-хәбәрләр шунда җыеп куела иде.

— Әйе, анда синең үзеңә дә нидер килгән бугай.

Фарукҗан көлемсерәп Юлтайга баш какты да үзенә адресланган конвертны ачты. Хат атасыннан иде.

«Хөрмәтле вә гыйззәтле углым Фарукҗан!

Сентябрь азагында Бохара каласыннан язган хатыңны алдык, исән-аман йөрүеңне белеп шат булдык.

Үзебезнең хәлләргә килсәк, бүгенгесе көнне бер көе яшәп ятабыз. Иген-тару, иншалла, җыйналып бетте, бу эштә дәү апаң белән Мөхәммәтгали җизнәң бик зур ижтиһат кылдылар. Кечкенә апаңнар бәрәңге алырга булышты. Мал азыгыбыз мулдан түгел, мәгәр башмак тананы сатсак, үгез бозауны сугымга суйсак, бәлки калган терлекне кыш чыгара алырбыз. Әмма бездә хәзер мал асрау кайгысы түгел, икебез дә чамасыз туздык. Әлегә кадәр дә без ул терлекләрне, улыбыз өйләнә калса, кирәге чыгар, дип кенә асрый килгән идек. Әмма син, теләгебезне санга сукмый, тагын еракка — әллә кайдагы Төркестанга китеп олактың. Авылыбызда «Озын Гыйльман Фарукҗаны солдатта йөреп бозылган, зимагурлыкка сабышкан икән», дигән сүзләр таралды. Без сиңа ярәшергә дип күз атып йөргән Алтау Әхмәрнең төпчек кызы да шушы көннәрдә кияүгә чыкты. Туена, күрше дип, безне дә чакырганнар иде дә, кермәдек. Беренчедин, сине көтмәүләренә хәтеребез калды. Икенчедән, келәткә иген ташыганда, бусагага абынып, әниең тез башын җәрәхәтләде, әле дә юньләп аягына баса алмый...

Син анда мәшһүр Бохарада җил куып кына гомер уздырмыйсыңмы? Шундагы берәр мәдрәсәдә «Шәрхе Габдулла»ны җиңеп кайтмыйсыңмы? Югыйсә, «Вакыт» гәзите алдырып торган Насретдин мәзин хәзер каммун булды, әлегә Балтай вулыс советында эшли, тиздән Тәтешкә, өяз хезмәтенә китә, дип сөйлиләр. Урыны шушы көннәрдә бушарга тора. Казанда да урысчаны белгән укымышлы татар җегетләре җитешми, имеш, юкса влачның җаваплы вазифаларга мөселманны күбрәк куярга нияте барлыгы рас, ди. Инде читтә ризык эзләп күп йөрдең, шушы хакта да уйла. Хәзер үзебез дә тәрәккә бик мохтаҗ. Гыйлеме дә, эше дә Казан ягында җитәрлек. Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар дигәннәр. Нәсел-нәсәбең белән бергә-бергә үз ояңда үз түгәрәк бәхетеңне кайгыртырга бик вакыт. Авылыбызда синдәйләрнең ике тезендә ике бала уйный хәзер. Әниең көн дә балавыз сыга. Абыйларыңның Ярман сугышында шәһит китүе кайгысыннан чәчләре бүздәй агарды, инде хәзер сине сагынып яшь коя, күзен бетерә. Әйтү шушы: тормышлары бүтәнчә акмаса, һаман начарлана гына барса андагылар нибуч, ривәлүтсәне үзләре дә ясар. Татарның үз кайгысы, үз нужа-мәшәкате дә

житәрлек, туган-үскән илкәеңне онытма. Атаң тугызынчы дистәне вакләды монда, язуым юкка гына таракан әзенә охшамый, тиктәстән генә кыек-мыек сырланмый. Кулның ибе юк, күз дә әлҗе-мөлҗе килә. Кышны әллә исән-имин чыгып була, әллә юк — ходайның ни язганын бәндә белми.

Инде ни, кәгазь исраф итеп, җавап биреп маташма, хатың түгел, үзең кирәк безгә. Шушының белән бетерәм. Күптин-күп, чуктыйн-чук сәламнәр озатып калучы атаң — Гыйльман Җиһангир углы».

Фарукҗан хатны кат-кат укыганда Симиниевне бөтенләй онытты. Атасы дөрес хәтерләп калган: авыл мәдрәсәсендә ул, зирәк шәкерт булганлыктан, төрки язуны, Корьәнне бик тиз укып китте, дин белеме, шәригать кануннары, мөселман әхлагы, хокук кебек белемнәр бәян ителгән «Төхфәтел мөлек», «Мохтасарел викая», «Фикеһ Кайдани» дәреслекләрен дә ерып чыкты, әмма «Шәрхе Габдулла»да абынды. Һади исемле иптәше белән алты кыш кимерде ул аны. Мулла абзый һәр көздә: «Алла теләсә, бу китапны без быел узып бетерербез»,— дип укыта башлый, әмма аның яртысына якынлашканда гына шәкертләр каникулга тарала иде. Әллә алла теләмәде, әллә мулла абзыйның әзерлеге әнә шул «Шәрхе Габдулла»дан югары ашмады. Ягъни, гарәп теле грамматикасын фарсы телендә аңлаткан дәреслектән! Атасы исә Фарукҗанның Казан мәдрәсәсендә белем эстәвен исеннән чыгарган, мәзин булыр яки вулыс советында эш майтарыр өчен улына шул гына җитми, дип уйлый, ахры. И картлык, картлык, замана үзгәрүен дә һич чамаламый, күрәсең. Мәзинлеккә кызыгамыни хәзер Фарукҗан?!

Аның хатны елмаеп, көлемсерәп укуын күзәткән Симиниев:

— Ни язалар, якташ?— дип кызыксынды.

— Әткәй мине өйгә кайтырга чакыра.— Фарукҗан хатның шул өлешен кычкырып укыды да башын күтәреп өстәде:— «Шәрхе Габдулла»ны су кебек эчсәм, димәк, мине илдә әнә нинди шәп урыннар көтә!

Әмма Симиниев җитди калды.

— Атаң төпле фикер йөртә бит, якташ,— диде ул.— Бөтенебез туган җирен ташлап китсә, милли учагыбыз сүнмәсме? Бигрәк тә үз республикабыз барлыкка килгәч, татарның читкә сибелүе гөнаһ. Кайтырга кирәк безгә.

— Үзең дә Бохарада йөрисең ич әле.

— Беренчедән, мин туган яклардан киткәндә, әле милли республиканың исе дә чыкмаган иде. Икенчедән, безнең Самар тарафы татар авылларының бик күбесе хәзер дә Татарстан эченә кертелмәде. Әмма мин шул хәлдә дә республикабызга җыйналу яклы.

— Татарстанда халык тыгыз урнашкан, җир әз. Шуңа күрә читкә китәләр.

— Татар тарала, аның урынына бүтәннәр килеп төпләнә. Ятларга җир бик җитә, димәк?

— Алар шәһәрләргә килеп эшче була, кендеген җиргә бәйләми.

— Шәһәре дә безнең ата-баба биләмәсе. Аның туфрагын ятлар табаны таптаганчы, яңгыр камчылавы, кояш көйдерүе яхшырак. Ничә гасыр сагынып, зарыгып аякка бастырган милли дәүләтебезне онытып, монда буталып йөргәнче...

— Без Бохарада да кирәк ич.

— Һәммәбез дә түгел. Келәм юкта чыпта яхшы, укымышлы төркестанлылар җитешмәгәндә, күзе ачык татар да әйбәт. Үзләре аякка басканчы! Ә аннары?

— Сез монда беркайчан да артык кашык булмассыз, минемчә. Телләрен, гореф-гадәтләрен үзләреннән ким белмисез, үзбәктән аерырлык та түгел.

Фарукҗанның мактавы Симиниевкә коймакка ягылган май кебек сеңде. Ул горурланып:

— Мин, чыннан да, һәр төрки кавемгә үз була алам,— диде.— Миңа монда һәммәсе якын, һәммәсе кадерле. Ләкин аларның күпчелегенә әнә шундый рух җитми, кабиләчелек чире өстенлек ала.

— Нилектән килә икән ул?

— Үсештән. Татарга язмыш үзе инде күптән бөтен төркиләрне кайгыртырга йөкләгән, ахры. Сәүдәгәрләребез колачын, мәгърифәтчеләребез кыюлыгын, сәясәтчеләребез укымышлылыгын, активлыгын гына күр!

— Шулай да ничә гасыр буе тирес корты сыман яшәгәнбез,— диде Фарукҗан.— Көрәк-сәнәктән, әлпи-тиси, бисмилладан ерак китә алмаганбыз.

Симиниев куе кара чәчен артка таба сыпырып, арлы-бирле йөренгән җиреннән капылт туктап, Байкучатовка төбәлде.

— Шулай. Аяусыз тәре походларының соңгысы асып-кисеп, яндырып-көйдереп узган безне. Бер хәлиткеч җиңелү дистәләгән буынны бәхетсезлеккә дучар кылган. Колонизатор, татарны кайгыртырга кирәк булса, ташбакадай, бик сүлпән, авыр һәм кыюсыз кузгалган, әмма аны йөгәнләү, изү-сыту фикере туса, юлбарыстай, гаҗәп соллы һәм елгыр хәрәкәткә килгән. Тик шул хәлдә дә безнең халык иманны җуймаган.

— Аннан ни мәгънә чыккан соң?

Симиниев гадәттән тыш таң калган сыман карап торды да ачуланып:

— Син моны чынлап сорыйсыңмы? Шул дәрәҗәдә рухыңны югалттыңмыни инде?— диде.

— Ә нәрсә...

— Газиз ата-бабаңа, нәселеңә, милләтеңә шулай икеләнеп карарга, ышанмаска мөмкинмени? Без тагын: «Байкучатов укыган, дөнья күргән, аңлы егет, үзебезнең кеше», дип йөрибез сине. Болай дулкын өстендәге йомычка, җил иркендәге тузганак кына булып каласың түгелме соң?

Фарукҗан, Юлтайның ихлас ачулануын күреп, акланырга омтылды:

— Урыс халкы тулаем татарны измәгән инде. Безгә ярдәм итүчеләре дә булган. Сыйныфына карап...

Юлтайның аны тыңлап бетерергә чыдамы җитмәде. Бәхәскә урын калдырмый торган рәвештә:

— Еланның сорысы да, карасы да бер, иптәшкәем!— диде.— Хаким милләт, шул хакимлеген саклар өчен, милләтчелектән өстен булып кыланырга, үз корбанын, табышын кулыннан ычкындырмас өчен, мескен булып маташырга, сыйныф дип баш катырырга да мөмкин.

— Син алай дисең дә, менә мине фронтта, контузия алгач, ут эченнән санитар Монастырев сөйрәп чыккан. Башта Молодчино станциясе госпиталендә аңыма килә алмыйча унбиш көн ятканмын, корсак тифе эләктергәч, Мәскәүнең Ксиль-Загорянский шәхси дворян шифаханәсендә янә өч ай дәваландым. Шунда урыс докторлары гына аякка бастырды.

— Тапкансың икән игелекле җаннарны!— диде Симиниев мыскыл иткәндәй.— Бердәм, бүленмәс Русия империясен саклап кан түк тә, сине дәваламасыннар, имеш. Тагын мөшкел хәлгә төшсәләр, синдәй тиләләр бик кирәк булачагын гына белә ич алар!

Фарукҗан күңелсез бу бәхәсне дәвам итәргә теләмәде. Йокысыз төн, тынгысыз көн дә гаять йончыткан иде.

— Кәеф юк, чыгып ятыйм әле мин.

Симиниев аны сүзсез генә озатып калды.

Фарукҗанның ятагы шушында, кәрвансарай бүлмәләренең берсендә генә иде. Ут кабызып тормады, бил каешын чишеп, унатарын

мендәр астына кыстырды да өстен чишенде һәм салам тутырылган түшәгенә килеп ауды. Туңмас өчен аңа җәймә ябыну да җитә иде.

Арудан тәне таралып китәр сыман тоелса да, башы мендәргә тигәч кенә йокысы очты. Зыятдин станциясендә бераз черем итү килешкәнме, алдагы бәхетсезлек тынычлыгын үчердеме — үзе дә белмәде. Әлегә Бохара серләрен ача төшәрлек кеше Каган вокзалында кулга алынган «Бум» гына. Аны Газәли чәйханәсендә үзенә атуда гаепләп, ялгыш җибәрде, билгеле. Өркетә, янәсе. Ялгыш фаразның эшне кыенлаштыруы, «әллә ни белми икән бу», дигән фикер тудыруы гына мөмкин. Балҗан кулга төшергән күчтәнәчләрне акыллырак файдаланып, басым ясарга кирәктер. Балҗан дигәннән, ата-анасының Фарукҗанны башлы-күзле итәргә план коруларын гына күр әле — Алтау Әхмәргә кинә куалар, имеш! Ә уллары монда Зөһрәгөл дип җан атып йөри. Хәзер инде ул түгәрәк битле, карлыгандай кара күзле, кара кашлы, бала чәчләре маңгаена сибелгән Анарны күбрәк искә ала бугай. Фарукҗанга әле берәү дә аның шулкадәр ягымлы итеп «әкәҗан» дип эндәшкәне юк иде. Иргәш кенә сеңелләре турында сүзне озайтырга теләмәде. Ят кавем кешесенең атап кызыксынуын өнәмәдеме, әллә Шәрык ир-атларына хас рәвештә, хатын-кызларны санламавын күрсәттеме? «Әкәҗан, сез кышлагыбызга янә дә киләчәксезме?» Йә хода, Анарның бу сүзләре сорау гына түгел, чакыру, гүзәл бер җыр сыман колакны иркәли иде. Кызыкай үзе туй күлмәге игән кыяфәттә күз алдына баса. Таң җиледәй саф, тау чәчкәседәй нәфис, тулган айдай солтанатлы. Чү, Анармы соң бу, ә аның янәшәсендәге егет Фарукҗанмы? Юк, юк...

Байкучатов инде төш күрә башлаган иде. Багбан кышлагын түгел, Кытай чиге буендагы Җәркәнт каласын, Мостафа Янбулатов тасвирлаган Баһаветдин белән Шаһикамал туен!

## 38

Фарукҗан, ниндидер хәвеф янавын тойган шикелле, кинәт уянды. Тышта инде яктырган, әмма кәрвансарайда тынлык саклануына караганда, таң әле яңа гына аткан иде, ахры. Нәрсә сискәндерде соң аны болай кинәт? Йокы аралаш аңына Штеннел хаты килеп керде түгелме? Чыннан да, ул инглиз агентының бер хәбәренә керфеген дә селкетмәде ләбаса. Дүшәк станциясендәге Тарасов резидент белән шымчы арасында хәбәр йөртә. Кулга алырга да саварга үзен. Йә телеграфта, йә тимер юлда эшли торгандыр. Дөрес, шифрланган телеграмма белән генә аны өркетүе читен, белмәмешкә салыныр, мөгаен. Ул очракта чит илгә чик аша рөхсәтсез-визасыз чыгып йөрүенә бәйләнергә мөмкин. Контрларга алып бара торган бер йомгакның очы шуңарда, ашыгырга кирәк!

Чека рәисен кичәге эшләре белән таныштыргач, ул шушы хакта сүз ачты. Әминев исә Зөһрәгөл сөйләгәннәрне телгә алып:

— Беренчедән, Дүшәк моннан йөзләрчә чакрымда,— диде.— Икенчедән, Тарасовның шифрлы телеграмма алуын да, аны Мәшһәдкә илтүен дә әле ачыклыйсы, дәлиллисе бар. Шунсыз аңа басым ясау файдасыз.

— Әгәр күзәтү оештырсак, якын-тирәсен капшап карасак?

— Ярар иде дә, кемгә кушарга соң бу эшне? Әбдиев биләмәсен сагаларга көчең җитсә дә, куан. Башта борын төбендәге контрлар оясын туздырыйк без! Бик күп серләрнең йомгак очы шунда сыман.

— Анысы да дөрес.

— Иргәш, Амантайларың карауласын. Зөһрәгөл сөйләгәннәрне Бум расласа, Әбдиев эшнәләрен кулга алырга да мөмкин.

— Ә аның үзен, Симиниевләрне нишләтергә?

— Син Шиһабетдинов һәлакәтен тикшерә идең түгелме соң? Ашык. Чеканың бүтән эшләре дә көтә.
— Беләм.
— Сәүдәгәр Габделшөкерхан әнә БХСРның Әфганстанга дошманлык күрсәтүе хакында дилбегә буе нота язып китергән.
— Бәлки базардагы малына утны үзе үк төрткәндер әле.
— Ишназар дигән бер сәүдәгәр чамадан тыш зур салым салынуы хакында үзе монда килеп зарланды.
— Монысы инде Чекага кагылмый.
— Кагыла. Төрле-төрле ризасызлыкларны революциябез дошманнары юри уята. Без аларны да фаш итәргә тиеш. Бөгештерүләрне төзәтергә!
— Ревком, Халык Комиссарлары Советы ни карый икән соң?
— Габделхәмит — эшнәң ич, бар да кызыксын.
Фарукҗан Чека рәисенең төрттерүенә елмаймый булдыра алмады. Юаштан юан чыга! Бәлки Әминев бер дә юаш түгелдер, чаманы белеп, ипле эш итүчедер? Әлеге киңәшнең нәкъ файдасы тиярдәйләрен генә бирә килде, ялгыш адым ясаудан да сакларга омтылды. Комиссар һәм аның тирәсендәге кешеләрне, вакыйгаларны ачыкларга да булышкалый тора.
Аның чыгып китәргә һаман ашыкмавын күреп, Әминев:
— Йә, һәлакәт турында хәзер фикерең үзгәрмәдеме әле? — дип сорады.— Баһаветдин иптәш бәлагә үзен-үзе тыкмаганмы?
— Миңа очраган танышлары комиссарны мактап кына телгә алды. Шулай да сизелә: һәрвакыт кылдан нечкә, кылычтан үткен сират күпереннән йөргән ул. Артык тәвәккәл булган, үз-үзенә артык ышанган.
— Кара син аны!
— Кешегә, мөселманлыгы чамалы икән моның, дип уйларга да нигез биргәләгән. Төркестанда кемгә ошасын икән инде бу?
— Дөрес әйтәсең, монда халык үтә диндар шул.
Фарукҗан Багбан кышлагында Нурморат байны гаепләгәндә, Иргәш белән Амантайның аны якларга атлыкмауларын исенә төшереп:
— Бәлки безгә Төркестан вакыйгаларына тыкшыну гомумән кирәкмәгәндер? — диде.— Аннары үсә төшкәч, эшче-диһканнар үзләре дә күтәрелер иде әле. Фронтта минем яралыларга операция ясаганны карап торганым бар. Бервакыт врач булмагач, бу эшкә ни белеме, ни тәҗрибәсе җитмәгән фельдшер тотынды да күпме солдатны я гарип калдырды, я җан тәслим кылдырды. Без дә, әнә шулай белер-белмәс йөреп, зыян гына китермәсәк ярар иде.
— Нишләргә кирәк соң, синеңчә?
— Сабыр итәргә. Бохара халкы сыйнфый яктан катлаулана, аңы ачыла төшкәч, гаделлек өчен көрәшкә дә үзе күтәрелер, аңа ирешер өчен муафыйграк юллар да табар иде.
— Бохара халкы үз үсеше белән дә берзаман кешелекле тормыш өчен көрәшер хәлгә, әлбәттә, җитәр иде,— диде Әминев уйланып.— Тик бу үсеш, читтән этәрмәсәләр, дистәләгән елларга сузылыр иде, тагын ничәмә буынның гомер буе михнәт кичереп яшәвенә китерер иде. Без әнә шул озын-озак үзгәреш вакытын кыскартабыз. Димәк, тыкшынуыбыз үзе шәфкать күрсәтү түгелме?
— Көчләп күрсәтелсә, шәфкатьнең дә тәме китәдер, андый миһербанлылыкны җирле халык ишетергә дә теләмидер.
— Ихтимал, шулайдыр. Рәхмәт ишетәсе урында бәлки нәфрәт кенә казанырбыз.
— Алайса без, татарлар, нигә Татарстаныбызга гына кайтып китмибез соң?
— Ашыкмыйк. Яман — оятка, яхшы моратка җиткерә. Яхшылык итәргә йөрүебезне киләчәктә төшенерләр.

— Киләчәктә? Бик озак көтәргә туры килмәс микән ул киләчәкне?

Әминев Фарукҗанның кайнарлануына тыныч кына җавап бирде:

— Хәзер инде безгә бүтән юл юк. Булышырга алындык, чигенергә ярамый.— Аннары урыныннан торып, тәрәзә каршына килде дә, якташына янә бер караш ташлагач, дәвам итте: — Синең уйлануың ошый миңа. Гаделлек, хакыйкать эзлисең. Киңәшүең дә әйбәт. Уртага салып киңәшми торып, гаделлек тумый.

— Галимҗан абый, сорау алганда файдаланыр өчен, миңа Бумның берәр хаты кирәк иде әле. Килгән берсен Нурморатовка тапшыра бардым да...

Чека рәисе аны ярты сүздән аңлап, өстәлдәге папкаларның берсеннән кирәкле язуны табып алды һәм Фарукҗанга сузып:

— Кара аны, мөгез чыгармыйча эшләргә өйрән! — дип кисәтте.

Байкучатов Шәмгун Аксолтанов белән Таштимер Тураевның да нәкъ менә Әминев сыман фикер йөртүен чамалый иде. Хәрби-комиссар да шундый караштa торгандыр. Фарукҗан үзе дә алар сапкан юлдан атлый. Чека рәисенә ни тегеләй, ни болай дип каршы килмәсә дә, сөйләшүдән канәгатьләнеп җитмәде ул. Дөнья, тормыш алар уйлаганнан катлаулырак. Мавыгып китеп, аны кәкре көзгедәге шикелле, чалыш хәлдә күрүең, фаразларыңа мөкиббән рәвештә иң дөрес, иң яхшы юлны сайламавың да бик мөмкин. Саташырга теләми Фарукҗан, ләкин адәм баласы фәрештә түгел. Абыну-сөртенүләр аны сагалап кына тора.

Ул, бүтән бер генә минут та югалтырга теләмичә, Каганга сәфәр чыкты, атын юл буе куды да куды. Комендатурада аның болай җилле килеп керүенә гаҗәпләнсәләр дә, тоткын ябылган зиндан ишеген берсүзсез ачтылар. Кичә кулга алынган карт йокламый, бары йоклаганга сабышып ята иде. Байкучатов аны «ә» дигәнче аягына бастырды һәм өстәлле-урындыклы, зур тәрәзәле якты бүлмәгә алып керде.

— Бохара республикасы хәзер сугыш шартларында яши,— диде ул, кәгазьләрен сумкасыннан чыгара-чыгара.— Тикшерүне тартып-сузып маташа торган чак түгел. Дошманнарга йомшаклык күрсәтү безнең өчен үлемгә тиң. Шуңа күрә, йә барлык гаепләреңне танып, алдагы планнарыгызны ачып, халык хакимиятенә каршы көрәшүдән тәүбә итәсең, йә салган зыяннарың өчен рәхимсез җәзага тартылачаксың.

— Мин уртак Нурморатов кушканнарны гына үтәдем,— диде карт, һич тә бирешергә теләмичә.

— Ул мине үтерергә фәрман бирдемени? Нигә дәшмисең?

— Алла сакласын, андый җинаять уема да кергәне юк.

— Алайса Зыятдингa нигә бардың? Газәли чәйханәсеннән нигә мине куа чыктың, Бум әфәнде?

Карт, үзенең кушаматын ишеткәч, агарынды, башын аска ия төште.

— Тәкъсир, сез, валлаһи, мине бүтән адәм белән буташтырасыз,— дип мыгырданды.

— Чү, алла дип авыз чайкама, ичмаса. Кабартма яңаклы иптәшең дә кичә: «Газәли чәйханәсендә Латыйфхан кушканны гына баҗардым[1], Чека йомышын үтәргә дип кенә юлга чыктым!» — дип сайрады. Үзе басмачылар кәрванына барып кушылган. Тотылды асылкош, телен чишәргә мәҗбүр булды.

— Минем андый уртагым юк кү.

— Әле өченче көн генә шушындагы вокзал мәйданында аның белән, җим көткән кошчыклардай, Латыйфхан авызына карап торуыңны оныттыңмыни? Әүвәл ул да, синең кебек, киреләнеп маташты, аннары

[1] Баҗардым — үтәдем

барыбер гаепләрен танырга мәҗбүр булды. Менә бу синең язумы?

Карт Байкучатов кулында кичә үзе язган аңлатманы күреп, баш какты:

— Әйе.

— Ә бусы?

Чеканың агентура бүлегенә «Бум» дип кул куеп җибәргән хатларының берсен күргәч, карт тагын авызына су капты. Байкучатов гаҗәпләнгән шикелле:

— Әллә син Чека шымчысы булуыңны да яшермәкче инде хәзер? — дип сорады.— Латыйфхан Нурморатов белән бәйләнеш тотуыңны?

Карт үзенең артыграк бөгештереп ташлавын төшенепме, тагын раслап куйды:

— Минеке.

— Менә бусы акыллы җавап,— диде Фарукҗан кәефле төстә сорау алу беркетмәсен тутырып.— Шулай, син, кадерлем, Бум дигән кешенең үзе инде. Дөре-е-с. Ә менә бусы — кушканнарны әйбәт үтәвең өчен бүләк. Рәхим ит!

Байкучатов кулында алтын балдак күргәч, карт аптырашка калды. Фарукҗан исә аны үсендереп:

— Шулай, кушканны вакытында һәм яхшы башкарып чыгучы һәрвакыт бүләкләнә,— диде.— Әйдә, үзеңнең Бум атлы шымчы икәнлегеңне һәм бүләк алуыңны раслап, беркетмәгә кул куй да балдагыңны тот.

Карт әле һаман ышанып җитмәсә дә, Фарукҗан сузган кәгазьгә күз йөгертте, аннары кул да куйды. Ул алтын балдакны кулына алгач кына, Байкучатов җиңгән кыяфәттә:

— Блеккер әфәндедән ул! — дип көлемсерәде.

Карт, утлы күмер тоткан кебек, чыраен сытып, Фарукҗанга төбәлде, балдак чыңлап идәнгә тәгәрәде. Байкучатов юрамалый кайгыртучан төстә:

— Син нәрсә, дуслар бүләгенең кадерен белмисең? — дип битәрләде.— Алтын ич ул, лаеклы эшләрең хөрмәтенә җибәрелгән!

— Мин һичнинди Беликерне белмәймен.

— Менә сиңа туеннан соң дөмбер. Әбдиевләр өендә серләшүегездән дә танасыңмы? Килешми болай, киле-е-ешми. Блеккер әфәнде үзе сине бик яхшы исендә тота лабаса, менә күр, хатында: «Алтын балдакны Бумга тапшырыгыз»,— дип акка кара белән язган. Дөрес, инглизчә.

Байкучатов Штеннелнең Блеккергә адреслаган хатын сак кына картка күрсәтте дә бөкләп сумкасына тыгып куйды. Тоткынның йөзенә кара коелды, әлегә кадәр бик үк абайланмаган бөкресе чыкты. Фарукҗан исә юаткан, үгетләгән кыяфәттә сүзен дәвам итте:

— Ике хуҗага — Чекага һәм инглизләргә берьюлы хезмәт кылу җиңел эш түгел, билгеле. Аның каравы, әҗере ике яктан ява. Инглизләрдән — алтын балдак, Чекадан... Тукта, Чека сине ни өчен бүләкләргә тиеш соң әле?

Карт җавап бирергә уйламый да иде. Үз эченә бикләнгән дә катып калган. Фарукҗан, аны карашы белән бораулап, бераз көтеп торды да өстәде:

— Тел яшереп оттыруың да бар, кара аны. «Остаз»ың сүзгә юмартрак, бар бәлане Бумга өяр дә котылыр, ә син җәзасын татырсыңмы? Без дә баштан сыйпап тора алмабыз: үлемгә — үлем!

Карт тынычсызланып әле тәрәзәгә, әле ишеккә күз салды, урыныннан кузгалгалап кыбырсый башлады. Аның бу хәрәкәтләрен үзенчә юраган Байкучатов, унатарын кулына алып болгый-болгый кырыс тавыш белән кисеп куйды:

— Бер эләккәч, бездән ансат кына котылу юк. Чекадагы дуслары-

ңа да, башкаларга да өметләнмә. «Уяу», «Маһир»лар күптән күзәтү астында инде. Фаш ителделәр! «Остаз»ыңның оясы туздьı, дәдәкәй!!

Һаман тынычлана алмаган карт:

— Нәзир нәрсә өйдә соң миңа? — дип сорады.

Димәк, дөрес чамалаган икән, «Остаз» — Әбдиев! Фарукҗан сөенечен тышка чыгармады, картны телдән яздыруны дәвам итте.

— «Остаз»ың Шиһабетдинов фаҗигасен дә сиңа ишарәли. Имеш, Рахманкол белән сүз берләшкәнсез дә...

— Нәзир алай дип гәперә алмады.

— Нигә?

— Мин ул төнне Чарҗуйда кундым. Шаһитларым бар.

— Алайса нигә сине каралта соң ул?

— Җанаҗан дусларын шик төшүдән саклыйдыр. «Уяу» белән «Маһирны» сата алмайды кү, аларның куллары озын.

— Исән каласың килсә, «Уяу», «Маһир», «Остаз»лар турында бар белгәнеңне сөйлә. Блеккер әфәндене дә онытма. Алар белән ничек таныштың, нинди әмерләрен үтәдең — һәммәсен.

— Җәдә күпне көтәсез,— диде карт ачулы тавыш белән.—Сыгарсыз, сыгарсыз да тагын зинданга ябып куярсыз аннары. Ышанмыймын мин сезгә.

— Сөйләми хәлең юк. Серләрне чишсәң, моннан соң безгә хезмәт итсәң генә, ирек алачаксың. Уйлап кара: тату аерылмасак, «Сезне Бум сатты»,— дип бер сүз салуыбыз җитә, «Уяу»лар өере хәзер башыңны ашаячак.

Карт уйга калды. Бу юлы Фарукҗан аны ашыктырмады, битараф кыяфәттә карандашларын очлады, кыштыр-кыштыр кәгазьләрен актарды. Шулчак тоткын үзе телгә килде.

— Минем болай кинәт юкка чыгуым аларны сагайтачак кү,— диде ул.

— Кемне инде, «аларны»?

— Нәзирне, «Уяу»ны.

— Син, абзыкай, юк белән башны катырма, өзеп әйт: Рахманколга кем булышты?

— Минем Рахманколга бөтенләй катнашым юк,— диде карт үҗәтләнеп.— Нигә шуңар бәйләргә тырышасыздыр. Ишетеп кенә беләм мин аны, хәрби назыйр фаҗигасеннән соң гына.

— Нәрсәләр ишеттең соң?

— Шиһабетдинов «Уяу» белән «Маһир»га ошамаган. «Маһир» үз җуралары белән аны Бохарадан куарга теләгән.

— Нинди җуралары белән?

— Шул Ревком, Советтагылар кү. Халык комиссарлары. Ике тәкә башы бер казанга сыймайды. Шиһабетдинов баш комиссарны да өнәмәгән, аның да кәефен кырган, диделәр.

— Шуннан соң ул Шиһабетдиновны юк итәргә кушканмы?

— Анык белмәймен. Әмма ул «Маһир»ны ниятеннән сүтмәгән күренәде.

— Комиссарга һөҗүме «Маһир»ның уң кулы Юлтай Симиниев оештырганмы?

— Бу хакта Нәзирдән сорашырга кирәк, ул яхшырак беләде.

— Хәзер кайда соң ул?

— Корал китерә торган кәрванны каршыларга китмәгән булса, өендәдер.

— Ә Блеккер әфәндене кайдан табарга була?

— Белмәймен.

— Килеш-килбәте ниндирәк аның?

— Озынча ак йөзле, зәңгәр күзле икәнен генә искәртмәсәм, калган яктан бохаралылардан аерылмый да. Буе сездән ашу имәс, яше аз гына өлкәнрәктер. Чалма-чапан кигән, кәвештән йөри.

— Кәрван кайсы тирәгә килергә тиеш?

— Мәшһәд ягыннан чыгуын гына беләмен. Зәрәфшәннең уң тарафында, чүлдә каршылыйлардыр.

Димәк, «Уяу» — Юлтай Симиниев. Ә «Маһир»? Ревком да телгә алынгач, Габделхәмит Гарипов булырга тиеш. Хәрби Назыйр Шиһабетдинов белән борчагы пешмәве билгеле. Әмма аны юк итәргә үзбаш кына алынуы мөмкинме соң? Ышануы кыен. Башкалар белән дә бәйләнгән булса, бу инде чын сәяси сүз берләшү. Карт белеп ишарәләсә, монда саклык та саклык кирәк икән. Әйтәм Әминев гел кисәтә, яшерен дошманнарның дәһшәтле көчен аныклагандыр, көрәш хөкүмәт эшлекләре дәрәҗәсендә кайнагач, белгәннәрен Фарукҗанга ачарга икеләнәдер. Юлтайның әрсезлеге дә аңлашыла мондый шартларда: ялгыз түгел, терәкләре нык. Аларны халык алдында фашларга нык дәлилләр, чигенми торган шаһитлар ярдәм итсә генә инде.

Фарукҗан шуларны уйлый-уйлый картка кул куйдырды да беркетмәләрен сумкасына тыгып куйды. Аннары әле һаман идәндә аунап яткан балдакны иелеп алды һәм коридордагы кызыл гаскәрине чакырып кертеп, боерды:

— Тоткынны кире каталажкага ябып куегыз, янына берәүне дә кертмәгез!

Чекистның китәргә җыенуын аңлап алгач, карт каударланып:

— Сез мине хәзер иреккә чыгармыйсызмыни? — дип сорады.

— Ашыкма! — диде Фарукҗан коры гына.— Сайраганнарыңның дөреслеген тикшерәсе бар әле.

* * *

Каган инде йокыдан уянган, вокзал тирәсендә тыз-быз халык айкала иде. Базар да якында гына булганлыктан, арбалылар да күренә, дөядер, ишәктер, аттыр — кем кайсы хайванга атланмаган да нинди генә йөкне төямәгән. Елның шушы фасылына хас хозур иртә — кояшлы, әмма ми кайнатырлык эссе түгел, ашыкмыйча, үз көеңә генә кинәнеп тик сәйран чик. Базарына кереп, кавын-карбызын, җиләк-җимешен авыз ит, вокзал тирәсендә чуалган халыкны тамаша кыл — пәрәнҗә ябынса да, сылулыгы, зифалыгы, нәфислеге сизелеп торган кыз-кыркын да аз узып китми яныңнан. Фарукҗан әйләнә-тирәсенә, чыннан да, кызыксынып күз ташлады: вокзал тирәсе җанлы, үзенә бертөрле күңелле хәрәкәттә иде.

— Байкучатов! Нәрсә дөньяңны онытып кагаеп торасың?

«Кызыл шәрык» поезды типографиясендә эшләүче якташы икән. Әлмисактан бирле таныш кешедәй күреште дә бераз битәрләгән рәвештә:

— Бланкларыңны нигә кереп алмыйсың? — диде.— «Тиз тотыгыз»,— дип ашыктырдың да хәзер оныттыңмы?

— Истән дә чыккан, якташ. Эшнең яңалары искеләрен күмә тора. Өлгерттегезме?

— Әллә кайчан. Ничек анда, контрларның койрыгына басасызмы инде?

Фарукҗанның сер бирәсе килмәде, әмма егетләнерлек җае да юк иде. Шуңа күрә:

— Әйдә үзең дә Чекага эшкә күч әле, аларны бергәләп авызлыкларыбыз,— диде.

— Юк инде, минем эш — матбага ярдәмендә җирле халыкның күзен ачу. Калганын, уянгач, үзләре кайгыртсын.

— Шушы зирәк акылыңны миңа да алданрак биргән булсаңчы!

Фарукҗан якташына ияреп тәгәрмәчләр өстендәге типографиягә

кагылды һәм, бәйләм-бәйләм бланкларын алып чыгып, аларны уңлысуллы атына аскач, госпитальгә йөгерде. Ялгышмады, Амантай әле һаман шунда иде. Таныш палата ишеге каршысында нәни урындыкка утырган да, башын диварга сөяп, йокымсыраган. Фарукҗан аның иңенә кагылып:

— Йә, юлдаш, хатыныңның хәле ничек? — дип эндәште.

Амантай сискәнеп күзләрен ачты, аннары елдам гына аягына басып, тонык тавыш белән:

— Авыр,— диде.— Әмма доктор «терeләчәк» ди. Төне буе сызланып чыкты бичаракаем. Әле таң алдыннан гына йокыга талды. Шуннан соң менә үзем дә калыгып киткәнмен икән.

— Доктор әйткәч, савыга инде ул, кайгырма.

Амантай аның юату сүзләрен игътибарга алмады, башын иеп пошаманлы төстә:

— Әтеге басмачы җан биргән инә,— диде.— Һушына да килмәгән.

— Ах, нәләт төшкере! Сорау алырга да өлгермәдек ләбаса ул хашәраттән.

Фарукҗан үкенечле төстә сүгенеп куйды һәм бөкләп тоткан камчысы белән күн итеге кунычына суккалады. Аннары иптәшенә сынап карап әйтте:

— Балҗанны син караулау гына күп файда бирмәс. Докторлар дәваласын аны. Көтик, терелер, бушка аһ ормыйк әле. Тынычлан, савыгыр Балҗан.

Байкучатов, иптәшен иңеннән кочып, госпиталь коридоры буйлап тышка атлады. Ишегалдына чыккач, аяз һавага ымлап:

— Күрдең, дөнья бүген нинди якты,— диде.— Шушы якты дөньяда Балҗан кебекләр имин, бәхетле яши алсын өчен, тормышыбызны агулаучы елан өннәрен тузгытырга кирәк, дускай. Беренче нәүбәттә безнең бурыч, чекистлар бурычы бу.

— Мин сезгә булышырга әзер.

— Алайса Иргәшкә хәзер үк хәбәр сал: Бохарага кичекми кузгалуыбыз хаҗәт.

Бераздан чуар киемле өч җайдак тузан туздырып, Каганнан чыгып китте. Иргәш Фарукҗанга да түбәтәй, чапан, кәвеш тапкан. Фарукҗан да хәзер үзбәкләр шикелле киенгән иде: йолдызлы күн фуражкасын куенына тыгып, башына чигүле кара түбәтәй чәпәгән, юка яшел чапанны хәрби кителе өстеннән бөркәнгән дә билен бөтерелгән зәңгәр ситса билбау белән буып куйган.

— Сезгә таман, килешле бер чалбар таба алмадым, кичерәсез,— диде Иргәш кыенсынып.

— Боларына рәхмәт, чалбарын гына юнәтербез инде.— Байкучатов аңа таба борылып сорады: — Ничек, бүген ыстансада төн тыныч уздымы? Атыш, шартлау-фәлән ишетелмәдеме?

— Тыныч. Әкәм яңа салып яткан йортын сакларга кушкан иде, изелеп йокланган шунда. Ишек-тәрәзәсе куелмаган кү, һавасы яхшы.

— Ишек-тәрәзәсез йортның нисен саклыйсың инде? — дип гаҗәпләнде Байкучатов.

— Кыегын коруга, кеше күчеп тора башласа, өйгә җеннәр оялавы мөмкин,— диде Иргәш белдекле төстә.— Аннары аларны биздерү, тараканны юк итү кебек, бик кыен булады кү.

— Бар икән ишетәселәрем!

Фарукҗан, хәтер калдырудан куркып, көлмәскә тырышты. Әмма Иргәш аның тавышыннан ук ни уйлавын чамалапмы, аңлатып куйды:

— Әкәм шундый ырымнарга җедә ышанады. Аңа каршы төшүдән ни мәгънә, ачуы гына киләчәк. Сез киңәш иткәнчә, сеңелемне дә монда алып килеп укытырга җыенсак...

Фарукҗан шундук иптәшен хупларга ашыкты:

— Төптән уйлыйсың, бик дөрес. Сеңелеңне, әлбәттә, үз яныңда тотып укытырга кирәк. Безнең татар кызлары әнә белем алырга әллә кайларга бара.

— Беләмен,— диде Иргәш.— Ләкин безнең кышлак халкы бу хакта башына да китермәйде кү.— Әти-әни риза булырмы, сеңел үзе теләрме?

— Теләр, теләр,— дип дәртләндерде аны Фарукҗан.— Бәлкем ата-анаңны бергәләп барып үгетләрбез. Үзең дә укырсың, сеңелең дә. Шулай ич, Амантай?

Әле һаман хатынын уйлап барудан бушамаганмы, Туктаров хуплап авыз ачмады. Хәер, Байкучатов моңа аптырамады, камчысын болгап, атын куарга тотынды. Анарны Каганга китерү уе аны хәзер тагын да җилкендереп җибәрде. Кара җимештәй күзле, түгәрәк алма битле, бигрәк ягымлы кыз ич ул! Монда килсә, Фарукҗан аны күрә дә, тагын-тагын сөйләшә, серләшә дә алачак. Ә Зөһрәгөл — киселгән телем. Бигрәк тә иренең Әбдиев, юха еланнарның берсе икәнлеге мәгълүм булгач! Хәер, ире кем булса да, ике бала анасы аңа инде пар түгел.

Байкучатов Зөһрәгөлгә карата үзенең гаделсезлеген аңлый, әмма аны әле һаман кичереп бетерми иде. Анарны уйлап та саташырга ярамавын тоя. Көрәш кызуы бер яктан, гореф-гадәтләр икенче яктан арага әллә нинди киртәләр салуы ихтимал. Ике йөрәкнең серләре килешкән тәкъдирдә дә. Юкса, сернең уртак булачагын да һичкем вәгъдә итә алмый. Шуңа да карамастан, хыяллана, өлешенә көмеш кенә түгел, алтын да юрый иде. Бәлки әле шулай юраудан артыграк мөмкинлеге булмау да хәерлегәдер?

Бохарага кайтып кергәч, Фарукҗан бу юлы да иптәшләрен таныш чәйханәдә калдырды, аулакта чишенеп, милли киемнәрен дә аларга тоттырды.

— Кайберәүләр минем мондый әверелешне алдан ук белеп тормасын әле,— диде ул аларга.— Шушында көтегез, үзем кереп алырмын.

Әминев партияне тазарту комиссиясе утырышына киткән булып чыкты. Чекада Нурморатовтан башка җаваплы хезмәткәр күренми, алгы бүлмәдә өч-дүрт кызыл гаскәри әле үзбәкчә, әле таҗикчага күчеп гәп сата иде. Фарукҗан бланк бәйләмнәрен үз кабинетына кертеп атты да кизү торучыга:

— Мине сораучы булмадымы?— дип мөрәҗәгать итте.

— Юлтай әкә эзләгән иде.

— Әле кая китте соң ул?

— Ревкомга.

Бу җавап Фарукҗанны тынычландыра төште. Агентура бүлеге башлыгы Латыйфхан Нурморатовның:

— Әле сезне Каганда йөри дигәннәр иде кү, кай арада кайтып өлгердегез? — дип әйтүе дә аны әллә ни сагайтмады.

— Инде хәбәр дә бирделәрмени? — дип кенә көлемсерәде.— Әнә сезгә кирәкле бланкларны кайгыртып йөрдем.

— Дөньяда ниләр бар? Ташкент сәфәреннән уңдыгызмы?

— Ходайның язганынча инде, Латыйфхан абый. Бәндә шуннан артыгын кыла алмый.

— Сездәй елгыр егет күпкә ирешә алады, Фарукҗан уртак. Күпкә!

Байкучатов, буш сүз ташкынын туктатыр өчен, тизрәк кабинетына кереп китү ягын карады. Латыйфханның төпчену максатында сүз башлавына ул тамчы да икеләнмәде. Тапкан ачык авыз, белми генә тор әле!

Кабинетында өстәленә таянып һәм ике кулы белән башын учлап уйларга керешкәч, ул Бумны Каганда калдырып ялгышуын төшенде. Штеннел хаты белән Әбдиевкә барыр һәм Блеккерне тапшырыр өчен иң кулай кеше ич ул. Контрларның ышанычын казанган

бәндә. Аңа бер чекистны тагын җибәрсә яки, Бум хат белән бүләкләрне Блеккергә тапшырганда, өсләренә барып керсә, төтенсез янарлар иде. Әллә соң картны алып килер өчен Амантайларны кире Каганга җибәрсенме? Юлда ук Латыйфхан, Юлтайлар күзенә чалынсалар?

Фарукҗан каударланып телефонга барып ябышты һәм станция комендатурасы белән тоташтыруларын үтенде. Каган җавап бирүгә, трубкага:

— Алло, Чекадан бу, Байкучатов,— дип кычкырды.— Каталажкагызда кичә бер картны калдырып киткән идем ич әле. Әйе, бүген иртән сорау алган бәндәм инде. Хәзер шуны алырга ике кызыл гаскәрине җибәрәм. Нәрсә?! Симиниев килеп алып китте? Ничек инде, мин аның янына беркемне дә кертмәскә кушкан идем ләбаса. Чека идарәчесе? Булса соң. Уф, суйдыгыз!

Фарукҗан, бүтән ни әйтергә дә белми, трубканы ачу белән дык иттереп аппаратка элеп куйды. Гөмберт икән хәзер хәлләр, дип уйлады ул эсселе-суыклы булып. Бердән, Бум, менә дигән шаһит, җәзасын алмыйча кулдан ычкына. Симиниев инде аны коткарыр өчен берәр хәйлә уйлап чыгармый калмас. Икенчедән, телефоннан кисәтсәләр, Бумның януын, серләре ачылуын хәбәр итсәләр, дошман өере Бохарада да хәзер үк итәк-җиңен җыя башлар.

Фарукҗан Үзәк Комитетка шалтыратып, партияне тазарту комиссиясе утырышыннан ашыгыч рәвештә телефонга Чека рәисен чакыруларын үтенде. Кискен таләпчәнлеге булыштымы, бераздан трубкада таныш тавыш ишетелде.

— Галимҗан абый, Байкучатов әле бу. Каганда сорау алу көткәннән дә нәтиҗәлерәк узды...

Әминев аның хисабын тыныч кына тыңлап торды да:

— Каударланып харап иткәнсең икән ахырда,— диде.— Сөйләшенгән урында Глафира да кичәге хатынны очратмаган әле. «З» тәки Зәргәрән гөмбәзенә килмәгән. Димәк, өйләрендә көтелмәгән нидер булган. Үз дәлилләрең дә шунда юнәлткәч, кичекми барып өйләрен төнте, егетне кулга төшер. Утарын ышанычлы кызыл гаскәриләр белән чолгап ал, кораллы каршылык күрсәтүләре мөмкин, уяу бул.

— Беләм.

— Син һәрчак күп «беләсең» дә форсатның байтагын кулдан ычкындырасың. Комиссарлар Советына да өстеңнән зар килгән анда. Симиниев тә бүген, «төп вазифасын үтәми», дип сукранган иде.

Байкучатов эндәшмәде. Әминев сүзен йомшаграк итеп тәмамлады:

— Төштән соң чекада булачакмын, хәбәр биреп тор. Хәерле сәгатьтә!

Фарукҗан милиция командасыннан тәз атучы ике егетне сайлап алды да Амантайлар калган чәйханәгә җилдерде. Монда Иргәшне читкә алып китеп, Штеннелнең Блеккергә язган, яхшылап төрелгән хатын, алтын балдак белән алкаларын тоттырды.

— Яхшылап яшер. Хәзер син басмачылар шымчысына әйләнәсең. Өлкән иптәшең белән Каракүл ыстансасына менә шушы хат, күчтәнәчләрне илтергә баргансыз, тик анда сезне сүз куешкан кеше урынына кызыл гаскәриләр каршы алган. Караңгыда атышкансыз, качканда иптәшең авыр яраланган, егылып җан биргәндә генә хат белән бүләкләрне ул сиңа тапшырган һәм Бохарадагы Нәзир Әбди дигән затның адресын әйткән, шуны күрергә васыять иткән. Төшендеңме?

— Әйе.

— Ә Нәзир Әбди бу хат белән бүләкләрне синең күз алдында иясенә тапшырырга тиеш икән. Төшендеңме?

— Әйе. Ләкин... әгәр алар минем кайда торуымны, хатны кем кулыннан алуыбызны сораша башласалар, нинди җавап бирергә?

— Хәзер уйлыйбыз. Болай аңлатырсың: син Зәрәфшаннең уң ягындагы Чәйрекәр кышлагыннан. Иптәшең баш булган, син муен гы-

на. Ара-тирә аны озатып йөргәләгәнсең. Әгәр һәлакәткә очрамасагыз, аның нинди эшләр майтаруын тәгаен генә белмәгән дә булыр идең.

— Исемнәребез ничек?

— Үзеңнекен әйт. Иптәшеңнекен уйлап чыгар шунда, буталма гына.

— Ышанырлармы икән?

— Һәй, шундый кадерле амәнәтне тапшыр да шикләнсеннәр, имеш. Алтын җирдә аунап ятмый, туганкаем. Тик син үзең күбрәк төпченергә кара. Бохара яңалыкларын, көрәштәшләр хәлен. Кяферләрне сүккән бул, шәригать бозыла, дип сукран! Курыкма, без якында гына торырбыз, хәлне чамалауга, басып кереп җитәрбез. Әгәр Блеккер янына алып китсә, артыгыздан иярербез.

— Сигнал нинди?

— Эшең җайлы барса, ишегалдына чыгып, насваеңны төкерерсең. Ун минуттан тышка күренмәсәң, бурычның икенче өлешен үти башлыйбыз.

Байкучатов башкаларга да ничек хәрәкәт итәсен тәфсилләп аңлаткач, үзбәк киемнәрен киеп, үзе алдан китте. Амантай белән Иргәш аның артыннан, милиционерлар шактый ара калдырып, шулай ук Байкучатовка иярделәр. Соңгылары әлеге мәхәлләне ике яктан күзәтеп, ихтимал качакны сагалап торырга тиеш иде.

Алдан сүз куешканча, Фарукҗан — күршеләрнең уң кулдагысына, Амантай сулына кереп посты, тавышка чыккан хуҗаларга, наган күрсәтеп, шауламаска ишарә ясадылар. Иргәш исә туп-туры «Уку өе»нә атлады. Тиздән ул үзе генә түгел, аңа ияргән Зөһрәгөл дә ишегалдында пәйда булдылар. Иргәш кулын изәп:

— Монда кереңнәр! — дип кычкырды. Иптәшләре якынлашкач, аңлатты: — Хуҗа әле генә каядыр чыгып киткән, өендә — базар.

Зөһрәгөл, Фарукҗанны танып алуга, чакырылмаган кунакларны өйгә керергә ымлады. Ишек ябылгач:

— Күршеләрнең кемгә ничек каравын белеп булмый,— диде.— Менә шундый хәл бездә, күченергә җыенабыз.

— Кая? — диде Фарукҗан.

— Ниндидер кышлакка. Нәзир бүген иртән генә кайтып керде дә бар өйнең астын-өскә китерде. Нишлим инде мин хәзер?

— Тиз кайтам, димәдеме?

— Олау табарга дип китте ул. Кыяфәте бик серле, ашыга-кабалана. Җигүле атлар килсә, үзен көтеп тормаска, әйберләрне төяп юлга чыга торырга кушты. Юк, булмый, качам мин мондый тормыштан, җитте!

Зөһрәгөл шулай өзеп әйтсә дә, чынлыкта яшьлек дустыннан берәр киңәш сорый шикелле иде. Ят ирләр алдында Фарукҗанны электән белүен сиздермәде, аларның өерләре белән килеп керүе сәбәбен дә сорамады, йөзен капларга да онытты, әйтерсең лә, Бохара гореф-гадәтләре аңа хәзер бөтенләй кагылмый да иде. Йөзе тимгел-тимгел кызарган, күз төпләрендә кипкән яшьләренең буй-буй эзе беленә, итәгенә килеп ябышкан балаларында да ваемы юк. Фарукҗан исә һич тә аның хәсрәтен уртаклашыр, киңәш бирер халәттә түгел, аның үз хәле хәл, фикеренчә, Зөһрәгөл язмышына әле соңрак әйләнеп кайтырга да бик мөмкин иде.

— Иреңнең кемнәргә китүен чама белән дә белмисеңме?

— Әйтә алмыйм шул.

— Бу безгә бик кирәк, Зөһрәгөл, безгә фәкать син генә булыша аласың.

Хуҗа хатын хәзер генә һушына килгәндәй:

— Уф, зиһенемнең таралуын гына кара инде,— диде.— Хәзер, бер якын әшнәсенең йортын гына күрсәтимче һич югы.

Урамга чыкканда Зөһрәгөл пәрәнҗә бөркәнгән иде. Атын җитәкләп янәшә атлаган Фарукҗаннан ул:

— Нәзирне кулга алсагыз, нишләтәчәксез? — дип сорады.

— Хәрби комиссар фаҗигасенә катнашы барлыгы исбатланса, хөкем каты булачак.

— Син әле монда озак хезмәт итәргә җыенасыңмы?

— Белмим. Әткәй карт өйгә кайтырга куша.

— Дөрес куша. Мин дә Ташкентка, бәлки әле аннан да арырак китәрмен, ахры.

— Гаиләңне ташлапмы?

— Мин гаиләдә бәхетемне тапмадым. Ирем белән күңел якынлыгы булмады.

— Киләчәктә ничек яшәргә уйлыйсың соң?

— Балаларымны каенаталарыма калдырачакмын. Укырга кирәк хатын-кызга да. Хәзер әнә нинди мөмкинлекләр ачыла ич.

Фарукҗан митинг-җыелышларда, матбугатта хатын-кыз ирегe, тиңлеге хакында күп ишетсә дә, күп укыса да, аларның никахка каршы да баш күтәрүе белән әле болай күзгә-күз очрашканы юк иде. Якларга тиештер инде ул Зөһрәгөлне. Ләкин нindидер көч аның ихтыярын богаулаган. Хатын-кыз күндәмлеге, аның тормыш михнәтләрен сабыр кичерүе, еш кына үз шәхси бәхетен корбан итү хакына гаилә бөтенлеген саклавы шулай тиеш кебек ата-бабадан ук аңына гына гүгел, канына да сеңгән, ахры. Революция солдатына килешми.

Аның сүзсез калуын үзенчә аңлаган Зөһрәгөл:

— Син шикләнмә дә, кыенсынма да, мин авырлыгымны беркайчан да кеше җилкәсенә салырга исәп итмим,— диде.

Фарукҗан уңайсызланып:

— Эш кыенсынуда түгел, булышырлык мөмкинлегең булу да кирәк ич әле,— диде.—Үзең дә беләсең: вәгъдә бирү ансат, үтәве бик читен.

— Кулыңнан килсә, ярдәм итәр идеңме?

— Сорап торасың тагын.

— Рәхмәт. Тик мин алдымдагы киртәләрне хәләл көчем белән җиңәргә тырышачакмын.

Биек дуваллар арасыннан боргалана-боргалана бара торгач, кирәкле капкага да килеп җиттеләр. Зөһрәгөл күздән югалуга, Фарукҗан иптәшләренә нишләргә кирәклекне аңлатты. Атларны бу юлы барын бергә якындагы бер хуҗаның ишегалдына кертеп бәйләделәр. Аннары Иргәш бәхет сынарга кереп китте. Бераздан ул ишегалдына чыгып, насваен җиргә төкерде дә тагын күздән югалды. Фарукҗанның йөрәгенә җылы йөгерде: эш пешәчәк болай булса!

Хәрбиләр көндез кеше күзенә бик тиз чалыначагын истә тотып, ул милиционерларга беренче нәүбәттә шикле биләмә эченә кереп яшеренергә булышты. Аннары Амантай белән үзе дә куакларга, хуҗалык корылмаларына ышыклана-ышыклана, мыдыр-мыдыр сөйләшү ишетелгән бүлмәләргә якынайдылар. Бохара йортларында тәрәзәләрнең сирәк һәм кечкенә генә итеп уелуы чекистларга хуҗалар күзеннән саклануны шактый җиңеләйтте.

Әмма бераздан тышта яшеренеп тору Фарукҗанны ялыктыра башлады. Өй эчендәге ирләр сөйләшүе ачык аңлашылмый, аны әчкәредәге хатын-кыз авазлары басып китә иде. Бу көтү барыннан да бигрәк күңелдә бүтән тынычсызлануны да көчәйтте: гәп озынга сузылса, Иргәшнең, берәр ипсез сүз ычкындырып, үзен тоттыруы ихтимал иде. Ләкин аңардан янә бер ишарә булмыйча, өйгә бәреп кереп тә уңмаулары мөмкин. Вакыт исә чаба, инде егерме минутлап узды бугай.

Шулчак бакчага табак тоткан бер үсмер кыз чыгып, йөзем өзә башлады. Аның дөпелдәве ишетелүгә, Фарукҗан да, Амантай да, җиргә иелгәләп, стена буеннан тирес өеме артына барып посарга өлгерде-

ләр. Кыштырдамадылар, тычкан сагалаган мәче кебек, сак кыландылар, кыз бакчада ят кешеләр барлыгын сизмәде шикелле, табагын тотырып, тыныч кына өйгә кереп китте. Бераздан күрше ишегалдын күзәткән милиционер алар янына килеп:

— Тегеләрдән шикле бер ир-ат чыгып йөгерде,— дип пышылдады.

— Нәрсәсе шик уятты соң аның?

— Мал абзарыннан килеп чыкса да, яхшы киенгән иде. Мин күзәткәндә ул анда кермәде. Элегрәк керсә, шул заман нишләп ятты икән ул? Абзарда нидер эшләве ишетелмәде ләбаса.

— Кыяфәте нindирәк иде?

— Сездән әз генә тәбәнәгрәк, какча. Базда ябылып утырган шикелле, ак йөзле.

— Күзләре зәңгәр түгел идеме?

— Ара шактый иде, аерырга өлгермәдем. Киң маңгайлы, озынча йөзле.

— Йөгер артыннан! — диде Фарукҗан милиционерга.— Берәр җиргә барып кергәнче күзәт, аннары шушында әйләнеп килерсең. Без китеп өлгергән булсак, Чекага кайт. Күргән-белгәнеңне анда иптәш Әминевкә генә ачарга мөмкин. Аңладыңмы?

— Хуп мәйле.

Амантай ярдәмендә милиционер дувалга үрмәләп менеп, урамга сикереп төшкәч, Байкучатов борчылып куйды: әллә кайдан ук күзгә бәрелер инде бу байгыш. Ярар, хәзер өйгә бәреп керәсе бар, әзәрлекләргә ышанычлы Амантайны җибәрә алмый шул инде ул. Милиционерларның икенчесен, берәүне дә өйдән чыгармаска, урамнан керүчеләр хакында шундук үзенә хәбәр бирергә кисәткәч, Амантайга:

— Наганыңны әзерлә! — дип боерды.— Башта бүлмәдәге ят ирләрнең һәммәсен коралсызландырабыз. Иргәшне танымыйбыз, шулай ук тентибез, әмма коралын тапмыйбыз.

Тәрәзәләре пәрдәләнгән ярым караңгы куак бүлмәсендә чәйле касәләрен тотып гәп коручы өч ир-ат өстенә Фарукҗан яшен кебек сискәндереп килеп керде:

— Селкенмәгез, йорт урап алынган!

Амантай наганын бүлмәдәгеләргә төзәп торган арада ул, җитез генә арттан килеп, табын янындагыларны капшап чыкты — Әбдиевнең чапан кесәсеннән револьвер тартып чыгарды.

— Кулыгызны артка куеп, маңгаегыз белән стенага терәлеп басыгыз!

Иргәшне ирекле калдыру шик уятмасын өчен, Байкучатов Нәзирнең генә кулларын бәйләде. Һәммәсен тагын бер кат капшап һәм бүлмәне тентеп чыкканнан соң да бүтән трофей кулга төшерә алмагач, таләпчән тавыш белән:

— Бандагызның бүтәннәре кайда? — диде. Хуҗа башын артка, аңа таба борып:

— Сез кем? Кандай банда? Йә раббым, инде үз өеңдә кунаклар кабул итәргә дә ярамыймыни соң? — дип җавап кайтарды.

Фарукҗан аңа таныклыгын күрсәтеп:

— Чекадан,— диде.— Сездә әмир куштаннары җыйналуын бик яхшы белеп килдек без. Кәмит уйнамыйк, коралларыгыз тагын кайда яшерелгән, күрсәтегез!

— Сәүдәгәргә корал нимәгә? Юк ул бездә,— диде хуҗа рәнҗегән төстә.— Әмир хәләл малыбызны талап ята иде, үз башына котырган икән. Шакаллар булышсын комсызга!

Юан гәүдәле, симез йөзле хуҗа ризасызлык белдерде, дәрвиш кыяфәтле Нәзир Әбдиев,— аны Фарукҗан бер күрүдә үк танып алды,— авызына су капкандай, ләм-мим эндәшмәде. Байкучатов бернәрсәгә генә сәерсенде: Иргәш күчтәнәчләрен тапшырган ич инде, кая яшереп өлгерделәр икән соң аларны?

— Чишенегез! — дип боерды ул әсирләренә. — Анадан тума калганчы!

— Булдыра алмыйм.

Әбдиев бәйле кулларын селкеткәч, Фарукҗан аны шул хәлендә яңадан бер кат җентекләп капшап алды. Аннары калган әсирләренең киемнәрен тикшерде. Шул чак Иргәш аңа күзләре белән түрдәге ишеккә ымлады. Бәреп кергәндә андагы бүлмәгә ул йөгереп кенә күз салып, буш икәнлеген барлап узган иде. Бүләкләрне шунда яшерделәр, диюе идеме бу иптәшенең?

Фарукҗан бу юлы арт бүлмәне игътибар беләнрәк карап чыкты. Аның ике стенасын бөтен буена идәннән түшәмгә чаклы затлы Иран келәмнәре каплаган, өченче ягындагы тәкчәгә — дивардагы махсус куышка юрган-ястыклар өеп куелган иде. Идәнгә дә калын келәм түшәлгән, ишек төбендә ике якта — ике нәни утыргыч. Фарукҗан келәм асларын, тәкчәдәге юрган-ястыкларны берәм-берәм күздән кичерде, капшап карады — берни тапмады. Шулвакыт тышта калган милиционер йөгереп кереп, аның колагына:

— Ишегалдында — иптәш Симиниев! — дип пышылдады.

— Үзе генәме?

— Бер юлдашы белән.

— Симиниевне кертеп җибәрегез дә юлдашын Амантай белән коралсызландырыгыз. Тавышы чыкмасын. Монда ыгы-зыгы ишетүгә, бәреп керегез. Барыгыз, тиз генә яшеренеп, өйалдында сагалап торыгыз!

Фарукҗан кунак бүлмәсендәге Амантайны милиционер белән коридорга озатты да Әбдиевне җилтерәтеп әлеге арткы бүлмәгә алып керде. Сагаеп калган хуҗаны түр ишектән күренерлек рәвештә табынга утыртып, кунагын сыйлауны дәвам итәргә кушты.

— Сездә чекистлар юк, булмады да. Хәзер яңа мосафир килеп керер. Әгәр аңа безнең хакта берәр нәрсә сиздерсәң, маңгаеңа — пуля. Онытма: йортың камалышта. — Фарукҗан аннары ысылдап диярлек Иргәшне дә кисәтте: — Син дә, егеткәй, мөгез чыгарма, без бик тәз атабыз!

Шулай диде дә, түр бүлмәгә ашыгып кереп, ишектә тар гына ярык калдырып, бусагада диярлек шым булды. Артка каерып бәйләнгән кулларын стенага терәп утырган Нәзир Әбдиев чекистлар күздә тотмаган ниндидер хәл тууын чамалаган, моңа сөенгән, әмма шатлыгын йөзенә чыгармаска гына тырыша иде, ахры. Байкучатов әсиренә наганын күрсәтеп, шыпырт кына торырга ымлады.

Сәүдәгәр өендә хәвеф тагын да куера төште.

## 39

Симиниев сәүдәгәрнең кунак бүлмәсенә, үз өенә кайткандай, үтә әшлекле төстә тулып-ташып килеп керде. Озын юл узганлыгы кыяфәтенә чыккан — киемнәре тузанлы, иреннәре кипкән.

— Әссәламе галәйкем!

— Вәгаләйкем, килең, килең!

Хуҗа урыныннан торып каршы алса да, гадәттәгедән тыенкырак исәнләштеме, әллә түрдә ят кеше утыруы икеләндердеме, Симиниев кискен хәрәкәт белән салган йолдызлы күн фуражкасын элеп куярга җыенган җиреннән тукталып калды.

— Кунагыгыз бар икән, гәбегезне бүлмимме?

— Килең, килең.

Хуҗаның тавышы бик тонык, нурсыз чыгуына кыйналды Фарукҗан. Шулчак Иргәш:

— Хуҗа — табыны белән, табын кунагы белән горур, имеш, түр-

гә узыгыз, — диде. — Мин үзем дә Каракүлдән җәдә әлсерәп килеп кергән идем, чәй эчкәннән соң гына хәлләндем әле.

Симиниев аякларын бөкләп табынга утырды, һәм бер-бер артлы ике касә чәй эчкәч:

— Әйе, Каракүл — ерак җир, тәкъсир, — диде. — Анда дөньялар тынычмы соң?

— Тынычлык кайда саклана икән инде ул хәзер? Юлдашымны монда килгәндә үтерделәр әнә, үзем дә көчкә генә сау калдым.

— Кайсы бәдбәхетләр гөнаһ кылды?

— Дуслар имәс кү. Ярый әле амәнәтен...

Хуҗа ишарә ясадымы, Иргәш үзе юри тукталдымы — сүзләре өзелеп калды. Симиниев исә кызыксына төшеп:

— Ә-ә, әманәт китердегезмени әле, тәкъсир? — дип сорады. — Безнең бүтән кунаклар кайда соң?

Фарукҗан, унатарын әзер тоткан килеш, колакларын торгызды. Әмма хуҗа, чәй ясаган булып, сорауны ишетмәмешкә сабышты. Иргәш белдекле төстә сүзгә кушылып:

— Сез икегез дә «Остаз»ның әшнәләре кү, аны теге күк-күз алдамады микән? — дип пышылдады. — Әманәтне кулыннан алды да юкка чыкты, миңа янә нишлисен дә әйтмәделәр.

Аны ничек туктатырга белмәгән хуҗа аптыраганнан тамак кырды, аннары диварда эленеп торган дөтәрне сузылып алып чирткәләргә кереште.

Иргәш шулай, бердән, иптәшләренә хәбәр бирергә, икенчедән, Симиниевнең телен ачарга тырыша иде, ахры. Юлтай, җимгә алданып, хуҗага:

— Блеккер әфәнде догасын биреп киттемени инде? — дип эндәште.

Дөтәр зыңлап идәнгә бәрелде, ул арада коридорда да нидер дөмберләде, шуның артыннан ук бүлмәгә купшы мыеклы, түгәрәк йөзле бер ир-ат йөгереп керде:

— Юлтай әкә, монда дошманнар!

Симиниев, утлы күмергә утыргандай, атылып сикереп торды, шундук кобурасыннан маузерын суырып чыгарды һәм стена буена — түр бүлмә ишеге ягына тайпылып, коралын коридор янына төзәп, тычкан сагалаган мәчедәй, хәрәкәтсез калды. Ят ирне эзәрлекләп килеп керәчәк Амантайларны мәгънәсез үлемнән коткару өчен, Фарукҗан:

— Туктагыз! — дип кычкырырга мәҗбүр булды.

Юлтай терелэй кирәк булганлыктан, аңа атарга кыймады. Симиниев исә яшен тизлегендә артына борылып, маузерын гөрселдәтте. Кырыйга чигенергә өлгергәнлектән, дошман пулясы ишекне тишеп, Байкучатовның колак төбеннән узып китте. Шул мизгелдә Иргәш, утырган урыныннан каударланып кузгалып, тәбәнәк өстәлгә әзерләнгән табынны туздырды, әмма идәнгә шуып төшкән ризыкка, чылтырап коелган касә, тәлинкәләргә игътибар итмәстән, Юлтай янына сикерде. Симиниевнең иптәше исә, бушаган өстәлне күтәреп алып һәм аны калкан итеп, үзен эзәрлекләп артыннан йөгергән Амантайларга каршы атлады. Фарукҗан ишекне тибеп ачып, кунак бүлмәсенә чыкканда, йөзе агарынган хуҗа әле бер, әле икенче якка ялт-йолт карапып, идәндә әүмәкләшә башлаган Иргәш белән Юлтай арасына керергә дә, купшы мыеклы, түгәрәк йөзле егетне туктатырга да икеләнеп, бүлмә уртасында басып тора иде. Фарукҗан аңа унатары белән изәп, аулак почмакка барып посарга боерды, аннары әле һаман җанфәрман чәбәләнеп, мышный-мышный Иргәш кочагыннан ычкынырга омтылган Юлтайга ябырылды, аның уң кулын артка каерып, маузерын тартып алды. Симиниевнең тешләрен шыкырдатып сүгенүен коридорда яңгыраган ату тавышы күмде — өстәл күтәргән егет деңкел-

дәп идәнгә ауды. Кемнәр белән алышуын хәзер инде яхшы абайлаган Юлтай җенләнеп:

— Нинди башбаштаклык бу, Байкучатов?! — дип акырды. — Ахмак, син моның өчен җәзаның иң катысын алачаксың, китер монда маузерны!

Фарукҗан иптәшләренә:

— Егетләр, һәркайсыгыз үз урыныгызга! — дип боерды. — Өйдән берәү дә чыгып кача, монда берәү дә яшеренеп керә алмасын. Килгәнен берсен каптыра барыгыз!

Аннары ул өс-башын тәртипкә китерде һәм юри хуҗага эндәшеп:

— Кара, нинди ачулы кунак килгән сезгә, Блеккер әфәнденең җан дусты! — диде. — Җыештырыгыз бүлмәне, мәҗлесне дәвам итик инде. Хәер, яраланган кунакка башта беренче ярдәмне күрсәтегез. Иргәш, син боларга күз-колак бул, түрә абзаң белән үзем эш итәрмен.

Ул, унатарын чапан астындагы кобурага салып куеп, трофей маузерның патроннарын тикшерде. Шуннан соң аны кулында уйната-уйната Симиниевка карап:

— Корал кулдан ычкынгач, бугаз ертабызмы? — диде. — Өркеттең! Утыр әйдә, гәп озын булачак безнең.

— Маузерны кайтар, ансыз мотлак авыз да ачмаячакмын.

— Мине шундук иләккә әйләндерер идеңме? Шәп гөрселдәтәсең, ишеккә кадәр чәрдәкләп бетердең әнә.

— Монда җанга сугып йөрүченең син икәнлеген кайдан белим? Вәхаләнки, чекист сакланырга тиеш.

— Менә без дә сакланырга мәҗбүр булдык.

— Сез фетнәчеләр монда минем шундаен әһәмиятле эшемне өздегез, трибунал каршында җавап бирәчәксез.

— Нинди яшерен эш иде соң ул? Англия разведкасына Бохара республикасы серләрен сатумы? Басмачыларга ничек булышу хакында киңәшүме?

— Сафсата! — диде Симиниев җирәнгән төстә. — Белеп әйтәләр шул: кара сөяк түрә булса, сәясәте тамак туйдыру, киенү ише түбәнчел ихтыяҗларны гына үтәүгә кайтып кала, милләтне кайгырту аның башына да килми.

— Монда милләтнең нинди катнашы бар? — дип гаҗәпләнде Фарукҗан. — Сүз юксылларга каршы күсәк күтәрүчеләрне, астыртын ут салучыларны тотып кисү турында гына барырга тиеш.

— Бәлки әнә шул «күсәк күтәрүчеләрне» түңкәрешкә, хакимияте гаделиягә хезмәт иттерергә буладыр? Кеше турында игълан иткән максатына карап түгел, куллана торган чарасы буенча да фикер йөртергә кирәк. Кирәкмәгән гауга, нәфрәт уятуга китерә торган адымнар революциягә фәкать аяк кына чала, максатка ирешүне бинибаа кыенлаштыра.

Фарукҗан Юлатайның ни өчен һушны алырга маташуын чамалый иде: авызы пеште егетнең, хәзер инде ничек тә үзен дөрес юлда йөрүче итеп танытырга, шулай котылырга азаплана. Ничек дигән әле Йөгәнәки бабай? «Елан дик бу аҗун, яныңнан еланны ку; сыйпарга йомшак, эче тулы агу!» Дөньяда, уяулыгыңны җуйсаң, бик тиз муеныңны сындырачаклар.

Симиниев, ничек кенә тырышса да, Байкучатовны үз ягына аудара алмасын белә, «маузерны кайтармасаң, авыз да ачмаячакмын», дип ычкындыруын да онытмый, әмма хәзер гөр-гөр килеп сөйләнми булдыра алмый иде. Чөнки түр бүлмәнең ярым ачык калган ишегеннән аңа Нәзир, Фарукҗаннар абайламаганда, бәйле кулларын күрсәтеп алырга өлгергән иде.

— Безне ничек тәрбияләделәр? — дип юри тавышын күтәреп дәвам итте ул. — «Улым, пылаудагы сөякне кимермичә ташларга ярамый, җеннәргә азык була»...

— Мин пылау ашап үсмәдем, — дип төрттерде Фарукҗан.

Симиниев исә, гүя, аны ишетмәде дә, кызып-кызып үзенекен тезә бирде:

— Һәркем ирекле яшәргә тиеш, кеше хөрриятен буарга, кысарга мотлак ярамый, дип баласына кайсы ата-ана тәрбия бирде? Шуңа күрә, кызганыч ки, күбебез җитди нәрсәләрне уйларга тулаем әзерлексез, кипкән мичкә кебек буш башларыбызга теләсә кемнең тузга язмаган сафсатасы кереп тула. Татар да, үзбәк тә Европа фикеренең, иҗтимагый хәрәкәтләренең күндәм мөрите, колы булудан уза алмый. Югыйсә, Шәрык халыкларының хәле, тормыш хосусиятләре бөтенләй башка, шунлыктан барыр юллары да Европа милләтләренекеннән тәмамысы үзгә.

Шомарган таш бу, дип уйлады Фарукҗан. Юлы буылса да, өне алынмаган. Тик аның тасма телләнүенә бирешәме соң ул? Тотсын капчыгын!

— Кешенең кешене изүеннән котылу Шәрыкка да бик килешер, — диде Фарукҗан. — Демократия, хөррият тантанасы булачак шул.

Яраланган кунакның ярасын бәйләп маташкан хуҗа:

— Үзегез хөррият дисез, үзегез шуның киресен эшлисез, — дип сүз кыстырды. — Гаделлек урнаштырырга теләгәч, нигә сәүдәгәрләрне җәберлисез?

— Күпчелекнең азчылыкны үз итхыярына буйсындыруы демократия була да инде.

Фарукҗан, шәп бәрдем, дип уйлаган иде, әмма Симиниев исе китмәгән кыяфәттә:

— Шәрыкта күпчелекнең нәрсәгә сусавын беләсеңме? — дип элеп алды. — Мәктәп-мәдрәсәләрдә дөньяви укыту кертү, салымнарны тәртипкә китерү, чамасыз узынган бәк-түрәләрне акылга утырту, исламга хезмәт итү — менә шуларга ирешүне бик җитә дип саный ул. Диһканы, һөнәрчесе, сәүдәгәре, мулласы — һәммәсе шуңа разый. Ягъни, бөтен мөселманнар. Европадагыча гөруһлар, сыйныфлар аслан юк монда.

— Ярар, бушка тегермән тартмыйк әле, — диде Фарукҗан бәхәсне туктатып. — Сез бер сорауга җавап бирегез: монда Блеккер, «Остаз» Нәзирләр белән мәҗлес корып йөрүләрегезне Чека рәисе беләме?

— Ул мәҗлесне әлегә сез генә корган күренә.

— Боргаланмыйча әйтегез: беләме, юкмы?

— Әлегә Чека эшләре өчен асасән мин җаваплы, сорауны да мин генә бирә алам, — диде Симиниев тәкәббер төстә. — Ә Чека Ревкомга һәм Комиссарлар Советына буйсына. Үзеңә генә түгел, бу вәхшәтең аркасында иптәш Әминевкә дә ифрат зур кыенлык киләчәк болай булса. Кем син? Теркәү бүлеге башлыгы. Яшерен-оператив эшләрне җәелдерү исә фәкать миңа гына йөкләнгән. Башбаштак рәвештә вәкаләтеңне арттырып, коралымны тартып алу җәзасыз калмаячак. Мине инде әзләргә дә керешкәннәрдер. Табарлар, коткарырлар. Ә мондагы җинаять, кан кою өчен кем җавап бирер?

Бу сүзләрнең буш янау гына түгеллеген, үзенең ут белән уйнавын Фарукҗан төшенә, әмма акланыр сәбәпләре җитәрлек дип уйлый иде. Бер тәвәккәлләгәч, чигенәсе килмичә:

— Каганда Бумны нишләттең? — дип сорады. Симиниев дәшмәгәч, икенче соравын да кабыргасы белән куйды: — Ә «Остаз» Әбдиевне Англия разведкасы ни өчен бүләкли?

Симиниев идәндә аунап яткан дөтәрне алып, бераүне дә санга сукмаган төстә чиртә-чиртә, үзбәкчә җыр сузып җибәрде. Фарукҗан аның артистлануын тыймады. Аның фикеренчә, җыр да ниндидер дәрәҗәдә сорауга җавап иде. Юлтай исә, көтелмәгәнчә дәртләнеп, ма-

тур куе тавыш белән җырлавын дәвам итте:

Әсирең җибәр, аучы, сәйярә икән миндәй,
Ал бавыңны муйныннан, бичара икән миндәй,
Язмышы яман, бәхте бик кара икән миндәй,
Аеру угыннан җисме гел яра икән миндәй,
Янган йөрәге-бәгъре йөз парә икән миндәй...

Аннары, төкергән шикелле, теш арасыннан берничә сүз сөзеп чыгарды:

— Нәзир — Халык Комиссарлары Советы рәисенең шәхси секретаре, дәү абзаңнардан сораш аны!

— Нигә инде алай иза чигәргә? — диде Байкучатов мыскыллы көлемсерәп. — Хәзер үзен генә сайратабыз аның. Иргәш, алып кер әле монда «Остаз»ны!

Аның ишарәсе буенча, хуҗа бүлмә түренә көчеп утырды. Яралы әле һаман идәндә ыңгырашып ята иде. Юлтай исе китмәгән рәвештә дөтәрен чирткәләп түр ишеккә төбәлде. Тик аннан Мирәхмәтевнең гаҗәпләнгән тавышы гына ишетелде:

— Уртак Байкучатов! Уртак Байкучатов, әсир юкка чыгыпту күт!

— Нәрсә? — Фарукҗан ышанмыйча түргә атлады, тик ишеккә килеп җиткәнче үк артына борылып, ачулы төстә: — Шыпырт! Урыныгыздан кузгалмагыз! — дип кисәтте. Аннары кире тышкы ишеккә таба борып кычкырды: — Туктаров, кер әле монда. Мена бу күн танаулардан күз язма!

Амантай күренүгә, үзе түр бүлмәгә кереп, келәмнәрне күтәреп, әүвәл идәнне, аннары стеналарны, гайре табигый яңгырау ишетелмәсме, дип бармаклары белән шакый-шакый тикшереп чыкты. Нәни тәрәзә ябык, ул кеше сыярлык та түгел иде. Нәүбәт бая юрганястыкларын үзе туздырып аткан тәкчәгә җитте. Ныгытып этәрүе булды, тәкчәнең арткы дивары урыныннан купты һәм бер кырыйга шуа башлады. Фарукҗан Иргәшкә күтәрелеп карап:

— Их без ачык авызларны! — дип сүгенеп куйды. Тикмәгә генә тасма телләнеп маташмаган ул теге юха елан, җыры, вәгазе белән юри игътибарны үзенә тарткан, кабәхәт! Бар, әле, кулларын бәйлә шуның!

Әле һаман сырт кабартып утырган Симиниевка күз дә салмастан, әмеренең үтәлүен генә көтеп торды да Амантай белән хуҗаны түр бүлмәгә дәште.

— Качкан һәр контр өчен башың белән җавап бирәчәксең! — диде ул сәүдәгәргә. — Йә бар малыңнан колак кагып, таш капчыкта черисең, йә әшнәләреңне тотарга булышасың — бүтән юл юк. Алып кер, әйдә, яшерен өнеңә!

— Кандай яшерен өн! Мин ай буе монда яшәмәдем, берни белмәймен.

— Мена танышырсың, шуыш әйдә тәкчәң эченә!

Фарукҗан уенча, анда кораллы дошманнар сагалап торса, беренче пуля корсагы чүмәләдәй кабарган хуҗага тиярга тиеш иде.

Сәүдәгәр юри кылана идеме, бисмилләсын укып капшана-капшана, сак кына караңгы бушлыкка кереп китте, агач баскычтан базга төште, аннары җир асты юлыннан шактый мүкәләп барды һәм икенче баскыч буйлап өскә үрмәләде. Фарукҗан, трофей маузерын атарга әзер тоткан килеш, аның артыннан бер адым да калмады. Аңа ярдәмгә Амантай да ияргән иде. Саман абзарга аяк басу белән сәүдәгәргә «тукта!» дип боергач, Фарукҗанның күзе төшкән элгәрегә әйбер ишек янагындагы чөйгә эленгән бер иске чапан булды. Балчыкка буялып беткән! Абзар ишеге ярыгыннан караса, әрләннекедәй җир асты юлы аларны күрше ишегалдына алып чыккан икән ләбаса. Ул да түгел, анда бая сәүдәгәр биләмәсендә йөзем җыеп йөргән кыз кү-

ренде. Хәзер инде Байкучатов һәммәсен аңлап алды, маузерын хуҗаның аркасына терәп, пышылдады:

— Чакыр әле шуны бирегә. «Агаларың исән-имин киттеме?» — дип сора.

Сәүдәгәр калак сөягенә терәлгән көпшәне тоеп:

— Кызым! — дип эндәшергә мәҗбүр булды. Пәрәнҗәле кызыкай ишеккә якынлашкач, Байкучатов әйткән сорауны бирде.

— Әйе, әкә.

— Нәзир әкәгезнең кулын чиштегезме?» — дигән сорауга да уңай җавап алгач, Байкучатов, ишегалдына чыгып, үзе телгә килде:

— Җәяү киттеме, аттамы?

Кораллы ят кешене күргәч, кыз өркә калды, әмма койрыгын бору мөмкинлеге юклыгын чамалап, башын түбән иде.

— Тиз бул, йә?

— Атта.

— Сине күзәтчелек итәргә күрше абзаң тарттымы?

Кыз эндәшмәде. Байкучатов сәүдәгәргә таба борылды.

— Кая барырга тиеш Әбдиевләр?

— Белмәймен.

— Уйла, ныгытып уйла, абзыкай. Сер саклап маташсаң, үзеңә генә түгел, бөтен нәселеңә авырлыгы төшәчәк. Шымчы кызыкайның да язмышы синең кулда. Яшь әле ул, зиндан газабын татыйсы килмидер. Ә гаебе би-и-ик зур. Синең аркада.

Байкучатов, иң гадәти бер эш эшләгән, сүзе гамәлдән аерылмый торган салкын акыллы, кырыс кеше сыман, тугыз-ун адымдагы алмагач ботагына кунган чыпчыкка төзәп атып җибәрде. Йә хода, тидерде, кошчык мәтәлеп җиргә тәгәрәде.

— Адәм баласының гомере дә шушы кошчыкныкы шикелле, — диде ул, маузерын әле сәүдәгәр, әле кызыкай ягына хәтәр юнәлткәләп. — Аны өзәр өчен чакмага бер басу җитә. Кунакларыгызның каршылык күрсәткән өчен нәрсәгә таруын күрдегез.

Ату тавышына өйдән бала-чага йөгерешеп чыкты, күрше-күлән ыгы-зыгы килә башлады. Байкучатов балавыз сыгарга тотынган кызыкайны да, сәүдәгәрне дә абзарга төрткәләп кертеп, таләпчән рәвештә:

— Көтәргә вакыт юк безнең, йә? — диде.

— Баланы ирекә чыгарыгыз, — диде, ниһаять, сәүдәгәр. Кызыкай елый-елый өенә кереп киткәч, төшенке рухта сукранды: — Сезгә аусам, тегеләр башыма җитәчәк, нинди болганчык заман бу, йә хода!

— Бу турыда берәү дә белмәячәк. Эшне яшерелгән кораллардан башлыйк.

Урамнан әйләнеп кире үз өенә кергәч, сәүдәгәр Фарукҗаннарны аулак йокы бүлмәсенә алып керде һәм кызыл мал тутырылган сандыкларның берсе төбеннән чүпрәккә төрелгән наган чыгарып тоттырды.

— Шул гынамы?

— Әйе.

— Амантай, булыш әле хуҗага, бәлки ул кайберләрен онытkandыр!

Бүлмәдән-бүлмәгә, шул исәптән, эчкәрегә — хатын-кызлар ягына кереп актарыну да, каралты-кураны тентү дә бүтән табыш китермәде. Йортның түбәсенә менеп баскач кына, Фарукҗан каршыдагы биләмәләрнең берсендә, ачык әвеслек астындагы шүрлекләрдә тезелешеп торган чүлмәкләрне күреп, җанланып китте.

— Әллә Чархарас мәхалләсеме бу? — дип эндәште ул хуҗага.

— Шул үзе.

— Каршыгызда чүлмәкче Хушмәмәт әкә яшиме?

— Тугры.

— Хуп! — диде Фарукҗан, канәгать төстә ишегалдына төшкәч. Аннары: — Ә сез Рахманкол белән кайчан аерылыштыгыз? — дип хуҗаның күзләренә төбәлде.

Тегесе керфеген дә какмый җавап бирде:

— Рахманкол! Кандай Рахманкол? Кичерәсез, мин андый адәмне белмәймен.

Байкучатов әлегә бүтән төпченеп тормаска булды. Ул арада капкадан килеп кергән, бая Блеккерне әзәрлекли киткән милиционерының борынын салындырган караңгы чырайлы кыяфәтен күрү белән үк төшенде: ычкындырган! Әмма моңа артык кыйналмады, чөнки ул тәҗрибәсез, әзерлексез ниндидер милиционерның йомышны уңышлы үтәячәгенә бик үк өметләнмәгән дә иде. Ятып калганчы атып кал, дип кенә җибәрде. Ә менә монда үзенең төп башына утырып калуы миен түндерерлек итте. Тәмам өннәренә баскач кына кулыннан ычкындырды лабаса еланнарны. Адәм көлкесе: Штеннел хатыннан, балдак, алкаларыннан да колак какты! Хәзер нинди дәлиле калды инде аның? Ничек кыса алачак ул дошманнарын?

Симиниевне сайрата алуы да икеле — гаепләүләрне берсүзсез кире генә кагачак. Йөз хәйлә, йөз мәкер уйлап куйгандыр инде. Монда гына ябып калдырса, сак куярга чамасы юк. Бүтән җиргә күчерсә, юлда эшнәләре очрап, кеше алдында ыгы-зыгы, дау кубарулары ихтимал. Кулга алып тотарга вәкаләте дә юк. Азат итәр иде, шундук тарафдарларын җыеп, Сафура бураннары күтәрәчәк, аяк чалырга, кара ягарга тотыначак. Бигрәк тә хәзерге бәрелештән соң.

Байкучатов төрлечә уйлап караганнан соң, һич югы бераз булса да вакыт отармын, дигән уй белән, әллә инде алдануы өчен үч тә аласы килүдән, Симиниевны шушында ябып калдырырга карар бирде. Сәүдәгәрне алып чыгып киткәндә, байбичәсенә:

— Тоткынны өч сәгатьтән чыгарырсыз, — диде. — Алданрак азат итсәгез, зыяны иregeзгә тиячәк, — дип кисәтте.

Яралыдан сорау алу файдалы мәгълүмат бирмәде. Шуңа күрә аны Чекага ала килделәр дә дежур карамагына тапшырдылар. Аннары Фарукҗан милициядә хезмәт итүче янә биш кызыл гаскәрине үзенә ияртте. Әбдиев корал китерүче кәрван каршына юнәлсә, аны әзәрлекләүчеләрнең шактый көчле басмачылар төркеменә очравы мөмкин иде. Чекистлар наганына өстәп, һәммәсе мылтык, җитәрлек санда патрон белән дә коралланды.

Чека урнашкан кәрвансарайдан чыгып барганда аларны агентура бүлеге мөдире Латыйфхан Нурморатов туктатты:

— Фарукҗан үкә[1], — дип кычкырды ул. — сез Юлтай уртакны күрмәдегезме?

— Юк шул.

— Кайда икән ул. Ревкомнан әзлиләр үзен.

— Белмим. Ә мине сораучылар бармы?

— Тураев күрергә теләгән иде, очратмады. Сез дә гел югалып торасыз кү.

Фарукҗан атын борып, кәрвансарай болдырыннан төшми генә гәпләшүче көяз Нурморатов каршысына килде. Мыек чолгыен бөтереп өскә җибәргән тук кыяфәтле хезмәттәше түгәрәк йөзенә ягымлылык, тавышына яхшатлану төсмере биреп эндәште:

— Бу кадәр баштанаяк коралланып кая юл тотасыз?

Байкучатов та итагатьле төстә:

— Латыйфхан абый, безнең язмыш — эт куып йөрү инде, — диде. — Ике яхшы бер сәкегә сыя, ике яман бер шәһәргә сыймый. Шулар аркасында безгә дә тынгы юк.

[1] үкә — эне

— Сездәй куш йөрәкле көрәшчеләр барда Бохара имин яши алады кү.

— Латыйфхан абый, Бум белән күрешкәләп торасызмы? Нинди яңалыклар ташый?

Фарукҗан бары менә шуны сорар. Нурморатовның ничек җавап бирүен ишетер өчен генә кире борылган иде. Симиниев Каган каталаҗкасыннан чыгаргач, шымчы аңа хәбәр биргәнме? Әгәр чыраен сыта икән, димәк, күрмәгән һәм хәзер кайдалыгын белми. Нурморатовның җавап бирергә ашыкмавын күргәч:

— Әллә Зыятдиннан кайтмадымы соң ул? — дип өстәде.

— Сез аны таныйсызмыни?

Сукыр бәхеткә өметләнергә ярамый. Керфек тә какмый имансыз, алырсың аңардан сер. Фарукҗан үкчәләре белән атланган атына какты да, кисәк борылып, кәрвансарайдан чаптырып чыгып китте. Иргәш белән сәүдәгәр аларны юл өстендәге мәхәлләдә көтеп тора иде. Оператив төркем шәһәрне артта калдыргач, юл күрсәтеп барган сәүдәгәрдән Байкучатов:

— Сез Нәзир Әбдиевне күптән беләсезме? — дип сорады.

— Ике ел чамасы.

— Ничек, кайда таныштыгыз?

— Ул Кириахта җәдит мәктәбе ачкан иде. Шуны ишетеп, углымны яңача укытырга ниятләдем — Кириахка сәфәр чыктым.

Сәүдәгәр тагын тынып калгач, Фарукҗан атын тыя төшеп:

— Йә, шуннан? — диде. — Кайсы ягы белән күңелегезне яулады инде ул?

Сәүдәгәр чалма очын сүтеп, тирләгән йөзен, муенын сөртеп маташа иде. Кояш баш түбәсенә җитеп кыздыра башлаган, һава бөркүләнгән иде. Очраган юлаучылар кораллы төркемне читкә кагылып уздырып җибәрә, кайсы үзбәкчә, кайсы хәрби кием киенгән мылтыклы ирләргә хәвефләнеп карап кала. Әмир чирүе еракка, таулар арасына чигенгәнлектән, көндез якын-тирә тыныч иде. Әмма әмирнең яшерен тарафдарлары әле шактый калган, алар караңгы төшкәч, юл буып һәм еш кына махсус кызыл гаскәриләр киемендә кышлакларга да бәреп кереп, халыкны куркытып-өркетеп маташа иде. Иртән төрле имеш-мимешләр дөнья гизә. Байкучатов ул турыда белә, шуның өчен дә үзләренә шикләнеп карауларын тоя, ләкин хәзер бу хакта уйламаска тырыша иде. Хәрби комиссар үтерелүенә бүген бишенче көн, инде кайбер нәрсәләр мәгълүм булды шикелле, тик астыртын аяк чалулар гына җинаятьне тәмам ачыкларга комачаулый иде. Чүлмәкче Хушмәмәт сөйләгәннәрне аның күршесендәге сәүдәгәр йортына чит ил разведчигы һәм сатлык Бохара бәкләре куштаны килеп йөрү белән бәйләсәң, — ә аны бәйләп карамый мөмкин түгел, — хәзер инде егерменче октябрь төнендәге фаҗигане анык күз алдына бастырырга мөмкинлек бар иде. Бу фаҗигадә Рахманкол, Нәзир Әбдиевләр нинди роль уйнаган? Алар кеше әмерен үтәгәнме, әллә үзләренең дә Шиһабетдиновта шәхси үчләре булганмы? Томанны менә кемнәр тарата ала. Тукта! «Талак» кычкырган, ләкин соңыннан бу ниятеннән сүтелеп, Балҗанны нигәдер кулыннан ычкындырасы килмәгән Әбдиевкә хәрби комиссар каршы төшә ич. Әбдиевне Ревком рәисе урынбасары Гарипов яклый, әмма ул да үз ниятен уздыра алмый. Шуңа үчләшүләреме? Бу очракта Амантай Туктаровка һөҗүм итүе ансатрак, хәвефсезрәк иде ич.

Фарукҗан сәүдәгәргә колак салып барган арада әнә шулай баш ватты.

— Өч-дүрт ел кадим мәктәбенә йөргән балам догалар ятлаудан узмаган иде. Җәдитчә исә берничә ай эчендә укырга-язарга өйрәнде, хисап, җәгърәфия, табигать гыйлемнәрен дә үзләштерә башлады. Әгъла остаз кү Нәзир, аның ысулы саутиясе белән танышырга без-

нең кәттә укымышлыларыбыз да күңел салды.

— Кемнәр инде ул?

— Садретдин Гайни, Кари Юлдаш, Фәйзулла Хуҗалар.

— Хуҗаев? Комиссарлар Советы рәисе булган кешеме?

— Әйе. Истанбулда белем алып кайткан кайбер затларыбыз да Нәзир остазга юлыгуны гарьлек санамады. Әмирлегебез бу өлкәдә артта калуын беләсез кү.

Байкучатов сүзне юри икенчегә борып сорады:

— Егермесеннән егерме берենә каршы төндә кайда идегез?

— Ташкентта.

— Моны кем раслый ала?

— Ташкенттан егерме икесендә генә китүемне анча адәм күреп калды. Кунган хуҗаларым, аларның күршеләре.

— Әбдиев Ревкомда озак эшләдеме?

— Ул анда барып булышкалап йөрәде. Уку йорты да тотады кү.

— Сезнең өйгә күптән юл салдымы?

— Бохарага күчеп килгәннән кәен.

— Блеккерне кайдан беләсез?

— Кемне?

— Идән астыннан качкан әлеге күккүзне.

— Аны минем башыма Нәзир бәла кылды. Ияртеп килде дә: «Иранлы галим Кәбирзадә әфәнде, Бохара мәдәниятен өйрәнәде, археолог», дип гәперде. Үзебез юкта өемдә тотарга рөхсәт сорады.

— Идән астыгызны шул «археолог» казыдымы?

— Тугры. Борынгы сарай урынына салынган, имеш, безнең йорт. Казып чыгарган балчыгын кала читенә ташып иләргә, табылдыкларны әтрафлы рәвештә өйрәнергә керешкән генә иде әле.

— Экият. Дөнья күргән сәүдәгәр башыгыз белән шул ялганга ышандыгызмы?

— Акылга хилаф нимәсен күрмәдем, уңа һичкандай давым юк. Фатир хакын да юмарт түләде кү.

Фарукҗан мыскыллы көлемсерәп башын чайкады. Әмма ышанмаска нигезе юк иде. Байлык дигәндә иманын да корбан итәргә әзер сәүдәгәр халкы. Шулай да ул әсирен:

— Кара аны, бай абзый, комнан аркан ишсәң, үзеңә үпкәлә, — дип кисәтте. — Җелегеңә үтеп, җаныңны суырырбыз.

— Бикәр гәп миңа нимәгә?

Кышлак арты кышлак артта калды. Зәрәфшәннең суы тездән ашмаган әллә ничә тармагын да кичтеләр. Чүлгә коя торган елгаларның язмышы шундый: тамагына якынлашкан саен саега баралар, ярлары тарая, агымнары сүлпәнләнә. Бохарадан ераклашкан чекистлар отряды да хәзер, әнә шул чүлгә коючы Зәрәфшән кебек, инде әүвәлге тизлеген, дәртен җуя төшкән иде. Утыз-кырык чакрым узганнардыр, ләкин сәүдәгәр үзенә билгеле җиргә килеп җитүләрен әле һаман әйтергә ашыкмады. Аңа карап, Фарукҗан икеләнеп тә куя иде: ихлас сөйләнде микән ул, дошманлыгын кылып, аларны тозакка төшерергә алып бармыймы?

Иргәшне ияртеп төркемнән бераз арткарак калгач, Фарукҗан:

— Син, туган, дошман өненә кыю үтеп кердең, рәхмәт, — диде.

— Кердем дә еланнарның кәттәләрен кулдан ычкындырдым кү.

— Монысы инде бер синең гаеп кенә түгел, анда археолог казынуын белмәдек лә. Әбдиев синнән шикләнмәдеме?

— Башта юк шикелле. Төпченүен төпченде инде.

— Блеккер белән сөйләшә алдыңмы?

— Ул миңа түр бүлмәдән карап кына рәхмәт әйтте, бүтән сүз катмады. Әманәтне Нәзир Әбди кертеп бирде.

— Ә хуҗа?

— Ул табын хәстәрләү белән юанды. Әзерләнгән ризыкны алып

керде, чәй ясады, гәпкә колак салып кына утырды.

— Сиңа яңа йомыш кушарга өлгерделәрме соң?

— Юк. Алар бүтән кунакларның килеп җитүен көтә иде, ахры. Пәрәнҗәле кыз хуҗаны чакырып алып пышылдашкач, миннән тагын сораша башладылар. Янәсе, өйләрен ялгызым тапканмынмы, артымнан берәрсе иярүен сизмәгәнмenme?

Атлар инде өшәнгән, каладан чыкканнан бирле бертуктаусыз иярдә бару җайдакларны йончыткан, бөтен гәүдәләре ял сорый иде. Малларны сугарып, үзләренә дә тамак ялгап алырга вакыт. Тик Фарукҗан алдагы кышлакка җиткәнче чыдарга булды.

Кышлак аларны гайре табигый җанлылык белән каршы алды. Мәчет мәйданына халык тулган, араларында кызыл гаскәриләр дә күренә, шуларның берсе чыгыш ясап тора иде.

— Рахманкол гәпердә кү! — диде Иргәш. — Ә-ә, егетләрне Кызыл Гаскәргә керергә өндәйде икән.

Чекистлар отряды мәйдан кырыена килеп туктагач, митингтагыларның бер ишесе аларга таба борылды. Фарукҗан исә нотык тотучы йомры гәүдәле, карчыга борынлы, купшы мыеклы Рахманколны гына түгел, аңа ничек күз салыр икән, дип әсир сәүдәгәрен дә күзәтә, телмәргә дә колак сала башлады. Сүзгә Фарукҗаннан остарак түгел сыман, әмма фәкыйрь диһканнарны, мал багучыларны яклар, әмир тарафдарларын туздырыр өчен, Кызыл Гаскәр корырга кирәклеге турында дөрес сөйли. Болай булгач, аның шушы максатта Зыятдиннан кышлакларга чыгып китүе дә рас инде. Бәлки әле шул сәфәрдән уралып кайтып баруыдыр бу. Катлаулы икән тормыш дигәнең: бер төрле фазар итәсең, икенче төрле ага да тора!

Бер-бер артлы үзбәк кызыл гаскәриләре дә чыгыш ясавын, халыкны үзләренә кушылырга өндәвен, кышлакта аларга теләктәш егетләр дә табылуын күреп, Фарукҗан сөенде, шул ук вакыт Рахманколдан бераз көнләшеп тә куйды. Шиһабетдинов мактәбен узу әрәм булмаган, аның үзенә менә шул җитенкерәмәгән икән!

Халык тарала, ыгы-зыгы кими төшкәч, Фарукҗан Иргәшкә отрядның тамак ягын кайгыртуны йөкләде. Аннары Рахманкол янына килеп:

— Чекадан Байкучатов, — дип күреште. — Сез хәрби комиссар йомышчысы ич әле?

— Йомышчысы идем дә, хәзер менә күрәсездер, вазифам үзгәрде.

— Күрәм, күрәм, иптәш Шиһабетдинов юлыннан әйбәт кенә атлыйсыз, эшен уңышлы гына дәвам итәсез икән.

Мактауга кәефе килсә дә, Рахманкол бик ачылып китмәде. Фарукҗанның сынап каравын, көчен сыздерергә теләгәндәй, кулын каты итеп кысып күрешүен, сүзен Чека кешесе икәнлеген искәртүдән башлавын, үзен хуҗаларча ышанычлы, хупларга да, хурларга да вәкаләте җиткән кеше сыман тотуын ошатмады бугай. Моны белгертергә теләмәсә дә, Байкучатов чамалады: егет бу очрашуга бер дә сөенми, аралашырга һич тә ашкынмый шикелле. Ни сәбәпле? Гаепсез икән, куркыр, тынычсызланыр урыны юк. Гаепле икән, нигә әллә кайчан бу тирәдән эзен суытмаган! Ил киң, мондый болгавырда эт тә эзләп табачак түгел.

— Баһауга җиту юк инде, — диде Рахманкол чекистның уйларын таратып. — Кешеләрне ышандыра, үзенә тарта торган тылсымы бар иде шул аның.

Фарукҗан хәрби комиссар турында болай аяк өсте генә сөйләшергә теләми иде. Шуңа күрә сүзнең үзе өчен ипле борылыш алуыннан файдаланырга омтылып:

— Мәйданда эшегез түгәрәкләнсә, аулаккарак китеп гәпләшик әле, — дип тәкъдим итте. — Мин сезне күптән эзлим инде, сорашасы,

аңлашасы нәрсәләр бар. Шиһабетдинов турында.

— Сүз озын булачакмы? Кешеләремне кисәтергә кирәкме, дип соравым.

— Әйе, әйе, кисәтегез.

Бераздан алар, итекләрен, чолгауларын ишек катында калдырып, яланаяк мәчеткә кереп утырдылар. Шактый биек һәм иркен, җир идәненә кайда келәм, кайда киез түшәлгән, тар тәрәзәләреннән саран гына яктылык сибелгән бинада бөркүлектән йончыган Фарукҗанга рәхәт булып китте. Калын диварлар эчендә тыныч, салкынча. Аларга ияргән Амантай Туктаровның да шушында гына кырын ятып ял итәсе килгәндер. Тик ул сөйләшүнең шаһитсыз гына барырга тиешлеген вакытында чамалап, болдырга чыгып утырды. Тышкы ишек ябылгач кына Фарукҗан:

— Рахманкол иптәш, Шиһабетдинов турында бар белгәннәрегезне сөйләгез әле миңа, — диде. — Сорашуыма гаҗәпләнмәгез, мин сезгә генә түгел, күпләргә мөрәҗәгать иттем инде. Һәлакәт сәбәпләрен, хәрби комиссарга теш кайрап йөргән дошманнарны ачыкларга кирәк. Монда комачауларга Симиниев, Нурморатовлар юк, бары дөресен генә сөйләргә тырышыгыз.

— Чека фаҗигане яңадан тикшерергә булдымыни? — дип сорады Рахманкол.

— Әйе. Яңа мәгълүматлар җыйналды. Хәрби комиссар мәетен караганда ялган өстенә ялган өелүен үзегез дә күреп тордыгыз ич. Туктаров! — дип кычкырды Фарукҗан, — Кер әле монда.

Амантай яннарына килеп баскач, Байкучатов Рахманколга:

— Безнең сөйләшәсе сүзләребез шул кадәр җитди, коралларыбызны шушы иптәшкә биреп куйыйк әле, — дип тәкъдим итте. Үзе, әңгәмәдәшен көтмәстән, унатарын Амантайга сузды. — Тенти аласыз, башка нәрсәм юк.

Рахманкол теләмичә генә наганын шулай ук тапшырырга мәҗбүр булды. Фарукҗан елдам гына аны капшап та алды һәм канәгать төстә Туктаровка:

— Монда хәзергә берәүне дә кертмә! — дип кисәтте. Амантай чыгып киткәч, бая башлаган сүзен ялгап җибәрде: — Әйе, яңа мәгълүматлар җыйналды, минем теге вакыттагы шикләрем тулысынча расланды.

Берәр сүз әйтмәсме, сорау бирмәсме, дип Фарукҗан көтеп торса да, Рахманкол ләм-мим эндәшмәде. Аягын бөкләп утырган да катып калган. Хәер, чекистны игътибар белән тыңлый төсле үзе. Ә йөзе караңгы, күз кабагы да кымшанмый. Байкучатов исә белгәннәренә фаразларын да кушып кысарга булды егетне.

— Беренчедән, фаҗигале егерменче октябрьнең кичендә дә, төнендә дә Шиһабетдинов иптәш янына сез әйткән хатын-кыз килмәде, — диде ул, моны шәхсән күреп торган шикелле. — Алар бер тәүлек әүвәл очраштылар. Икенчедән, үзегезгә дә мәгълүм, төнге сәгать унбер тулганда ул Чекадагы сакны алыштырды, дежур кабинетына кереп, минем белән дә сөйләшеп чыкты. Без шулчак аның белән иртән очрашырга килештек, кайбер нәрсәләр турында киңәшеп тә алдык. Хәрби комиссарның вәгъдәле егет булуын, сүзен җилгә очырмавын сез инде бик шәп беләсез. Җанкисәгем. Шулай ич?

Рахманкол бу юлы да җавап бирмәде. Келәм бизәгенә төбәлгән дә каткан. Фарукҗан, аның телгә килүен көтмәстән, әңгәмәдәшен карашы белән бораулап, тагын да ышанычлырак төстә дәвам итте:

— Әмма тагын да мөһимрәге — сезнең икәүдән-икәү генә Чархарас мәхәлләсенә аяк басуыгыз, шунда мылтык шартлау, ияреннән ава башлаган Шиһабетдиновны тотып алуыгыз һәм Бохарадан чыгып китүегез. Сез комиссар мәете янында бер нәрсәне генә дөрес әйттегез: «Без иптәшләргә хәбәр итеп кайтканда, әлеге хатын-кыз күренми

иде», дидегез. «Без» диюегез хак, ә менә башкасы...

Төсе качкан Рахманкол кыбырсып куйды, күтәрелеп Фарукҗанга карап алды. Күзләрендә аптырау, газаплану, икеләнү — әллә ничә төрле тойгы берьюлы чагыла иде. Байкучатов, дөрес эзгә басуын сизеп, тагын да канатланыбрак дәвам итте:

— Бай малае булсаң ярар иде, авызың ачканда үпкән күренгән башың белән Ревкомга, Комиссарлар Советына кереп оялаган сәүдәгәрләргә сатыл, имеш! Туй ясарлык, йорт салырлык мая вәгъдә иттеләрме? Хәзер инде үзеңнең кемлегеңне яшерер өчен, Кызыл Гаскәр җыйган булып йөрисеңме?

— Юк! Дөрес түгел!!! — дип кычкырып җибәрде Рахманкол әллә нинди карлыккан елак тавыш белән. — Уф, ник кенә килдем мин бу каһәр суккан Бохарага?

Ул изүен чишә-чишә утырган җиреннән тәгәрәп, йодрыклары белән идәнгә дөп-дөп иттереп суккалап ачыргаланды. Ишек ачылып, наганын кулына тоткан Амантай мәчет эченә күз салды. Идәндә аунаган Рахманкол әле һаман тузына иде:

— Җыен хәшәрәт дөнья болгата, баламут, мөселман дуңгызы. Яраттым лабаса мин Баһауны, кабахәтләр! Җиде бабаларынның кабер тактасын, каналья...

## 40

Чеканың үзенә дошманнар оялаган, Фарукҗан исә, шуны белә торып, тынычрак җиргә китеп баруны уйлап та карамый. Тәвәккәл, батыр егет, көрәсең. Алайса нигә Зөһрәгөл хәленә керергә, аны да үзенә көрәштәш итәргә алынмый соң ул? Нәзирнең кемнәр тарафдары икәнлеген ачыклаганнан соң да. Дөрес, Зөһрәгөл кияүгә чыгарга өлгергән, ике бала анасы. Ләкин теге чакта яратуы, Бохарага нәкъ менә яшьлек мәхәббәтен эзләп килүе чын икән, егетнең үтә тиз суынуын, аның инде бер табышканнан соң ничәмә көн күзгә-башка чалынмавын, бүген дә Чекадагы йомышы төшкәч кенә өйгә аяк басуын ничек аңларга? Килеп йөрүен тыеп, әллә соң эшне үзе боздымы Зөһрәгөл? Хәер, яраткан кеше тыюларга гына карап торыр идемени? Тормас иде, әлбәттә! Мең хәйләсен табар, әмма күрешер, яман язмыш иркенә бирелгән, дөнья яңарту хәрәкәтеннән читтә калган сөйгәнен үзенә юлдаш итәр өчен чарасын күрергә тырышыр иде. Димәк, сөюе дә шуның кадәр генә булган инде.

Чекистларны таныш сәүдәгәр өенә кертеп җибәргәч, Зөһрәгөл юл буе Фарукҗан турында әнә шулай баш ватып кайтты. Кулыннан килсә, ярдәм итәр иде, имеш. Мескенгә салышырга унбиш-уналты яшьлек шәкертмени ул хәзер? Әллә кемнәргә каршы көрәшергә гайрәте дә, елгырлыгы да бик җитә, ә менә Зөһрәгөлгә дуслык кулын сузарга... хәтта күңел табар өчен генә аның хәлен сорашырга да ашыкмады. Әгәр бу аның эш белән мавыгуы аркасында гына булмаса?

Үпкәләргә тиеш иде Зөһрәгөл, әмма ул хәзер күңелендәге үпкә хисләрен мин-минлек, гарьлек, Фарукҗанны үзенә каратасы килү тойгысы күмә баруын сизде. Инде бүтәннәргә күз салуы белән үзеннән биздерергә өлгергән Нәзиренә ияреп, әллә кайдагы кышлакка китеп югалсынмы, тагын да нурсызрак, уңайсызрак шартларда яшәүгә дучар булсынмы? Бала чүпрәкләрен, иренең каткан күлмәкыштаннарын юудан бушамасынмы? Дөньяда китап, гәзит-журнал ише нәрсәләрнең барлыгын да белмәгән кышлак хатыннары арасында җанына нинди ризык тапсын? Аларга хөррият әле гасыр ахырында да килеп җитмәячәк ләбаса!

Өенә кайтып кергәч, үзен чыр-чу килеп каршы алган, йөз чалымнары белән Нәзиргә охшаган кызларын ул, аңсыз рәвештә кырыс-

лык күрсәтеп, балаханәгә куып чыгарды да тагын көзге каршына килеп утырды. Бер-бер артлы бәби табып та ялгышкан икән, күкрәге инде элекке кебек тыгызланып калкып тормый, тулы йөзе дә суырылып, күз төпләре бата төшкән сыман күренә. Ир-ат моны абайламый каламы соң? Бәлки аның кырау алган төсле шушы кыяфәтен күреп суынгандыр Фарукҗан? Яшьнәп торган егет ич ул хәзер. Безнең халыкта сирәк очрый торган якты карашлы зәңгәр күзләре генә дә ни тора? Шуның өстенә кешелеклелеге бар. Бәлки Фарукҗан гомумән дә сирәк очрый торган әйбәт егеттер? Шәкерт чагындагы җан җылысы, дәрте сүрелү генә кызганыч. Тотнаклы, ыспайга әйләнгән хәзер. Йөрәгендә ут кабынса, бәлки ул нәкъ элекке хәленә кайтыр? Көчле куллары белән сөйгәнен кысып кочаклар да...

Зөһрәгөл керфекләрен йомды да ят кайнар сулышның йөзенә бөрелүен, күкрәгенең көчле күкрәккә орынуын тойгандай булды. Ире яшь хатынга өйләнеп маташты, хәзер дә кайсыдыр Хуҗаевларның чәчбиенә кармак салып йөри икән, әйдә, тик йөрсен. Үзе капкынга килеп эләккәнче! Аңа гына дигәнмени бу якты дөнья? Нигә әле шушы яшеннән Зөһрәгөл үзен читлектәге кош хәленә куеп гомер итсен? Яктырак язмышка лаек түгелме әллә ул?

Фарукҗан белән урамнан атлаганда Бохарадан китәргә җыенуын ул егетне сынар өчен генә әйткән иде. Ниятен әллә ни кутәреп алмады, әмма кирегә дә сукаламады ич. Бу адымның аның хакына да ясалуын белсә, бәлки ул Зөһрәгөлгә яңадан куәтлерәк тартыла башлар? Әгәр Зөһрәгөл үзендә яңа тормыш башларлык көчнең барлыгын исбатласа...

Ул керфекләрен ачып, тагын бер мәртәбә көзгегә төбәлде, тансык кешесе бәяләгәндәй, үзен-үзе күздән кичерде. Аннары сөрмәсен, иннек-кершәннәрен алып, бизәнергә керешге. Кунакка барырга җыенгандай, алтын алкаларын, ахак кашлы йөзеген, яраткан атлас күлмәген киде, чәченә энҗеләр тезеп чигелгән зәңгәр калфагын кадап куйды. Кашлары-керфекләре элеккечә үк куе, туткыллы түгәрәк йөзе элеккечә үк сөйкемле түгел, дип кем әйтә алыр икән? Менә шушы сылулыгы белән Ташкентка яки Казанга китеп, берәр югары уку йортына да керсә, нишләп Фарукҗанга тиң булмасын икән ул? Хәзер ирне ничек тәрбияләргә, кулда ничек тотарга мөмкин икәнлеген дә төшенә башлады бугай инде. Тота-каба егеткә тагылу, шулай үз бәяңне арзанайту ярамас, әмма аның күзеннән югалудан да ходай сакласын!

Тыштан бик тату күренгән гаиләнең таркалуын ишеткәч, күршекүлән гайбәт чәчәр, туганнары борчылыр, ата-анасы аһ орыр, билгеле. Әмма аларга карап, үз бәхетен нигә кайгыртмаска тиеш соң әле ул? Кеше чәйнәр, чәйнәр дә туктар, ә алдагы озын гомерне Зөһрәгөлнең үзенә яшисе. Аннары яңа җирдә аның үткәне белән кем генә кызыксынып торыр икән? Хафаланып йөрәген бозасы юк, тәвәккәллек, кыюлык кына кирәк аңа, калганы үзеннән-үзе көйләнеп китәр!

Ул тәмам бер карарга килеп, ерак юлга хәстәрләнә башлады.

## 41

Бу очрашу моннан ике атналар чамасы элек булган иде. Баһаветдин Шиһабетдинов, нәүбәттәге киңәшмәгә кереп киткәндә, аңа:

— Утырыш ике сәгатьтән дә тизрәк бетмәс, якын-тирәдәге берәр чәйханәдә юана тор! — диде.

Мондый тәкъдимгә колак салмаслык кире кеше түгел иде Рахманкол. Шуңа күрә ул бик рәхәтләнеп күрше мәхәлләгә таба атлады, инде ияләшеп өлгергән чәйханәсенә кереп, бер җамаяк мәнте, әзрәк күрәгә, уртача зурлыктагы чәйнек белән чәй һәм касә алып, ачык

эйвандагы палас җәелгән сәкегә килеп урнашты. Һәркемгә үз өлеше — хәрби комиссар Бохара мәмләкәте язмышын кайгырта, шуңа бәрабәр шан-шәраф казана. Рахманкол, командирының яңа әмерен көткән арада, күләгәдә кәеф-сафа корып ала. Революция. юксыллар, дип аһ-уһ килүне, дөресен әйткәндә, аңлап бетерми ул. Баһаветдин арбасына утыргач, киресен сукалап маташмый, әлбәттә. Сөйләнергә, гомумән дә, һәвәс түгел Рахманкол. Полициядә хезмәт иткәнгәме, тешләк гадәтле. Бәлки әнә шул әз сүзлелеге кызлар каратырга да комачаулыйдыр әле. Баһаветдинга әнә, мөселман дип тә тормадылар, Лидия белән Глафира бер юлы гашыйк булды. Апалы-сеңелле! Башкалары да үз итте. Бер мәртәбә казакъ җәйләвенә барганнар иде, яшьләр уенында да катнаштылар. Рахманкол анда да әллә ни майтара алмады, билгеле. Бер яхшылыгын истә тотыпмы, аның күңелен хуҗалар — бай абзыйлар күрде. «Өлкән ага, Ракә», дигән булып, тирмәгә алып кереп кымыз, бишбармак белән сыйладылар. Үзеннән олырак кешеләрнең яхшатлануы ошады ошавын, әмма Баһаветдинның инеш буенда кызлар-егетләр белән мәйханә килүеннән көнләште ул. Тирмәдән бер чыгуында Баһаветдин әйтештә катнаша, икенчесендә «Каратургай»ны җырлый иде. Аның көчле куе тавышы еракка яңгырап ишетелә. Рахманкол аның казакъча шома сөйләшүен белә. Әмма ләкин казакъ җырын болай оста сузуын беренче ишетүе иде. Бергә мәҗлестә утырган, аннары тышта әңгәмә сугып, җилләнеп, шул ук вакыт яшьләр авазына да колак салып торган агайларның берсе:

— Уйбай-ау, монау сирегең чибәр әнче икән гуй, калай чыркайды! — дип сокланган иде.

Әллә яшьләр — кунак егетен, әллә кунак үзе аларны бик ошатты, иптәше җәйләүдә, суга җибәрелгән балыктай, рәхәтләнде, монда ияртеп килгән Рахманколны исеннән дә чыгарды бугай. Моңа мин-минлеге кытыкланып, ул үзе дә учак уты баядан бирле ымсындырган инеш буена атлады. Аны хуҗаның җиткән улы:

— Морза, менә монда утырыгыз, — дип каршы алды һәм пыскып торган коры гөмбә тоттырды. — Чебен-черки күп, төтен генә кургаса кургайды безне.

Баһаветдин исә аны күрмәде дә — бер чибәркәй белән инеш ярына иңгә-иң утырган да учак яктысы төшкән йөгерек агымга чәчәк таҗларын өзеп ата-ата уйный, үзе бертуктаусыз сөйләнә иде:

— Шаһит бул, Алатау, шаһит бул, аем: агып китте гөлкәй, куа китте бае.

— Чәчәкнең дә ире буламыни? — дип сорады шулчак кыз чытлыкланып.

— Сездәй әдиме, чибәр гөлне кем ялгыз яшәтсен инде? — дип остарды Баһаветдин. — Әнә алар кавыштылар, безнең кебек, кочаклаштылар...

Кыз билен урап алган көчле кулны читкә кагып:

— Оят имәсме сезгә, агатай, кеше алдында?! — диде. Баһаветдин аптырап калмады:

— Гөлләрдән безнең кай җиребез ким? — дип акланды. — Алар кочаклаша да, үбешә дә әнә. Аулаккарак китик алайса, монда яктыга озынборын, черкиләр дә күп җыелган.

Кызның ризалыгын көтми, сикереп торды да, аны да урыныннан кузгатып, учак яныннан читкәрәк алып китте. Чибәркәе дә карышмады тагын...

Әйе, Баһаветдинда ул чакта ук ышаныч уята торган ихласлык, кызлар күңелен эретә торган ягымлы гайрәт бар иде. Рахманкол ярдәмендә почтага урнашканда, казакъ җәйләвенә кунакка барганда, егет әле сәясәткә кереп батмаган, юньлерәк киенү һәм ашауэчү, яшьтәшләре белән күңел ачуны иң зур бәхеткә саный иде.

Даими эше, сыеныр почмагы табылгач, күңеле тагын да үсеп китте егетнең.

Танышуларының икенче җәендә шикелле, ул үзе Рахманколны бер кичәгә чакырды.

— Глафираларда аулак, түрдә утырырга без кирәк,— диде.

Глеб Мартьяновның кире Ташкентка күчеп китүен белә иде Рахманкол. Баһаветдинны берничә мәртәбә Глафира белән күргәләве дә рас, тик алар арасында нидер булу ихтималын башына да китермәгән иде. Шуңа күрә ул гаҗәпләнеп:

— Шул чыпчыкка бәйләндеңме? — дип ычкындырды.

— Беренчедән, Фира апаең — сандугач, ничек сайравын үзем генә беләм,— дип көлде Баһаветдин.— Икенчедән, анда сиңа яраклы түше киерелгән күгәрченнәр дә булыр. Гайрәт суын да кыстыра кил, кызлардан өмет итү ярамас.

Монысы инде Рахманколны бигрәк тә таң калдырды. Полициядәге иптәшләре белән хәмер авыз иткәне бар барын, ләкин кызлар табынында... Баһаветдин көлеп:

— Тәһарәт алып, бисмилла әйтсәң, аның языгы юк,— диде.— Кыюлык өчен, арыслан тотарлык кына кәгәрбез.

— Мин дежурда шул бүген.

— Эштән соң рәхим ит, аулакка куна баралар.

Рахманкол килгәндә мәҗлес инде кызган, җыр, гармун тавышлары урамга кадәр ишетелә иде. Полиция формасын салгач, әллә чыннан да гайрәте кимегән иде, утлы эчемлек ярап куйды, бераздан ул үзен иркенрәк тота башлады. Баһаветдин аның колагына:

— Лида тирәсендә бөтерел әле! — дип пышылдады.— Юкса ул безгә көн күрсәтмәячәк. Макта, өйалдына алып чыгып кочакла, марҗалар кыюларны ярата!

Әйтерсең, белми иде моны Рахманкол. Дөрес, кызлар белән чуалганы булмады. Тик хәзер нигә бик тырышырга тиеш соң әле ул? Көнчел Лида сеңелесен әзәрлекләмәсен, Баһаветдин сандугачын аулакта туйганчы иркәләсен, серләшсеннәр өченме? Лидия буйга Рахманколдан калкурак та бугай әле, аңа бәйләнеп көлкегә калсынмы?

Шулай да ул аның белән вальс биергә чыкты. Кыюлыгы җитмәгән булыр иде, өстәл янында ялгызы гына утырып калгач, Лиданың бүтән ни эшләргә белмәгәннән генә, табак-савыт җыештырырга керешүен күргәч, хәрәкәткә килде. Эчемлек тә йөрәкләндерде, ахры, берничә мәртәбә Лиданың аягына басуын да тоймады. Кыз чыраен сытмады, гармун көе уңаена егетне үзе тәвәккәлрәк бөтереп йөртә башлады. Кичәгә килүчеләрнең күпчелеген танымаганлыктан, Рахманкол:

— Боларның барысы кемнәр соң? — дип сорады.

— Фира бергә укый торган курсташларын чакырган.

— Ә теге затлы киемле, озынча йөзле, сәлам чәчле егет?

— Павелмы? Фираның укытучысы. Әллә француз, әллә поляк теле өйрәтә шунда.

Рахманкол гаҗәпләнеп:

— Фирага француз теле нәрсәгә соң? — диде.

— Тиле ич ул, нишләгәнен үзе дә белми. Сез шундыйларга, мөкиббән инде. Баһау да әнә яныннан китеп тормый.

Лида шулай диде дә вальсның сүзләрен көйли башлады. Рахманкол, иптәше өйрәткәнчә, кызыкайның кәефен күрер өчен, берәр мактау сүзен кыстырырга тиеш иде, тик ул берни дә уйлап тапмады, күңеленә килгәннәрен ятышсыз санады, аның өчен бүген биюгә катнашу үзе генә дә зур кыюлык иде. Музыка тынуга, бүтәннәр белән ул да тышка чыкты. Егетләр-кызлар парланып беткән, кайсы кая таралышуын сизми дә калды. Кайчандыр Глеб яшәгән бүлмә

ишегенә кагылган иде, бикле. Эчтә пырхылдау, урындык-карават шыгырдавы ишетелә. Шүрәле кытыклагандай, чырык-чырык килүченең Фира, аны шундый халәткә китерүченең Баһаветдин икәнен аермачык таныды Рахманкол. Бүтән колак салып тормады, ишегалдына чыгып, тәмәке кабызды... Хупламады ул иптәшенең бу эшен. Кеше кылана дип нигә артыгын бөгештерергә? Урыс халкында күрше иренә охшаган бала табу да шаккатырлык нәрсә түгел. Тик Фира — кыз кеше ич әле, уеннан уймак чыкса, Баһау нишләр?

Салкынча һавада Рахманкол кайта-кайта шушы хакта уйлады. Караңгыга күзе иялəшкәч, койма чатында, лапаста пар карачкылар тәрәлешеп торуын абайлады да башын чайкады — әллә соң ул саташамы? Рахманкол, юләр, Лидияне бүлмәдә ялгыз калдырып чыкты — әдәп саклый, имеш. Атаң башына кирәкмени ул монда? Һәр халыкның үз гореф-гадәте, сөешүдә хөррият төрле милләттә төрлечә. Урысларның бер дә үз гадәтләреннән зарланганын очратканы юк әле. Мөселманда гына шәригать дигән булып йөгәнне каты тоталар.

Ул өйгә кергәндә тагын аулактагы Глеб бүлмәсен барып карады. Якынлашканда эчтә ниндидер тавышлар ишетелсә дә, аның адымнарын тоепмы, тындылар. Фира тагын чырык-чырык көлде, аңа искәртү ясаган иргә Баһаветдинның калын тавышы кушылды. Йомшак тавышлысы теге сары чәчле француз теле укытучысы инде әллә? Ул да түгел, ишек ачылып, анда Баһаветдинның башы күренде.

— Нишлисең син монда? — диде ул шикле карап.

— Лиданы таба алмыйм,— дип хәйләләде Рахманкол.— Сезнең янда түгелме ул?

Ишектән коридорга төшкән яктылык тоныкланды, филтәне төшерделәр, күрәсең.

— Менә Хуҗа Насретдин! — диде Баһаветдин көлемсерәп.— Ике кыз белән ялгызым нишлим инде мин? Сандугачның берсе дә биш күгәрченне алыштырганда!

Хәзер инде Рахманкол аулак бүлмәдә ким дигәндә өч кеше утыруына шикләнми иде. Димәк, бая да... Өстәл-караватт шыгырдау түгел, кабатлана торган ниндидер бүтән тавыш яңгыраган икән ләбаса. Шуны күмәр өчен чыркылдаганмы Глафира? Бая да, әле дә!

Иптәшенең бөтен кыяфәтеннән: «Тизрәк кит инде!» — дигән бер теләк аңлашылгач, Рахманкол ирексездән мәҗлес бүлмәсенә таба атлады. Сере күп булгач, нигә монда кеше чакырган инде?

Мәҗлес таралган, һәркем үз җаен үзе карый торган вакыт җиткән иде, ахры, лампа кысып куелган, бер почмакта гына ике-өч кыз пыш-пыш килә дә көлеп җибәрә, аларның егеттә бөтенләй эше юк иде. Рахманкол монда да үзен артык санап, Лиданың көен-җаен таба белмәвенә кыйналып, кайту ягын карады.

Янә бер елдан Баһаветдин яшерен почта белән эләккәч, француз теле укытучысының сөргендәге революционер икәнлеге ачыклангач кына, ул теге аулак кичәдә үзенең — сәяси ышанычлы полицийскийның калкан ролен үтәгәнлеген, Баһаветдин, Павелларның Глеб бүлмәсендә җилем басмада прокламация күбәйтеп маташуларын, белде.

Рахманкол чәй эчә-эчә тагын нинди хатирәләргә бирелгән булыр иде — бүлделәр, янына кабартма яңаклы, кысык күзле бер ир килеп утырды һәм:

— Чәегез тәмле булсын! — дип сүз кушты.

— Рәхмәт, бергә булсын.

Кабартма яңак бүтән аны-моны дәшмәстән, суытып та тормастан, ике касә чәй эчте, аннары Рахманколга күтәрелеп карап, әле генә таныгандай:

— Сөбханалла, таныш адәм икәнсез кү,— дип сүзен дәвам итте.— Бохарага иялаштегезме? Солдат хезмәтеннән чарчамайсызмы, арып аяктан егылмыйсызмы? Хәрби назыйр җөдә тынгысыз адәм, монда да Рәчәй тәртипләре урнаштырам, дип кышлактан-кышлакка чабамы? Кәмбәгалләрне Кызыл Гаскәргә җыйнап ятырсызмы?

— Ятырбыз.

— Инде янә кан коеш булады икән. Янә балалар ятим калады.

Рахманкол куәтләргә дә, каршы төшәргә дә ашыкмады. Күршесе аның сүзсез утыруын үзенчә аңлатып:

— Моңа җаныгыз көймәйде кү,— диде.— Үзегез буйдак, монда ят кавемнең кырылуына кайгырмыйсыз, Бохара Рәчәй кулыннан гына ычкынмасын.

— Нигә алай уйлыйсыз?

— Өйләнергә әле яшьсез, гаиләсез адәм балалар бәхетен саклауны кирәк дип белмәйде.

— Мин яшьме? — дип көлемсерәде Рахманкол.— Миндәйләрнең инде Бохарада икешәр хатыны бардыр!

Кабартма яңак җанланып китте.

— Анысы да тугры, вәләкин сездән күпкә өлкәнрәкләрнең дә өйләнә алмый йөрүчеләре байтак. Никах укытырга беренче нәүбәттә мыек имәс, мал кирәк.

— Ә безнең комиссар малсыз да бер диган кызга өйләнде әле. Туе да мулдан узды.

— Кем хисабына? — дип сорады кабартма яңак.

— Җәркәнттәге милләттәшләребез тырышты.

— Иганәгә генә өмет сузып яшәргә ярамайды. Мәһәре, торыр куышы, ашар ризыгы, кияр киеме кирәк. Балаң туса, чыгым янә артады. Өйләнү — гомергә бер килә торган кәттә бәйрәм, күп мал, анча пул җыеп әзерләнүең яхшы кү. Ә монда атышып йөреп мал җыйналмайды, башыңны җуюың гына мөмкин.

Рахманкол табындашының болай сукалавында хаклык барлыгына икеләнмәде. Гаиләдә өлкән бала, башка чыгарга тиешле ир бала иде ул. Энеләре, сеңелләре дә буйга җитте, аларны парлы итү ата-анасына ансат бирелмәячәк. Ярый әле татарда, Бохарадагы кебек, калым түләү йоласы юк!

Әйе, Баһаветдинны тыңлап уңмады, ахры, монда килеп хаталанды ул. Әмир тарафдарлары бирешергә уйламый, таулар арасында көч җыйнап ята. Хәрби комиссар бушка гына Кызыл Гаскәрне көчәйтергә бу кадәр ашкынмыйдыр. Киләчәктә әле күп кан коелуы ихтимал. Бәрелеш кызуында кылыч-пулядан исән-имин котылып калуы ике яклы. Сугыш — сабантуй түгел, хәтәр, бик хәтәр көннәр көтә аны монда!

Үз уена чумган Рахманкол табындашының бөтен сүзләренә дә колак салып тормады, сәлам биреп узган ир-атларга да җавап катмады,— «вәгаләйкем» дип утыруына караганда, аларның һәммәсе кабартма яңак танышлары иде. Гаҗәп түгел, ят кызыл гаскәрине монда кем белсен?

— Рахманкол кардәш,— дип эндәште аңа табындашы тыенкы тавыш белән.— Үзегез монда, күңелегез алыста күренәде. Төшенәмен, сез монда үтә һәвәсләнеп килмәдегез кү, комиссар йогынтысына бирелүдән, Бохара хәлләрен белмәүдән генә. Бәланең башы кызыл Гаскәр җыйнаучы Баһаветдинда. Сезгә шул уңайдан бер арзимиз бар, серне һичкемгә чишмәсәгез генә, әйтәмен.

Рахманкол, ризалыгын белдергән шикелле, баш какты. Кабартма яңак аңа таба үрелә төшеп пышылдады:

— Кул кулны, ике кул битне юады. Безгә булышыңчы, әҗеренә үзегез теләгән мөкафәтне алырсыз: аяклы мал, затлы ефәк тукыма яисә алтын-көмеш.

Уяулыгы шунда ук колагын торгызган Рахманкол:

— Күпме? — дип сорады.

— Бохарада яхшы гаиләнең кызына калым түләрлек. Яхшы гаиләнең!

Рахманкол гаҗәпләнде — бик зур сума тәкъдим итәләр түгелме соң? Табындашының чандыр гәүдәсе, гади генә киемнәре, үз-үзен тотышы бай аксөякне бер дә хәтерләтми иде. Рахманкол ирексездән тирә-ягына да караштырды — күрше сәкедәге чыршы кашлы, кара сакаллы, таза зур гәүдәле ир аларны күзәтә иде, ахры, аңа баш кагып куйды. Кулы чапан кесәсендә, әллә коралын да атарга әзер тота инде?

Кабартма яңак як-ягына баккалап алды да эшлекле пышылдады:

— Бозгынчы түрәгезне юк кылуга, бүләк сезнеке!

— Кемне-е-е? — дип тавышын күтәрде Рахманкол.

— Шиһабетдиновны! Тыныч кына гәпләшик, монда безнең журалар ишле. Серне сакларга вәгъдә бирдегез ку, уйлашыйк.

Юк, гауга куптарырга да, кабартма яңакны кулга алырга да кыҗрамады Рахманкол. Ниятләре барып чыкмаса, ул алар ягына аумаса, нишлисен шулай ук әллә кайчан килешеп куйганнардыр. Нәрсә эшләргә, ни дип җавап бирергә икән? Иптәше үзе бәлагә тыкты түгелме соң аны? Былтыр Верныйга аяк баскач ук, ревкомга чакыртып китерде, кеше алдында кочаклашып күреште дә, Совет җитәкчеләренә:

— Реакция елларында берничә революционерга булышкан егет бу,— дип аңлатты. Аннары кабинетына алып кереп хәл-әхвәл, шәһәр яңалыкларын сораша башлады.

Рахманкол аны ыспай күн киемдә, таза-сау, дәртле-егәрле комиссар кыяфәтендә күрүенә гаҗәпләнми. Совет әһле элекке полицийскийларны өнәмәгән көннәрдә дустанә мөгамәлә күрсәтүенә ташланмый булдыра алмады. Шулай да күзгә-күз калып, бераз истәлекләр тузанын какканнан соң, Баһаветдин үзенә иярергә тәкъдим иткәч, җавап бирергә ашыкмады. Җидесуда хәлле хуҗалыклар күп, алар тулаем акларга булыша, монда әле кемнең җиңәсен белеп бетереп булмый. Рахманкол исә тагын да ераккарак күз атмый. Рәсәй киңлегендә фикер йөртә алмый иде.

— Син нәрсә? — дип таң калды Баһаветдин,— һаман бай казаклар җырын җырламакчы мәллә? Ун ел патшага, аның яраннарына хезмәт иттең, нәрсә котайттың? Айлыгың арттымы, дәрәҗәң үстеме? Гаделлекне якладым, дип юана аласыңмы? Капкорсаклар иминлеген сакладың, ялчы идең, ялчы булып калдың да.

Анысы ишетмәгән вәгазь түгел, хикмәт Баһаветдинның сүзләрен эшкә ашырып яши белүендә иде. Верный кебек кечкенә шәһәрдә киемне салып атып кына полицейский булганлыгыңны яшереп булмый. Бүтән эшкә алынмыйм дисә, юньле һөнәре дә юк. Ә монда дәрәҗәсе белән генә дә нинди Баһау үзе өндәп тора, электән таныш хәрби хезмәткә кодалый. Дөнья шулкадәр үзгәрә икән, нигә әле Рахманкол гына искегә ябышып ятсын? Бай утарга, меңләгән баш мал көтүләренә кендеге бәйләнмәгән ич аның!

Ирде Рахманкол Баһаветдинга. Республика хәрби комиссарының адъютанты, чынлыкта, офицер вазифасын үти ул хәзер. Революциягә кадәр мондый урын биләү турында хыяллана да алмый иде ул. Хәзер менә кемнәргәдер сатылып, үзенә зәррә кадәр дә яманлык эшләмәгән кешегә хыянәт итсенме, хәтта җинаять кылсынмы? Юк, юк... Дөрес, ун алашаны аңа тик торганда бирәү дә бушка бүләк итмәячәк...

Рахманкол, җавап көтеп утырган табындашына карамыйча, тагын чәй уртлап куйды. Димәк, шушы эшне кушар өчен сагалаганнар аны, Верныйдагы тормышын да ачыклаганнар сыман. Комис-

сарга кизәнгәнне, аның йомышчысын гына кызганып тормаслар. Уяулыкны җуймаска, кискен карышмаска, әмма ризалык бирүдән дә тайчанырга кирәк.

— Уйлап карармын,— диде ул урыныннан кузгалыр алдыннан.— Нишлисен хәл кылгач, шушында хәбәр итәрмен.

* * *

Рахманкол хикәясен сабырсызланып тыңлаган Фарукҗан:

— Шуннан соң контрлар тәкъдимен кабул иттеңме? — дип сорады.

— Ю-ук! — диде Рахманкол ашыгып.— Мин Баһауга кызыгам, аннан бераз көнләшәм, ахры, дип уйлый идем. Чынлыкта исә аны хөрмәт итәргә генә түгел, яратырга да өлгергәнмен икән. Шунлыктан чәйханәдә ясалган тәкъдим хакында тоттым да комиссарның үзенә сөйләп бирдем.

— Ничегрәк тыңлады соң ул моны?

— «Тугрылыгыңа ышанам, рәхмәт! Миңа ул ике тинтәкне күрсәтерсең әле»,— диде. Тик һаман эше бик тыгыз булды — әле каладагы киңәшмәләрдән, митинглардан, әле кышлакларга барып чыгыш ясаулардан бушамады. Без эш белән тегендә-монда йөргәндә әлеге кара еланнар ялгыш та очрамады. Кабартма яңакны мин, чәйханәдәге сөйләшүдән соң өч-дүрт көн узгач кына, уйламаган җирдә күреп калдым. Ревком янында. Ревкомда киңәшмә үтәргә тиеш, халык Комиссарлары Советы җитәкчеләре дә шунда агыла иде. Килүчеләрнең берсе аның белән бер-ике авыз сүз алышты, аннары болдырда Гарипов белән сөйләшеп торды. Сез Габделхәмит иптәшне беләсездер?

Фарукҗан дәшмәде, дәвам ит, дип кенә ымлады. Чишмәсе тулган икән, актарылып аксын әйдә!

— Кабартма яңакның хәтәр тәкъдимне үзбаш кына ясамавына мин шунда тагын бер мәртәбә ышандым,— дип сүзен ялгады Рахманкол.— Чөнки аның белән гәп корган бәндә, иптәш Гариповтан аерылгач, йөзе белән миңа таба борылды. Таныдым: комиссарлар Советында эшләүче зыялы иде ул. Аның хәтта Фәйзулла Хуҗаев белән гәп сатып торуын да күргәнем бар иде. Бу чукынмышларның тамыры бик тирәндә, ахры, дип уйлап йөрәгем сикерә башлады. Баһаветдинны кисәтергә соң, ул инде утырышка кереп югалган иде.

— Нәрсә, теге зыялы кабартма яңагың белән, күптәнге ашналардай, дустанә гәпләштемени?

— Алай ук димәс идем. Әмма кабартма яңак ни мескенләнгән, ни яхшатлыланган суратта түгел иде.

— Ничек уйлыйсың,— диде Фарукҗан,— Шиһабетдиновның шул утырышта катнашасын белгәч, синең дә Ревком тирәсендә чуалачагыңны кабартма яңак чамаламады микән?

— Мөгаен, белгәндер.

— Күзәтеп торачагыңны алдан ук фараз кылып, кабартма яңагың теге зыялы, аның аркылы Гариповка да юл барлыгын юри күрсәтергә тырышмады микән? Болай ул берьюлы ике куян ата: сине тагын да ныграк тәшвишләндерә, зур җитәкчеләргә дә күләгә төшерә ләбаса?!

— Белмим. Тиздән мин, вакыт уздырыр өчен, якындагы чәйханәгә кереп утырдым. Артымнан бастырып диярлек теге кабартма яңак та килеп җитте. Гаҗәп, без сүз куешкан чәйханә бөтенләй буш иде үзе. Аның артыннан тагын ике ир-ат күренде: чыршы кашлы, кара сакаллы таза абзый белән әлеге зыялы. Чәй алгач, соңгылары аерым, кабартма яңак минем янга килеп утырды.

— Зыялының кыяфәте нинди иде?

— Озын буйлы, какча гәүдәле. Кара чәчләре бүселеп, кәләпүше астыннан чыгып тора. Күбрәк татарга охшаган. Ярым европача киенгән, штиблит, чалбар, ак күлмәктән. Әмма чапан бөркәнгән. Пөхтә.

— Почык борынлымы?

— Әйе.

Нәзир Әбдиев, дип уйлады Фарукҗан. Барлык чалымнары туры килә.

— Шуннан?

— Кабартма яңак дустанә кыяфәттә исәнләшеп, хәлемне сораша башлады. Чәйдә гаме юк иде, сүзне үзе теләгән юнәлешкә борырга ашыкты. «Рахманкол жура, нигә җавабыгызны сузасыз? — диде ул.— Көтәргә вакыт калмады кү. Ризыгын кисү кирәк ул мөртәтнең: ни шәригатьне санламайды, ни мөселманлыкка күңел салмайды, кяфернең үзеннән дә яманрак — Бохараның тамырын корытады. Сукыр тавыктай, илбасарлар юлыннан гына атлый бирәде. Аның өчен ике генә юл калды: йә Рәчәйгә, китеп олага, йә...» «Хәтәр эш бу»,— дидем мин. «Аның каравы әҗере мулдан, алтынның беркайчан да кесәне тишкәне юк әле». Кабартма яңак шулай диде дә, тәмәке янчыгыннан сары шайтаннарын — балдак, беләзек, алкаларын чыгарып, миңа сузды. «Алың, алың, болары әле вәгъдәне ныгыту өчен генә!» — диде. Ни алырга, ни кире кагарга белми аптырадым. Агу йоткандай, эчем янарга кереште, телем аңкавыма ябышты. Дәшмәвемне өнәмәгән кабартма яңак шуннан соң: «Менә нимә, хәрби комиссар хәзер постларны төннәрен үзе тикшереп йөрәде,— диде.— Безгә булышырга ниятләсәгез, иртәгә чархарас мәхәлләсеннән узганда, Шиһабетдинов белән янәшә барыгыз, юк икән, бер-бер артлы!» Чархараска килеп җиткәндә безнең икәү генә калуны да күзәтеп өлгергәннәр икән дип уйладым. Әлбәттә, Шиһабетдиновка эчке дошманнар хакында бу юлы да һәммәсен сызгырдым. Егерменче октябрь төнендә кинәт кенә постлар алмаштырырга тотындык. Караңгы төшкәч, Чархарас мәхәлләсен кызыл гаскәриләр төркеме ике мәртәбә караштырып узды — шикле нәрсә абайламаганнар иде. Хәрби комиссар: «Минем арттан гына бар. Сүз тыңламавыңны ачыклагач, алдан биреп куйган алтыннарын сорарга килерләр, шунда каптырырбыз ул чучкаларны!» — диде. Тыңладым Баһаветдинны. Әмма Чархараста вакыйга көтелмәгәнчә фаҗигале тәмамланды — хәрби комиссарга читтән аттылар. Башта югалып калдым. Аннары дошманнарның җинаятьләрен миңа сылтарга омтылачаклары турында уй, яшен ташыдай, миемне көйдереп узды. «Гаепсезлегемне ничек исбатлармын?» — зиһенемне биләгән беренче сорау шул булды. Һушымны җыйгач, авыр яраланган хәрби комиссарны шәһәрдән алып китеп, аның үзен-үзе атуы турында хәбәр таратырга карар бирдем. Артымнан иптәшләре белән куып җиткән кабартма яңак ниятемне хуплады — якындагы капкадан алар кешесе сакка куелган булган икән, ул безне шыпырт кына каладан чыгарып җибәрде. Калганы инде сезгә билгеле.

Чырае качкан Рахманколга карап, Фарукҗан шырпылы төстә сорау бирде:

— Нишләп сез дошманнарны каплау юлына бастыгыз?

— Бохарада кем дус, кем дошман икәнен белеп карагыз! Сүздә һәммәсе революционер, ә чынында Чека хезмәткәрләре Симиниев белән Нурморатовка хакыйкать кирәкмәвен үзегез дә күрдегез ләбаса.

— Дошманнардан алган балдак, беләзекләр кайда?

— Баһаветдин сейфына бикләп куйган иде.

— Талгар ягындагы станицада Шиһабетдиновка атучыны нигә туктатмадыгыз?

— Күрми калдым. Фетнә күтәрүчеләр коралларын ташларга килешкән иде.

— Нишләп әфган сәүдәгәре Габделшөкерхан тирәсендә бөтерелеп йөрдегез?

— Бөтерелмәдем, хәрби комиссар әмерен үтәдем. Сәүдәгәрнең кемлеген ачыклар өчен, Кызыл Гаскәрне коралмаучы, аның белән сугышырга корал эзләүче байбәтчә булып кыландым.

Фарукҗан сәүдәгәр хакында сорашып тормады. Шиһабетдинов капшап караганнан соң аны иректә калдырган, димәк, пошынмаска мөмкиндер. Көрәшер өчен дошманнарының ачыкланганнары да җитәрлек әлегә.

Рахманкол күп нәрсә сөйләде, вакыйгаларга байтак ачыклык та кертте шикелле. Шулай да бу аңлашу Байкучатовка канәгатьләнү китермәде. Хәрби комиссар йомышчысына ул әле һаман ышанып бетми, әмма аның сөйләгәннәрен кире дә кага алмый иде.

Ял иткән кызыл гаскәриләр белән чекистлар янә бер сәгатьтән юлга җыендылар: Рахманкол отряды — Бохарага, Фарукҗан оператив төркеме Караком чүле барханнары арасына юл тотты. Аларны кышлакта мәзиннең мөселманнарны икенде намазына чакырган азан авазлары озатып калды.

## 42

Чекистлар инде ике сәгать чамасы көньяк-көнбатышка юырта иде. Офыктан-офыкка җәелгән чүл әчпошыргыч бертөрлелеге белән күңелгә пошаман салырлык — күктә көндез кояш, төнлә йолдызлар калыкмаса, бүтән һичбер маяк күренмәгән япан киңлектә адашуың, эзсез юкка чыгуың бик ансат икән. Фарукҗан шулай уйлый-уйлый барганда Амантай якынлашты да:

— Таныш җирләр башланды,— дип таң калдырды.— Көтү көтеп йөргән барханнарым бу. Ел әйләнәсендә чүл буйлап йөзләгән чакрымны уза идек без.

Тиздән алар барган юнәлештәге сары җирлектә нәни көрән тап сыман күзгә ташланган нәрсәнең тирмә, аннан уң тарафта җәелгән ала-кола икенчесенең сарык көтүе икәнлеге беленде. Саклык өчен тирмәгә башта Амантай ялгызы гына якынлашты, төркем исә сибелеп, киез өйне ерактан камап алды да көтеп торды. Бераздан Туктаров чакырып кул болгагач кына, аның янына җыелдылар.

— Тирмәдә кеше юкмы?

— Бар,— диде Амантай командирына төшенке рухта.— Мин көткән көтүгә юлыкканбыз шул. Чалабай карт ыңгырашып ята анда.

Фарукҗан атыннан төште дә, иптәшенә ияреп, киез өйгә керде. Төнлеге ачык тирмәнең уртасында табак битле, җалпак борынлы, китәрелгән сирәк сакаллы бер ир-ат чалкан ята, сары йөзендә канлы яра эзләре, күз төпләре күмгәкләнеп шешкән, күлмәк изүләре аерылган — бөтен кыяфәте аның күптән түгел генә кыйнап ташлануы хакында сөйли иде. Хырылдап авыр сулый, керфекләрен дә ачып карый алмый иде ул. Амантай асыл төсе нинди икәнлеге беленмәс дәрәҗәдә каралган тастымал табып, аны чылатты да картның йөзендәге каткан каннарын сөртеп алды, аннары юеш чүпрәкне Чалабай картның маңгаена япты. Чәйнекне тикшереп, шуннан касәгә чәй агызды һәм, хәлсезләнгән көтүченең башын күтәрә төшеп, эчерергә тырышты. Карт шунда гына күзен ачып, ят ирләрне күрде һәм көрмәкләнгән теле белән:

— Бал... Балҗан кызым монда юк гүй, белмәймен, юк, юк,— дип пышылдады.— Күптә-ән күргәнем юк, кал-лым кайтарырлык малны кайдан таб-баем...

— Чаләкә, ни сөйлисез? Бу — мин, Амантай. Сезне болай кем сабады, кем кыйнады?

— Амантай? — Карт терсәкләренә таянып күтәрелергә, чакырылмаган кунакларга яхшылабрак карарга омтылды. Туктаров шундук аның аркасына юрган белән мендәр кыстырырга ашыкты. Карт аны танып алып:

— Уйбай, балам, синмени был? — дип сорады.— Ә теге мәлгуньнәр кайда соң?

— Кемнәр?

— Тилергән Нәзир кияү, аның башкисәрләре. Куйларны калдырганнармы? Инде хуҗама ни җавап бирермен? Ходай каргаган Нәзир: «Кызың качып китте, кайда ул? Түләгән калымымны кайтар!» — дип бугазымнан алды, көтүдән биш куйны егып суйды...

— Кайчан? — дип сорады Фарукҗан.

— Әлерәк кенә.

— Ничә кеше иде алар?

— Өч куштаны тагылган, шакал да ерткыч, монаулар да ерткыч, арам каткырлар!

— Кайсы якка киттеләр?

Карт кулын хәлсез генә көнбатышка изәде. Амантай тастымалны яңадан чылатып сыкты һәм каенатасының маңгаена тагын япты. Аннары аңа иелә төшеп:

— Чаләкә, Балҗан Каганда, без аның белән өйләнештек,— диде.— Кичерегез, сездән ризалык сорарга килә алмадык. Без...— Аның сүзе күп иде әле, ләкин картның янә мендәргә сыгылып төшүен күргәч, хәвефләнеп: — Көтүдә ярдәмчегез бармы соң? — дип гәпне кыскартырга мәҗбүр булды.

Карт телен авырлык белән әйләндереп:

— Бар, балам,— дип пышылдады.— Айналайын, мин риза, бәхетле булыгыз. Ә теге... таш йөрәк... ак сакалымны мыскыллап... Куйлар кешенеке гуй, бирмәскә тырышкан идем, үземне камчы белән...

Фарукҗан, башын изәп, Амантайны тышка алып чыкты.

— Гәпне соңыннан сатарбыз,— диде ул.— Хәзер аларны тизрәк куып җитәргә кирәк. Сәүдәгәр алдашмый, дөрес алып бара икән ләбаса.

Иптәше исә картны кызгануыннан, Нәзиргә нәфрәтләнүеннән арына алмыйча:

— Очрасын гына, Чаләкә өчен дә, Балҗан өчен дә бирәм мин аның кирәген! — дип кайнады.

— Монда безнең бәхеткә тукталган алар,— диде Фарукҗан.— Сарык түшкәсе дә аскач, атлары тизрәк өшәнер, ансатрак куып җитәрбез. Күр әнә, комдагы эзләре ап-ачык ярылып ята.

Чүл җыерчыкларын тагы да челтәрләп узган юл туп-туры көньяк-көнбатышка сузылган, берән-сәрән очраган саксаул куакларын әйтмәгәндә, игътибарны тартырлык нәрсә бик озак күзгә чалынмады. Мондагы балыккүз, бозаубаш, янтаклар инде әллә кайчан кибеп, корып, малларны азык булган, яртылаш комга күмелеп яткан сирәк кәлтәләр һәм ташбакаларны, өсләренә килеп басмыйча, абайлавы кыен иде. Болытсыз зәңгәр күктә йөзгән кояш хәзер инде хәлне алмый, офыкка тәгәри барган саен кызара төшеп, хәвеф көтелүен генә искәртә иде сыман.

Фарукҗан ара-тирә өзәңгеләренә басып өскәрәк калка һәм карашы белән тирә-юньне айкый, эңгер куерганчы дошманнарын кулга төшерергә атлыга, хәзер инде янәшәсендә барган сәүдәгәргә икеләнеп карамый, бары: «Киләчәктә ничек яшәр икән инде бу, серне чишүен ачсалар, тарафдарлары аны кызганып тормас, әллә хәзер үк кайтарып җибәрергәме үзен?» — дип баш вата иде. Чүл юлын

нәкъ менә ул күрсәтүен Симиниев белми, аның шикләнүен кире кагарга мөмкин булыр. Бу тирәләрдә Амантай адашмас, теге еланнар гына офыкта күренсен иде...

Алда дүрт кара нокта пәйда булгач, ул атын тыя төшеп һәм әсиренә таба борылып:

— Очраша торган җирегезгә хәтле еракмы әле? — дип сорады.

— Янә бер-ике сәгатьлек юл. Анау җайдаклар шулар кү.

— Син хәзер үк кире борыл,— диде аңа Фарукҗан.— Азат итәбез. Безне монда ияртеп килүең хакында һичкемгә сайрама. Симиниев сорашса, «мине ниндидер таш капчыкта бикләп тоттылар», диген. Берни сөйләмәгәнсең, төшендеңме?

— Мәйле.

— Дошманнар белән бүтән чуалма, кара аны! Бар!

Сәүдәгәр, җиңел сулап, артка борылды, чекистлар исә атларын куа төштеләр. Ара кимегән саен, кара ноткалар зураеп, җайдакларга әверелде. Алар да ят отрядны күреп алды, билгеле. Арттан яхшылык көтмиләр иде, ахры, тизлекләрен арттырдылар, алай да «койрыктан» аерыла алмагач, уңлы-суллы аскан капчыкларын җиргә тондырдылар. Ул да түгел, икегә аерылып, бер пары көнчыгышка таба томырылды, икенчесе юлын әүвәлге юнәлештә дәвам итте. Фарукҗан бер кызыл гаскәри белән Иргәшкә беренче парны тотарга боерды.

— Мылтыклары күренми, сез ерактан атып кисәтегез, коралларын ташлаткач кына, якынлашыгыз! — диде.

Аның исәбенчә, Нәзир кәрванны каршы алыр өчен ашыгырга тиеш иде. Җайдакларның озынрак какча гәүдәлесе шулдыр, берәр «күккүз» белән серләшергә, хәбәрләр алмашырга ашкынадыр, бәлки әле, фаш ителгәч, болганчык Бохарадан вакытында үкчә күтәрү хәерлерәк, дип тә уйлыйдыр. Балҗан өчен дә исәп-хисапны юкка гына ашыгыч өзеп маташмагандыр.

Куышу озакка сузылды, качакларның атлары, йөкләре җиңеләйгәч, җир җимертеп чаба, җайдаклар аларга парны өстәп кенә тора. Ара кыскармый, кызыл гаскәриләрнең кайберсе хәтта ияргә алмый арткарак та калды. Әле бая гына, «дошманнарны терелей кулга төшерергә!» — дип боерган Фарукҗан үз әмеренең үтәләсенә икеләнә башлады һәм беренче булып мылтыктан ут ачты. Тәгәрәттеләр! Байкучатов иптәшләрен туктатып:

— Атлардан төшегез, шуышып, төрле яктан берьюлы якынлашыгыз. Башларына, күкрәкләренә төзәмәгез! — дип кисәтте.— Ашыкмагыз, патроннары күпкә җитмәс.

Саклык күрү ярады, чаптарлары егылса да, дошманнар тере иде, котырынып револьверлардан ата башладылар.

— Карышу файдасыз, бирелегез! — дип кычкырды Фарукҗан аларга хәвефсез ераклыктан.— Сезне мылтыктан атып үтерү кыен эш түгел, кан коясыбыз гына килми. Бирелегез!

Җавап урынына тозлап-борычлап сүгенү ишетелде. Кызыл гаскәриләр бердәм залп бирде — револьвер төчкерүләрен мылтык тавышлары күмеп китте. Билдән түбән атарга тырышсалар да, бәрелеш кызуында кемнең кая тидерәсен алдан белеп буламыни? Дошманнар каршылыгы басыла төшкәч, отряд аякка басып алга ыргылды, әмма шундук Амантай, күкрәген тотып, җиргә ауды. Мылтыклар ирексездән янә шартлый башлады — бу юлы инде җәлләп атмадылар, шаярышу түгел, чын сугыш кабынуын хәзер һәммәсе аңлаган иде.

Фарукҗан, атышу тынгач, башта Амантай хәлен белергә йөгерде. Иптәшенең сулавы сизелми, күкрәгеннән бәреп чыккан кан чапанына кадәр юешләгән иде. Киемнәрен салдырып, ярасын карады, йөрәк тибешен тыңлады, ышанасы килмичә, тагын йөзенә

төбәлде. Амантай җан биргән иде. Фарукҗан, унатарын кулына тотып, кургашын ябыштырылгандай авырайган адымнар белән дошманнарга таба атлады. Алар янына алданрак килеп өлгергән иптәшләре, трофей маузерларны күрсәтеп:

— Пулялары беткән, икесе дә берничә җирдән авыр яралан-ган,— дип хәбәр бирде.

— Яраларын бәйләгез!

Күп кан югалткан Нәзир Әбдиевтән сорау алуны кичектерергә ярамый иде. Шуңа күрә ул аны ял итәргә җыелган егетләрдән бер читкәрәк, бархан сыртына алып килеп утыртырга кушты. Флягасын ачып, үзе берничә йотым су эчерде. Аннары җиргә чүгәләп:

— Хәзер инде күп ниятләрең эшкә ашмаячагын төшенәсеңдер,— диде.— Качып котылулар да үтүт! Укымышлы, чая кеше үзең, күрәләтә үлемгә баруың белән генә шаккатырдың. Теге дөньяга Бохарадан да китәргә мөмкин иде аны. Әйтерсең, ике татар егете бербересенең канын Караком сахрасында гына коя ала. Ә сәбәбе?

Сау чакта да суфый кыяфәтле, ач яңаклы Нәзир хәзер тагын да сула, агарына төшкән, ярадан гына түгел, уйларын да яшерәсе килүдәнме, күзләрен йомып-йомып куя иде. Ә хәленең мөшкеллеген, үлемнән коткарса, Фарукҗан гына коткара алачагын чамаларга тиеш иде. Ләкин бөтен кыяфәте: «Аптыратма, күрәсем дә, ишетәсем дә килми сине!» — ди иде. Горурлыгыннанмы? Серләрен үзе белән кабергә алып китәргә җыенуыннанмы? Фарукҗан нигә аны сөйләтергә тырышмасын әле?

— Син үзеңне мәгърифәтче, халыкны бәхеткә илтүче санайсың инде,— диде ул.— Шиһабетдинов та шундый кеше иде ич. Сездән аермасы булса, аң-белемнең тизрәк таралып, тормышны үзгәртүгә тизрәк хезмәт итүен теләүдә генә.

— Тинтәк! — дип чыраен сытты Нәзир.— Тормыш капылт үзгәрә алмый. Бохарада аның шартлары өлгермәгән әле.

— Димәк, сез ул шартларның өлгерүен теләмәдегез, комиссар ярлылар аңын уятыр, дип курыктыгыз? Сез нәрсә, әмир һәм аның бәкләрен сәүдәгәрләр белән алыштырудан диһканнар, һөнәрчеләр хәле яхшырачак, дип уйлыйсызмы әллә? Мәгърифәтче күпчелекне кайгыртырга, революцияне киңәйтер өчен җирлек әзерләргә тиеш!

— Андый киңәйтүне көчләп читтән такмыйлар,— диде Нәзир.— Шартлары өлгергәч, халык үзе ирешәчәк аңарга.

— «Шартлар, шартлар!»,— дип үчекләде Фарукҗан.— Хәйлә генә ул сезгә, батканда саламга тотыну. Нух пәйгамбәр заманындагысын көчләп сакларга ярый, үзгәртергә — юк. Ишек-тәрәзәләрне гасыр җилләренә ачарга вакыт инде, юкса, Бохараның тынчу һавасыннан сулыш буыла.

— Һәркем үз өенең ишек-тәрәзәсен кайгыртсын,— диде Нәзир.

— Алайса сезгә дә Бохарага килмәскә, мондагы эшләргә тыкшынмаска иде, «Остаз» әфәнде. Хәрби комиссарга һөҗүм итүегез инде бер генә киртәгә дә сыймый.

— Аның каруы Бохара халкы алдында татарларның йөзе ак хәзер. Корылтай сайлаган хөкүмәткә каршы казынган тинтәк чәнчелде, без Төркестан тарихында мәгърифәт таратучы булып кына калырбыз.

— Кара, сез әле татарларның йөз аклыгын да кайгыртасызмыни? Бәлки бохаралыларның йөздән туксан тугызы Шиһабетдиновны, аның тарафдарларын үз күрәдер?

Нәзир күзләрен йомган, гүя, чекистны бар дип тә белми иде. Фарукҗан камчы сабы белән киң итек кунычына суккалап:

— Шулкадәр изге уйлар белән янгач, гамәлләрең нишләп гел этлек белән бетә соң синең? — дип сорады.— Зөһрәгөлдәй укымыш-

лы кызга өйләндең дә аңа пәрәнҗә бөркәттең. Икенче хатынлыкка көчләп Балҗанны алдың да, «талак» кычкырып, куып чыгардың, аннары кире шуны кайтарырга чаба башладың. Каенатаң Чалабай аксакалның көтүен таладың, аның үзен канга батырганчы кыйнап аттың. Шулмы мәгърифәтчелегең?

Нәзирнең йөзе тартышты, ул күзләрен солы кадәр генә ачып, әмма салкын тынычлык белән:

— Синең кеше гаиләсендә ни дәхелең бар? — диде.

Фарукҗан шаккатты. Юк, мондый бәндә кеше гомерен сукыр рәвештә үтәүче генә була алмый, бозыклыкның чишмәсе моның үзендә. Тукта, башка яктан да бәрсен әле аңа Фарукҗан!

— Фәйзулла Хуҗаев иптәш Куйбышевка: «Мин Шиһабетдиновны кисәтергә генә кушкан идем»,— дип акланган. Симиниев: «Комиссарны үтерүгә катнашым юк, Гарипов белән Әбдиев яратмый иде аны»,— дип бара. Ә Гарипов: «Мин — Ленин кушуы буенча «Кызыл шәрык» агитпоездында килгән революционер. Шиһабетдиновның иң якын фикердәше, җинаятьчеләрне шушындагы байлар, милләтче зыялылар арасыннан эзләргә кирәк»,— дип сиңа ишарәли. Рахманкол белән кабартма яңаклы дустың: «Комиссарга сәүдәгәр йорты түбәсеннән Чархараста Нәзир иптәш атты»,— дипраслыйлар.

— Ялган! Яла!!

— Без сине дәвалап терелтербез дә Регистан мәйданында хөкемгә тартырбыз. Халык алдында. Шунда Хуҗаев, Гарипов, Симиниевләрнең үзләренә кычкырырсың моны.

Фарукҗан, сүзе тәмамланган шикелле, аягына торып басты һәм егетләренә күз салды. Кичке шәфәкъ бөтен тирә-якны куе кызгылт төскә коендырган, атларның һәм кешеләрнең күләгәләрен әллә кая кадәр сызылган иде. Амантай, вакытсыз кайнарланып, харап булды, дошманны куа киткән Иргәшләр дә, комга тамган тамчыдай, офыкта юкка чыкты. Тагын да сирәкләнгән отряд белән кәрванны эзләп йөрү хәвефле булмасмы? Багбан коесы янындагы бәрелештә аларны бары тик алданрак килеп өлгерүләре һәм пулеметлар гына коткарды. Капкан саен калҗа эләкмәс, бу юлы көчләре дә кимрәк, басмачылар белән кәрванның очрашу сәгате дә билгесез. Ишләме икән корал көтүчеләр?

Фарукҗан, шушы хакта сорарга теләп, артына борылды һәм, үзенә таба төбәлә башлаган көпшәне күреп, шашып калды: тентемәгәннәр, яшергән пистолеты булган икән еланның!

Тынып калган чүлне бер-бер артлы яңгыраган ату тавышлары сискәндерде. Әллә үзен-үзе белештерми җиргә тәгәрәве булышты, әллә авыр яралы Нәзирнең хәлсезлеге, ашыгуы ярдәм итте, Байкучатовның күкрәгенә төзәлгән пулялар аның беләген һәм иңбашын гына чагып узды. Башкалар урыннарыннан сикереп торганда, Нәзир Әбдиев инде, көлтә кебек, чалкан ауган — соңгы пулясын ул үзенә-үзе аткан иде.

Тик Фарукҗан шатлык хисе кичерә алмады, нииндидер аңлаешсыз бушлык, тынычсызлык биләгән иде аны. Чөнки Нәзирнең фикер сөрешендә, Баһаветдин белән үзенекенә охшамаган чит бер җирлек, эзлеклелек, чит бер хакыйкать яшәвен сизә, тик бу хакта уйламаска, күңеленә вәсвәсә кертмәскә тырыша иде. Үз иманының Шиһабетдиновныкыдай нык түгеллегеннән оялуы. Нәзир белән Баһаветдин фикерләренең аерым-аерым алганда берьяклырак икәнлеген чамалап та, шуларны килештерү әмәлен тапмаудан кыйналуы идеме бу аның? Бәлки ике төрле башлангыч бәрелешендә берсенең икенчесен тулысынча инкарь итәргә маташуын шәфкатьсезлек кенә түгел, мәгънәсезлек санавы булгандыр. Әмма Фарукҗан күңел чайпалышын тышка чыгармады, үз-үзен кулга алып:

— Теге бәндәне шушында күмегез,— дип баш изәде.— Ул да

адәм баласы. Амантайны исә якындагы кышлак зиратында җирләрбез.

Алар иртән Бохарага кайтып җиткәндә, таң җилләре инде чүлдәге бәрелеш эзләрен күмгән, андагы ялгыз кабер өемен җир белән тигезләгән иде.

Фарукҗан кәрвансарайга кайтып керүгә, бүлмәсенә бикләнеп, хәрби комиссар фаҗигасен тикшерүнең барышы һәм аның нәтиҗәләре турында Әминев исеменә рапорт язарга утырды. Шулчак Чека рәисе аны үзе эзләп тапты.

— Кайттыңмы? Бөтен гаеплеләрне фаш итеп бетердеңме? — диде ул борчулы төстә.— Яле, кыскача таныштыр мине.

— Күбесен фаш иттем, Галимҗан абый,— дип башлады Фарукҗан.— Җитәкчелеккә кереп оялаган әчке дошманнарны хәзер үк кысрыкларга мөмкин инде...

Әминев аның хәбәрләренә көтелмәгәнчә нәтиҗә ясады:

— Сиңа ышанам, Байкучатов,— диде ул.— Тик бер искәртү ясарга тиешмен: Комиссарлар Советы рәисенә бүрәнә тәгәрәтмә.

— Ничек инде? Бөтен эзләр шуңа илтсен дә...

— Иптәш Хуҗаев бохаралылар арасында иң намуслы, иң абруйлы җитәкче. Рәсәйгә күптән бәйләнгән, революциядән байлык өмет итми — аның малы болай да җитәрлек. Шул хәлендә дә диһканнарны якларга тырыша. Бохара халкы хөрмәт итә торган иң йогынтылы юлбашчы ул.

— Тымызык күлдә корт уйный.

Әминев аның мыскыллавын, гүя, ишетмәде дә, «укырга җибәрелүе уңаеннан, Фарукҗан Байкучатовны Бохара чекасы теркәү бүлеге башлыгы вазифасыннан егерме алтынчы октябрьдә азат итәргә»,— дигән боерыгын тоттырды һәм:

— Ә хәзер юлга җыен,— диде.

Фарукҗан үз колакларына үзе ышанмастан:

— Сез, дошманнар басымына бирешеп, мине моннан куып җибәрергә ниятләдегезмени? Чекага шулай файдалыракмы? — диде.

Әминев аның үпкәләвен һәм ачулануын урынлы саный, ләкин үзенең дөрес карарга килүенә дә икеләнми иде. Шунлыктан нык тавыш белән сүзен дәвам итте:

— Кайберәүләрнең иң авырткан сөяленә баскансың шул. Синең өчен кичә мине кемнәр генә шелтәләмәде монда! Аңла, энем: хәзергә Бохарадан китеп торуың яхшырак синең. Югыйсә, көрәш кирәкмәгән юл алып, зуррак корбаннар бирүебез мөмкин.

— Шиһабетдинов башлаган эшкә хыянәт булмасмы соң бу?

— Булмас. Син җыйган дәлилләр безгә бик шәп хезмәт кылачак әле. Дошманнар бүтән җирлектә чигенергә мәҗбүр булачак. Кыскасы, син чекадан артмыйсың, вакытлыча гына югалып торачаксың. Республика җитәкчелегендә көчләр нисбәте үзгәрүгә, чакыртып алырбыз. Ләкин бүген һәр минут кадерле. Кулга алынып, мәкерле рәвештә һәлакәткә очраганчы, исән-имин китеп өлгер.

— Ә рапортым? Иргәш белән Балҗаннар? Аларны язмыш иркенә ташлыйммы?

— Иргәшләреңне үзем кайгыртырмын, рапортны Ташкенттан язып җибәрерсең. Без әле очрашырбыз, энем. Ошадың син миңа, рәхмәт. Йә, сау бул!

Солдатның малы булмый — Фарукҗан күз ачып йомганчы юлга җыенды. Алдан ревтрибунал рәисе, аның артыннан гаскәриләрнең икесе, уртада — Фарукҗан, иң арттан янә гаскәриләр мәгълүм ара калдырып, бер-бер артлы кузгалып киттеләр. Ревтрибунал рәисен күргәч, шәһәр капкасын саклаучылар таныклык сорап тормадылар. Солдатларның икесе Фарукҗанны Каганга хәтле озатып куйды.

Хәрби комендатурада ул тиздән Ташкентка поезд китәчәген белде. Шуннан соң вокзал мәйданына чыгып басып, әле кайчан гына үзенең шушында дөбер-шатыр эш куып йөрүен искә төшерде. Дөнья гел ыгы-зыгыдан тора, ахры. Адәм баласы беркайчан да барына гына канәгать түгел: яхшыга, матурга кызыга, көче җитәме-юкмы, һаман югарырак үрелә. Ерак юллар уза, хәтәр сынауларга дучар була, тик барыбер өметен өзми, хыялына кер кундырмый. Бирәүләр бары үз файдасын гына кайгырта, икенчеләр ил-көн өчен дип җанын кыла. Фарукҗан дөрес юлдамы соң? Монда адашып кына йөрмиме ул?

Үз уйларына чумып вокзал тирәсен арлы-бирле ураганда, күләгәдә утырган пәрәнҗәле хатын-кызларга әллә ничә мәртәбә карап узды, әмма шуларның берсе өзлексез аны күзәтүен бөтенләй сизмәде. Перронга поезд килеп туктагач һәм әлеге хатын-кызлар вагонга таба ир-атларсыз атлап киткәч кенә, күңел күзе Бохара өчен гайре табигый хәлгә игътибар итте. Хатыннарның берсе, ишек төбендә саубуллашып, вагонга кереп югалгач, зиһене тәмам ачылып киткәндәй булды: чү, Зөһрәгөл түгелме соң бу?

Әле генә үзен биләгән таркаулыгы шундук каядыр очты китте, Фарукҗан җитез-җиңел атлап, әлеге вагонга юнәлде. Бары тик купеларның берсендә пәрәнҗәсен салган зур коңгырт күзле, куе каш-керфекле, туткыллы таныш йөзне күргәч кенә, ул үзенең ялгышмавын аңлады.

— Зөһрәгөл, зинһар гафу ит, билләһи, танымадым! — диде.— Димәк, китәсең? Бөтенләйгә?

— Әйе.

— Мин дә китәм. Кара, ничек бергә туры килдек. Язмыш юк дигән булалар тагын!

Тик Зөһрәгөл аңа җавап бирмәде, дымланган күз төпләрен яшерер өченме, йөзен тәрәзәгә таба борды да хәрәкәтсез калды. Фарукҗан моны үзе белән очрашудан, сәфәрнең бергә дәвам итәчәген белүдән дулкынлануга, шатлануга юрады, әмма юлдашының яңагы буйлап эре-эре яшь тамчылары тәгәри башлавын күргәч:

— Син нәрсә, Зөһрәгөл, тынычлан инде! — диде.— Алда өр-яңа тормыш башлана. Якты, шатлыклы...

— Шатлыклы? Монда калучы нарасыйларым гомер буе бәгыремне телгәләсә дәме?

Фарукҗан, саташуын тоеп, телен тешләде. Зөһрәгөл кульяулыгы белән күз төпләрен сөртте, аннары игътибарны бүтән нәрсәгә күчерергә омтылып, ләкин Чека исемен телгә алудан сакланып:

— Сез тагын мәркәзегез йомышларын үтәргә чабасызмы? — дип сорады.

— Бу юлы дүрт ягым кыйбла — бөтенләй үз иркемдәмен. Бәлки әле син киңәш иткән сукмактан да атлый башлармын.

«Тут-ту-ту-у-у!» Паровоз сузып-сузып гудок бирде дә кузгалып китте. Башка юлаучылар шикелле, Фарукҗан да тәрәзәгә капланды һәм артка шуышкан Каган вокзалы перронында ике таныш кешесен күреп алды: өрлектәй таза, киң җилкәле, түгәрәк йөзле Таштимер Тураев белән янәшә диярлек очлы иякле, кылыч борынлы, маңгаенда яра эзе ярылып яткан Бум басып тора иде. Йөрәге чәнчеп куйды, ачык тәрәзәдән кычкырып, Таштимерне кисәтәсе килде Фарукҗанның, әмма үз-үзен көч-хәл белән тыеп кала алды — Бохарада үзара көрәшнең әле тиз генә басылмаячагын, мондый чакта читтән килеп ярдәм итәргә тырышуның каш ясыйм дип күз чыгару кебегрәк тә булу ихтималын ул инде төшенгән иде.

*Бохара — Ташкент — Казан*
*1982—1989*

# Бәкер Чобан-задә

## Дунай таша

Дунай таша сорыланып, каралып,
Киртәләрне юлыннан ора алып,
Ярдан ыргып чыгалмыйча тилмерә,
Күперләрне, таш ярларны кимерә.

Моны күреп сагаялар кешеләр,
Ни булган, дип, сорый минем ишеләр.
Житмеш еллап бит болай ташканы юк,
Киртәләрнең тезеннән ашканы юк.

Үз иреген барыннан изге күргән,
Синең якты йөзеңне күреп көлгән —
Меңәрләгән инсаннар белми сине,
Дунайчыгым, ташкын яшь күңелеңне.

Бүген тик мин сине күрдем ачулы,
Киртәләрне җиңеп ташкан, ярсулы...
Яшермимен, ташу тели йөрәгем,
Мең еллык киртәне еру теләгем.

Мин дә синдәй ташып һәм шашып аксам,
Явызлыклар киртәсен бәреп атсам,
Арык халкымны чыгарсам киң юлга,
Зур дәрьяга җиткезсәм, булып елга!

Гөл-чәчәкләр чыкса үсеп бу җирдән,
Яшәсә халкым тупланып вә бердәм,—
Шул вакытта күрерсең син, белерсең,
Бу ташкынның серенә төшенерсең...

Юкка, Дунай, йокламадым ярында,
Синдәй таша минем йөрәк каным да!

---

Бәкер ЧОБАН-ЗАДӘ *(1893—1938) — Кырымның Аргын авылында туа. Карасудагы Рөшдия, Истанбулдагы Солтания мәктәпләрен тәмамлый, Одесса, Будапешт югары уку йортларында белем ала. Күренекле мәгърифәтче, төрки телләр, әдәбиятлар белгече, Кырым һәм Әзербайҗан университетлары профессоры, сталинчылык корбаны. Шигырьләре 1914 елдан дөнья күрә башлый.*

## Болытлар, болытлар

Болытлар, болытлар...
Агылган болытлар,
Чоңгарга, Кытайга
Юл алган болытлар!
Алыгыз мине дә,
Күзләрем ачылсын,
Яңгырдай, яшьләрем
Җиремә чәчелсен.

Болытлар, болытлар...
Кул җитмәс болытлар,
Ал, яшел һәм саргылт,
Кат-катлы болытлар:
Алыгыз мине дә
Күрмәгән илләргә,
Салгырны[1] каймаган
Чирәмле җирләргә.

Болытлар, болытлар...
Кояшлар иленә
Алыгыз мине дә —
Йолдызлар күгенә.

Алыгыз мине дә
Давыллы диңгезгә...
Йә тамыйм бал булып
Чулпанның йөзенә.

Болытлар, болытлар...
Камышлы күлләргә,
Йолдызлар атылган
Кайнар ком-чүлләргә
Мине дә алыгыз,
Яшенләп яуганда,
Диңгезгә тамганда,
Сыланып ярларга,
Бергәләп ярлабыз —
Явымлы көзләрдәй,
Саргаеп суларбыз
Йә яшьсез күзләрдәй.

Җәйләүгә китәрбез,
Күрербез Әсмамны...
Кул болгап озаткан
Улымны — Османны.
Күрербез Анамның
Яшь юган күзләрен,
Юарбыз кайгысын,
Үбеп чал йөзләрен.

# Әнвәр Сәламәт

## Имә, шагыйрь, башыңны

Ераклардӑн, карлы Тянь-Шань артыннан
Тавридамның тауларына күз атам...
Челтерәп аккан Салгыр суы моңнарын
Җырларыма кушып, сазлар уйнатам.

Хыялымда Тавридамның чүленә
Йөзеп килдем Днепр суларында,
Замандашлар миңа суза кулларын,
Яшәреп мин яшимен җырларымда.

Күз алдымда янар чүлләр, үзәннәр,
Ятып үбәм туфрагыңны, ташыңны...
Моңлы шагыйрь Тавридасын сагына,
Күтәр, Чатыр[2], һич имә син башыңны!

---

Әнвәр СӘЛАМӘТ *(1917—1980)* — *«Эчкән суларым», «Белгән булса Прометей», «Таян омузыма» һ. б. шигъри җыентыклар авторы.*

[1] Салгыр — Кырымдагы елга исеме.
[2] Чатыр — Чатыр-Даг тавы.

# Җәвәһирә

## Анам

Мин алдым синең йөз нурың,
Куаныч, шатлыгың, җырың...
Инде җандай күреп багам,
Балачак багым син — Анам!

Туган кояшы көнемнең,
Чишмәсе аккан гомернең...
Бары да сиңа багланган,
Җиләкле аланым — Анам!

Син янсаң, йөрәгем яна,
Син — йөрәгемә саф һава...
Авырган чагымда — дәвам,
Үлемсез дастан син — Анам!

## Сөю хатым

Син булгансың гөлләремне
Чәчәк аткач өзәчәк.
Син минем өчен тугансың—
«Сөю» атлы киләчәк.

Син булгансың, сыйпап-сыйпап,
Чәчләремне үрәчәк,
Сулып-шиңсәм, шифа сулар
Йөзләремә сибәчәк.

Син булгансың ут-ялкында,
Мине яклап, яначак...
Син булгансың бал шикелле
Иренемә тамачак.

Син булгансың тормыш ямен
Минем белән табачак,
Боекканда, гел иркәләп,
Күңелемне ачачак.

...Ник мин шуны әйтәлмәдем,
Сиңа сөйләп бирмәдем?!
Күзләреңә туры карап,
Ай-Кояшым, димәдем?!

Яшьлегемдә очкан коштай,
Ерак хәзер ярым да...
Бирче, хатым, аңа сөйләп,
Соң булса да, барын да!

*Әдхәт СИНУГЫЛ тәрҗемәләре.*

---

Җәвәһирә МӘҖИТОВА — *«Онытылмас сәхифәләр», «Яшел яфрак арасында», «Гомер сазым» шигъри җыентыклары авторы. Чирчик шәһәрендә яши.*

# Шамил Алядин

## Кара кыз

«— Бакчы, кара кыз, минем шинелемә,
Итәккә кылыч күпме эз салган.
Ертык кесәмдә тик икебезгә
Берәр төрерлек махорка калган.

Ал, берсе сиңа, кызыл казактан
Бер бүләк итеп кабул ит аны.
Кабызып җибәр, тик күз уйнатма,
Кайтам ерактан, кузгатма җанны...

Кара кыз сүзсез-җавапсыз гына,—
Сизәм күңелендә дәртләр уйнавын,—
Күзләрен төбәп тик карап тора,
Нәрсә тели бу солдаттан тагын?!

— Илгә кайтамсың, сугышчы егет,
Анда мине дә хәтерләп сөйлә:
Юлда бер чегән кызы күрдем, дип,
Тапшыр миннән дә сәлам илеңә.

Минем дә кардәш-ыру бар иде
Гаҗәп Өнделес иле ягында,
Өебез кабер сыман тар иде,
Ташладым, киттем, калдым чатырда.

Моңлы авылда дөньяга килдем,
Атам гасконлы, анам хәсрәтле...
Артык җан булып яралган идем,
Өебез тузды, өзелде бәхете...

Поезд туктый да, тагы кузгала,
Йокламыйм, күзгә йокы һич керми.
Кара кызга дим: «Сөйлә, кыз бала,
Ник күңелең тулды, ник йөзең тирли?»

Кара кыз тора тәрәздән карап,
Анда таллыклар, сукмаклар-эзләр...
Аһ, күзләр, күзләр! Ялкынга камап,
Бәгырьне йөзгә телә бу күзләр!

*Нури АРСЛАНОВ тәрҗемәсе.*

---

Шамил АЛЯДИН *(1912) — Кырымның Мәхүлдүр авылында туа, иҗатын шигырь белән башлый, прозасы белән таныла. Күп кенә романнар, повестьлар, хикәяләр, эсселәр авторы, Үзбәкстанның халык язучысы. Ташкентта яши.*

# Сәет-Гомәр Әмин

## Өч аршын җир

...Тик өч аршын җирең...
Үтенәмен,
            тик өч аршын җирең...
Бары өч...
            соңгы дымлы урын-ятагым...
Бүтән кирәк түгел...
            Түгел!..
Яшәгәндә сине, газиз җирем,
            бер туйганчы коча алмадым...
Чит җирләрдә,
            ком-буранлы илдә
                        тимер ятакларда аунадым!
Тартып алды сине — өметемне
            бәгырьләре корыч кешеләр!
«Хыянәтче», «Илен саткан» булып йөрде
            җирдә безнең ишеләр!
Тора-бара барысын да тартып алды явыз-усаллар.
Без исемсез калдык һәм Ватансыз.
Аһ, алар да бездәй булсалар!
Безнең тәкъдирләрдә торсалар!!!

...Тик өч аршын!
            Үлгәннән соң?!
            Ятыйм кереп синең назлы куеныңа?!
Анам диеп, туган газиз җирем, сарылыр идем
                        синең муеныңа!
...Тик өч аршын!!!
Ятса иде сөякләрем, табып тынгылык:
Ватанымда, газиз Ватанымда тынычланыйк инде,
                                    шым булыйк!
Рәнҗетелдек...
            Кимсетелдек...
Яндык!..
Эт язмышы — безнең чынбарлык!
Бабаларның каберләрен изеп,
корбаннардан кылды корбанлык.
Кабер-кадер ташларыннан
            дуңгызына абзар ясады,
Юлларына, урамнарга түшәп, мыскыллады безнең башларны!

Яши иде авылым Албат таулар арасында,
гөл-чәчәккә күмелеп...
Килде гаскәр, бөтен бер халыкны алып китте...
                        Киттек сөрелеп...
Авыл гына зәңгәр ераклыкта һаман тора,
                        тора күренеп...

---

Сәет-Гомәр ӘМИН *(1921) — «Ак чәчәкләр», «Ялкынлы көннәр», «Юл» һ. б. шигырь китаплары авторы. Новороссийск шәһәрендә яши.*

Өч аршын җир!
Шуның өчен риза күзләремне сиңа бирергә!
Алар зәңгәр — Кара диңгез сыман!
Риза булсаң, йөрәгемне бирәм.
Мин утырткан сәлби-тирәк өчен,
Өч аршын җир өчен...
Газиз илем, кирәкме
бу кулларым,
аякларым — үзем?!
Мин чыдам,—
сабыр, түзем...

Өч аршын җир үпсен минем йөзем...
Өч аршын җир...

*Әхмәт ГАДЕЛ тәрҗемәсе.*

## Билал Мамбет

### Яшәү өчен...

*Бер йотым су булсын,*
*Суларга — һава...*
Әнвәр Сәламәт.

— Яшәвең өчен ни кирәк? — диләр...
«Бер йотым су булсын,
Суларга — һава...»

Шушы сорауны ничә кат бирделәр...
...Бер йотым су...
Һәм һава...

Яшәү өченме? Күп нәрсә кирәкми:
Тик туган туфрагым! —
Тик шунда дәва...
Һәм дуслар елмайсын,
Шатлансын янда...

...Бер йотым су,
Суларга — һава...

Яшәү өченме? — диңгезем кирәк,
Ә ярда —
Багларда кызарсын җимешләр.
Тик шуннан көч алыр бу йөрәк...
...Бер йотым су кирәк,
Һәм һава...

Яшәү өченме? — Кирәк үз телем,
Ул телдә җырлансын бишек җыры, дим,

---

Билал МАМБЕТ (1935) — *Кырымның Куз авылында туа, балаларга һәм өлкәннәргә атап язылган «Яңгыр», «Яз ризыклары», «Тау лаләсе» кебек дистәләгән шигъри җыентыклар авторы. Ташкентта яши.*

Яшәү өчен... аһ, булсын үз илем,
Тамырым бәйләнсен тик аңа минем!

Яшәвем өченме? Аю-Даг кирәк,
Чайкалсын аста — диңгездә дулкын...
Ансыз иркенлек тапмый бу йөрәк!
Кайсы ил-җир соң ят санар — халкын?!

Хыялым — яд итү Бакчасарайны.
Теләгем — күрүме? Юк, шунда яшәргә.
Йөрәккә сыйдырып ул изге сарайны,
Телимен өр-яңа хәятым башларга.

— Сиңа соң яшәвең өчен ни җитми? — диләр.
Аңлыйм
Һәм ашыкмыйча гына
бирәм җавап:
— Булсын, дим, илемдә — бер йотым су
Һәм сулар һава!

*Рәдиф ГАТАШ тәрҗемәсе.*

# Черкез-Али

## Гафу ит мине

Каберең кай җирдә,
Кем белә аны...—
Үлгән җиреңне тапмадым, әни.
Соңгы сүзеңне
Ишетми калдым:
Тайга эченнән кайтмадың, әни.

Миңа әкиятләр
Сөйли идең син
Бала чагымда, аю турында.
Җиләкләр җыеп
Кайтам дип киттең,
Ләкин кайтмадың киткән урынга.

Ни булды сиңа,
Белмибез аны.
Сине баткаклар упкандыр, бәлки.
Синең бәгырьне
Чал тайгаларның
Ач аюлары йоткандыр, бәлки...

Шуңа күрә мин
Кабереңә түгел,
Тез чүгәм бүген рухың алдында.
Шулай да сине
Исән-сау итеп
Яшәтәм, әни, һаман янымда.

---

ЧЕРКЕЗ-АЛИ (1925) — *Кырымның Баһадир авылында туа, шагыйрь һәм прозаик, «Таңнар кочагында», «Юмартлык» романнары, күп кенә повесть, хикәя, шигырь җыентыклары авторы. Ташкентта яши.*

Рәнҗемә миңа,
Гафу ит, әни,
Сине тик шулай хәтерләвемне.
Бер һәйкәл итеп
Кабул ит, әни,
Минем кан-яшьле сәтырьләремне.[1]

*Хәсән ТУФАН тәрҗемәсе.*

## Саф җилләр

Җилләр исә, җилләр исә
Биек таулар түбәсендә.
Йә тына ул, йә куба ул
Бәгырькәйнең эргәсендә.

Җилләр кирәк, исә бирсен
Җан сусаган бу көннәрне.
Тик афәткә илтмәсен ул
Тыныч, иркен көнелләрне.

Искән җилләр исеп үтәр,
Яңгыр килер сагындырып —
Көйгән җир куанып эчәр,
Дөнья калыр чәчкә булып.

Кешегә бир — тыныч хәят,
Тыныч хәяткә — бир канат.
Яшәвең булмаса тыныч,
Үкенечле булыр кабат.

Иссен җилләр, җилләр иссен,
Йөз чөерми куаныр лык.
Табигатьнең җаны көлсен
Торгынлыктан уяныр лык.

Кичеп чыктык ничә буран,
Ничә афәт кичте баштан.
Биюдән аерылгандай,
Аерылдык каләм каштан.

Мәрмәр биле сөйгән ярның
Афәтләрдән төште сыгылып.
Җаныбызны аямадык,
Аннан котылмакчы булып.

Зәһәр еллар сынавында
Җаныбызны кызганмадык.
Һәр вакытта, һәр адымда
Ильичка юл турыладык.

Хезмәт иле, күз ачтык без,
Егылсак та калкып тордык.
Ярдәмләшеп һәрберебез
Берлек булып хәят кордык.

Бер-береңә тотынсаң, кул —
Егылганга таянычтыр.
Адашканга күрсәтсәң юл,
Ахыры сиңа куанычтыр.

Без адашу эстәмәдек —
Тагылса да төрле акыл.
Кыенлыкка баш имәдек,
Ленин булды безгә факел.

Андый эшкә баш салмадык,
Һәрбер хәлдән җиңеп чыктык.
Искелекне, яманлыкны
Буйсынмыйча бәреп ектык.

Иссен җилләр, иссен җилләр,
Күк күкрәсен сафландырып.
Эсселектән кызган тәннең
Хәл-әхвәлен сорар булып.

Еракларда канатланып
Ул саф җилләр исеп килсен.
Бәйгедәге чабыш аттай
Йөрәккә дәрт биреп килсен.

Сафлык белән иссен җилләр
Күңелләрнең сынап көчен.
Хезмәт халкы маңгай тирен
Нәзакәтле сыйпап кичен.

Афәтләргә, гаугаларга
Күнми иссен бу саф җилләр.
Таш бәгырьле тупасларны
Күрми иссен бу саф җилләр!

*Мөдәррис ЭГЪЛӘМОВ тәрҗемәсе.*

[1] Сәтырьләр — шигырь юллары.

# Әбләзиз Вәлиев

## Кораблар

Килсәм мин ул ярга, әй кораблар,
Сезне тагын күрсәм...—
Ник әле күңелдә һаман да
Шатлык һәм сагыш-гамь?!

Алып китегез мине дә, кораблар,
Теләгемә ирешим...
Иртәгә ни көтә әле безне?
Әйтә алмыйм ич мин...

Сезне уйлыйм да, кораблар, хәтердә
Яшьлегем уяна.
Ә күрсәм, яшәрәм, кораблар:
Сабыйдай куанам.

Алып китегез мине сез, кораблар!
Диңгезгә, диңгезгә...
Тәкъдирне сыныймчы мин сездә —
Диңгездә, диңгездә!

*Рәдиф ГАТАШ тәрҗемәсе.*

# Риза Фазыл

❀

Нинди гүзәл бу яз — гаҗәеп заман!
Былбыллар тавышы йөрәктә сыман!
Бакчалар дөньясы ак чатырын ача,
Тирә-як хуш истә, салкыннар кача!

Кил, дустым, тыңлаек язларның җырын,
Урманнар, чишмәләр, тауларның серен.
Илдә саф җилләр искәнгә күңелле тышта:
Яз өчен көрәшләр булмады бушка!

*Әхмәт ГАДЕЛ тәрҗемәсе.*

---

Әбләзиз ВӘЛИЕВ *(1938) — Кырымның Куз авылында туа, шагыйрь, прозаик, халык иҗатын җыючы. «Байракка тамган күз яшьләре», «Бәхет йолдызы», «Теләк» һ. б. китаплар авторы. «Ленин байрагы» газетасы редакторы урынбасары. Ташкентта яши.*

Риза ФАЗЫЛ *(1929) — Кырымның Чәләби-иле авылында туа. Шагыйрь, прозаик, халык иҗатын җыючы. «Нәүрүз», «Тугрылык», «Әхмәтханның йолдызы» һ. б. китаплар авторы. «Йылдыз» журналының җаваплы секретаре. Ташкентта яши.*

# Дилявер Осман

*

Аһ, татарлар, татарлар...
Зур кайгылардан эчләре янган,
«Ватаным!» — диеп гел юлга чыккан,
Бер хәсрәттән икенчесенә таянган —
Газиз халкым, татарлар...

Һәр тарафтан, төрле яклардан
Дәрьядай агып кына Йортына
Җыелышып кайтса икән татарлар —
Кара дингез ярына,
                таулар янына...

Һай, татарлар, татарлар!

Чүлдә ятып калган газиз кардәшләр,
Аерылышабыз, туганнар!..

Моңсуланды янә йолдызлар...

Юлга чыкты янә — соңгы катмы?! —
                халкым, татарлар...

Еллар үтәр, узар гасырлар...
Алышыныр тәхет, падишалар... дөньялар!
Онытылмас хурлык заманнар,
Аһ, татарлар, татарлар...

*Әхмәт ГАДЕЛ тәрҗемәсе.*

---

Дилявер ОСМАН *(1959) — яшь шагыйрь, композитор, Казан консерваториясен тәмамлады, хәзер Кырымда Карасубазар шәһәрендә яши.*

**Үло Маттеус,**

эстон язучысы

# ҖЫР

ХИКӘЯ



Атаклы җырчы Ион Ионсон бу кечкенә шәһәрдә ике көннән соң чыгыш ясарга тиеш иде. Адәм аягы баскан һәр урынга, дивар, коймаларга әлеге җырчының булачак концерты турында хәбәр итүче афишалар ябыштырылды. Иртә таңнан билет кассасына чират тезелде. Концертка әләгергә теләүчеләр бихисап булганлыктан, ахырданрак килүчеләргә көне буена чират сиратын узырга туры килде.

Шундый түземлек белән чират торучылар арасында чал чәчле, иңбашларын картлык баскан, әмма күзләрендәге нурны сүндерә алмаган, җитез хәрәкәтле бер карчык та бар иде. Бераздан аның янына күршедә яшәүче ахирәте дә килеп җитте. Чираттагыларның ризасыз авазларына карамастан, алар бергә бастылар һәм, һични булмагандай, Ион Ионсон турында белгәннәре хакында үзара уртаклаша башладылар. Аларның сөйләшүенә карағанда, илаһи тавышлы бу җырчы милләте белән швед икән, ике мәртәбә өйләнгән, бер көтү баласы бар ди; кыскасы шул: ходай аңарга талантны да, булдыклылыкны да мулдан биргән...

Беренче карчык Ион Ионсон башкарган җырлардан иң кәттәсе дип Риголетто партиясен саный, ә икенчесе — Ягоны мактый. Шулвакыт болар алдындагы кортка да сүзгә кушылды. Ул Моцартның Дон Жуанына мөкиббән икәнен, ә Верди операларына әлләни исе китмәвен әйтеп, кырмыска оясына таяк тыгып болгагандай итте. Бәхәс кызды. Карчыклар үзләренең җыр сәнгатендә шактый тирән йөзүләре белән чираттагыларны гаҗәпләндереп, атаклы Ион Ионсон катнашкан барлык операларны, ул башкарган арияләрне берәмтекләп саный-саный бәхәсләштеләр. Шулай итеп, чиратлары килеп җиткәнен дә сизми калды болар. Билгеле инде, карчыкларга янәшә урыннар эләкте һәм, концертны карагач, өр-яңа тәэсирләрдән соң бәхәсне янә дәвам итү мөмкинлеге бар иде. Ахирәт дуслар беренче карчык яшәгән йортка юнәлделәр. Гәрчә бу яшьтә йөрәккә авырга киләсен белсәләр дә, кофе йоткалап, әңгәмәне дәвам итәргә булдылар. Әңгер-меңгер төшкәнче чүкердәште алар. Ахыргы нәтиҗә мондый булды: Ион Ионсон һәрьяктан талантлы, бөтен җырны һәм арияләрне бердәй әйбәт итеп, йөрәккә сары май булып ятардай итеп җырлый. Ләкин ахирәтләр моның белән генә туктап калмадылар, әлбәттә, тагын да тирәнгәрәк кереп, атаклы җырчының тормышына кагылышлы һәр нәрсәне аерым-аерым берәмтекләп тикшереп чыктылар. Хуҗабикә кайдандыр поднос кадәр альбом алып килде. Анда Ион Ионсон хакында ниләр генә юк: матбугатта чыккан рецензияләр, фоторәсемнәр дисеңме — һәммәсе бар иде. Чын мәгънәсендә диссертация язу өчен әзерләнгән диярсең. Хәтта ки һәр материалдан соң карчыкның үз бәяләмәсе, искәрмәләре дә язып куелган. Монда Ион Ионсонның тәрҗемәи хәле дә, иҗаты да, ике иңендәге ике фәрештәсе язып барган сыман, ап-ачык күренеп тора. Архивны актара-актара янә шактый гәпләште-

ләр. Ахирәт дуслар тәмам караңгы иңгәч кенә кайтырга кирәклекне искә төшерделәр, телефоннан чылтыратып, такси чакырдылар.

...Карчыклар ул көнне концертка иң затлы киемнәрен киенеп килгәнлектән, яшәреп тә киткәндәй күренәләр иде. Алар бер-берсенә ерактан ук сәлам бирештеләр, инде аларны ниндидер күзгә күренмәс бик мөһим нәрсә фикердәш иткән, бу бәйләнеш йөзләренә, күзләренә нур булып сирпелгән шикелле иде. Алар зур көзге каршына тукталып, тормыш тараганнан соң калган чәч толымнарын төзәткәләделәр, яшь вакытта кешелеккә кия торган һәм кием шкафында озак торудан нафталин исе сеңгән затлы күлмәкләрен сыпыргалап алдылар, муеннарына, колак артларына ислемай сөрткән булдылар да гөжләп торган тамаша залына атладылар. Тиздән кыңгырау өченче тапкыр чыңлады һәм яктыртылган сәхнәгә, балкып, Ион Ионсон үзе килеп чыкты. Өстендә — гәүдәсенә ятып торган фрак, чәчләре шома итеп артка таба таралган. Көчле алкышларга кушылып, залда «афәрин!» авазлары да яңгырады. Ион Ионсон, залда тынычлык урнашканчы, тамашачыларга туктаусыз баш иеп торды. Бу баш июдә артистның үз бәясен белүе, горурлыгы сизелеп калды. Һәр номерны башкарган саен кул чабулар көчәя барды һәм Ионсонга яңа җырын башлаганчы алкышлар басылганны шактый көтәргә туры килде. Аңа әледән-әле чәчәк бәйләмнәре тоттырдылар. Тиздән сәхнә чәчәк аткан бакчаны хәтерләтә башлады. Ион Ионсон халык җырларын да, опералардан арияләрне дә зур дәрт белән җырлады.

Тәнәфес вакытында безнең корткалар буфетка ашыкты, дулкынланулары басар өчен булса кирәк, берәр чәркә коньяк алдылар. Алар шулкадәр тәэсирләнгәннәр иде ки, телләрен йоткандай, тын гына эчтеләр.

Ниһаять, беренче карчык телгә килде:

— Искиткеч концерт! — диде ул.

— Илаһи тавышлы бу Ион Ионсон! — дип көрсенде икенчесе.

Ә өченче карчык әлегә дәшми калды, чөнки ул Дон Жуан ариясенең башкарылуын көтә иде. Гәрчә аның да концерттан бик канәгать икәне йөзеннән күренеп тора иде.

— Безнең шәһәрдә опера театры булмау кызганыч, юкса Ион Ионсон Риголетто ролендә дә чыгыш ясый алыр иде,— дип авыр сулады беренче карчык.

— «Отелло»ны да куярлар иде,— дип өстәде икенчесе.

Аларны залга чакырып, кыңгырау чыңлады.

Атаклы җырчыны яңадан көчле алкыш белән каршыладылар. Карчыклар арттагы рәтләрнең берсендәге үз урыннарына кереп утырдылар һәм, сихерләнгән кебек, сәхнәгә йотылдылар, эчтән генә ямансулап җырчыны тыңладылар. Менә Ион Ионсон күптән зарыгып көтелгән Дон Жуан ариясен җырлый башлады. Өченче карчык ахирәт дусларының кабыргасына төрткәләп алды. Ишетәсезме, янәсе. Ишетмиләрме соң, дөньяларын онытып тыңлыйлар иде.

Җырчы соңгы номерны башкарганнан соң алкышлардан концерт залының түшәме күтәрелде сыман. Ион Ионсонның талантына баш июче ләр сәхнә алдына ук килеп, туктаусыз кул чаптылар, сәхнәгә чәчәк бәйләмнәре очты. Чәчәкләргә күмелеп калган җырчы туктаусыз баш иде, хәлбуки, аны сәхнәдән һич кенә дә чыгарасылары килми иде. Шул арада беренче карчыгыбыз кысылакысыла, халыкны ырып-ерып, сәхнә янына килеп җитә алды. Калтыранган куллары автограф алу өчен Ион Ионсонга концерт программасын сузды. Җырчы түш кесәсеннән авторучка алып, программа кәгазенә тиз-тиз нидер сызгалап бирде. Башкалар да Ионсонга ашыга-ашыга открыткалар, кәгазь кисәкләре, программалар суза башладылар. Эшнең озакка сузыласын чамалаган җырчы, гаепле сыман елмаеп, баш иде дә сәхнәдән чыгып китү ягын карады.

Ниһаять, зал тамашачылардан бушап калды. Безнең ахирәтләр дә кайтырга чыкты. Беренче карчык нәни сумкасына яшерелгән автографлы программаны алып, дусларына күрсәтергә ашыкты. Ул үзенең сабыйларча куануын һәм горурлануын яшерә алмый иде. Карчыклар кадерле программаны тегелей дә, болай да әйләндереп-тулгандырып карадылар һәм мондый нәтиҗәгә килделәр: искиткеч шәп язган! Хәлбуки, анда ашык-пошык сызгаланган имзадан гайре берни дә юк иде.

Карчык фатирына кайткач, яраткан җырчысының кулы тигән программаны изге бер эш башкаргандай, альбомына ябыштырып куйды һәм сөенечен уртаклашу өчен күршеләрен чакырды. Тегеләр автографны караган арада ул граммофонга Ион Ионсон тавышы язылган пластинканы куеп, уйнатып

җибәрде. Үзе биеп тә китмәкче иде, әмма аягындагы ревматизм ирек бирмәде. Күршеләре карчыкның болай иләсләнеп китүенә гаҗәпләнгәндәй үзара мәгънәле генә карашып алдылар да, аны Ион Ионсон белән генә калдырып, чыгып киттеләр. Ләкин бу нәрсә генә карчыкның кәефен төшерә алмады. Бүген аның өчен, юк аның өчен генә түгел, ул яши торган йорттагылар өчен, хәтта бөтен шәһәр халкы өчен дә зур бәйрәм иде бит! Тәлинкә уйналып беткәч, карчык граммофонны туктатты да урын җәеп, йокларга ятты, әмма тамчы да йокысы килми иде. Узган көннең дулкынландыргыч вакыйгалары берәм-берәм аның күз алдыннан агылды. Ул вакыйгаларның уртасында Ион Ионсонның фрак кигән мәһабәт сыны тора иде. Атаклы җырчының үзен генә түгел, кеше күңелен аңлый торган мәрхәмәтле олы җанын да аермачык күрә иде шикелле ул. Ә колагында илаһи тавышы туктаусыз яңгырап торды. Бу мәһабәт гәүдә, бу илаһи аваз карчыкны әллә кайда калган яшьлегенә күтәреп алып китә, аның тормышын тулыландырып, мәгънәле итә иде сыман. Карчык хыялында очып барган мәлдә йөрәгенең, читлектәге коштай, күкрәк читлегендә бәргәләнүен, аның торган саен сыкрап авырта баруын тойды. Гомере буе, эттәй аның артыннан тагылып, аны әзәрлекләп килгән я л г ы з л ы к хәзер, нәкъ менә шундый ләззәтле минутлар кичергәндә эләктереп алды. Карчык авыр ыңгырашты, ялгызлык тырнагыннан ычкынырга теләп, әле бер, әле икенче ягына әйләнде. Ниһаять, таң беленгәндә генә килеп җиткән йокы, барысын да онытгырып, карчыкны үз кочагына алды.

Кояшның тәүге нурлары бүлмә тәрәзәсенә төшүгә, ишек кыңгыравы чыңлады. Елмаеп-балкып, күрше йортта яшәүче ахирәте килеп керде. Минут та үтмәгәндер, икенче дусты да күренде. Иртүк килеп җитү өчен таксига утырган, акчасын җәлләп тормаган. Хуҗабикә озак йоклавы өчен гафу үтенә-үтенә ятагыннан торды, һәм, өстенә бизәкле халатын элеп, кухняга юнәлде. Кофе әзерләргә. Юл уңае ванна бүлмәсендә краннан су агызып, йөзенә бөркеде. Аннары, кофе пешерү өчен кайнатырга су куйганнан соң, дуслары янына чыкты. Аның инде йөзендә йокы әсәре калмаган, җыерчыклары елмая. Шулай да хәрәкәтләренең салмаклыгы аның төнне тынычсыз үткәрүен, арганлыгын күрсәтеп тора иде. Моны ул кунакларыннан да яшереп кала алмады.

Ахирәт дуслар, кофены көтеп торырга тәкатьләре җитмичә, кичәге концерт турында рецензия язарга утырдылар. Алларына Ион Ионсон турындагы теге архив материалларын алып куйдылар, кадерле автографлы программаны да онытмадылар. Язу-сызу белән шулкадәр мавыгып киттеләр ки, хәтта кофе пешерү өчен дип плитәгә куелган суны да оныттылар. Сөйләшә-киңәшә тамаклары кипкәч кенә исләренә төште. Хуҗабикә, ут капкандай ашыгып, кухняга кереп китте, бераздан буларын бөркеп, тәмле кофе исләре аңкыткан чәйнек күтәреп чыкты. Карчыклар кофе эчү белән мавыгуның үзләре өчен бик үк файдалы түгел икәнен аңласалар да, хуш исле кайнар эчемлектән баш тартырга көчләре җитмәде.

Кофе эчкәннән соң карчыкларның кәефләре тагын да күтәрелеп китте, алар торган саен дәртләнебрәк эшли, кычкырыбрак сөйләшә башладылар. Монда ни булды икән, дип аптыраган күршеләре ишекне ачып-ачып карауга да игътибар итмәделәр, дөньяларын онытып, шау-гөр килеп, яза бирделәр. Дөресрәге, берсе яза, икесе әйткәләп тора иде.

Төшкә таба рецензиянең яртысы диярлек язылып беткән бер вакытта радиодан Ион Ионсон турында тапшыру башланды. Башка көйләр белән беррәттән, карчыклар граммофонда уйнаткан арияләр дә яңгырады радиодан. Концерт тәмамланганнан соң, ахирәт дусларның башына яңа уй килде: универмагтан Ион Ионсонның яңа җырлары язылган тәлинкәләр алып кайтырга!

Тик универмаг төшкегә ябылган булып чыкты. Ашыгып килүдән тыннары кысылган карчыклар, вакытны ничек тә бушка уздырмас өчен, якындагы бер кафега кереп, капкалап алырга булдылар. Алар яшелчә салаты белән икешәр тутырма алдылар да баскан килеш кенә тамак ялгарга керештеләр. Әмма ләкин күзләре — ашамлыкта, уйлары бүтән нәрсәдә иде, шуңа күрә тамакларыннан ризык авырлык белән генә узды. Ашап чыкканнан соң да вакытлары калган икән әле. Алар универмаг урнашкан кварталны ике тапкыр әйләнеп чыктылар да, арып, кибет каршындагы эскәмиягә килеп утырдылар. Ниһаять, универмагны ачу вакыты да килеп җитте, әмма ходайның хикмәте, ишек һаман ачылмады. Карчыкларның түземе төкәнде, алар витринага шакырга тотындылар һәм ишекне ачтырмыйча туктамадылар. Менә арыган кыяфәтле склад эшчесе ишекне ачып, карчыкларны эчкә уздырды.

Сатучылар мебельләр бүлегенә җыелып, йомшак диванга киерелеп утырганнар да ләчтит саталар иде. Чакырылмаган «кунаклар»ның гозерен чырай сытып кына тыңлаганнан соң, сатучыларның берсе авыр гына кузгалып, ары-бире каранган булды да салкын, битараф тавыш белән:

— Сез сораган тәлинкәләр юк,— диде.

Аптырашта калды ахирәтләр. Нишләмәк кирәк, заказларын кәгазьгә яздырдылар да ризасыз мыгырдана-мыгырдана китеп бардылар.

Заказ бирелгән тәлинкәләр магазинга бер айдан соң да, ике ай үткәч тә килмәде. Тик карчыклар өметләрен өзмәде: грампластинкалар фирмасы директорына хат язып җибәрделәр. Атна-ун көннән соң җавап килде. Рәсми кәгазьгә басылган һәм секретарь кул куйган җавапта мондый юллар бар иде: «Кызганыч ки, безнең завод Ион Ионсон тәлинкәләрен җитәрлек дәнәдә җитештерә алмый әле. Шулай да киләсе кварталда бәлки җибәрә алырбыз».

Көннәр берсен берсе алыштырды. Кечкенә бу шәһәрчеккә сирәк-мирәк булса да төрле театрлар, эстрада коллективлары сугылгалады. Тик аларның берсе дә Ион Ионсон концертын алыштыра алмый иде шул. Бердәнбер юаныч: яраткан җырчылары турында хәбәрләр ишетелгәли тора. Йә газетада язалар, яки радиодан сөйлиләр, яисә шәһәр кешеләреннән кем дә булса кайдадыр аның концертын тыңлап кайтканын әйтә. Андыйларга безнең карчыклар бигүк ышанып җитмиләр җитүен. Әйтик, кайбер белдеклеләр Ион Ионсонның соңгы вакытта сырхап киткәнлеге турында лыгырдый. Нишләп авырсын ди ул шундый гөрнадир кебек кеше. Әнә бит, гәзитләр аның төрле зур шәһәрләрдә һәм чит илләрдә куйган концертлары турында язгалап тора. Шулай да нишләп бу шәһәрчеккә яңадан килеп чыкмый ул? Әллә үзен зарыгып көтүчеләр барын белмиме икән? Карчыкларның кулы эшкә бармады, тамакларыннан аш үтмәс булды. Үзара аралашулар да сирәгәйде, тора-бара бөтенләй дә тукталды. Теге, автографлы кадерле программа хуҗасы сырхаулап, түшәккә үк егылды. Врачлар тиздән сәламәтләнәчәген әйтеп, аны юаттылар, әмма карчык үз хәлен үзе генә белә иде. Ул, стенада эленеп торган Ион Ионсонның фоторәсеменә моңсу карашын текәп, көннәр буе урында ятты. Күрше хатын кергәләп хәлен белешеп торды, аңа аш-су әзерләде, кибеттән кирәк-яракларын алып кайтып бирде. Әмма күршесенең зур бер кимчелеге бар иде: ул җыр турында да, Ион Ионсон турында да сөйләмәде, авыру үзе шул турыда сүз кузгатканда да, тизрәк бүтәнгә борып җибәрергә ашыкты.

Ә көннәрдән бер көнне һич көтмәгәндә Ион Ионсонның концертын уртасында бүлделәр. Йөрәкне сыздырып, бүлмәгә матәм музыкасы тулды. Диктор кайгылы тавыш белән Ион Ионсонның озакка сузылган каты авырудан соң вафат булуын белдерде, аның үлеме бөтен культура җәмәгатьчелеген тирән кайгыга салуын хәбәр итте. Кинәт карчыкның күз аллары караңгыланып китте, башы әйләнә башлады, хәле начарайды. Бераздан бу халәт узды, ләкин ул үзендә кыйнап ташланган кебек нык арыганлык, ватылу һәм әллә нинди битарафлык сизде. Шулай да ул Ион Ионсонның фоторәсеменә күтәрелеп карарлык һәм дога укырлык көч таба алды.

Ярый әле бераздан ахирәт дуслары килеп җитте. Ишектә алар күренгәч, авыру карчык җиңел сулап куйды. Алар үзара кайгы уртаклаштылар, Ион Ионсонның авыр туфрагы җиңел булуын теләделәр һәм архивтагы альбомга соңгы мәгълүматларны язарга утырдылар. Тирән һәм тантаналы тынлыкта атаклы җырчының, кабатланмас тавышлы артистның озакка сузылган каты авырудан соң вафат булуы, шунлыктан бөтен культура җәмәгатьчелегенең олы кайгы кичерүе турындагы сүзләрне теркәп куйды алар. Аннары ахирәтләре авыру хуҗабикәнең ятагы янына утырып, өстенә юрганын яхшылап яптылар, озак итеп кулларын сыйпап тордылар. Хәлбуки, алар бүген үзләре дә юатуга бик мохтаҗ иделәр.

Авыру күзләрен йомды, ул йоклап китте шикелле. Лимон сарысы иңгән йөзенә тынычлану галәмәте чыкты.

— Йоклыйсыңмы? — дип сорады ахирәтләре.

Әмма авыруның иреннәре кыймылдамады. Йөзе тыныч калды, гүя ки ул язмышында ни язылган булса, шуларның барысын да күреп-кичереп бетергән иде инде.

Бүген аның дөньядагы иң зур куанычы булган җыр бүләк итеп торучысы — Ион Ионсон мәңгелеккә киткән иде...

Шамил МАННАП тәрҗемәсе

# ПУБЛИЦИСТИКА

# ИЛ КАЛА, ХАЛЫК КАЛА...

*Мәгълүм булганча, бу айда без Татарстанның автономияле республика булып төзелүенә 70 ел тулуны билгеләп үтәбез. Газета-журналлар, гадәттә, мондый вакыйгалар уңаеннан, республика узган юл, ирешелгән уңышлар, ил байлыгына керткән өлеш турында җитәкчеләрнең чыгышын бастырып чыгара торган иде.*

*Без бу юлы башка алымны сайладык. СССР Югары Советы депутаты, күренекле драматургыбыз* ***ТУФАН МИҢНУЛЛИН,*** *редакция үтенече буенча, язучы* ***МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ*** *белән сөйләшеп, фикер алышып утырды. Укучыларыбыз игътибарына шул әңгәмәне тәкъдим итәбез.*

— *Туфан әфәнде, сез айлар буена парламент эшендә катнашып, бүгенге сәясәтнең утын-суын кичкән кеше. СССР Халык депутатлары яныннан нинди тәэсирләр белән кайттыгыз?*

— Әйдә, Марсель дус, без болай килешеп куйыйк. Син — сорау, мин җавап бирүче булып сөйләшмик. Илдә ниләр эшләнгән, СССР Югары Советында ни турында сүз барганын син миннән ким белмисең. Өстәвенә, син минем хөрмәт иткән язучыларның берсе. Бу сөйләшү интервью дип аталмыйча, ике язучының фикер алышуы булса, укучыларга да файдасы тияр. Әгәр дә мине «кабызып» җибәрү өчен кирәк икән, берәр мәкерле сорау әзерлә. Әмма ул сорауга синең үз җавабың да әзер торсын. Килештекме?

— Сез бит, Туфан әфәнде, «коеп куйган» язучы гына түгел, Халык депутаты да, шуңа күрә, тигез каланчадан торып кына сөйләшеп булмас... Үземне күптән борчып йөргән фикерне җиткерү өчен Салтыков-Щедрин сүзләреннән башлыйсы килә. «Гаепләне эзләү... нинди дә булса бер Ивашканы табып алып чиркәү манарасыннан ыргыту Россиядә гадәткә кергән...» — ди ул. Шулай... Без җитмеш ел буена йокымсыраган аңыбызны уятып, зур өметләр белән тагын югарыга төбәлдек. Ашыгабыз. Җәмгыятьнең бик күп тармакларында тиз генә үзгәрешләр булыр кебек. Гаепләне эзләүгә, тәнкыйтьләргә остарып киттек. Парламент эшенә, халык депутатларына карата негатив фикерләр матбугат битләрендә дә гадәткә әйләнде. Мин дә, бу шаукымга кушылып, сезнең СССР Халык депутатларының I съездында ясаган чыгышыгыздан ризасыз калган идем. Үзебезнең республика турында берничә генә сүз әйтүгә, башка республикаларга күчеп, аларның да мәнфәгатен кайгыртырга тырышу, перестраховка, бөтен халыкның да пәйгамбәре булырга тырышу сизелгән иде чыгышыгызда.

— Син Салтыков-Шедриннан мисал китерәсең. Мин Фатих Кәримебезне ярдәмгә чакырам: «Үзең турында уйлама, илең турында уйла»,— дигән ул. Әгәр дә үз халкыңның язмышы сине борчый икән, аңа ярдәм итәргә телисең икән, беркайчан да аны бүтәннәрдән аерып алып карарга кирәкми дип саныйм. Сталинның явызлыгы, валюнтаризм шаукымы, торгынлык еллары галәмәте бер татар халкына гына кагылмады. Халыкларны сортларга бүлеп бутадылар. Берәүләр аны ялгышлыктан дип атый. Мин махсус эшләнгән җинаять, дим. Дуслык дип кычкырдык кычкыруын, ләкин бергә, берберенне хөрмәт итеп яшәргә өйрәнмәдек. Киресенчә, дуслык дип шаулаганда күңелебез тулы ризасызлык иде. Уңны, сулны аермый башладык. Менә хәзер шушы буталчыклыктан бергәләп кенә чыга алабыз. Әгәр, Татарстан зуррак дәрәҗәгә лаек, дип тәкрарласам, икенче берәүнең, ә ни өчен Татарстан гына, дип әйтүе ихтималмы? Ихтимал. Ул хаклымы? Хаклы. Димәк Тукаебыз әйтмешли:

*Тигез булды законда,*
*Татар, урыс, япон да,—*

дигән хыялын тормышка ашыру өчен көрәшергә кирәктер.

*— Сезнең сүзләрдә хаклык бар анысы... Халыкларның сортларга бүленүе турында, ачынып, күптән инде әйтә килдегез. Ләкин, Туфан әфәнде, һәр регионның язмышын кайгырту өчен үз депутаты бар бит. Бәлки кайбер автономияләр үз статусларын үзгәртергә теләмиләрдер, әзер түгелләрдер? Башка автономияләр белән чагыштырганда безнең үзебезгә генә хас шактый аерымлыклар бар. Борынгыдан ук дәүләтле халык без. Промышленность потенциалы, экономик һәм мәдәни яктан да мәгънәле саннар белән чагыштырып карасаң, кайбер союздаш республикаларны да узып китәбез түгелме?! Аннары татар халкының күпчелеге республикадан читтә яшәвен дә онытмыйк. Матди һәм рухи яктан ныгысаң кына, без аларның кыерсытылган язмышын кайгырта алачакбыз. Эш атына әйләндерелгән татар, милли тыйнаклыкта йомылып калмасын дисәк, республиканың статусын күтәрү турында, тирәннән алып, нигезле итеп, зур форумда чыгасы иде.*

— Ә син моны белмиләр дип уйлыйсыңмы? Беләләр һәм ничек кенә беләләр әле. Әмма элегрәк, белгән хәлдә дә, шул системаны сакларга кирәк иде. Халыкларны бер-берсеннән өстен яки ким кую идарә итү өчен җиңелрәк дип санаганнардыр. Империалистик дәүләтләрнең: «Бүлгәлә һәм хакимлек ит!» дигән сәясәтенең дәвамы иде ул. Бүгенге көндә мондый сәясәтнең һәлакәткә алып баруын, ниһаять, аңлый башладылар. Ләкин барысын да кинәт үзгәртергә куркыбрак торалар шикелле. Чөнки, кабатлап әйтәм, проблема бик нык буталган, чияләнеп беткән. Шул төенне чишәргә кыюлык җитенкерәми. Теория мәсьәләсе дә йомшак. Моны озакка сузарга ярамаган кебек, артык кабаланырга да ярамыйдыр. Түземлеге соңгы чигенә килеп җиткән халыкларны сугыштырмаска иде. Милли мәсьәләдә бүген иң җитди проблема — шул.

*— Хокуклы дәүләт төзү, яңа законнар булдыру гаять катлаулы, җаваплы хезмәт икәнен әкренләп аңлый башладык. Халык парламент утырышларын телевизордан карап бара. Чыгышлар буенча депутатларга үзенең мөнәсәбәтен белдерә. Күз алдында көчле шәхесләр ачыла. Шунысын да әйтик: берәүләрне нинди акыл иясе! дип яратып кына өлгерәсең, икенче вакыт шактый каршылыклы чыгыш ясый да... кичәге солтан бүген олтанга әйләнеп кала. Парламент — чын мәгънәсендә өйрәнү мәктәбе, барысын да күтәргә була. Ләкин утырышларның экранга чыккан өлеше — өскорма гына икән.*

*Сез Мәскәүдә чакта, мин телефоннан шалтыратып караган идем, төнге уникенче яртыда гына «тота» алдым. Арыгыз тавышыгыздан ук сизелә иде. «Комиссия утырышыннан «талашып» чыктым» — дидегез. Менә шул бәхәсләрегезнең безгә күренмәгән кайнап торган учагы — комиссияләрнең «кара эше» турында бераз мәгълүмат бирсәгез иде.*

— Телевизор тәрәзәсеннән безнең эшнең бик азы гына күренә. Төп эшләр хәзер комитет, комиссия утырышларында хәл кылына. Бөтен законнарның да проектларын сессия утырышларына комитет, комиссияләр әзерли. Мин үзем — мәдәният, тел, традицияләр, тарихи мирасны саклау комиссиясендә. Безнең җитәкчебез — Чыңгыз Айтматов. Без, мәсәлән, тел турындагы законның проектын әзерләдек. Экспертлар тәкъдим иткән берничә вариантны кире кагарга туры килде. Бәхәсләр вакыты-вакыты белән бик нык кызды. Тел турында СССР күләмендәге закон кирәкми, диючеләр дә бар. Мин, кирәк диючеләр ягында булып, ни өчен кирәклеген исбатларга тырышып, әллә ничә тапкыр чыктым. Соңгы берничә дистә ел эчендә милли телләргә ясалган һөҗүмнән закон нигезендә генә сакланып була, дидем. Милли һәм интернациональ бюрократлар, чиновниклар кешелек законнарын аңларлык дәрәҗәдә түгелләр. Шуңа күрә без дәүләт тарафыннан чыгарылган махсус законга мохтаҗ, дидем.

Аннан соң, бүтән комитет-комиссияләр әзерләгән закон проектлары да безнең комиссия аша уза. Моңарчы закон чыгару процессында мәсьәләнең юридик ягы, социаль, политик, экономикага бәйле яклары тикшерелсә дә, әхлак ягы еш кына читтә кала бирә. Без шул якка игътибарны юнәлтәбез.

Инде дә килеп автономияләр проблемасы бар бит әле. Закон проектларын кулга алган саен безнең хокукларның юк икәнен күрәбез. Хакыбызны даулыйбыз. Мәсәлән, милек, җир турындагы безнең киләчәгебезне хәл итә торган закон проектларында автономияләр җирдән, судан мәхрүм ителгәннәр иде. Без, автономияләрдән сайланган депутатлар, моңа кискен каршы чыгып, бу гаделсезлекне төзәттергән идек. Сессия утырышында безгә каршы чыгучылар булды. Тавыш биргәндә безнең вариант үтмәде. Шулай да матбугатта, тикшерү өчен, автономияләрнең фикерләре шактый исәпкә алынган нөсхә басылды. Әмма яңадан Мәскәүгә комиссия утырышына килүгә, «автономияле егетләр» әйтә: закон проектыннан безне тагын сызып ташлаганнар, диләр. Күрәсеңме, нинди каршылыклы көрәш бара. Һәм ул бик кискен. Журналның бу саны чыккан вакытта бәлки күп нәрсәләр хәл ителгән булыр. Әмма бүгенгә өмет зур түгел. Союздаш республикалар үз мәшәкатьләре белән мәшгуль. Безнең зарны бик үк ишетергә теләмиләр. Әлеге дә баягы — һәркем юрганны үзенә тарта.

Без инде автономияле депутатларның группасын төзергә мәҗбүр булдык. Мин ул группаның совет члены. Без хәзер үз таләпләребезне шул группа исеменнән дә куячакбыз.

Янә килеп, Югары Советта махсус оештырылган комиссияләр эшли. Мин — совет немецларының автономияле республикасын яңадан кайтару комиссиясендә. Ул да шактый катлаулы эш. Дөресен әйтергә кирәк, үзләренең туган җирләреннән куылган Идел буе немецларын да, шулай ук кырым татарларын да үз җирләрендә кочак җәеп каршы алырга җыенмыйлар...

*— Сезне без электән үк туры сүзле, уйлаганын көчле тавыш белән ярып сала торган шәхес дип белә идек. Законнарны гамәлгә ашырганда депутаттан кыюлык соралган бәхәс-киңәшмәләрдә йомылып калмавыгызга да ышанабыз. Чыңгыз Айтматов, Давид Кугелтдинов һәм милләтләр палатасындагы башка депутатлар каршында да абруегыз зур.*

*Рус шагыйре Дудин безнең әдипләрне күргәч, Хәсән Туфанны искә алып: «Саклагыз Туфанны!» — дип әйтә торган булган. Бу хикмәтле сүзне сезгә карата да кулланырга буладыр дип уйлыйм.*

— Шаярып, «салпы якка салам кыстырып» әйтсәң дә, бу сүзләрне мин җитди кабул итәм. Мәсьәлә минем яки бүтән берәүнең шәхесендә генә түгел. Гомумән, кешенең кадерен белү безнең табигый халәтебез булырга тиеш. Чөнки һәрбер кеше — бу дөньяда бер генә. Әгәр дә инде теге яки бу шәхескә җаваплы эш тә ышанып тапшырганбыз икән, аны сакларга да, якларга да, иң әһәмиятлесе, аңа ышанырга кирәктер. Гел төрткәләп торсалар, күңел бик тиз сүрелә. Чынлап әйтәм, депутат эше бүген гаять авыр, үтә җаваплы. Физик һәм рухи көчне күп таләп итә. Мин үзем, шәхсән, ярдәмгә бик мохтаҗ. Эшлекле киңәшләргә мохтаҗ. Югары Совет сессияләренең утырышларында күтәрелгән мәсьәләләрне тикшергәндә әзерлек тә җитеп бетми. Ялгышуым да ихтимал. Шуңа күрә, ялгышымны эләктереп алып, мине талкыганчы шул ялгышны киләчәктә кабатламаслык киңәш бирсәләр, аларны игътибар белән тыңлап, рәхмәтле булыр идем.

*— Депутат үзенең сайлаучыларына, халыкка таянып эш итә. Элекке елларда сайлаучылар үз депутатларына бары тик шәхси үтенеч белән генә мөрәҗәгать итәләр иде. Ләкин бүгенге көндә җәмгыятьнең нигезен кузгатып, һәртөрле законнар чыгарганда сайлаучылар да дәүләти масштабта фикер йөртергә тиештер бит. Сезнең шундый таянычыгыз бармы?*

— Бу мәсьәләдә мин үзем синең фикереңне ишетәсем килә. Кемнәр ул безнең сайлаучыларыбыз?

*— Сайлаучы дигәндә мин үзебезнең милләтне күз алдында тотам. Шулайдыр, ваграк мәсьәләләр белән күбрәк мөрәҗәгать итәләрдер. Ваграк дию дә дөрес үк булмас. Һәммә кешенең дә әйбәт яшисе килә. Аяк киемең кысса, йолдызларга карап хозурлана алмыйсың. Тукай әйткән «Кая барабыз?» дигән сорауны кемнәр генә бирми хәзер?! Миһербанлык, шәфкатьлелек кебек асыл сыйфатлар әдәби төшенчәгә генә әйләнеп калды. Без, Сталин чорыннан башлап, бүгенге көнгә кадәр халыкны идеаллаштырып килдек. Аерым алганда, бер кеше дә фәрештә түгел, бәс, шулай булгач, бергә тупланып, халык массасына әверелгәч кенә, нишләп идеалга әверелә соң әле ул? Үз телен, тарихын, горурлыгын җуйган халык зур була алмый. Дәүләтле халыкларның гына киләчәге бар! Чиксез киңлекләргә сибелгән, рухи изелгән газиз халкымны артык яратканга күрә, вак мәшәкатьләреңнән арын да, як-ягыңа уйланып күз сал бер! Ил табынында бүтән халыклар лаеклы урын яулаган чакта, син дә кыю фикереңне әйт, таләп ит, бичара! дип тупас эндәшәсе дә килә кайчагында. Мин аңлыйм: гел киләчәк белән алданып түгел, бүген дә рәтле итеп яшисе килә. Кая карама — хуҗасызлык, мең төрле каршылык тулып ята. Ярдәм сорап депутатка килүләре гаҗәп түгел. Шулай да...*

— Әйе, шулай да...

Мине сигез район халкы сайлады. Миннән күп нәрсәне өмет итеп сайладылар. Язучының сүзе үтә, бәлки аны ишетерләр, утын эзләп интеккән, изаланган авыл халкын газлы итәрләр, юл юклыктан язын-көзен җәфа чиккән авыл халкын юллы итәрләр, дип өметләнделәр. Маңгай тирен түгеп эшләп алган акчасына сатып алырлык товар кайтартырлар авылга, дип сайладылар. Сайлаучыларның өметен акларга тырышам. Әллә ни эш кыра алмыйм — шунысы җанны көйдерә. Илнең хәле бигрәк мөшкел шул.

Ләкин мине депутат итеп сайлаучылар җиргә карап йөреп кенә күктәге йолдызларны оныткан халык түгел. Алар миннән халкыбыз язмышы, аның теле, мәдәнияте, киләчәге турында уйлавымны да таләп итәләр. Рәхмәт аларга. Әмма мин тагын да күбрәкне өмет итәм. Минем сайлаучылар гына түгел, бөтен бер халыкның — милли үзаңы нык үскән халыкның вәкиле буласы килә. Мин үзебезнең халыкка тел-теш тидерергә җыенмыйм. Тарихның сикәлтәле юлларында үзенең йөзен саклап калган халык ул.

Талантлы, тырыш халык. Әмма шулай да... «Нәрсәгә кирәк ул татар теле?» — дип әйтүчеләребез азрак булсын иде. Бүгенге көндә халкыбызның биштән бере үз телен туган тел дип атамый. Нишләдек без, җәмәгать? дип уйланып алсак иде. Ваемсызлыктан тизрәк арынасы иде!

*— Милләтләр Советының председатель урынбасары итеп сезнең кандидатура тәкъдим ителгәч, сөенеп куйган идек. Дәрәҗәле урын. Президиум биеклегеннән торып, халыклар өчен күп нәрсәләр эшләргә була. Бу постта сез үзегез үк күтәргән проблемаларны җиңелрәк хәл итәр идегез кебек. Шушы сирәк килә торган форсаттан файдаланмавыгызны мин аңлап бетермәдем.*

— Мин үзем дә аңламый калдым. Беренчедән, бу минем өчен көтелмәгән нәрсә булды. Ә без, авыл малайлары үзең беләсең, андый чакта югалыбрак калабыз. Гәрчә Өлкәннәр Советында чыгыш ясап, ике палата председательләренең урынбасарларыннан берәү автономияле республикадан булырга тиеш, дип үзем әйткән идем. Һәм менә шул мөмкинчелек тугач...

Беләсеңме, мондый вакытта эчке сиземләү хәрәкәткә килә. Минем дә шул көч миңа әйтеп куйды кебек: «Син саескан түгел, һәр ялтыраган нәрсәгә кинәт ташланма, үз кадереңне үзең бел»,— диде. Һәм мин хәзер уйлап торам да дөрес эшләдем дигән нәтиҗәгә киләм. Миңа, мактанып әйтә димә, зинһар, шуннан соң күпләрнең хөрмәте артты шикелле.

*— Татарстанда 70 ел эчендә су астында һәм гигант заводлар астында калган үле җирләрне хисапласаң, йөз меңнәрчә гектар җыела. Димәк, без Европаның уртакул зурлыктагы бер дәүләте кадәр мәйданыбызны, Атлантида кебек, яшәүдән туктатканбыз. Моның экологик нәтиҗәләре торган саен безне каһәрләячәк әле.*

*Язучыларның партия җыелышында «Камгэсэнергострой» турында борчулы фикерләр әйтелде. Чынлап та, бу галәмәт зур төзелеш оешмасына туктаусыз эш фронты кирәк. Аның җитәкчеләренә олы күрсәткечләр, орден-медальләр яулап алу кирәк. Шушы оешма аркасында Алабуга гиганты, АЭС төзелә башлады. Һәр олы төзелеш компаниячелеккә кайтып кала. «Дөньяда иң зур!» — дип күпме ачык авызлар мактанып йөри. Заводлар төзелә тора, ә кибетләрдә адәм баласына кирәкле әйберләр артамы? Юк бит! КамАЗ һаман җәелә бара, уңдырышлы иген кырларына басып керә, авылларны сыта, туктарга исәбе дә юк. Әгәр «Камгэсэнергострой»га мөмкинлек бирсәң, гигант заводлар белән ул бөтен республиканы капларга әзер. Корьәндә әйтелгән кызыл балчыкка кадәр ашап баручы Әәҗүҗ-Мәәҗүҗ мифик җанвар түгел, шушындый хәтәр заводлар булып чыга түгелме?! Гарип балалар туууга китергән, гарасатлы төтеннәре ургылып торган Түбән Каманың химия заводлары янында аударылган агачлар, рәхимсез актарылып ташланган җирләрне күргәч, мин моңа ачык төшендем.*

*Ә эшчеләргә барыбер, шундый бер анекдот бар иде бит әле: кешеләрне җыеп, иртәгәдән сезне тезеп куябыз да һәрбер уынчы кешене аса башлыйбыз, диләр. Бер каршылык юк. «Бауны профсоюз бүлеп бирәме, әллә үзебез алып килимке? — дип сорый, имеш, тыңлаучан кавем. АЭС мисалында күрдек без моны: бер кило шикәр арттырып бирсәң, «льгота» хакына коне-төне үзенә кабер казырга да ризалар.*

*Гигантомания дәүләт көчен, престижын арттыру өчен генә икәненә, җирле халык мәнфәгатен кайгыртып эшләнмәгәненә инана барабыз. «Камгэсэнергострой»ның аппетитын туктатып, кешегә кирәкле төзелешләргә күчерүне депутатлар кичекмәстән кузгатырга тиеш. Сез, Туфан әфәнде, ТАССРның Югары Советы депутаты да идегез бит әле. Сез, шушы катлаулы проблемалар тулып яткан чорда, яңа сайланган депутатларга, үз тәҗрибәгездән чыгып, нинди киңәшләр бирер идегез?*

— Синең бу сүзләреңә өстәп ни әйтим икән?

Республикабызның иң шәп болыннарын су бастырып, җир-суларыбызны нефть белән пычраттык. Басуларыбызны әче төтен өрдереп торучы завод-гигантлар басты. Бу үзе бер куркыныч хәл булса, шуның бәрабәренә нәрсә алдык дип тә сора син. Шымытыр. Барысы да диярлек читкә китеп бара. Безгә пычрагы, газы гына кала. Торырга өйләребез, йөрергә юлларыбыз, ягарга газыбыз җитми.

Безгә, депутатларга, хәбәрдарлык чорында «Камгэсэнергострой» кебек «аждаһа»ларның безнең җиребездә ни белән шөгыльләнгәннәрен төгәл белергә, һәрвакыт уяу булырга кирәк. Югыйсә, аларга торак йортлар төзү файдасыз, алар төп табышларын, һәм билгеле, дан-премияләрне промышленность объектлары төзегән өчен алалар.

Республика депутатлары республикага, район авыл Советы депутатлары районавылларның төп хуҗалары булсыннар иде! Конституция тарафыннан бирелгән властьны тулысынча файдалансыннар иде! Аның өчен күп белергә, нык әзерләнергә, чын мәгънәсендә фидакарь шәхес булырга кирәк.

Гражданин булган кеше, шәхес булган кеше вакытлы данга, яки тәтигә кызыгып, үзенә-үзе чокыр казымый инде ул.

*— Балтик буе республикаларының югары культуралы депутататлары съезд һәм парламент эшенә тон бирә. Аларның дәүләт һәм партия җитәкчеләре дә революцион хәрәкәтнең алгы сызыгында. Аларның үз җире-суы, үз халкы турында кайгыртканнары һәр чыгышта сизелеп тора. Бездә исә һаман торгынлык... Союз статусын таләп итү турында сүз купса, йомып калдырырга тырышу сизелә. Имеш, статус кына хәл итми, региональ үзисәпләүгә күчүдә бөтен хикмәт. Имеш, союздаш республикаларның да проблемасы баштан ашкан. Шулай... Берәү чабатасын ямарга азаплана, икенче берәү хром итегенә шпорлар кую турында хыяллана — һәр икесенең дә үз проблемасы бар...*

*Республиканың җитмеш еллык яшәү дәверендә без кайчандыр татар укытучыларыннан сабак алган, сәнгать һәм дәүләт эшлеклеләребездән өйрәнгән Урта Азия республикаларыннан да артта калдык. Илгә фантастик суммалык миллиардлаган тонна нефть тапшырган Татарстан болай, икенче сортлы булып яшәргә тиеш идеме?! Бездә яшәүче күп кенә руслар (бу депутатлар арасында да шулай) союздашлык статусы мәсьәләсенә сагаеп карый. Сүз бит югыйсә аерым бер татар милләте турында гына бармый, барыбызның да яшәеш шартларын яхшырту турында бара. Бу очракта инде рус халкының бөеклеген, киң күңеллелеген еш әйтелгән сүздә генә түгел, ә гамәлдә күрәсе килә.*

*Күрше Башкортстанда союздаш республика статусы мәсьәләсендә хәл итү өчен махсус комиссия төзелү хәбәре безне дә ашыктырырга тиеш түгелме?! Республиканың Югары Советы сессиясендәге чыгышыгызда Сез, Туфан әфәнде, бу хакта кискен сүзегезне әйтә алмадыгыз...*

— Әйе, әйтә алмадым шул. Күңелемдә син биргән сорауларны йөртеп тә, әйтергә җыенып та әйтә алмадым. Беләсеңме, сәбәбе нәрсәдә? Нигә әле бу Туфан Миңнуллин чәчри дә чыга, чәчри дә чыга, дип әйтүләреннән шикләндем. Ә шикләнергә сәбәпләр бар, анысын беләсең. Шул ук депутатлар арасында күпмесе милләт язмышы белән борчылып, тел, милли мәдәният, статус дип янып-көеп йөри? Татарстаннан сайланган СССР Югары Советы депутатлары арасыннан күпмесен шушы мәсьәләләр борчый? Бөтен милләт язмышы турында сөйләү һәм көрәшү дә берничә депутат өстенә генә өелгәч, көчкә килә башлый. Тыныч акыл белән сөйлисе, хакыңны даулыйсы урынга кычкырырга тотынасың. Әрнүгә чыдый алмаган кешеләр кычкыра бит ул.

Бик дөрес, без шактый әкрен кыймылдыйбыз. Башкортстанда оешкан комиссия хакында сүз кузгаткач, бер җитәкче иптәшебез: «Ярыш оештырырга, бу Сабан туе түгел»,— диде. Әлбәттә түгел, ярыш кирәкмидер, әмма дегет чиләге шикелле, арба артында селкенеп бару да безнең республикага килешми. Әнә тагын бер хәбәр укыдык: Башкортстанда киностудия төзү турында карар кабул ителгән. Без ничәмә еллар буена шул турыда сөйләп тә сүзләребез коры сүз генә булып кала бирә. Ул хакта дәшмәдегез, дип мине һәм башка язучыларны берәү дә гаепли алмыйдыр. Әкрен кыймылдыйбыз. Эшләгән эшләребез дә юк түгел. Яшьләр һәм сабыйлар өчен журналлар чыга башлады, тел турында закон проекты булдырылды. Тик бүген болар аз. Безгә күп нәрсәләрне тамырдан үзгәртергә кирәк. Моның өчен партия, совет, хуҗалык җитәкчеләреннән һәм барыбыздан да фидакарьлек, егетлек сорала. Милләтчелек өрәгеннән куркып күпме яшәргә мөмкин?! Милләтчелектән милли горурлык, милли үзаңны аера алмый интегәбез. Кемдер берәү: «Милләтчелек исе килә»,— дигәнгә йөрәгебез алына. Кем белә: бәлки ул иптәштән шовинизм исе киләдер... Яшерен-батырын түгел бит, без — автономияле республикалар арасында үзенең экономик җегәре, мәдәни бай традицияләре белән аерылып торган республика. Безгә татар халкының читтә яшәүче дүрттән өч өлеше өмет белән карап тора. Күп республикалар да безгә карап эш йөртә. Шушы җаваплылыкны онытмаска иде дә бит...

Безнең җитәкчеләр союздаш республикалар дәрәҗәсенә экономик юл, ягъни региональ хуҗалык исәбе, үзфинанслау юлы белән ирешергә телиләр. Бу — үз-үзеңне алдау. Әгәр республиканың статусы политик юл белән тәгаенләнмәсә, өстәгеләр экономик исәп-хисаплар белән генә санашып тормый. «Сезгә анысы билгеләнмәгән!» ... дип элек ничек әйтсәләр, киләчәктә дә шулай диячәкләр. Безгә политик статустан башка юл юк. Калганнары вакытлыча юату гына...

*— Илдә барган зур төзелешләрдәме, кырыс себер якларындамы — кайда гына булмасын, татар, беренчеләрдән булып, хәтәр җирләргә омтыла. Көтелмәгән фаҗигалар булса да (Әйтик: Чернобыль, Әрмәнстандагы җир тетрәү һ. б.) безнең милләттәшләр, үз-үзен аямыйча, ярдәмгә ашыга. Бөек Ватан сугышында безнең якташлар күрсәткән батырлыклар турында да маршал һәм генералларның лаек бәһасен беләбез. Революциягә кадәрге объектив тарихчыларның хезмәтләрендә, елъязмаларда да Россия дәүләтен ныгытуда безнең халык күрсәткән каһарманлык ачык чагыла.*

*Бу — шулай. Ә менә инде бүгенге көндә, тыныч тормышта киресенчә, безнең сораутеләкләр, матди һәм рухи ихтыяҗларга караган мәсьәләләр арткы планга күчә. Хәт-*

*та бу Югары Советка депутатлар сайлаганда да сизелде. Республика депутатларының милли составын карасаң, безнең файдага сөйләми. Без илдә, сан ягыннан, җиде миллионга якын дибез. Башка өлкәләрдән сайланган депутатлар арасында татарлар бармы?*

— Депутатлар арасында татар милләтеннән булганнары 24 әү. Шуларның унөче Татарстаннан, 5 се Башкортстаннан, Икесе Ульяновск өлкәсеннән. Калганнары башка төбәкләрдән сайланганнар. Күпме бу, азмы? Әлбәттә, халык саны белән чагыштырып караганда бик аз. Дүрт миллион грузин халкының, мәсәлән, Югары Советта 70 депутаты бар.

Әгәр дә инде бу хәлне тирәннән, төрле яклап анализласаң, күңелсез нәтиҗәләр ясарга мөмкин. Гаделсезлек, гаделсезлек, гаделсезлек... Һәм ул гаделсезлек бер татар халкына гына кагылмый. Әлеге дә баягы милли политиканы өр-яңадан карап чыгарга кирәк безгә. Сиплап кенә булмый. Нигезеннән үк өр-яңадан, һәрбер халыкны, иң аз санлы милләтне дә күздән ычкындырмыйча карап чыгарга! Югыйсә, халыклар дуслыгы «нығытыр» өчен безгә һәрвакытта да гаскәр кирәк булачак.

Хөрмәтле язучыбыз Миргазиян Юнысның «Казан утлары»нда (3 сан 1990 ел) дөнья күргән «Телсезләнү: тамыры һәм җимешләре» исемле публицистик мәкаләсе тирән мәгънәле, һәрберебезне дә уйландырырлык язма. Аның үтә җитдилеген искә алып, бер урының ачыклый төшәсе бар дип саныйм.

Минем Мәскәү радиосы аша чыгышымны уңай бәяләве өчен авторга рәхмәт. Ә инде «Руслар белән мәңге дуслык!» — дип «кычкыруыма» килгәндә, аны шаблон дип атавы белән килешә алмыйм. Мин зур мәдәниятле, тәрбияле халыкның баласы буларак, һәр халык белән, шул исәптән рус иптәшләр белән дә бары тик дустанә мөнәсәбәттә генә яшәү ягында. Ул мөнәсәбәт минем өчен шаблон лозунг түгел, ә яшәү нормасы. Әгәр дә кемнәрдер: «Татарлар белән дуслык мәңге яшәсен!» — дип әйтмиләр икән, аңа мин үземне гаепле санамыйм. Димәк, ул сүзләрне әйтергә теләмәүчеләрнең рухи тәрбиясе, цивилизация дәрәҗәсе чамалы.

— *Язучы Туфан Миңнуллин белән депутат Туфан Миңнуллин арасында каршылыклар чыкмыймы?*

— Чыкмый димени, Марсель дус!? Без бит йөрәк белән уйлаучылар, дөньяны образлар аша күрәбез. Ә монда чыкылдап торган чынбарлык. Закон статьялары, пунктлар, параграфлар. Кайвакытта, нигә кешегә шул чаклы закон, законнар язмыйча да матур итеп, гөрләшеп яшәп була бит, дип уйлыйсың. Ни дисәң дә, закон кешене аерым кысаларда тотар өчен чыгарыла. Кеше үзе чыгарган законнардан өстен булырга тиеш ләбаса. Юк шул, кеше — катлаулы җан иясе. Шуңа күрә, үзебезне үзебездән саклар өчен кануннар уйлыйбыз. Закон чыгару гына җитмәгән, кеше шул закон нигезендә берсен-берсе төрмәгә яба, үлем җәзасына хөкем итә. Чынбарлык аяусыз. Яхшылык һәм явызлык янәшә атлый. Яхшылыкны явызлыктан саклар өчен законнар кирәк, статьялар, пунктлар, параграфлар кирәк. Иҗатка дигән көч шуңа сарыф ителә. Язасы килә. Гомер үтә. Тик мин үкенмим. Бүгенге эшем милләткә кирәгрәк дигән юаныч белән яшим. Чөнки, яшерен-батырын түгел, милләт бүген үз улларының фидакарьлегенә аеруча мохтаҗ. Бәлки ялгышамдыр? Бәлки бу үз-үзеңне алдаудыр? Син — тормышның иҗатка, халыкка иҗатың белән хезмәт итүгә багышлаган кеше, үзең ничек уйлыйсың?

— *Җитәкчелек итү эшенә, кеше нигезендә, ике тармак буйлап үстерелә. Беренчесе — партия линиясеннән, баскычтан-баскычка күтәрелү билгеле бер лабиринт буйлап бара иде. Икенчесе — технарьлар юлы. Хәтерлибез бит: кеше җанына кагылмый торган докладларда капрон тел барлыкка килде. Тимер чыңы әле дә колак төбендә яңгыравын җуймаган. Җитмәсә, ул чиксез докладларга, башкаларны әйткән дә юк, рус үзе дә аңламый торган чит сүзләр кереп тулды. Ялганны яшерү томаны кебек. Җитәкчеләрдә, әнә шулай итеп, җылы кешелекле тел бетте. Ни хикмәтле телгә ия авыл агайларына кадәр «яңа үрләр яулыйбыз» дип сөйли башлады бит. Тел хасияте күп нәрсә турында сөйли... Нәтиҗәдә, табигатькә һәм кешегә карата рәхимсез, дан һәм план артыннан куучы, үз балаларының киләчәге турында уйлап та карамаучы технократик җитәкчеләр кавеме барлыкка килде. Бу чиру кылган явызлыкларны төзәтергә бик күп еллар кирәк булачак.*

*Япониядә, инженер-техник хезмәткәрләрне әзерләгәндә, аларга әдәбият-сәнгать белеме дә укытыла икән. Әдәбият-сәнгатьнең матурлыгын тойган шәхес кеше җанын да аңлый белә, диләр акыллы японнар.*

*Ниһаять, без дә хәзер кешегә борыла башладык. Россиядә әдәбият-сәнгать әһелләре дәүләт системасы белән гомер-гомергә капма-каршылыкта яшәгән дигән тар карашган бүгенге көндә арыну бара. Күрәбез: иҗат кешеләрен, галимнәрне дәүләт эшенә тарту башланды. Безнең республикада да, башка регионнарда да шулай. Шөкер, дөнья җылына бара.*

— Күз тимәсен! — диик.

— *Сез — берничә дистә ел буена татар сәхнәсен тотып торган танылган драматур-*

*гыбыз. Илнең кайсы тарафына барып чыкма, иҗатыгызны яхшы беләләр. Язучы-эдипләр арасында шундый сүз йөри: «Иң шәп әсәр — әлегә язылмаган әсәр» — диләр. Иҗат кешесен әнә шундый матур хыял яшәтәдер, мөгаен. Ләкин мин сезнең бай иҗади хезмәтегез арасында, аерым бер урын алып торган, чын мәгънәсендә классик булып саналырга хаклы «Әлдермештән Әлмәндәр» исемле моңсу комедиягезне хәтергә төшерәсе килә. Әлдермеш карт — халкыбызның үлемсез рухы — моңландыра да, елмайта да, елата да торган гаҗәп милли образ. Сез ул әсәрегезне илле яшькә җиткәнче үк яздыгыз. Бу — бер яктан караганда, бәхет тә, икенче яктан караганда, бәхетсезлек тә түгелме? Таләпчән тамашачы бит сезнең һәрбер яңа әсәрегезгә шул пьеса биеклегеннән карап бәя бирәчәк. Холкыгызны яхшы белгәнгә, минем иң шәп әсәрем язылды инде, дип әйтергә җыенмавыгызны да сизәм. Тулаем иҗатыгыздан аерым алып, әнә шул әсәрегезгә соклану белдергәндә, хөрмәтле Әлдермешкә бармак яныйсыгыз килмиме?*

— Безнең авылда бер малай беренче класста «А» хәрефен өйрәнеп кайткан да, хәзер кирәгең калмады инде, дип «Әлифба»сын ябып торган мичкә аткан. Ни хикмәттер, шул малай беренче класста бишме, алтымы ел утырган да, мәктәптән куып чыгарганнар...

Рәхмәт мактавыңа. Тик син «Әлдермештән Әлмәндәр»не күккә чөеп, бүтәннәрен бераз кимсеттең шикелле. Минем өчен алар барысы да кадерле, барысы да — минем күңелемнең җимешләре.

Исәнлек-саулык булса, язарга әле исәп. Бәя бирү минем эш түгел. Мин бер нәрсәне ышандырып әйтә алам: язганнарымның элеккеләре дә ихлас күңелдән язылган иде, язылаcылары да алла боерса, шулай булыр. Җае туры килгәндә әйтеп калыйм, элек язганнарымның берсе өчен дә бүген оялмыйм, чөнки кемгәдер ошарга тырышып язмадым, конъюнктурага сатылмаска тырыштым.

— *Ил узган тарих бөтенләй башка яктан ачылгач, шаккатып* калдык. *Башка сыйдырырлык түгел. Коточкыч информация каршында акыл-гамь көчсез кала. Элегрәк язылган бик күп әсәрләр дә шушы фонда тоныкланып китте шикелле. Безнең чор теориясе әдәбият-сәнгатьтә ялган оптимизм рухын сугарырга тырышты. Борын-борыннан килгән әдәбиятның төбендә олы мәгънәдә трагедия ятканын беләбез югыйсә. Күз алдына китерик: Сак белән Сок кавыштылар ди. Бу гаҗәеп бәетне гасырлар буена моңланып укырлар иде микән? Ромео белән Джульетта, бәхетле картлыкка җитсә, бу әсәр мәхәббәт символына әверелер иде микән? Аларның каберенә әле дә дөньяның күп якларыннан хатлар язалар. Үзебезнең «Галиябану»ны алыйк: Хәлил белән Исмәгыйль килештеләр дә, Галиябану Хәлилгә кияүгә чыкты, ди...*

*Трагик әсәр кеше җанын йомшарта, шәфкать, мәрхәмәт уята. Ә тормышыбызда сындырылган күпме язмышлар. Утызынчы елларга ук чигенмик, әле күптән түгел генә дә илгә игелек кылырга теләгән күпме талантлар харап ителгән. Сез әсәрләрегездә тормышның өстә ятмаган киеренке хәлләрен оста тотып алгансыз икән. Ләкин... арттырып әйтсәк, Шекспирга бер адым кала дигәндә, курыккан шикелле тукталып, бәхетле азак белән тәмамлаган драмаларыгыз күбрәк...*

— «Бәхетле финал» ул минем, әгәр шулай әйтергә ярася, эстетик принцибым. Тормыш болай да авыр, үз әсәрләребез белән кешегә ярдәм итәргә тиеш дип саныйм мин. Бәлки ул наив караштыр, әмма шулай. Фаҗигале, өметсез финаллы әсәрләрне укысам, яшисе килми башлый. Кешедә, киләчәктә яшәр өчен, өмет калдырырга кирәктер. Караңгыны караклар гына ярата. Кара син бүгенге фильмнарны: талаш, ызгыш, суеш, фәхишәлек, наркомания... Әлбәттә, тормышта барысы да бар. Әмма сафлык та бар дөньяда, мәрхәмәт тә бар. Дөньяны шул яшәтә. Өметегезне өзмәгез, кешеләр, дип әсәр ахырында әйтеп кую начармыни?! Мин бу фикеремне берәүгә дә көчләп такмыйм, мин әйткән генә дөрес димим. Күңелем кушканны шулай язам. Торгынлык елларының басымы астында уңышсызрак тәмамлаган әсәрем — «Дуслар җыелган җирдә». Анда миңа әйтәсе сүземне әйтеп бетерергә ирек бирмәделәр. Ләкин аны бүген төзәтергә җыенмыйм. Ничек язылган, шулай калсын. Югыйсә әсәрләрендәге Сталин, Хрущев, Брежнев исемнәрен сызып ташлап, тәти булып калырга тырышучылар күренә башлады.

— *Дөнья кайный, ил кайный. Тетрәндергеч вакыйгалар булып ала. Без дистә ел буе менә-менә иртәгә атом сугышы чыгарга мөмкин дип, авыр шом астында яшәдек. Шөкер, аңысыннан котылып кына барабыз дигәндә, таш булып иңнәребезне тагын шом басты. Тормышыбызда бик күп билгесезлекләр. Шушындый чакта язучыларның публицистикага тотынуы да аңлашыла. Нилэр булыр? Нилэр кыла алырбыз? дигән мең сораулы билгесезлек һәр язучының йөрәге аша уза. Мәскәүнең күз яшьләренә ышанмавын белсәк тә, барыбыз да өмет белән башкалага төбәлгәнбез. Сезнең эш даирәгез шунда, могтәбәр шәхесләр арасында, үзәктә. Сез без белмәгән бик күп яңалыклар чолганышында яшисез.*

— Шу-ла-ай... Катлаулы заманда яшибез. Һәркем акыллы фикер әйтә. Ләкин төп

юнәлешне тәгәл күрсәтүче, кызганычка каршы, юк. Бу — табигый. Чөнки без үзебезне табигатьтән өстен санап, табигать законнарына каршы барып, җиребезне, суыбызны, һавабызны пычраткан шикелле, кешелекнең үсеш законнары белән дә исәпләшмәдек ахры. Идея коллары булдык сыман. Иң изге ният, иң якты хыял да, дөнья кануннарына таянмаса, утопия булып кына кала. Килер заман, без яшәгән елларга бәя бирүчеләр табылыр. Бәлки безгә шактый ук авыр сүзләр дә әйтерләр. Менә без синең белән синең өеңдә сөйләшеп утырабыз. Вакыт-вакыт икебез дә уйларыбызга чумып, дәшми калабыз. Мин, беләсеңме, нәрсә уйлап куйдым әле. Әгәр безнең сөйләшү ташка басылып калса, кайчандыр, кемнәрдер, бәлки укырлар. Бәлки безнең сөйләшүебездән көләр дә ул киләчәк кешесе. Бигрәк юк нәрсәләрне проблема итеп сөйләшкәннәр, дияр. Ләкин, нишләтәсең, без бит-шушы заман кешеләре. Заманның килеп җитмәгән яклары бездә дә чагыла. «Җаныңның вaклыгын сылтама заманга!» — дигән шагыйрь. Безгә, киләчәк алдында бик үк гаепле булып калмас өчен, җаныбызны вакламаска, намус, вөҗданыбызны саф килеш сакларга кирәк. Дөнья бизәкләренә артык алданмыйча, мәңгелек турында уйлансак, иманыбыздан язмабыздыр, кыйбланы югалтмабыздыр. Бүген адәм баласына иң кирәкле сыйфат — кыйблаңны югалтмау.

*— Тормыш үзенекен итә. Нинди авыр чакларда да бәйрәмнәр барын онытмый халык. Менә без Идел-йорт дип йөрткән, туган республикабыз Татарстанның 70 еллык юбилеена җиттек. Җитмеш ел азмы ул, күпме ул? Тарих өчен, әлбәттә, мизгел генә. Ләкин борылып карасаң, бер кеше гомеренә тиң шушы еллар эчендә нинди бай-катлаулы гомер кичкәнбез. Вакыйгалары белән гасырга тиң вакыт. Без бу бәйрәмне, элеккечә, фанфаралар уйнатып, мактанчык саннардан фейерверклар чөеп кенә уздыра алмыйбыз. Җиремсуым ни хәлдә, халкымның киләчәген ни көтә — әнә шулай үткәннәрне, бүгенгене, киләчәкне уйлап, олы гамь белән яшибез без бу көннәрдә. Кайда гына булмасын, йөз аклыгын саклаган, яуда да, тыныч хезмәттә дә сынатмаган, илгә бөек уллар биргән халкымның бәйрәм итәргә хакы бармы? Бар!*

*Менә, Туфан абый, безнең әңгәмә тәмамланып килә. Әйтегез әле, безнең җитмеш яшькә җиткән республикабыз еракган, Мәскәү биеклегеннән караганда ничегрәк күренә?*

— Нинди генә биеклектән, кая гына китеп карасам да, Татарстанга мин аның газиз баласы булып, олы өмет, зур ышаныч, чиксез ихтирам белән карыйм. Һәм бүтәннәрнең дә Татарстаныма шулай карауларын таләп итәчәкмен. Ул аңа тарихы белән дә, бүгенгесе белән дә лаек. Шунысын да әйтеп куйыйм: Татарстанның 70 еллык бәйрәме дигәндә мин, ул тантана республикабызның географик чикләрендә генә үтәр дип уйламыйм. Ул — татар халкының илебезнең төрле киңлекләренә таралып яшәгән җиде миллионлы халыкның бәйрәме.

Без язганда да, трибуналардан сөйләгәндә дә, шул халыкның баласы булуыбызны онытмаска, кылган эшләребез белән шул олы халык алдында имтихан тотарга бурычлы икәнебезне истән чыгармаска тиешбез. Ыгы-зыгылар үтә дә китә, ил кала, халык кала...

**Эмиль Әмит,**
кырым татары язучысы

# ҮЛЕМНЕ ҖИҢГӘН ХАЛКЫМ ТУРЫНДА

Мине әнием һәр иртәдә иркәләп, назлап, иңнәремә сак кына кагылып уята торган иде. Бу юлы ул бик каударланды, мин ничек аякка басканымны да хәтерләмим. Уянып җитә алмый интектем: тезләрем бөгелә, тик әни мине кабат тәз иттереп бастыра, үзе елый, әллә ниләр сөйләнә.

Бүлмәдә итек кигән кешеләрнең каты басып йөренүләре, тупас тавышлары яңгырап тора. Әле таң атмаган, тәрәзәләрдән караңгылык кына бәрелә, шунлыктан мин берни дә аңламыйм: кем килгән соң безгә? Немец фашистлары дияр идең, аларның авылдан чыгып качуларын мин үз күзләрем белән күреп калдым. Дошманның эзләренә бастырып, авылга совет армиясе частьлары килеп керде. Авыл халкы кызыл гаскәрне, юлның ике ягына басып, чәчәк бәйләмнәре белән каршылады. Кочак-кочак чәчәкләр машиналарны күмеп китте, кайбер бәйләмнәр тәгәрмәч астына да эләкте әле. Солдатлар елмаялар, чәчәкләрне йөзләренә тидерәләр, күкрәкләренә кысалар, сирень ботакларын югары күтәреп, нидер кычкыралар иде.

Безнең бүлмә идәнен таптап йөрүчеләр исә елмаймый — болар безнеке түгел микәнни? Берсе гел бер үк әмерне кабатлый:

— Тизрәк җыеныгыз! Биш минут вакыт сезгә! Егерме килодан артык әйбер алмаска! Тизрәк, тизрәк!

Әнине дә, әбине дә мондый хәлдә беренче тапкыр күрәм. Хәер, гестапо солдатлары килеп кергәч тә шулай каушап калганнар иде. Алары әтине таптырып интектерде. Тик аларның фуражкасына баш сөяге белән аркылы-торкылы сөякләр сурәте кадалган иде. Боларныкында — кызыл йолдыз бит?!

Әнием ишекне каерып ачып кергән солдатларның берсеннән бакчага чыгарга рөхсәт сорады. Анда әтиебезнең кулъязмалары тутырылган чемодан күмелгән икән. Бу хакта миңа соңыннан сөйләделәр. Немец фашистлары Кырымга керер алдыннан әтием, шагыйрь Осман Әмит, бөтен кулъязмаларын алмагачлар арасына күмгән. Ул шигырь язу белән генә чикләнмәгән, Пушкин, Крылов, Шевченко, Лермонтов кебек күренекле шагыйрьләрне кырым татары теленә тәрҗемә дә иткән. 1941 елны исә аның шигырьләре һәм поэмалары аерым китап рәвешендә басылырга тиеш булган. Тик... сугыш башланган. Хыял тормышка ашмый калган.

Кулъязмалар арасында әле язылып бетмәгән поэманың аерым өзекләре дә булган — «Сәет улы Сәетөмет». Поэма яман язмышка дучар ителгән шул, тәмамланмыйча калган. Әтиемне исә фашист палачлары, Саки шәһәренә алып киткәннәр дә, шунда җәзалап үтергәннәр.

Туган җиребездән сөрелгән шомлы төннең кайбер хәлләрен миңа, шактый вакытлар үткәч кенә, аңлаттылар. Болай булган икән. Җиргә әлеге шомлы төн ябырылыр алдыннан, берәү безнең тәрәзәне шакыган. Карасалар, әүвәл бездә фатирда торган совет офицеры икән. Ул, башын үлем куркынычы астына куеп, кисәтеп калырга ашыккан:

— Иң кирәкле әйберләрегезне җыеп куегыз! — дигән.— Бүген төнлә сезне сөрәчәкләр. Вакыт бик аз биреләчәк, өлгерә алмассыз...

Безнекеләр ышанырга да, ышанмаска да белмәгәннәр. Шулай да әни әби-бабай белән киңәшкән. Бабай — дингә ышана торган кеше:

— Булмас! — дигән.— Аллаһы тәгалә алдында бер гөнаһыбыз да юк. Андый гаделсезлеккә юл куймас.

Шулай да үзе, таягына таянып, авылны әйләнеп кайткан. Сөйләп биргән:

— Бөтен авылны солдатлар уратып алган, мине ары үткәрмәделәр, атмакчы булдылар,— дигән.— Күрәсең, нидер бар, нидер булачак...

Солдатлар алтынчы яртыда килеп кергәннәр.

Алдан ишетсәләр дә, безнекеләр берни дә җыештыра алмаганнар. Әй кабаландылар, әй аптырадылар бичаракайларым. Сандыктагы иң кадерле әйберләрне исә солдатлар үзләре җыя икән, анысы — конфискация. Безгә ипи, он кебек нәрсәләрне генә төйнәргә куштылар.

— Юлда нәрсә ашарсыз соң? — дип акырындылар алар.

Безне йөк машинасының әрҗәсенә тутырдылар. Мин бабайның тезенә сөялдем. Әниебез генә әле һаман бакчада, алмагачлар арасында казына, әтинең кульязмалары күмелгән урынны таба алмый интегә иде. Ниһаять, тапты! Чемоданны саклык белән генә кулына алды. Машина исә бары аны гына көтеп тора икән. Капитан яман ямьсез кычкырына:

— Әйдә, тиз бул, нәрсә маташасың һаман! — Ул, ашыгып барып, әни кулындагы чемоданны тибеп төшерде.

Еллар буе җир астында яткан чемодан тәмам муртайган икән — таралды да төште. Тирә-юньне әтиемнең кульязмалары тутырды. Буталдылар, читкә оча башладылар. Капитан тәмам чыгырыннан чыкты:

— Ахмак! Кара инде нәрсә өчен күпме көттереп торды?! Мин аны асылташ яки алтын-көмеш тутырылган савыт әзли дип торам...

Әни, бичаракаем, кульязмаларны, ничек җитте шулай, кочагына алды да безнең янга менеп басты...

**Тарихи белешмә.** *Туган җиремдә Кырым АССР 1921 елның 25 октябрь карары нигезендә төзелә. Кырым татарлары бу яңалыкны олуг бәйрәм итеп каршылый. Кырым автономияле республикасында ике телгә: рус һәм кырым татары теленә дәүләт теле статусы бирелә. Шул рәвешле безнең халык иркен сулыш алып яши башлаган. Бу яңалыкның шифасы да тиз сизелә. Кыска гына вакыт эчендә Кырым иң үңган хуҗалыклар рәтенә чыга. 1934 елның 3 гыйнварында республика Ленин ордены белән бүләкләнә...*

Безне Саки шәһәренең станциясенә китерделәр, шәһәр халкын да, якын-тирәдәге авыл кешеләрен дә шунда куалап китергәннәр. Бөтенебезне моңа кадәр терлек-туар йөртелгән вагоннарга кысрыклап керттеләр. Вагоннан абзар исе килә, ашыкканнар, идәндәге тиресне себереп чыгарырга да вакыт тимәгән, күрәсең. Ишекнең ике ягына да киң-киң сәндерәләр, сәкеләр ясалган. Бик ямьсез иттереп. Ышкыламаган да такталардан. Кешеләрнең ул сәкеләргә сыймаганы әлеге тирес исе аңкып торган идәнгә урнашты. Бер-береңнән бүленеп калсаң, кабат якынлашу өчен, кешеләр аша атлап үтәргә туры килә.

Менә вагон ишеген томалап куйдылар. Дөм караңгы булып калды. Поезд кузгалып китте...

Шул рәвешле, минем халыкны җир йөзеннән себереп ташлау өчен көйләнгән ерткычлык машинасы үзенең кара эшен башлап җибәрде. Мондагы бер генә карт та, хатын-кыз да, бала да үзенең кая таба юл тотуын белми иде. Аларны Дәүләт Оборона Комитеты 1944 нче елның 11 маенда чыгарган, кырым татарларын тамырдан һәлак итәргә юнәлдерелгән карары белән таныштырып торуны да кирәк санамаганнар хәтта. Кемдер, хөкем ителгәннәрнең бу хакта белүе мөһим түгел, карарны җиренә җиткереп үтәүчеләр яхшы аңласын, дигән, күрәсең.

...Поезд зур шәһәрләргә туктаганда, безнең вагон ишекләрен ачмадылар. Составның буеннан-буена автомат аскан сакчылар йөренә. Кайчак безнең кебекләр белән дыңгычлап тутырылган ике состав янәшә туктала. Андый чакта, вагонның уч кадәре тәрәзәсеннән карап калу өчен,ниләр генә эшләмиләр иде?! Тәрәзәгә чәнечкеле тимер чыбык кадакланган. Куллар, иреннәр тырнала. Кешеләр шулай да яктылыкка тартыла, сүзләренең кемгә барып ирешәсен дә белмичә: «Бу кайсы як? — дип кычкыралар.— Нинди авыл?» Немец оккупациясе вакытында кешеләргә бер авылдан икенчесенә йөрергә ярамады. Туганнар сагынышып беттеләр. Кемнең хәле ничек икәнен белә алмадык. Шунлыктан, совет гаскәрләре килеп җитүгә, халык, туган-тумачасының хәлен белергә, тирә-күрше авылларга таралган иде. Әлеге афәт күбесенә шул чакта ябырылды. Һәр тукталышта кешеләр әти-әниләрен яки бала-чагасын эзли...

Вагон ишеген кечкенә тукталышларда гына ачалар. Монда поезд берничә минут кына тора. Состав буйлап солдатлар ияртеп офицер ашыгып үтә. Андыйлар гел бер сорауны кабатлый: «Мәетләр бармы?» — диләр. Мәет булмый калмый торган иде. Күбесенчә балалар һәм картлар кырылды. Үлгәннәрне, тимер юлдан өч-дүрт метр гына читкә китеп күмәргә рөхсәт итәләр. Өлгерә алганда, сай гына чокыр казып, мәетне ком, ташлы балчык белән күмгәндәй итәләр. Кайчак аныена да вакыт тими, поезд кузгала башлый...

Сөрелгәннәр арасында кеме дә булса фронтка китмәгән бераү генә дә юк иде. Һәм бу вәхшәтне һәммәсе коточкыч бер хаталану гына дип кабул итте. Тиздән «халыклар атасы», иптәш Сталин бу ялгышуны үзе ишетеп алыр, җентекләп тикшерер дә кичекмәстән кире кайтарырга әмер бирер, дип ышаналар. Вагондагыларның байтагы, дыңгырдык поезд шартларына игътибар итмәстән, «бөек юлбашчы»га хат язып азапланa иде.

Нәрсә турында яздылар соң алар? Кырым татарларының фашистларга каршы актив көрәш алып баруларын, партизан отрядларындагы эшчәнлекләрен тасвирладылар. Дәлилгә бу хакта язылган рәсми басмаларны китерделәр. 1943 елны, мәсәлән, Кара диңгез флоты сәяси идарәсенең «Кырым» исемле китабы чыкты. Анда әйтелгәнчә, кырым татарларының күпчелеге, немец фашистлары басып алган җирдә, дошманга нык каршылык күрсәтә. «Красный Крым» дигән газета 1944 елның 18 февралендә, партизаннарга ярдәм күрсәткәне өчен, дистәләгән кырым татары авылларының тоташтан яндырылып бетерелүе турында язды, йөзләрчә һәм меңнәрчә кырым татарлары фашистлар тарафыннан җәзалап үтерелде. Бу, чыннан да, шулай иде. Һәм әле дә булса әллә ничә мең кырым татары фронтта фашистларга каршы көрәшен дәвам иттерә иде.

**Тарихи белешмә.** *Сугыш башлануга, безнең язучыларның күбесе, үз ихтыяры белән, Ватанны якларга фронтка китте. Байтагы кире әйләнеп кайтмады. Һәлак булган каһарман әдипләребез — уникәү. Күп еллар узгач, алар турында «Уникенең истәлегенә» дигән китап чыкты, исемнәре мәңгеләштерелде. Бу урында да исемнәрен кабат телгә алыйк әле... Менә алар: Ыргат Кадыйр, Хәмди Хәлим, Осман Әмит, Максуд Сөләйман, Бәкер Ваһап, Эзһәм Әхмәт, Мәхмүт Дибач, Маннан Җаманаклы, Әбләй Шамил, Таһир Хөсәен, Осман Батыров, Ханнан Хәлимов... Аларга — мәңгелек дан! Уникәү! Гомерләрен Ватан өчен биргән бу әдипләр ул чорда кырым татарлары язучыларының яртысын диярлек тәшкил итә иде.*

*1960 еллар башында Язучылар Союзының Кырым бүлекчәсендә Бөек Ватан сугышында һәлак булган язучылар исемләгән мемориаль тактага язып элделәр. Тик, «югарыдан» килеп төшкән әмер буенча, аны бик тиз арада юк иттеләр. Шулай да Үзбәкстан Язучылар Союзы фойесындагы мемориаль тактага кырым татарларыннан да дүрт әдипнең исеме язылган. Гаҗәп: ни өчен дүрт кенә? Нигә барысы да түгел?*

Әлбәттә, кырым татарларыннан коллаборационистлар, ягъни сатлыклар, бөтенләй чыкмады димим. Фашист оккупациясендә калган һәр халыкта андыйларны да очратырга мөмкин. Күбесенчә элекке бандитлар, «утырып чыкканнар», кулаклыкта гаепләнгәннәр сатылды. Әмма күп түгел иде алар, санаулы гына. Тагын шунысын да әйтергә кирәк, Кырым азат ителүгә, фашистларга ялланган ул бичара җаннар, көне-сәгате белән үз җәзаларын алды: аларны атып үтерделәр, аз гына шикләләрен дә төрмәгә яптылар. Билгесезлеккә юл алган әлеге эшелоннарда исә Ватан алдында һичнинди гаебе булмаган затлар гына иде.

Әмма безнең бәхетсезлекнең башында торган бер хәлне телгә алмыйча да үтә алмыйм. Кырымдагы партизан хәрәкәте җитәкчеләреннән Мокроусов һәм Мартынов, үзләре җибәргән хаталардан котлары алынып, бөтен гаепне, тоташы белән, татарларга сылтады: янәсе, татарлар партизаннарга хыянәт иткән дә, болар җиңелүгә дучар булган. Дөрес, соңыннан бу бәндәләрнең чын йөзе ачылды, тик алар минем халкыма карата коточкыч явызлык кылып өлгергән иде инде.

...Сак астындагы вагоннарда «бөек юлбашчы»га хат язучылар арасында партизан отрядларында каһарманлык күрсәткән командирлар һәм комиссарлар — А. Аединов, С. Минһаҗиев, М. Мәхмүтов, Н. Билялов та бар. Алар үз отрядларында якташларыннан ничә кеше булуын, аларның ничек сугышуын хәбәр итәргә ашыгалар. Искә төшереп китәргә кирәктер: Кырымдагы партизан берләшмәләре өчәү иде. Шуларның икесендә комиссар булып кырым татарларыннан Р. Мостафин һәм М. Сәлимов хезмәт итте. Ә утыз партизан отрядының унысын шулай ук кырым татары комиссарлары җитәкләде. Көньяк берләшмәнең генә дә өчтән бер өлеше кырым татары сугышчыларыннан тора. Кырым АССРда ул елларда бөтен халыкның нибары 19,4%ын гына кырым татарлары тәшкил иткәнлеген исәпкә алсак, бу саннар шактый күпне сөйләр.

Бөек Ватан сугышында кырым татарларыннан дүрт генерал, сиксәннән артык полковник, йөздән күбрәк подполковник, бик күп офицер һәм кече командирлар катнашты. Аларның һәммәсе илнең орден-медальләре белән бүләкләнде. Кырым татарларының җидесенә Советлар Союзы Герое дигән исем бирелде. Иң гайрәтле очучыбыз Әхмәтхан Солтан Герой исеменә ике тапкыр лаек дип табылды. Орден-медальләр белән бүләкләнүче сугышчыларыбызның гомуми саны илле меңгә җитә.

Кырымда калган татарларның 19%ы гитлерчыларга каршы көрәшне партизан отрядларында алып барды. Бу көрәшчеләрнең яшерен оешмаларын утыз ике төркемгә бүлгәннәр иде. Шулардан егерме биш төркемне кырым татарлары җитәкләде. Уйларга да оят: фронтта һәлак булган егерме алты мең сугышчыбыз да, оккупациядә калып фашистлар тарафыннан юк ителгән унике мең кырым татары да — барысы да «сатлык җан» исемен күтәрергә мәҗбүр ителде.

Халыкны тулаем кыруга юнәлдерелгән бу вәхшәтне акларга бер сылтау кирәк булган шул. Безне илгә хыянәт итүдә гаепләгән язмалар чыга башлады, безне башкалар алдында җирәнгеч итеп күрсәтә торган дәреслекләр төзелде. Максат бер иде: кырым татарларына карата илдә нәфрәт уятырга! Әле гаилә башлыклары — сугышта, сөрелгән карт-карчыклар белән балалы хатыннар терлек вагоннарында билгесезлеккә бара, типографияләр исә ашык-пошык хәлдә «СССР тарихы»н үзгәртеп басалар. Кырымда безнең халыкны ерткычтан да яманрак итеп тасвирлаучы кыйссалар таратылды. Радио һәм вакытлы матбугат шул гайбәтләрне тәфсилләп сөйли башлады...

Кырымда барган канкоюлы бәрелешләрдә каһарманлык күрсәткән кешеләрнең исеме исә руслаштырып бирелә килде. Мәсәлән, «Севастополь-Балаклава» дигән партизан отрядының разведгруппа командиры Сәетгали Агаевны С. Агеев дип яза башладылар. Төньяк берләшмәнең 17 нче партизан отрядындагы разведгруппа командиры Сәетгали Көрдсәедев С. Курсаковка әйләнде. Симферопольдә фашистларга каршы көрәшүче иң зур яшерен оешма җитәкчесе Абдулла Дагъҗине «Дядя Володя» дип кенә телгә алу гадәткә керде. Керчьтагы «Яшь гвардия» исемле яшерен оешманың легендар җитәкчесе Хәлимә Габделханнанованы «Аня» дип кенә йөртәләр. Шундый ук каһарманнардан Асия Әхмәтова Асяга әйләнде, Рифкат Мостафаев — Лагутин, Сиражетдин Минһаҗиев — Сергей М., Нажия Батталова — Батаева; партизан отрядында аеруча зур батырлыклар кылган, Польша халык республикасы Герое исемен алган, «Мишка — Татар» кушаматлы Гомәр Акмулла Адәмәнов Михаил Татаринов дип йөртелде.

Ул гынамы?! Хәзер инде Кырымдагы авыл, шәһәр, тау һәм елга исемнәре дә русчага әйләндерелеп бетеп бара...

...Безнең эшелонны Ач даланың Урсатьевск дигән станциясендә бушаттылар. Кояш сугудан сакланырлык бер куак та юк. Ул, кайнар җил белән бөтерелеп килеп, битне кисүче ком вәхшәтен мәңге онытмам кебек. Күзне ачып булмый.

Кичкә таба биек арба җиккән атлылар күренде. Алар безне тагын да ераккарак алып китәр өчен җибәрелгән икән. Тирә-юньдә җан иясе юк дәрәҗәсендә. Ни булсын? Исеме үк котыңны алырлык бит — Ач дала. Шул юлларда күргәнемнән чыгып мондый нәтиҗәгә килдем: дөньяда иң шыксыз яклар комлыкның сазлыкка әйләнгән урыны икән.

Безне Баяут исемле поселокка урнаштырдылар. Ком һәм тузан басып киткән ярым җимерек алачыклар бар иде монда. Унбиш-егерме еллар элек бу алачыкларда кулаклыкта гаепләнеп сөрелгән кешеләр яшәгән. Алар акрынлап үлеп беткән, күрәсең. Үлем дигән нәрсә безнең арага да бик тиз үтеп керде. Кешеләр бизгәк, эч авыруыннан кырыла башлады. Яшьтәшем Мидхәтнең, эче авыртуга чыдый алмыйча, идәндә бөгәрләнеп ятуы әле дә күз алдымда. Ул тилмереп-тилмереп:

— Әни! — дип кычкыра.— Әнине чакырыгыз! — ди.

Тик әнисе кайтканда, аның ябык гәүдәсе суынып беткән иде инде.

Үзбәкстанга килүебезнең беренче аенда ук 40 мең кешебез һәлак булды. Безнең янга фронтта гариплэнгән әтиләр, абыйлар кайта торды. Кайсының кулы юк, кайсының — аягы. Күкрәкләрендә орден-медаль тәңкәләре чыңлый. Алар үзләренең әниләрен, хатыннарын, балаларын эзли, тик күбесенең сукмагы каберлеккә тоташа. Сугыш каһарманнарын көтеп ала алмадылар шул, күпләр дөньядан китте...

Килделәр дә килделәр. Күпме икәнен кем исәпләгән?! Кырым татарларыннан Урта Азиягә сөрелгәннәрнең төгәл санын әлегә кадәр әйткәннәре юк. Үзбәкстанның ул чактагы Җәмәгатьчелек тәртибен саклау министры урынбасары генерал М. Бегловның бер язмасында: «Үзбәкстанга әле генә 151 424 кеше сөрелеп китерелде; күбесе — картлар һәм балалар»,— дигән сүзләр бар. Бу генерал әлеге кешеләрнең күпмесе юлда үлеп калганын белми, әлбәттә.

Яман чир безнең гаиләдә, беренче булып, бабакаема ябышты. Аның хәле начарланган көнне әби бригадирдан: «Башка чакта икеләтә тырышырмын, бүген картымның кәефе юк, калдырыгыз сана!» — дип, үтенеп сорады. Кая ул!? Рөхсәт итмәделәр. Авыру бабай янында мин генә калдым. Берчак күрәм: бабайның нидер әйтәсе килә, иреннәре кыймылдый, күзләре бер ачыла, бер йомыла... Күршедәге олы кешеләрне чакырасым килә, куркам. Алар бит безнең күзне дә ачырмыйлар: «Сезнең хыянәтегез аркасында, безнең этиләр үлеп калган»,— диләр. Соңыннан белдек: мондый котки махсус таратылган икән. Белдек тә... дуслаштык. Бик тату яшәп киттек.

Ә бабам авырган көнне мин аларга керергә кыймадым шул. Әни белән әби мамык кырыннан кайтканда, мин, бабамның үле гәүдәсен кочаклап, йоклап киткән булганмын...

Юлда безнекеләрне ачлык яки авыру гына кырмады. Кайберәүләр, якында су краның күреп, аны-моны уйлап тормастан, шул якка йөгерә, бер адым атларга да

өлгерми, аны автоматтан атып үтерәләр иде.

Җиңү көненнән соң безнең янга кайтучылар тагын да артты. Бу юлы җиңүче солдатларны сөрделәр. Андыйларны, әлеге каһәрләнгән җиргә аяк басу белән үк, махсус исәпкә алып куялар иде. Алар ай саен комендатурада «билгеләнергә» мәҗбүр ителде. Бу чара алар «тиешсез» җирләргә барып-килеп йөрмәсен өчен эшләнде. Шулай итеп, әле кичә генә ил азатлыгы өчен сугышып йөргән солдатлар, хәтта Советлар Союзы Герое исеменә лаек каһарманнар да, үзеннән-үзе сатлык җаннарга әйләнделәр. Бу коточкыч тамганы тагу өчен кырым татары булып тууың җитә иде...

* * *

Уникe ел гомер узды. 1956 елның 28 апрелендә СССР Югары Советы Президиумының «Бөтек Ватан сугышы елларында туган җирләреннән сөрелгән СССР гражданнарыннан — кырым татарлары, көрдләр, балкарлар, төрекләр, хемшидлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан сөргенлек буенча төрле чикләүләрне алып ташлау турында»гы карары чыкты. Бу көнгә кадәр 400 мең кырым татарының өчтән бер өлеше һәлак булып беткән иде...

Без үзебез турында гадел сүз ишетергә өметләнми башлаган идек инде. Яшьләр исә хак сүзгә бигрәк тә сусады. Әмма безнең хакта дөрес сүзне ил күләмендә яки дөнья күләмендә яңгыратып әйтүче кеше булмады, дияргә мөмкин. Аның каравы, безнең йөзгә кара ягудан чирканмадылар. 1947 елда П. Павленконың «Бәхет» исемле романы басылып чыкты. Бу әсәрнең каһарманнары «вәхши»ләрдән, ягъни бездәй татарлардан, азат ителгән Кырымда чиксез бәхетле яшиләр. Роман Сталин премиясенә лаек табылды.

И. Козлов («Кырымдагы яшерен оешмалар»), А. Первенцев («Намусны яшьтән саклыйлар»), И. Віргасов («Кырым дәфтәрләре») кебек язучы бәндәләр кулларыннан килгәнчә мәсхәрәләде безне. И. Вергасов хәтта үзенең көрәштәш дусты Бәкер Османовны, исемен дә үзгәртеп тормыйча, Төркия шпионы дип язды. Бу авторларның китабын безнең халыкны бөтенләй белмәгән кеше генә ышанып укый ала. Әсәрләрнең төп максаты — безне совет кешеләренең гомуми дошманы итеп сурәтләргә тырышу иде.

Тагын бер гайбәт таратылды: янәсе немец фашистлары Кырымдагы татарларга һичнинди явызлык та кылмаганнар. Чеп-чи ялган иде бу! Фашистлар, Бакчасарайга килеп кергән көнне үк, шәһәрнең үзәк мәйданына сигез кешене асып куйды: Йосыф Таһиров, Әблә Ибраһимов, Лотфия Аетдинова (аңа нибары 13 кенә яшь иде), Хәлил Османов, Хәлим Куршунов, Йоныс Фәтхиев, Хөсәен Җаббаров, Мәхмүт Әхмәтов...

Фашистларның минем халкыма карата кылган вәхшилеген санап кына бетерерлекме? Шулай да тагын берне искә төшерик әле: партизан отрядлары аеруча актив көрәшкән таулы якта фашистлар 70 тән артык татар авылын бөтенләй юк итте. Анда халкымның 25% лабы яши иде. Дөнья фашистлар көлен күккә очырган Хатынь, Саласпилс кебек урыннарны яхшы белә. Аларда һәйкәлләр булдырылды. Әлек анда яшәгәннәрне сагынып искә алалар, батырлыкларына дан җырлыйлар. Ни өчен соң минем халкым кичергән коточкыч фаҗигалар әлегәчә ачылмый ята?! Ни өчен Кырымда бездәй татарларның каһарманлыгын мәңгеләштергән бер генә һәйкәл дә, язулы таш кисәге генә дә куелмаган? Ни өчен?!

Бу хакта авыз ачкан кыю затлар исә үзләре яман тәкъдиргә дучар ителде: безне яклап Л. И. Брежневка хат язган С. Писарев тиеләр шифаханәсенә ябылды; генерал П. Григоренконы АКШка озаттылар; академик А. Сахаровны Горькийга сөрделәр. Гаделсезлек шул дәрәҗәгә җитте ки, хәтта кырым татары белән гаилә мөнәсәбәтенә кергән руслар да безнең язмышны кичерергә мәҗбүр иде. Әнисе рус хатыны булган Рөстәм Әминов, мәсәлән, Севастопольдагы суднолар ясый торган техникумга керер өчен, документларын тапшыра алмый интегә. Директор В. Молоканов аңа ачыктан-ачык:

— Минем кулда күрсәтмә бар,— дип аңлата.— Кырым татарлары белән немец балаларын монда укырга алырга ярамый.

Хәл СССР төзелүгә 60 ел тулган чакта була, шунлыктан Әминовлар, тәвәккәлләп, КПСС ҮКына, Ю. Андропов исеменә телеграмма сугалар. Аннан О. Курин дигән кеше Рөстәмнең әтисенә: «Үзәк Комитетның карары чыкты, улыгызның документларын алырлар»,— дип җавап җибәрә. Уйлап карасаң, уелыплар китәрлек түгелмени: унбиш яшьлек малайның укырга керү-кермәве белән Үзәк Комитет үзе (!) шөгыльләнсен инде, ә?!

...Минем яшьтәшләр, мөгаен, үзләрен комсомолга яки партиягә алган көнне ачык хәтерлидер. Миңа исә башка хатирәләр турында уйланырга туры килә. Әйтик, беренче

тапкыр комендатурада исәпкә алынган көн. Мине, кырым татары булганым өчен генә, комсомолга алмадылар. Комендатурада исә мине тиешле вакыттан бер ел алда исемлеккә теркәделәр. Әле унбиш кенә тулган иде. 1954 ел. Мин җиденче классны тәмамладым. Ул елларда дәреслекләр табу гаять авыр иде. Җилкенеп китүем шуңа күрә булгандыр: кемдер, Сәмәркандка сигезенче класс дәреслекләре кайткан, дип хәбәр таратты. Миңа шул гына кирәк — аны-моны уйлап-нитеп тормый, чыктым да киттем. Барып җиттем. Чыннан да, китаплар бар. Бер-икесен алдым. Юл чатында безнең якка кайтучы машина көтеп торам.

Якамнан корыч куллы берәү эләктереп алды. «Әйдә әле!» — ди бу. Котым калмады, кулымда шәһәргә барырга рөхсәт бирә торган кәгазь юк иде бит. Мине НКВДның шәһәр бүлегенә алып керделәр. Бүлмәдә — сулуга каба торган тәмәке төтене. Тәрәзәләргә тимер рәшәткә кадакланган. Өч-дүрт ир-ат тәмәке көйрәтә. Шул нык бәдәнле агайларның берсе миңа кәгазь сузды:

— Яхшылап укы! — диде.— Укы да имзаңны сал! Башка чакта уйлабрак йөр!

Мин кәгазьгә ни язылганлыгын беләә идем. Бу — СССР Министрлар Советының 1947 ел, 21 ноябрь карары. Аңа сөргендәге кырым татарының үзенә билгеләнгән җирдән качканы өчен нинди җәза биреләчәге язылган. 20 елга кадәр каторга алуың да бик ихтимал. Бу хакта һәр кырым татары белә, зурлардан имзалар да куйдырып чыктылар. Комендант рөхсәт итмәгәндә, берәү дә бер кая да китә алмый. Күчеп йөрүләр катгый тыела иде. Ялгыш кына атласаң да, качуда гаепләячәкләр.

Беренче агай миңа тәртип кагыйдәләрен аңлаткан арада, икенчесе яныма ук килеп басты, чәчемнән умырып тотты да башымны өстәлгә бәрә башлады. Бер, ике, өч... Ул әлеге кәгазьгә минем борыным бәрелүне, кан агып чыгуын тели иде кебек.

— Укы! Укы! — дип кабатлады ул.— Мәңге онытылмаслык булсын!..

Аның теләге кабул булмады. Ике елдан соң комендант сәгатьләре бетерелде.

Бу яңалыктан соң ел да үтмәде, СССР Югары Советы сессиясе тагын бер шатлыклы карар кабул итте. Бу карар нигезендә чеченнар, ингушлар, калмыклар, карачайлар һәм балкарларга, туган якларына кайтып, үз автономияле республикаларын кабаттан аякка бастырырга рөхсәт ителде. Ә... безгә?! Юк, бу хисне сүз белән генә аңлату мөмкин түгел. Кырым татарлары, месхет төрекләре һәм Идел буе немецлары турында әлеге карарда бер генә сүз дә юк иде. «Ник болай бу? Бездән әле һаман да шикләнәләрмени соң?» — дигән сорау халкымның үзәгенә үтте.

Кыскасы, әлеге вак-төяк ташламалар безгә сөенеч урынына көенеч кенә китерде. Берәүләрне аклап, безне игътибардан читтә калдырган карарлардан соң киләчәгебез өчен аеруча кайгыра башладык.

Кырым татарларының әдәбият-сәнгать вәкилләре үз әсәрләрендә Кырым атамасын телгә алмаска тиеш иделәр. Уйлап кына карагыз: кеше үзенең туган җирен телгә алудан тыелсын әле! Кара диңгез, аның зиһеннәрне чуалтырлык матурлыгы, Кырымдагы элекке шәһәр һәм авыл исемнәре... Безгә аларны искә төшерергә дә ярамый иде. Ташкентта кырым татарлары телендә китаплар басыла, газеталар чыга, әмма дөньяда бу телнең барлыгын ил халкына горурланып сөйләргә ярамый. Үзбәкстанның партия һәм совет органнары исә КПСС ҮКына һәм Политбюрога гел ялган хәбәрләр җибәреп тордылар, хәлне шомартып, безнең тормышны матурайтып күрсәттеләр. Ул мәгълүматларга караганда, кырым татарларының сөргендәге тормышы ал да гөл иде. Бу чеп-чи ялган хәбәрләрнең нәрсәгә китереп чыгаруын «Фергана вакыйгалары» бик ачык сөйли.

1967 елның 5 сентябрендә СССР Югары Советы Президиумы Указы безнең мәсьәләгә тагын бер үзгәреш кертте. «Кырымда яшәүче татар милләте гражданнары турында» дип исемләнгән бу Указ, «Кырымда яшәгән татарлардан, бигрәк тә җәмгыять үсешенең яңа баскычында туган яшь буынын истә тотып, элекке гаепләү алып ташланырга тиеш», дип белдерде. Кырым татарлары бу Указны чирек гасыр (!) буе көтеп алдылар. Бу Указда, Сталин заманнан нахак гаепләвен алып ташлаудан тыш, тагын бер яңалык бар. Анда: «... Элек Кырымда яшәгән татар халкы, СССРдагы башка милләт вәкилләре кебек үк, илнең теләсә кайсы тарафында яшәргә хокуклы» — диелгән иде.

Димәк, без туган якларыбызга да кайта алабыз! Моннан да зуррак шатлыкның булуы мөмкинме?! Тик, кызганычка каршы, без тиз арада әлеге сүзләрнең гап-гади күз буяу икәнлегенә төшендек. Указ, туган җирен төшендә күреп аптыраган халык өчен түгел, башкалар өчен чыгарылган икән. Хөкүмәт җитәкчеләрен шәфкатьле итеп күрсәтер өчен. Кырымның яңа җитәкчеләре безне туган җиргә якын да җибәрми, шул ук вакытта Үзбәкстандагы рәшидовчылар да безне үз ягыбызга озатырга теләми, кырым татарларының көченнән файдаланырга гына тырышалар иде. Баксаң, әлеге Указ 1956 елгы карарны юкка чыгара алмый икән. Киресенчә, монда кырым татарларына «ябыштырылган» төп гаеп түгел, бары тик җәза гына бетерелә.

Н. Хрущев чорында кырым татарлары тормышында әллә ни үзгәрешләр булмады. Дөрес, Ташкентта «Ленин байрагы» исемле газета чыгарырга рөхсәт иттеләр. Китаплар бастыргаладык. Әмма безгә «Кырым», «Кара диңгез» кебек атамаларны телгә алырга рөхсәт юк иде.

Без 1956 елдан бирле Кырымга, туган җиребезгә кайтырга рөхсәт сорыйбыз. КПСС ҮК Политбюросына җибәргән үтенечләребезгә ун меңнәрчә имза салынган. Тик хатларыбыз җавапсыз кала бирде.

Өлкә җитәкчеләре исә, ярымутрауның төп халкын кире кайтармау өчен, Кырымга читтән башкаларны оештырып-оештырып китереп урнаштыралар. Соңыннан: «Монда кеше күп, кырым татарларына урын юк!» — дияр өчен нигез ныгыталар.

Шунысы да мәгълүм булсын: илдә Төп Закон саналган СССР Конституциясеннән тыш күпсанлы указлар, инструкцияләр чыгару гадәте яши. Халык Конституцияне генә белә, теге күрсәтмәләр киң халык массаларына җиткерелми, киресенчә, аларны яшертен саклыйлар. Мәсәлән, 1972 елның 9 ноябрендә Генераль прокурор үзе (!) Конституциягә каршы килә торган приказ бирә.

*«СССР Генераль Прокуроры приказы № 54. 9 ноябрь, 1972 ел. Мәскәү.*

*СССР Югары Советы Президиумының 1972 ел, 3 ноябрь указын басып чыгарырга ярамый дип игълан итәргә. Приказның төгәл үтәлүен тикшереп торуны тәэмин итәргә...»*

Инде шуңа охшаш өстәмәләрнең нинди приказларга теркәлеп таратылуын да ачыклыйк. Менә алар:

*1955 елның 13 декабрь указы — немецлар һәм аларның гаиләләренә карата;*

*1956 елның 13 декабрь указы — грек, төрек, фарсы кешеләренә карата;*

*1956 елның 28 апрель указы — кырым татарлары, балкарлар, көрдләр һәм хемшидларга карата...*

Сталинчыл шушындый ысуллар белән эшләп ятучы чиновниклар бүгенге үзгәртеп коруларга да аяк чала. Шунлыктан безгә иң әүвәл шул яшерен документларны фаш итәргә, аннары инде, җиң сызганып, яңача эшли башларга кирәк.

Дөрес, Кырымдагы гаделсезлекләргә карата соңгы вакытта шактый ачыклыклар керә, әмма эшнең зур өлеше — алда әле. Без бу эшкә, Кырымның акгвардиячеләрдән азат ителү тарихына ук кире кайтып, кырым татарларының ул көрәштәге каһарманлыкларына дөрес бәя биреп тотынырга тиеш.

Хәзер дә, безнең халыкны Кырымга кайтармас өчен, әллә нинди чаралар эзләп азапланалар. Кырымга читтән бик күп кеше килгән дә, анда безгә урын калмаган, аяк басар җир дә юк, янәсе. Андый тар урынга кырым татары ничек сыйсын?! Чынында исә бу сүзләр — мәсьәләне һаман суза килү өчен бер уйдырма гына. 1987 елгы мәгълүматларга караганда, кырымның һәр квадрат километрына 93,6 кеше туры килә. Экономистлар, демографлар, социологлар әйтүенчә, бу — һич тә куркыныч сан түгел. Мондый шартларда кеше рәхәтләнеп яши ала. Кырымга якын гына булган Донецк өлкәсендә, мәсәлән, бер квадрат километрда 200 ләп кеше яши; Фергана үзәнендә, ягъни кырым татарларының бүген яши торган урынында — 370.

Шулай. Безнең халыкка ябырылган бәладән котылу җиңелләрдән түгел. Юлга аркылы төшәргә мең сәбәп табылып кына тора. Иң азактан:

— Кырым татарларының ярымутрауга кайтуын монда яшәүче башка халыклар — руслар, украинлылар өнәп бетерми бит,— дип тә куялар әле.

Мин ышанам: безнең халыкны тирәннән белгән бер генә адәми зат та аңа каршы сөйләмәс! Кемдер безгә каршы әйтә икән, димәк, ул безне бөтенләй белми, өйрәнмәгән яки аны алдаганнар.

Еллар безне акыллырак, зирәгрәк булырга өйрәтте. Күпләр кырым татарлары язмышында коточкыч гаделсезлек хөкем сөргәнен яхшы аңлый. Кемнең кем икәнлеге дә ачыклана бара. Илебезнең әле бер, әле икенче ягында гаделсезлекләргә каршы хәрәкәтләр күтәрелеп-күтәрелеп ала. Кырым татарлары, мисхет төрекләре, көрдләр гаделсезлекнең тиз арада бетереләчәгенә ышаналар. Мәсьәләнең гадел чишелеше — моңарчы җәберсетелгәннәр өчен генә түгел, бөтен илнең халыкара абруен күтәреп күрсәтү өчен дә иң беренчел чара.

СССР Югары Советындагы махсус комиссия, ниһаять, кырым татарларының хәлен Кырымда автономия булдырып кына төзәтергә мөмкин, дигән дөрес карарга килде. Украина составында Кырым АССРы төзелергә тиеш, дип табылды. Кырым татарлары бу гадел карарның тизрәк тормышка ашырылуын көтәләр. Халкым белән бергә мин дә көтәм, мин дә ышанам.

**Кояш ТИМБИКОВА** тәрҗемәсе.

## Айрат Садыйк

# АФӘРИН, АДАШ!

Узган ел «Идел» журналы «Татар-89» конкурсы игълан итте. Аның шартлары буенча, журнал укучылар 1989 елда татар дөньясында, үзләре фикеренчә, иң популяр булган татар кешесен атарга тиешләр иде. Конкурс барышында күпләрнең исемнәре әйтелде: академик Роальд Сәгъдиев, җырчы Альберт Әсәдуллин, Татар иҗтимагый үзәгенең идарә әгъзалары Марат Мөлеков, Дамир Исхаков, Рафаэль Хәкимов, язучы Фәүзия Бәйрәмова, СССР Югары Советы депутаты Туфан Миңнуллин, мөфти Тәлгать хәзрәт Таҗетдин, КПСС Үзәк Комитеты секретаре Гомәр Усманов, шахматчы Артур Йосыпов, футболчылар Ринат Дасаев һәм Вәгыйз Һидиятуллин...

Иң популяр кешеләр исемлегендә моңарчы күпләргә билгеле булмаган боксчы Айрат Хаматов исемен дә күрәбез. Кем, нинди шәхес соң ул Айрат Хаматов? Милләттәшләре арасында шундый мәхәббәт казанырлык ниләр эшләгән ул?

...Мин Айратны Мәскәү чемпионатына кадәр үк белә идем. Бөтенсоюз һәм халыкара ярышларда чыгыш ясап, ул үзен азмы-күпме таныткан иде инде. Әмма миңа аның белән якыннан танышырга туры килмәде. Ниһаять...

1989 елның 3 октябре. Казанның тимер юл вокзалына җыелган спорт сөючеләр «Мәскәү — Абакан» поезды килүен көтәләр. Аңа утырып бокс буенча дөнья чемпионы Айрат Хаматов кайтырга тиеш.


Гадәттәгечә соңга калып килгән поезд перронга туктауга, күпләр унбишенче вагонга ташланды... Карап торышка, малайсыман кыяфәтле Айрат вагон ишеге төбендә бер мәлгә тукталып калды. Үзен каршыларга килгән моның кадәр кешене, кочак-кочак чәчәк бәйләмнәрен, кызыл комачларны аның беренче тапкыр күрүе иде. Шуңа да аның йөзенә аптырау катыш гаҗәпләнү чыкты. Каршылаучылар исә кәләпүш кигән егетнең кулын кысарга ашыкты. Хәтта башка поездлардагы пассажирлар да, чәчәк күтәреп, Айратка таба йөгерде. Бокс ярышларын телевизордан караучылар Айратны танып алды: «Афәрин, Айрат!», «Котлыйм, Хаматов!», «Һәрчак җиңү телим!» кебек сүзләр яңгырады. Дербышки кешеләре аеруча нык тырышты. Мин дә барып чемпионның кулын кыстым: «Афәрин, адаш!»— дидем. Айрат, елмаеп, рәхмәт әйтте. Танышуыбыз шулайрак башланып китте.

Айратның үзбәк кәләпүше киюе турында әйткән идем инде. Татар газеталарында аның мондый фотосурәте басылып чыккач, кайберәүләрдә бик урынлы сорау туды: ни өчен чемпионыбыз үзбәк кәләпүше кигән, татарның үз кәләпүше юкмы әллә? Бар, әлбәттә. Безнең милли түбәтәйләр күпләрне кызыктырырлык. Ә Айратка килгәндә, эш шунда: чемпионат тәмамланганда, аңа тамашачылар мәхәббәте бүләге тапшырылды. Аны Үзбәкстан вәкилләре билгеләгән иде. Гаҗәп түгел, бу бүләк үзбәкләрнең милли киеме — чапан белән кәләпүштән гыйбарәт булды. Казанга менә шушы кәләпүшне киеп кайтты ул. Дөресен әйтим, чемпионга бик килешә иде әлеге баш киеме.

24 яшьлек Айрат Хаматовның тормышы моңарчы җиңел булмаган. Дөрес, мөстәкыйль тормышка аяк басу берәүгә дә җиңел түгел. Кайберәүләр авырлыклар алдында югалып та калгалый. Айрат исә үз-үзен саклый алган. Чемпионның тормышында борчулы вакыйгалар да, шатлыклы сәхифәләр дә җитәрлек. Аларны күздән кичерик.

Айратның әти-әнисе — Касыйм абый белән Люция апа Чаллы ягыннан, элеккеге Минзәлә, хәзерге Тукай районына керүче Югары Байлар авылыннан. Казанга күчеп килеп, Дербышки поселогындагы торак конторасында эшли башлыйлар, үзләренә вакытлыча фатир бирәләр, уллары Азат (ул энекәшеннән өч яшькә өлкәнрәк) һәм Айрат туа. Тормышны зур кыенлык белән алып баралар. Акча җитми, фатир кысан... Нишлисең, шәһәр авыл кешеләренә тиз генә ачык йөз күрсәтергә теләми. Касыйм абый бу кыенлыкларны бигрәк тә авыр кичерә, тәмам авыруга сабыша һәм 1978 елда дөньядан китә. Бу вакытта Айратка 13 яшь кенә була әле. Әтиләренең вафатыннан соң Хаматовлар гаиләсенең тормышы тагын да авырлаша. Әниләре улларын авылга, туганнарына кайтарып куярга тели. Тормыш анда бераз җиңеләер дип уйлый ул. Әмма күпме кыстасалар да, әнисе дә, абыйсы да Айратны ризалаштыра алмыйлар. Ул Казанда кала.

Мәктәптә укый башлауга Айрат бик тиз «авыр холыклылар» исемлегенә керә. Дәресләрне дә еш калдыра, иптәшләре белән сугышып та алгалый. Үзе начар укымый ул, математиканы аеруча ярата. Өйгә бирелгән эшләрне үтәргә теләми, күңеле гел урамга тарта. Кечкенә чакта күпләр шулай була торгандыр инде. Айрат моны хәзер дә гадәти хәлдән саный. Малайларны өйдә генә утырту кыен. Тик урамда нәрсә белән шөгыльләнү бик мөһим. Казан хәзер үзенең «тыңламас малайлары»— төркемнәргә берләшкән үсмерләре белән җәфалана. Бу җинаятьчел төркемнәр бер-берсен кыйнау-үтерүдән дә чирканмый. Айрат Хаматов шундый «урам малаена» әйләнүдән ничек сакланып калган соң? Җавап бер генә: аңа спорт ярдәмгә килгән.



1978 елда, мәктәптә яңа уку елы башланыр алдыннан, иптәшләре белән Дербышки урамнарында каңгырып йөргән Айрат «Ракета» стадионына чакырган белдерү күрә. Дербышки малайлары арасында бокс белән көрәшнең популярлашып киткән чагы була бу. Нәрсә уйлагандыр: якын дуслары көрәшкә кыстаса да, Айрат бокс белән шөгыльләнергә тәвәккәлли.

Тәүге тапкыр бокс секциясенә аяк басканын яхшы хәтерли ул. 7 сентябрь. Аның кебек берничә малайны тренер Минхан Вәлиуллин каршы ала. Беренче дәрес төрле мәгълүматлар язып алудан узмый. Икенчесендә исә футбол, баскетбол уйныйлар, бокс бияләйләрен киеп карыйлар. Эшләр акрын гына җайлана... Төшкә кадәр — мәктәп, аннан — күнегүләр. Бирегә йөри башлавына ярты ел дигәндә Айрат шәһәр күләмендә уздырылган ярышларда җиңеп чыга. Аның кебек берничә җиңүчене Харьковта узачак турнирга алалар. Казан белән Чаллыдан ары китмәгән малай өчен бу әйтеп бетергесез бәхет була. Әлбәттә, ул әле киләчәктә байтак кына чит илләрдә дә буласын башына да китереп карамый. Дөрес, бу беренче сәяхәт Айрат өчен күңелсезрәк тәмамлана. Харьковта рингка чыгуга ул беренче көндәшенә үк оттыра. Берәү мондый уңышсызлыктан соң барысына кул селтәр иде. Ләкин Айрат андыйлардан түгел. Киресенчә, ул үз-үзенә сүз бирә: тренерын шатландырачак, нәрсәгә сәләтле икәнен барыбер расләячак, үзенә багышланган вакытның әрәмгә узмаганын күрсәтәчәк.

Менә шуннан соң малай бокска тагын да «үҗәтләнебрәк» ябыша. Әнисе, абыйсы белән авылга китмәве дә нәкъ менә шуның белән аңлатыла. Тренер Минхан Вәлиуллин малайга әтисен, аннары әнисен дә алыштыра. Бәхетсезлек очрагы аркасында Айрат белән Азат әнисез дә калалар. Язмыш ике бертуганны ике якка ташлый: берсе — Чаллыда, икенчесе Казанда яши. Юлында Минхан Вәлиуллин, Виктор Краснов, Павел Царев, Фоат Гатин кебек кешеләр очрамаса, белмим, Айрат язмышының бу сынауларына ничек каршы торыр иде икән?!

8 классны тәмамлаганнан соң малай, тренеры Вәлиуллин ярдәмендә, 53 нче һөнәр училищесына укырга керә, эретеп ябыштыручы булырга әзерләнә. Монда да мәктәптәгечә дәвам итә: төшкә кадәр — дәресләр, төштән соң — күнегүләр. Янында бер якыны да яшәмәгәч, Айратка кыен була, әлбәттә. Училищеда бирелә торган стипендия әллә ни түгел: кесәдә бик тиз җилләр уйный башлый. Ярый әле, дуслары, остазлары ярдәм итә. Абыйсы исә гел үзе янына чакыра, бергә яшәгәч, җиңелрәк булыр, янәсе...

Училищедан соң Айрат Казан оптика-механика заводына эшкә урнаша. Тормышлар бераз җайлана төшә, тулай тораклан бүлмә бирәләр. Бүлмәдәше Виктор Царев Айратның чын дустына, аның кайгыртучысына әйләнә. Токарь Виктор Айрат турында туган абыйсыдай кайгыртырга тырыша. Малай өчен көннәр буе ач йөрүләр бетә, өс-баш та бөтәя. Царев аңа яңа эштә дә гел ярдәм итеп тора. Бу дуслык белән Айрат хәзер дә горурлана. Тулай торак бүлмәсендә алар дистәләп ел бергә яшиләр.

Куйбышев шәһәрендә армия сафларында хезмәт иткәндә дә Айрат чын остазлар кулына килеп эләгә. Атаклы боксчы Василий Шишов белән бергә күнегүләр үтү генә дә ни тора?! Өлкән иптәшенең киңәшләре, хәер-фатихасы егет күңеленә шифа булып иңә. Шишовның кешелеклелек сыйфатлары өчен иптәшләре аны илебез җыелма командасы капитаны итеп сайладылар да инде. Ләкин спорт чиновниклары аны аңларга теләмәде. Нәтиҗәдә, чемпион зур спорт белән хушлашты һәм, кайбер иптәшләре кебек, кооператорлар сафын тулыландырырга мәҗбүр булды. Нишлисең, сәләтеңнән файдалану өчен бу — әлеге иң кулай юл.

Ниһаять, Айратның тагын бер остазы турында сөйләргә чират җитте. Виктор Васильевич Краснов. Ул Хаматовны Вәлиуллиннан кабул итеп ала. Алар инде берничә ел шулай эшлиләр: берсе яшүсмерләрне боксның беренчел серләре белән таныштыра, өметлеләрне билгели, икенчесе инде әлеге өметле яшьләр белән тагын да киеренкерәк, тынгысызрак эш башлый. Моңарчы ил чемпионатларында чыгыш ясаган Владимир Индюков, Виталий Шобанов, Арслан Гарифуллин — әлеге ике остазның уртак ачышлары.

Краснов карап торышка усал, кырыс кебек. Ләкин тора-бара бу фикереңнән бик тиз кире кайтасың. Оста педагог һәр малайның күңеленә юл таба белә. Сафның койрыгында гына торучы, шуңа күрә һәрчак күзгә бәрелүчән Айрат аңа кай ягы белән ошагандыр, хәзер әйтүе кыен. Остаз белән шәкерт тиз арада уртак тел табалар. Шуңа күрә уңышлар да озак көттерми...

Мәскәүдә узган дөнья чемпионаты алдыннан Айратның инде мактанырлык уңышлары бар иде. Ул ил, Европа һәм дөнья күләмендә дә инде танылып өлгергән иде. АКШ, Куба, Таиландта үткән халыкара турнирларда җиңүләр үзләре генә дә ни тора?! Әмма дөнья беренчелегендә җиңү — бу инде бөтенләй башка. Планетаның көчле боксчылары арасында иң көчле булып танылу — бу инде ничә ел хыялланган хыялларның тормышка ашуы.

Дөнья чемпионатында катнашу өчен башта илнең җыелма командасына керергә кирәк. Бу ничек мөмкин булды соң?

Мәскәүдә чемпионат башланыр алдыннан Подольск шәһәрендә сайлап алу ярышлары үтте. Анда Казаннан тагын бер егет — тренер Сергей Ромадановский шәкерте, А. Хаматовның якын дусты Фоат Гатин да катнашты. 54 килограммга кадәрле авырлык үлчәвендә чыгыш ясаучы Фоат рингта Сеул Олимпиадасына бронза медаль алган Тимофей Скрябинны һәм Владимир Присяжныйны бирелергә мәҗбүр итә. Ә менә Ленинград егете Владимир Антонов белән очрашуда Гатин җәрәхәт ала. «Якын сугыш»та көндәше башы белән Фоатның ияген җимерә. Нәкъ менә шушы җәрәхәтне сәбәп итеп, тренерлар җыелма командага Гатинны түгел, ә Скрябинны керттеләр. Тик ул, кызганычка каршы, хәтта чирек финалга да барып җитә алмады. Әгәр дә әлеге җәрәхәт булмаса яки тренерлар тәвәккәлрәк эш итсә, Казанга, бәлки, ике медаль кайтыр иде. Фоат та — Айрат кебек, үзен шәп таныткан боксчы. Аларның спорт биографияләре берберсенекенә үрелеп бара. Күнегүләргә дә алар күп вакыт бергә йөриләр, төрле җыеннарга да бергә баралар...

Инде яңа Айратка кайтыйк. Командадагы 12 төрле авырлык үлчәвенең унберендә кандидатлар бик тиз билгеле булса да, 57 килограммга кадәрле авырлык үлчәвендә кем чыгыш ясаячагы турындагы мәсьәлә һаман да хәл ителмичә кала. Ике кандидатның кайсын сайларга: дебютант Хаматовнымы, әллә Ленинградтан «Динамо» вәкиле — СССР чемпионы Александр Артемьевнымы? Хаматов соңгы вакытта аз җиңелә. Артемьев исә Европа беренчелегендә һәм XXII җәйге Олимпия уеннарында начар чыгыш ясады, соңгы вакытта үткәрелгән җиде халыкара очрашуның икесендә генә отты, Айрат үзенең 9 көндәшенең җидесен бирелергә мәҗбүр итте. Сайлап алу ярышларында исә Александрны Әрмәнстан вәкиле Арсен Казарян җиңде, Хаматов исә Казарянны 5:0 исәбе белән отты. Күргәнегезчә, беренче карашка ук, өстенлек А. Хаматовка бирелергә тиеш. Юк шул, өлкән агайлар алай тиз генә хәл итәргә теләмиләр...

Торгынлык елларының тәэсире, җәмгыятебезнең башка өлкәләрендәге кебек, спортта да сизелә әле. Бу өлкәдә эшләүче чиновникларның административ-команда алымы эш йөртүе спортчыларга да, аларның тренерларына да байтак зыян китерде, аларның мөстәкыйльлеген буып торды. Дан, акча артыннан куу, бер-берең юл бирмәү кебек күренешләр чәчәк атты, күп нәрсә осталыкка түгел, ә бәлки таныш-белешлеккә нигезләнде. Мондый күренешләр бокс буенча илебез җыелма командасын Александр Лавров җитәкләгән вакытта аеруча зур үсеш алды. Җыелма команданың шулай кодакодагыйлык буенча тупланыуы үкенечле җиңелүләргә китергәләде. Сеулдагы Олимпия уеннарында да безнекеләр үзләрен күрсәтә алмады. Шуңа күрә кайберәүләр, Мәскәүдә үтәчәк дөнья чемпионатында СССР вәкилләре уңышка ирешер, дип өметләнмәделәр дә.

Ниһаять, җыелма команданың баш тренеры итеп Константин Копцов билгеләнә. Ул А. Лавров тарафдары түгел иде. Копцов спортчыларның тренерларына ирек бирә, алар белән киңәшләшеп эшли башлый. Элегрәк шәхси тренерларның фикере бөтенләй исәпкә алынмый иде. Сайлап алу ярышларында да Копцов Артемьевның да, Хаматовның да остазларын игътибар белән тыңлый. Ниһаять, тренерлар киңәшмәсендә аларның кайсын командага алу мәсьәләсе куелгач, кулын Хаматов өчен күтәрә. Әлбәттә, Копцов тәкъдиме белән исәпләшергә теләмәүчеләр дә табыла. Җыелма команда членнарының да кайберләре Артемьев ягында була: янәсе, без Александрны Айратка караганда әйбәтрәк беләбез, ул — сыналган сугышчы. Менә шундый вакыйгалардан соң Ай-

ратның нинди хәлдә калганын күз алдына китереп карагыз. Үзенә каршы оештырылган бу «психологик һөҗүм» вакытында да егет каушап калмый. Ул аңлый: монда аңа шәхсән бәйләнмиләр, бу — Айратка ышанмау түгел, ә бәлки аның башка милләт кешесе булуында түгелме? Кем белә?.. Башка милләт кешеләренә юл бирергә теләмәү тормышыбызда әле очраштыргалый. Хәтерлисездер, шахматчы Гата Камский вакыйгасының кайтавазы бик еракларга ишетелде. Әтиле-уллы Рөстәм һәм Гата Камскийларның АКШта калуына нәрсә сәбәпче булганын мин «Татарстан яшьләре» газетасында басылган «Гата Камский вакыйгасы яки талантлы шахматчының илгә кайтмавы турында» (1989 ел, 31 август) дигән язмада аңлатырга тырышкан идем инде. Камскийлар хәзер АКШ гражданины статусын алдылар. Гата, кайберәүләр алдан раслаганча, Штатларда югалып калмады — киресенчә, инде ул берничә турнирда җиңеп, шактый саллы призларга лаек булды.

Футболчы Вәгыйз Һидиятуллинның спорт биографиясе ничек катлаулы? Язмыш спорт интернатында тәрбияләнгән егетне нинди генә командаларга ташламады: ЦСКА, СКА, «Карпаты» (Львов), «Спартак» (Мәскәү)... Хәзер ул Франциянең «Тулуза» клубында уйный. Казан кызы, өч тапкыр дөнья чемпионы Алисә Галләмовага шахмат буенча халыкара гроссмейстер исемен бирү дә, шахмат функционерлары гаебе белән, гел сузыла килде... Әйе, киртәләр җитәрлек. Әмма моңа карап, шөкер, милләттәшләребез спортта сынатмый. Моны раслау өчен түбәндәге исемнәрне санау да җитә торгандыр: бөтен дөньяда билгеле футбол капкачысы Ринат Дасаев (ул бүгенге көндә Испаниянең «Севилье» командасы данын яклый), хоккейчылар Зиннәтулла Билалетдинов («Динамо», Мәскәү командасы тренеры) һәм Мидхәт Фәхретдинов (чит ил командасында чыгыш ясый), шахматчы Артур Йосыпов, мотоциклда узышу буенча җиде тапкыр дөнья чемпионы Габдрахман Кадыйров (хәзер ул — Башкортстан дәүләт филармониясендә администратор), фехтование буенча олимпия чемпионнары Наилә Гыйлаҗева һәм Ольга Князева (бүгенге көндә икесе дә тренерлар), Олимпия һәм дөнья чемпионы чаңгычы Федор Симашев («Динамо» җәмгыятенең Үзәк Советында тренер), регби остасы Рамил Хәйруллин, марафончы Равил Кашапов, көрәшче Ленар Сәлимуллин...

Подольскига Айрат белән ТАССР дәүләт спорт комитеты председателе урынбасары Мансур Мифтахов та барган иде. Гаделлек яратучы бу кеше турында бары тик мактау сүзләре генә әйтәсе килә (республикада милли спорт төрләренә игътибар бирелә башлау аның исеме белән дә бәйле). Мансур Мифтахов сайлап алу ярышларында Айрат өчен барган көрәшне җиңеп чыгарга булышучыларның берсе булды. Айрат үзенә күрсәтелгән ышаныч-өметләрне, үзенә салынган көч, тырышлыкларны аклады. Совет спортчылары арасында мондый сүз йөри: җыелма командага эләгү — чемпион медален яулауга караганда кыенрак. Бу сүзләрдә, мөгаен, азмы-күпме хаклык та бардыр, әмма чемпион исеме беркайчан да җиңелдән бирелми...

Баштарак Хәматовны җыелма командага кертүгә каршы торган командадашлары Айратка ничек карый соң? Дебютантның нәрсәгә сәләтле икәнен, рингта бар көчен биреп көрәшкәнен бик тиз күреп алалар. Шулай ул иптәшләренең мәхәббәтен казана. Команда капитаны Александр Мирошниченко, иң авыр үлчәүдә чыгыш ясаучы боксчы, Айратның ничек тырышканын күреп, еш кына аның җилкәсеннән каккалап ала: булдырасың, янәсе... Шунысын да әйтик, әлеге чемпионатта Мирошниченко көмеш медаль белән генә канәгатьләнде. Финалда ул легендар Теофило Стивенсонның (ул хәзер бокс буенча Куба җыелма командасын җитәкли) алмашчысы Роберто Баладага оттырды.

Айрат Мәскәү чемпионатында биш тапкыр рингка чыкты. Һәр очрашуны игътибар белән күздән кичерик, чөнки аларның һәркайсы пьедесталга менүдә хәлиткеч бер адым булып тора. Айратның беренче көндәше Румыния вәкиле Октавиан Стойка иде. Тәүге бәрелеш һәрвакыт авыр була. Өстәвенә, кайберәүләрнең эчтән генә якташыбызның җиңелүен теләп торганын да (мондый очракта аларның сүзе өстен чыгачак бит!) искә алсак, бу очрашуның Айрат өчен нинди кыйммәткә ия булганын күзаллау кыен түгел. Әмма Айрат каушап калмый...

Икенче очрашу — Гыйрак спортчысы Аббас Калеф белән. Әлеге ил вәкилләре бокста көчле түгел түгелен, ләкин дөнья чемпионатында көчсез көндәшләр булмаганын истә тотарга кирәк. Айрат бу юлы да ота, шуның белән бергә аңа булган ышаныч та арта бара.

Айрат үзе өчен иң авыры чемпионатта Көньяк Корея боксчысы Ха Хва Те белән очрашу дип саный. Беренчедән, Азия вәкилләре традицион бокс алымнары белән эш итмиләр, аларның сугышу тәртибе башкача. Икенчедән, Айрат рингка чыгар алдыннан җиңелчә салкын тидерә. Нәтиҗәдә, көрәшкә температурасы күтәрелгән хәлдә чыгарга мәҗбүр була. Шулай да Хәматов җиңүне ычкындырмый. Бу җиңүдән соң аның үз-үзенә ышанычы арта, хәтта чемпион исеме турында уйлый башлый. Виктор Краснов белән аның шәкерте чемпионат алдыннан үз алларына нинди максат куялар соң? Алар бронза медаль алырга өметләнәләр. Өченче урын да дебютант өчен җитди уңыш булачак

иде. Копцов та моның белән килешә. Краснов һәм Хаматовның «алтын»га үрелергә исәпләре барлыгын белгәч, әлбәттә, ул аларга каршы килеп маташмый, хәтта мөстәкыйль әзерләнү өчен шартлар тудыра.

Дүртенче көндәш — Куба боксчысы, дөнья кубогы хуҗасы Арнольда Меса. Бу очрашуны Айрат җиңел отты. Үзенең әйтүе буенча, ул хәтта әлеге бәйгедән соң тирләп тә чыкмаган. Бәлки, трибуналарның «ярдәме» тигәндер. «Олимпийский» комплексына барып әләгүчеләр һәм шулай ук телевизор караучылар яхшы белә: Айрат рингка чыкканда трибуналар «Айрат, Казан!» дигән авазлардан гүләп торды. Ул беренче очрашуыннан ук тамашачылар мәхәббәтен яулады.

Арнольда Меса җиңелде. Димәк, көмеш медаль кесәдә инде. Әмма хәзер Айратны алай гына туктатып булмый инде. Финал: 57 килограммга кадәрле авырлык үлчәвендә Айрат Хаматов (СССР) һәм Киркор Киркоров (Болгария) очраша. Болгария вәкилләренең соңгы вакытта бокстагы уңышлары бәхәссез. Киркоровның Европа чемпионы исемен йөртүе моңа тагын бер дәлил. Әмма Айрат чемпионга сулу алырга да ирек бирмәде. Аның татарга хас бер ныклык, үҗәтлек белән һөҗүм артыннан һөҗүм оештырулары көндәшенә бөтенләй мөмкинлек калдырмады. Өч раунд дәвамында ул Киркоровны өч тапкыр нокдаунга җибәрде, ягъни көндәше өч тапкыр аңын җуеп алды. Судьялар Хаматовның сизелерлек өстенлеген күреп, очрашуны, тиешле вакыты беткәнче, туктатырга мәҗбүр булалар. Чемпионатта башка бер генә тапкыр да мондый хәл кабатланмады. Ни өчен шундый тактика сайлавын Айрат болайрак аңлатты. Финалга Киркоровтан тыш, Болгариядән Тодоров та чыккан иде. Әмма ул беренче көнне үк оттырды. Болгарларның өмете Киркоровта булды. Җитмәсә, судьялар комиссиясен АИБАның (халыкара бокс федерациясе) вице-президенты профессор Э. Жечев (Болгария) җитәкли. Шуңа күрә төрле хәлләр котәргә була. Димәк, бары бәхәссез өстенлек кирәк! Казан егете шуңа иреште! Монда инде Жечев та, башкалар да берни кыла алмый иде.

Менә шулай Айрат татарлар арасында бокс буенча беренче дөнья чемпионы булып танылды. Ә җыелма командага Хаматов китергән бишенче алтын медаль безнекеләргә Куба вәкилләрен узып китәргә мөмкинлек бирде. Менә шулай дебютант үзен бөтен дөньяга танытты, үзен күпләр алдында раслады. Рәхмәт аңа!

...Айрат һәм Азат Хаматовлар белән Казан Спорт сараенда утырабыз. Хоккей матчы бара. Якташларыбыз, Урицкий исемендәге спорт клубы командасы хоккейчылары, илебездәге иң мәртәбәле коллективларның берсе — «Динамо» (Мәскәү) белән уйный. Өстенлек — кунаклар ягында.

— Беләсеңме,— ди Айрат,— минем чемпион булуда аларның да өлеше бар бит... «Олимпийский»да бокс барганда урицкийлылар Мәскәүдә очрашулар үткәрделәр. һәм, күпләрне гаҗәпкә калдырып, ЦСКА белән «Спартак»ны җиңеп куйдылар. Мин әйтәм, нишләп миңа да якташларымнан үрнәк алмаска?!.

Диктор Спорт сараена җыелган тамашачыларга уенны бокс буенча дөнья чемпионы Айрат Хаматов та каравын әйтә. Айрат шыгрым тулган трибуналарга гаепле сыман оялып кына башын ия. Аңа чемпионлык хәленә яраклашу кыен кебек. Хәер, безнең халыкка элек-электән тыйнаклык хас. Айратка якынрак торучылар автограф алырга хоккей программаларын аңа сузган арада абыйсы Азат кушыла:

— Айратны журналистларыбыз читтә калдырмады, рәхмәт аларга. Ләкин сезнең халыкка бер дәгъва белдерәсем килә. Фамилияне ике «м» белән язасыз, безнең бөтен документлар электән үк бер «м» белән генә языла. Ул ерак бабабыз Минхәмәттән килә...

Шуңа да, Азатның теләген истә тотып, мин «Хаматов» дип яздым. Хәер, исемдә генә түгел хикмәт, ә бәлки җисемдә, дип юкка гына әйтмиләрдер. Моның шулай икәнен Айрат күрсәтте инде. Шунысын да әйтик, абыйсы Азат гаиләсе белән хәзер дә Чаллы каласында яши, шәһәрнең электр челтәрендә эшли.

Гаилә дигәннән, узган елның ноябрь аенда Айрат та башлы-күзле булды. Күптән яратып йөргән Резедасы белән тормыш корып җибәрделәр.

Шатлык өстенә шатлык дигәндәй, СССР Дәүләт спорт комитеты коллегиясенең чираттагы карары дөнья күрде: спорт өлкәсендәге уңышлары өчен Айрат Касыйм улы Хаматовка — «СССРның атказанган спорт мастеры», ә Виктор Васильевич Красновка «СССРның атказанган тренеры» исемнәре бирелде. Кызганыч, чемпионның беренче остазы Минхан Вәлиуллин игътибардан читтә калды. Тәүге остазны, башкалар оныта да, Айрат оныта күрмәсен иде! Чемпионат көннәрендә ул шәкертеннән ким дулкынланмагандыр.

1989 елның спорт нәтиҗәләре буенча Айрат Хаматов республикабызның һәм Казанның иң яхшы спортчысы булып танылды.

Офыкта — Испаниянең Барселона шәһәрендә узачак XXV җәйге Олимпия уеннары. Бу вакытта 1965 елның 2 февралендә дөньяга килгән Айрат Хаматовка 27 тулачак. Олимпия чемпионы өчен иң уңай яшь, минемчә.

# ЯҢАРЫШ ҺӘМ ӘДӘБИЯТ

ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ ЯНЫНДА ӘҢГӘМӘ

## Фәез Зөлкарнәев:

— «Яңарыш»... Соңгы биш елда татар матбугатында бу сүз бик еш телгә алына башлады. Урысларның «перестройка» сүзен бездә шулай тәрҗемә иттеләр. Ләкин мин бу атама белән килешмим. Яңарыш — димәк, яңа! Димәк, яңа икәне бәхәссез! Ә бәхәссез нинди яңа нәрсә бар соң әле безнең тормышта, безнең әдәбиятта? Бары тик яңартуга омтылышны гына күрәбез ич әлегә. Ә ул омтылыш безне кая илтеп чыгарыр — яңагамы, әллә искегәме — хәзергә билгесез. Бабаларыбыз мондый очракта төгәлрәк сүзләр кулланганнар: «ислах заманасы», «үзгәрешләр заманасы» дип әйтә торган булган алар. Яңарыш икән, ул сыйфат яңалыгы, яңача яшәү һәм фикерләү рәвеше алып килергә тиештер бит инде. Мондый яңалык әлегә безнең татар әдәбиятында күренми, минемчә. Кайбер графоманнарыбызның моңарчы тыелган темаларны шау-гөр килеп яза башлавы гына «яңарыш» була алмый. Андый «тыелган» темаларны намуслы әдипләребез элек тә онытмадылар — яздылар. Фәкать ул әсәрләрнең чын бәясен аңлаучылар, чын асылын бәяләүчеләр генә җитмәде.

Менә ничә ел инде рәттән җитәкчеләр һәм көндәлек матбугат «яңача фикерләү» дип авыз суын корыталар. Дөрес, «яңача фикерләү» халыкара мөгамәләләр өлкәсендә үзенә ныклы урын яулады, анда аның тәэсире сизелерлек. Андый фикерләүнең һаман саен киңрәк хокук яулый баруы хәтта СССРда беленә башлады. Союздаш республикалардагы иҗтимагый-сәяси хәрәкәтләр, милли-мәдәни уяну, тернәкләнү — һәммәбезнең күз алдында. Ә бездә, безнең республикада бармы соң болар? Бармы бездә яңача фикерләү?

Әдәбияттагы яңарыш, барыннан да элек, менә шул фикерләү рәвешенең яңаруына бәйле, минемчә.

## Гәрәй Рәхим:

— Безнең илдә менә инде биш ел буе рухи яктан теге яки бу күләмдә яңарыш барса да, матди яктан халык көнкүрешендә торгынлык дәвам итә. Брежнев заманында игълан иткән Азык-төлек программабыз үтәлмәде, инде үзгәртеп кору елларында игълан иткән «Торак-2000» программабызның да якын елларда үтәлмәячәге билгеле булды. Халыкка кирәкле көнкүреш товарлары кибетләренең киштәләре һаман буш әле.

Инде рухи яңарыш барышының илдә һәм үзебездәге тизлегенә килсәк, бу яңарышны мин үзгәртеп коруның иң зур казанышы дияр идем. Әлбәттә, темплар төрле җирдә төрлечә. Әйтик, Мәскәүдә рухи яңарыш тизрәк бара, аның эчтәлеге дә тирәнрәк, колачы да киңрәк (мин үзәк газета-журналларын, радио-телевидениесен, халык тормышының төрле өлкәләре буенча үткәрелә торган Бөтенсоюз киңәшмәләрне, съездларны һәм СССР Югары Советы съездларын, сессияләрен күз алдында тотам). Әмма дистә еллар буе Мәскәүдән өркеп яшәгән, илнең рухи һәм матди тормышында «демократик централизм» дигән тәгъбирнең «демократик» дигән төшенчәсен төшереп калдырып, аның «централизм» дигәнен генә кулланып өйрәнгән провинция әле һаман яңарышны бик авырлык белән кабул итә, бу өлкәдә алдына-артына бик нык карап кына эш йөртә. Безнең Татарстанда исә бу күренеш аеруча ачык чагыла. Мисалга халкыбызның иң укымышлы һәм талантлы язучыларыннан берсе булган Гаяз Исхакыйны һәм аның әдәби мирасын кире халкыбызга кайтару һәм әдәби иҗтимагый хәрәкәтебезгә кертеп җибәрү эшенең никадәр каршылыклар, кыенлыклар белән алып барылганлыгын искә тө-

шереп үтү дә җитә. Ә бит Исхакый һәм аның мирасын кире кайтаруга каршылык күрсәтүче, аны тоткарларга тырышучы көчләр гап-гади кешеләр даирәсеннән түгел, республикабызның рухи һәм матди тормыш дилбегәсен кулларында тотып баручы җаваплы даирәләрдән иде. Миңа калса, үзгәртеп кору закончалыклары буенча, бу даирәләр рухи яңарышны тоткарлау түгел, ә киресенчә, яңарышны тизләтү эшенең башында торырга, хәтта шул эш белән җитәкчелек итәргә тиешләр иде. Әйтик, Балтик буе республикаларында рухи яңарыш башында нәкъ менә җитәкче даирәләр тора. Бездә исә бу даирәләрдәге мәгълүм дәрәҗәдә тамырланган консерватизм яңару эшенең акрын темплар белән баруына тәэсир итми калмый.

Акрынлыкның икенче сәбәбе — безнең милли интеллигенциянең иҗтимагый һәм сәяси яктан гаять тә сүлпәнлеге. Әйтик, илдә үзгәртеп кору башланганга инде биш ел вакыт үтте, бөтен халык үзенең тарихи, сәяси, сәнгати байлыгын барлый, үзенең законлы хокукларын ничек тормышка ашыру турында уйлана. Әмма безнең язучылар, композиторлар, рәссамнар, архитекторлар, артистлар, әдәбият-сәнгать белән шөгыльләнүче галимнәр, культура эшлеклеләре бүгенгә кадәр бөтенесе бергә җыелышып республикабыздагы рухи яңарышны ничегрәк тизләтү юллары турында сөйләшә алганнары юк. Минемчә, әдәбият, сәнгать, мәдәният, фән әһелләренең берләштерелгән конференциясен үткәрү эше кичектергесез булып көн тәртибенә килеп басты. Игътибар итегез, мин монда Татарстан АССРда яшәүче әһелләр турында гына сүз алып бармыйм; бу конференциягә илебезнең төрле почмакларында һәм чит илләрдә яшәп иҗат итүче әдәбият, сәнгать, мәдәният һәм фән кешеләре чакырылырга тиеш. Халкыбызның иҗтимагый тормышындагы рухи яңарышны тизләтүдә бу конференциянең гаять зур әһәмияте булыр иде.

## Рашат Низамиев:

— Әдәбиятыбыз шушы көнгә кадәр артта да өстерәлмәде, алга да чәчрәп чыкмады, ә бәлки уртаданрак барды шикелле. Ә инде урталыкның нәтиҗәсен беләбез: ул артык сүгелми дә, әллә ни дан да китерми. Ни өчен Чехов, Достоевский яисә Айтматовларыбыз юк? Ни өчен бөтенсоюз мәйданда татар әдипләренең исемнәрен ныгыта алганыбыз юк? Тикшерә китсәң, моның сәбәпләре күп, әлбәттә. Мин исә шуларның берсенә ныграк тукталырга телим.

Чагыштыруым тупас тоелса тоелыр, әмма өзеп әйтәсем килә: торгынлык елларында әдәбиятыбыз аркандагы бозау хәлендәрәк иде. Аның билгеле бер радиуста гына хәрәкәт итәргә хакы булды. «Сызык»ның теге ягына тартылдыңмы, баш очында, алай гына да түгел — тәмам сыртында ук уяу оешмаларның чыбыркысы шартлый башлый: рөхсәт ителгән җирдә генә йөр, янәсе! Менә сезгә нефть һәм производство кишәрлекләре, КамАЗ һәм ТатАЭС темалары, «нык үскән социализм»ны төзүче каһарманнар... Шулар хакында язсаң, тамагың тук, өстең бөтен булыр, әле әдәбият өлкәсендәге уңышларың өчен дәүләт премиясе алып куюың да бик ихтимал. Күпләребез, бик күпләребез шушы җиңел, мактаулы юлдан киттек, йөрәк һәм каләм көчебезне зур-зур төзелешләргә дан җырлау, аның кешеләрен пьедесталга күтәрүгә сарыф иттек. Заманның әхлаксызлык, имансызлык, экология һәм демократия кебек иң актуаль проблемалары игътибардан җуелды, аңыбызны томалаган алсу пәрдәнең теге ягында бүленеп калды. Яраклаштык, илһам дулкынын «югары»дан искән җилләр уңаена көйләргә тырыштык. Әдәбият күпмедер дәрәҗәдә кәсепкә әйләнде.

Партия һәм административ органнарның әдәбият-сәнгать өстеннән туктаусыз җитәкчелек итүе, аңа идеологик юнәлеш биреп торуы әнә шундый аяныч нәтиҗәләргә китерде.

Тыелган темалар, әдипнең чабуыннан тартып, һаман саен кисәтә килде: «Әй, ярамый, ярамый!». Күпләребез шушы таләпчән тыюны кабул иттек, дөреслеккә күз йомдык. Кырыс хакыйкатьне язуга караганда алсу буяулар белән эш итү отышлырак, абруйлырак иде. Бер үк темалар кабатланды, чәйнәлде — бу күренешкә тәнкыйтьчеләр тора-бара «арыганлык» дигән мөһер сугып та өлгерделәр. Нәтиҗәдә, сүзнең кадере бетте, тәме китте, ничек кенә сәер тоелмасын — әдәбиятта девальвация чәчәк атты.

Артист, кул чабып сорыйлар икән, халык теләгән җырларны бик теләп башкара. Сәхнә өчен табигый хәл бу. Язучы исә кул чабып ни сорасалар, шуны эшләп утырырга гына тиеш түгел. Аның вазифасы, тарихи миссиясе — бер адым алдан бару! Халык тормышының, иҗтимагый хәятнең киләчәген сиземләү, шатлык яки хәвеф булып ургылачак хәлләр офыгыннан сөрән салу...

Ә без юл ярып, алдан бара белдекме? Экология, табигатьне саклау мәсьәләсендә әдәбият беренчеләрдән чаң кагарга тиеш иде. Ә без, киресенчә, роман яки повестьларыбызда табигатьне җимерә килгән зур-зур төзелешләрне зурладык, җирне әҗүҗмәҗүҗдәй ашап килгән экскаваторларны мактап яздык. Туган телнең бетүе һәм мил-

ли культуралар экологиясе уңаеннан да әдәбият үзенең ныклы сүзен башлап әйтергә тиеш иде.

## Марсель Галиев:

— Тормышта без, миражлар уйлап чыгарып, алданырга яратабыз. Ярдан ярга ташланабыз. Әдәбиятне магистраль юлыннан бүлеп, вак ерганакларга аерып җибәрергә тырышабыз. Беләбез, тоябыз бит югыйсә — чын әдәбият вакытлы шаукымнардан өстен тора, шуңа күрә аңа таләпне дә ашыкмыйча, гасырлар акылы туплаган биеклектән торып куярга кирәктер.

Чын әдәбият тудыру өчен кешелек китаплары — корьән һәм библия, мораль, философиянең мең еллар буе чарланган зирәк акыл хәзинәсен белү кирәк. Бу зарури фән яшьтән үк ана сөте белән керергә тиеш. Кызганыч, без болардан мәхрүм үстек. Шуңа күрә әдәбияттә үзешчәнлек кабыгыннан чыга алмыйбыз. Баш миебез йокымсыраган хәлдә кала бирә. Борын-борынгыдан ук шәрык, бигрәк тә һинд һәм Кытай философиясе кешене галәм югарылыгына куеп караган. Чиксезлек һәм мәңгелекнең аерылгысыз өлешен тәшкил иткән галәми кеше җанына канат куя белгән шәрыкның фикер дөньясы әнә шулай итеп шәхесне көндәлек ыгы-зыгылардан биеккәрәк чөйгән. Үз алласын күңелендә тойган кеше бүтәннәргә дә, хәтта җан иясенең иң кече туганына — бөҗәкләргә карата да гаҗәп инсафлы булган. Табигатькә табыну аның җанын матурлаган.

Ә без — имгәтелгән, үтә берьяклы, кеше җанын исәпкә алмаган ярлы философия нигезендә тәрбияләнгәннәр — бәхетне бары җирдән табарга омтылган хәлдә, табигатькә һәм кешегә карата мәрхәмәтсезгә, коточкыч явызларга әйләндек. Күзе тонып, каядыр вак максатларга омтылган эш атлары әдәбият геройларына әверелде. «Тормышны өйрәнеп язарга кирәк!»— дигән мәгънәсез лозунглар ташланды. Берәү дә тормыштан читтә яши алмый, тормышны өйрәнергә түгел, ә аннан мәгънә чыгара белергә кирәк. Аның өчен әдиптә акыл, гамь тәрбияләнергә тиеш.

Без, берничә дистә ел эчендәге әдәби мираска таянып, тиз генә классикларны билгеләп куйдык, әсәрләрен дәреслекләргә керттек. Югыйсә бит әдәбият тере әгъза кебек, анда һәрчак көрәш бара, вакыт бишегендә рәхәт тирбәлеп кенә ята алмыйсың, анда рәхимсез, гадел сайланыш кануны хакимлек итә.

Безгә, артка борылып карап, утызынчы елларда язылган күп әсәрләрнең ялган чүп икәнен әйтеп чыгар вакыт җитте. Киләчәктә хаталанмас өчен кирәк ул безгә.

Вакыт белән бергә җәмгыять үзгәрә, әхлакый кануннар бүтән төс ала. Тормыштан өстенрәк булып, алгарак омтылган фикри аң, чын тарихилык белән сугарылмаган әсәрләр гамәлдән төшеп кала бирә. Рухы бөкре геройлар эстетик яктан алама карачкыны хәтерләтә.

Вакыйга сөйләүгә генә корылган көнкүреш әдәбияты үләргә мәхкүм. Тормыш агачының ябалдашына карагач, тамырын, тамырына карап ябалдашын тоярлык тигез гармониядә, фәлсәфи гомумиләштерелгән, кешенең баш мие югарылыгына менә алган әдәбият кенә озын гомерле булачак.

Ә без бүген, һаман да шулай вакытлы шаукымга бирелеп, күбрәк көнлекче әдәбият турында сөйләшәбез. Мин, фикеремне җәелдереп җибәрергә җирлек тапмыйча, аптырабрак калдым әле.

## Рафаэль Мостафин:

— Әйе, без, гадәттәгечә, артта, койрыкта сөйрәлеп барабыз. Моның сәбәпләре — кыюлык җитмәүдә генә түгел. Мәсьәлә, минемчә, тирәнрәк: олы талант, чын белем, зур эрудиция, киң карашлар җитешмәүдә. Бу мәсьәләдә мин М. Галиев белән тулысынча килешәм: җитди фәлсәфи нигез булдырмыйча, тормышны бөтен катлаулылыгы белән аңлап та, тасвирлап та булмый.

Яңарыш кирәк дип, күпме генә кычкырма, хәл үзгәрмәячәк. Иҗади эзләнү, югары таләпчәнлек кирәк. Без бер яктан да берәүдән дә ким түгел. Ләкин үзебезгә үзебез ташлама ясап, таләпләрне киметеп, мескенләнәбез, укучы ихтирамын югалтабыз.

## Фәез Зөлкарнәев:

— Дөньякүләм сәясәттә «яңача фикерләү» дигәндә, гадәттә, глобаль масштабта фикер йөртүне, илләр-халыклар язмышы бер-берсенә тыгыз бәйләнгән икәнен аңлап эш йөртүне күз алдында тоталар. Ягъни «андагылар»— үзбашка яшәп ятучы бәйсез, мөстәкыйль милләтләр — үзләренең башка милләтләргә күпмедер дәрәҗәдә бәйле икәнлекләрен аңладылар. Чөнки дөнья бербөтен икән, космос заманасында, компьютерлар цивилизациясе башланган хәзерге заманда моны аңламау мөмкин түгел.

Ә СССРда һәм «социализм системасы»ның башка илләрендә «яңача фикерләү» бөтенләй бүтән юнәлеш алды. Монда үзара бәйлелек, интеграция күренешләре түгел, ә, киресенчә, бәйсезлеккә, суверенитетка омтылу тенденцияләре өстенлеккә ирешге. Безнең халыкта да нинди дә булса уяну, хәрәкәт билгеләре бар икән — ул барыннан да элек менә шушы тенденциянең чагылышы. Ләкин, уйлыйк әле, яңалыкмы соң бу? Безнең әдәбият өчен яңалыкмы?

Мин моны яңалык түгел дип әйтер идем.

Нигә яңалык түгел? Шуны аңлатырга тырышып карыйм.

Әдәбиятыбызда, рухи тормышыбызда мин әлегә фәкать бер генә яңалык күрәм. Ул да булса без хәзер татар мәдәниятен, татар әдәбиятын бербөтен итеп карау, тикшерү, аңлау мөмкинлегенә ия булдык. «Идегәй»ләр һәм Г. Исхакыйларның үзебезнеке икәнен, мөселман дининең, ул тудырган рухи хәзинәләрнең үзебезнеке икәнен, ниһаять, таныдык һәм аңладык шикелле. Милләтебезнең рухи үсеш-хәрәкәт юлын, мәдәният һәм әдәбият тарихыбызны менә шушылай бербөтен итеп карау җае тугач, аермачык итеп зур бер «яңалыкны» күрдек. Менә ничә гасырлар инде, Иван Грозный заманнарыннан бирле, татар иҗтимагый фикеренең умыртка баганасын тәшкил иткән төп идеясе — ул милли азатлык идеясе икән! Татар халкы азатлык турындагы уйны беркайчан да күңеленнән чыгармаган. Татар әдәбияты тарихына күз салсак, бигрәк тә мулла Моратлар, Батыршалар заманыннан алып соңгы 200-250 елда милли азатлык, милли суверенитет яулау хәстәре аның төп проблемасына әйләнүен күрербез. Татар милли хәрәкәте, бер тәбәктә томаласалар, икенче тәбәктән бәреп чыккан, ватаныбызда җай калмагач, милли социализм идеясе булып формалашып, чит илләргә саркып чыккан, татар милли идеясе шулай башка милләтләр тормышында гәүдәләнеш тапкан (мисал — «өченче дөнья» илләрендә Солтангалиев фикерләренең гаять югары бәяләнүе!) «Тимер чаршау» белән дөньядан аерып куелган татар халкы «казарма социализмы» кочагында җан асрарга дучар ителгән чакта да сүнмәгән-сүрелмәгән ул: татар милли идеясе булып әле бер, әле икенче илдә татар мәдәнияте учаклары яшәгән (әйтик, Кытай, Финляндия, Германия, Төркия, Корея, Япония, АКШ һ. б. илләрдәге татар милли-мәдәни җәмгыятьләре, Г. Исхакый, Р. Ибраһимов һ. б. эшчәнлеге).

Бүген килеп карасак та, милли азатлык идеясе татар әдәбияты, татар мәдәнияте өчен һаман әле төп идея булып кала икән. Моның мисаллары музыка, нәкыш сәнгатендә дә, әдипләребез иҗатында да тулып ята.

Шулай булгач, татар әдәбиятындагы нинди яңалык, сыйфат яңалыгы турында фикер йөртергә мөмкин? Без һаман искечә яшибез, искечә уйлыйбыз түгелме соң? Чөнки башкача булдыра алмыйбыз. М. Әгъләмов кайчандыр әйткән иде:

*Авырткан җирем син, Татарстан.*
*Син ярадыр миңа, бәгырьдер.*
*Кайда гына килеп бәрелсәм дә,*
*Иң беренче сиңа бәрелер,—*

дигән иде ул. Без һәрвакыт менә шул авырткан җиребез турында уйларга дучар ителгән. Авыру кешене сәламәт кешеләрнең шатлыгы кимсетә, ирекле кеше кол күңелендәге гамьнәрне аңламый. Ачның хәлен тук белми. Безнең татар әдипләреннән күбесе үзләренең кимсетелгән, изелгән халык уллары икәнлекләрен һәрвакыт тоеп яшәделәр, иҗат иттеләр. Һәм алар шуны яздылар да — иҗатларының тел төбендә менә шул ята. Бездә еш кына, нигә татар әдәбияты урыс укучылары арасында яңгыраш тапмый, дип сүз кузгаталар. Моның гаебен язучыларда, тәрҗемәчеләрдән, тәнкыйтьчеләрдән эзлиләр. Ләкин кайсы заманнарда соң ачның хәлен тукның аңлаганы бар? Безнең проблемалар, безнең күңелләрне көйдергән гамь-хәсрәтләр урыс укучысы өчен бөтенләй ят, аңлашылмый. Алар бөтенләй бүтән рухи ихтыяҗлар белән яшиләр.

Халыклар бер-берсен аңласын өчен, аларның тигез хокуклы, тиң тормышлы булулары кирәк.

Безнең әдәбиятта әлегә үзенең коллык хәленнән риза булмаган кеше фикерләве өстенлек итә. Өстенлек дип әйтүем шуңардан: бездә әле үзенең кол хәлендә икәнен бөтенләй аңламаган кеше фикерләвенә корылган әсәрләр дә хәттин ашкан, ләкин алар, бәхеткә каршы, әлегә безнең әдәбиятта, урыс әйтмешли, «погода» ясамый.

*Арын көн дә коллыгыңнан,—*

ди Р. Фәйзуллин. Менә шушы чакыру рухы белән сугарылган әсәрләр укучыларыбыз күңелен били. Коллык белән көрәш фәлсәфәсе, үзенең тәэсирчәнлеге, тормышчанлыгы аркасында, бүтән төрле барлык фәлсәфәләргә дә үз йогынтысын салган. Шуңа күрә дә аны безнең әдәбиятның хәзерге характерын, сыйфатын билгеләүче төп факторларның берсе, дип әйтергә ярый.

Әйткәнемчә, бу идея, бу фәлсәфә безнең әдәбиятта күптәннән гамәлдә йөри. Яңа түгел ул. Әлегә безнең әдәбияттагы «яңалык» менә шушы идеяне курыкмыйча, ачык итеп, турыдан ярып әйтүдә генә күренә. Ләкин бу идея халыкка барып житеп, аңын тулысынча биләсен өчен, аның уйлау рәвешен, дөньяга мөнәсәбәтен, холык-фигылен үзгәртүгә өлеш кертә алсын өчен безгә бик нык тырышырга, бик озак җан көчен түгәргә туры килер әле. Әдәбият — халыкның рухи ихтыяҗларын чагылдыра, дибез, аны шул ихтыяҗларның көзгесе, дибез. Табигый ки, көзгедәге сурәт үзгәрсен өчен, ягъни әдәбият үзгәрсен, яңарсын, яңа сыйфат алсын өчен, халыкның үзгәрүе, коллык психологиясеннән котылуы кирәк.

## Рашат Низамиев:

— Әйе, шөкер, хәбәрдарлык һәм демократия, ачыктан-ачык сөйләшү заманы килде. Хакыйкатькә һәм әдәбиятка киң юл ачылды. Хәзергә рус әдәбиятының үзендә дә яңарыш, нигездә, басылмый яткан әсәрләрнең дөньяга чыгуы беләнрәк билгеләнә. Ә бездә, татар әдәбиятында, басылмыйча тыелып яткан әйберләребез бармы соң? Аяныч булса да әйтик: әлләни күп түгел... «Идегәй» дастаны — башка мәсьәлә, ул ерак гасырлар истәлеге, халык эпосы. Ибраһим Салаховның «Тайгак кичү» романы да — бөтенчәрәк мисал, кагылып-сугылып йөргән әсәр түгел, авторның шәхси архивында балаларыоныклары өчен бары форсат көтеп яткан... Аһ, форсат көтеп яткан шундый әсәрләребез күбрәк булсачы икән! Юк шул, киштәләребез буш диярлек. Хәер, Батулланың торгынлык елларында язылган байтак кына әкият-хикәяләре сәхнәдә һәм матбугатта күренә башлаган икән.

Заман һәм кешенең бәхәсләшүеннән язучы шәхесе туа. Язучы кыю булганда гына заман белән бәхәсләшә, үз фикерләрен курыкмый әйтә ала. Уңышларның нигезе — кыюлыкта. Гаделлек хакына әйтергә кирәк, соңгы ун-унбиш ел эчендә әдәбиятыбызда уңышлы әсәрләр дә байтак язылды. Аерым әсәрләрне атап тормастан, Ә. Еники, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев, М. Юныс, Т. Миңнуллин, Р. Харис, Р. Фәйзуллин, М. Әгъләмов исемнәре белән чикләник... Яхшы, кыю әсәр мактауга мохтаҗ түгел: аны шундук күреп алалар, укыйлар, яраталар. Бу очракта исә сүзне менә нәрсәгә юнәлтәсе килә.

Без элегрәк тә: «Кыю язарга кирәк!»— дип сөйләнергә ярата идек анысы. Әмма, ни хикмәттер, кыюлыкка өндәмә ташлау белән кылган гамәлләребез арасында кискен аерма килеп чыга иде. Аяз Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» повестен басарга курыктык: артык кыю язылган, янәсе. Әмирхан Еникинең кайбер повестьларыннан да «шүрләдек». Заманында Мөхәммәт Мәһдиев —«Фронтовиклар», Мәхмүт Хәсәнов «Язгы ажаган» романнарын, Нурихан Фәттахның «Артта калган юллар» повестен дөньяга чыгарган чакта, колхозлашу һәм шәхес культы елларын дөрес һәм тормышчан тасвирлаганнары өчен, күпме кыен ашадылар. Ике романның да әлеге өлешләре киселде, туралды, почмаксыз рәвешкә китерелде. Үзебез кыюлыкка чакырып та, үзебез үк кыюлыкны кисә бардык. Торгынлык еллары редакторлары буларак, үзебез үк кыю әйберләрнең башына суга тордык. Ни әйтсәң дә, моның механизмы әйбәт эшләнгән иде шул...

Инде, шөт, уяндык, күзләребез ачылды (бигрәк тә яшьләрнеке), алсу пәрдәләр артындагы чынлыкны бөтен барлыгы белән күрдек шикелле. Тагын да үсү, алга таба китү һәм халыкны да үзе белән ияртү өчен татар әдәбияты бүгенге көндә нишләргә тиеш соң? Зур сорау бу. Моның җавабын һәркем үзенчә тулыландыра алыр.

Миңа калса, безгә хәзер кабатланудан, як-якка каранып иҗат итүдән котылырга кирәк. Тарихыбызда ак таплар, дөресрәге кем кулы беләндер корым ягылган сәхифәләр күп. Бу хакта фән генә түгел, әдәбият та үз сүзен әйтергә тиешле! Без хәзер тарихи темаларны күтәрергә, эшкәртергә, алга сөрергә бурычлыбыз. Казан ханлыгы чорын, мөстәкыйль дәүләт булып яшәгән дәверебезне дөрес һәм художестволы яктыртмый торып, әдәбият татар халкы алдындагы бурычын намуслы үти алмас. Без тәмам уянып җиткәндә генә «перестройка» капкалары киредән ябылып куйса, бик тә үкенечле булыр.

Бүгенге Ренессанс, үзебезчә итеп әйтсәк, бүгенге Яңарыш тагын да көчлерәк барсын дисәк, беренче чиратта түбәндәге өч нәрсәнең үтәлүе мәҗбүри: Татарстан җөмһүриятенә союздашлык статусы бирү; Татар телен республикабызда дәүләт теле итү; балалар бакчасында, мәктәп һәм югары уку йортларында туган телдә укуны гамәлгә ашыру. Менә шушы шартлар үтәлгәндә генә татар әдәбиятының чын-чынлап үсүе, танылуы өчен яңа иҗтимагый атмосфера барлыкка киләчәк. Чөнки укучың юк икән — әдәбиятың да юк, телең юк икән — милләтең дә юк диган сүз. Татар әдәбиятының гомерен, киләчәген менә шушы өч мәсьәләнең ничек чишелеше хәл итәчәк.

Калганы, әлбәттә, әдипләрдән, аларның кыюлыгыннан һәм фидакарьлегеннән торачак. Ак кәгазь һәм каләм безне һаман да көрәш мәйданының уртасына чакыра, җиң сызганып эшләргә куша.

## Гәрәй Рәхим:

— Кызганычка каршы, бүгенге әдәбиятыбызга иң-иң олы таләпләрдән чыгып карасак, бездә әле яңарыш рухын һәм хәзерге тормышның иң төп, иң мөһим конфликтларын чагылдырган роман да, повесть та, драма әсәре дә, поэма да юк, дип әйтергә мәҗбүр булачакбыз. Мин моның белән язучыларыбызны булдыксызлыкта, талантсызлыкта гаепләргә җыенмыйм. Югарыда әйтелгән жанрлар әдәбиятның гаять зур, җаваплы жанрлары. Ул жанрларда бүгенге катлаулы, яңарышлы, каршылыклы, фаҗигале, шул ук вакытта бик кызыклы да булган тормышыбыз турында югары сәнгать таләпләренә җавап бирерлек әсәр берничә айда гына түгел, хәтта берничә елда да языла алмавы табигый хәл. Ышанам, татар язучыларының иҗат лабораторияләрендә андый әсәрләр, һичшиксез, язылып ятадыр. Һәм аларны якын елларда бик тә күрәсе килә.

Шулай да, бу урында безнең язучыларның соңгы елларда публицистикада яңарыш рухын, бүгенге тормышның иң кискен конфликтларын тоеп эшләүләрен әйтми китеп булмый. Шушы өч-дүрт ел эчендә генә дә безнең күп кенә язучыларыбыз радио һәм телевидение аша булсынмы, газета-журналлар аша булсынмы, яисә ачык аудиторияләрдә булсынмы — халкыбыз тормышының катлаулы, бик нык өлгергән мәсьәләләрен кыю рәвештә көн тәртибенә куялар. Бу эшкә шулай ук поэзия жанрының да акрын-акрын булса да кушыла баруын күңелле бер күренеш дип бәяләргә кирәк.

Тәнкыйть жанры безне һәм укучыны һаман да гаҗәпкә сала бирә. Инде бу рухи яңарыш, бу үзгәртеп кору елларында тәнкыйть әдәби хәрәкәтнең, яңа әдәби кузгалышның иң алгы сафына чыгып, бөтен җәмәгатьчелекнең игътибарын үзенә җәлеп итәр, әдәбият тарихының бөтенлеге, аның сәяси сафлыгы, бүгенге әдәби тормышыбызның торышы турында көндәлек кайгыртучанлык күрсәтер дисәк, ул һаман бер урында таптана бирә. Дөрес, Гаяз Исхакый иҗатын һәм «Идегәй» дастанын әдәбиятыбызга кире кайтару эшендә әдәбиятчы галимнәребез эш күрсәтмәде түгел. Моны күрми калу безнең тарафтан хаксызлык булыр иде. Бу эш беренче чиратта галимнәр кулы, алар акылы белән эшләнде. Ә бүгенге көн әдәби хәрәкәте белән шөгыльләнергә тиешле тәнкыйтебез, югарыда әйткәнемчә, ким дигәндә бер урындарак таптануын дәвам итә.

## Рафаэль Мостафин:

— Мин татар әдәбиятында яңарыш рухы иң көчле чагылган ике әсәрне шикләнми күрсәтә алам: М. Хәсәновның «Язгы аҗаган» романы һәм И. Салаховның «Колыма хикәяләре». Берсендә колхозлашу чорының фаҗигале «раскулачивание» җинаятьләре ачылса, икенчесендә 37-38 еллар фаҗигасе күрсәтелә. Мондый рухта язылган әсәрләр әлегәчә бездә чыкканы юк иде әле.

Хәзерге тормышның иң төп, иң мөһим конфликтлары, минемчә, кеше җанында чагыла. Әгәр кеше җаны, бөтен каршылыклары, тирәнлеге, психологик нечкәлекләре белән ачылса — заман конфликтлары да күрсәтеләчәк. М. Хәсәнов һәм И. Салаховның уңышларын да мин шунда күрәм. Такташ, Туфан иҗатларының бөеклеге дә кеше җанына керә белүдә. Бу зур максатка тулысынча ирешә алганыбыз юк әле...

## Гәрәй Рәхим:

— Бүгенге көндә тел мәсьәләсе мине аеруча борчый. СССРдагы һәр союздаш, автономияле республиканың, автономияле өлкә һәм милли округның, һәм әлегә милли дәүләтчелек бирелмәгән башка күп кенә халыкларның иҗтимагый тормышындагы иң катгый мәсьәлә булып көн тәртибенә килеп басты ул. Әйе, ниһаять, без халыкның, милләтнең булу-булмавы, аның иҗтимагый күренеш буларак сакланып калу-калмавы беренче чиратта туган теленең саклану-сакланмавына турыдан-туры бәйле икәнлеген бөтен тулылыгы һәм катлаулылыгы белән аңлап барабыз. Гади генә итеп сөйләшсәк, Р. Низамиев әйткәнчә, туган тел булса — милләт бар, туган тел булмаса — милләт юк. Димәк ки, халыкның милли әдәби теле булса, аның милли әдәбияты бар, әдәби теле юк икән, әлбәттә аның әдәбияты да юк. Шуңа күрә без бүген халыкны бербөтен милләт итеп саклап калуның иң беренче, иң мөһим юлы — аның телен саклап калу, дип әйтәбез.

Инде сорауга якынрак килеп, татар әдәби теленең ниндирәк халдә икәнен карап карыйк. Советлар Союзында үзенең язма әдәбиятын иң борынгылардан булып башлап җибәргән татар әдәби теле, әлбәттә, искиткеч бай тел. Ул лексик, морфологик, синтаксик, стилистик яктан гына бай түгел, ә иң әһәмиятлесе: образлы, сәнгати сөйләм өчен гаять җайлы, иҗле тел. Татар әдәби теле чын мәгънәсендә «сүзләрдән чәчәкләр тезә» торган тел ул. Без моны фольклорда да, телне бик яхшы белгән кешеләр (әйтик чиста авыл кешеләрнең) үзара сөйләшүендә дә, әдәбиятыбызның классик әсәрләрендә дә

һәм хәзерге язучыларыбызның байтак китапларында да ачык күрәбез. Димәк, гомумән алганда, мин татар әдәби теленең хәленнән бик тә канәгать, ул гына да түгел, мин аның белән лаеклы рәвештә горурланам да.

Ә менә шушы бай, гүзәл, сөйкемле әдәби телебезнең бүгенге кулланылышы мине бик нык борчый. Гаять тарайды аның кулланылыш сферасы. Дөреслекнең күзенә карап әйтергә кирәк: әдәби телебез хәзерге бер төркем язучылар, журналистлар, артистлар һәм аларның шулай ук артык зур төркем булмаган китап сөючеләре, тыңлаучылары өчен генә кирәкле бер телгә әверелеп бара. Ни кызганыч, хәтта әдәби телне, милли телне гасырлар буена күз карасы кебек саклап килгән мәктәбебезгә дә кирәге бетеп килә — мәктәпләрдә татар телендә укыту бик нык кимеде. Олпат җитәкчеләребезнең үзара аралашуы, алар оештырган гаять әһәмиятле җыелышлар, сессияләр, конференцияләр, пленумнар, съездлар өчен дә кирәге юк бу телнең, шул ук вакытта әче телле кибетчеләр һәм көнкүреш хезмәте күрсәтүчеләр, урам-урам җыелып сугышкан яшүсмерләребез өчен дә кирәк түгел. Хәтта инде урамга вывеска язып куярга да ярамас хәлгә килде безнең бөек туган телебез. Бу — бик кызганыч хәл һәм, һичшиксез, гарип бер күренеш.

Гәрчә конституциябезгә, СССРның дәүләт төзелешенә теоретик яктан якын килсәң, безнең илдәге һәр милли телгә һаман саен үсә генә барырга тулысынча хокуклар бар кебек. Әйтик, безнең илнең иҗтимагый тормышында җәмгыять кулланылышы ягыннан өч төрле күренеш яшәп килә: дәүләт теле, милли аралашу теле, туган тел. Бу өч төрле тел күренешен һәр кеше, нинди территориядә яшәвенә һәм кайсы милләт вәкиле булуына карап, үзенчә куллана ала. Мәсәлән, РСФСР өлкәләрендә (әйтик, Ульяновск, Свердловск өлкәләре һ. б.) яшәүче рус кешесе өчен дәүләт теле дә, милли аралашу теле дә, туган тел дә бер үк рус теле. Бу очракта рус теле югарыдагы өч төрле тел күренешенең өчесен дә бергә берләштерә. Ә инде шул ук өлкәдә яшәүче татар кешесе өчен дәүләт теле белән милли аралашу теле рус теле булса, туган тел аның үз теле, ягъни татар теле була. Татарстан АССР территориясендә яшәүче татар кешесе өчен исә татар теле әлеге өч төрле тел күренешенең икесен үз эченә ала — ул бер үк вакытта туган тел дә, дәүләт теле дә. Татарстандагы татар кешесе өчен милли аралашу теле беренче чиратта рус теле булса, төрки телле кешеләр белән аралашканда ул татар яки башка бер төрки тел булырга мөмкин. Татарстанда яшәүче рус кешесенә килсәк, аның өчен дәүләт теле татар теле булса, милли аралашу һәм туган тел рус теле була. Бу очракта инде рус теле өч төрле тел күренешенең соңгы икесен бергә берләштерә. Ә инде Татарстанда яшәүче башка милләт вәкиле өчен, әйтик чуваш кешесе өчен дәүләт теле татар теле (шул ук вакытта Чувашстанда яшәүче татар кешесе өчен дәүләт теле чуваш теле була); милли аралашу теле, беренче чиратта, рус теле, яки әлеге аралашучы кеше белән сөйләшә торган башка бер тел; туган тел, табигый ки, чуваш теле була. Монда инде әлеге өч төрле тел күренешенең өченчесе дә активлаша. Күп кенә милли республикаларда рус һәм шул республика милләтеннән булмаган милләт вәкилләре өч төрле тел күренеше реаль кулланылышта булган мөхиттә яшиләр. Шуңа күрә мин безнең илдә икетеллелекне генә яклаучылар белән килешә алмыйм. Бездә бу өлкәдә дә өч төрле тел күренеше бар: бертеллелек, икетеллелек, өчтеллелек. Безнең илдә икетеллелек турында күпме сүз сөйләнә, матбугатта мәкаләләр басыла, әмма чын күпләр тормышта яшәп килгән әнә шул өчтеллелек күренешен искә алмый.

Тормышыбызда гамәли рәвештә яшәп килгән әлеге тел күренешләрен нигездә аңлаган кеше күрә ки: без үзебезнең конституцияне шәрехләгәндә дә, *дәүләт теле, милли аралашу теле, туган тел һәм икетеллелек* турында бәхәсләр алып барганда да, аларны катып калган төшенчәләр итеп кабул итәбез. Без ни өчендер: дәүләт теле икән, ул фәлән тел генә, һәм ул икенче бер телне кысырыкламыймы; милли аралашу теле фәлән тел генә, һәм төрле милләт кешеләре үзара аралашканда бары тик шуны гына кулланырга тиешләр; туган тел ул икенчел, хәтта өченчел әһәмияттәге тел; икетеллелек бездә бердәнбер реаль күренеш, дип фикер йөртергә өйрәнгәнбез. Без дәүләт теле, милли аралашу теле, туган тел, икетеллелек дигән төшенчәләрне тормыштан, үзебез көн саен үзара аралашып торган сферадан аерып алып, теоретик догмага әйләндергәнбез. Гәрчә, алда әйткәнемчә, тормышта телләрнең кулланылу дәрәҗәсе гаять сыгылмалы, ул конкрет тормыш таләбенә буйсынып, һәр очракта кешеләргә прогрессив хезмәт итә. Дәүләт теле, милли аралашу теле һәм туган телнең төрле территорияләрдә, төрле ситуациядә, төрле милләт вәкилләре тарафыннан яшәү кануннарына буйсынып, төрлечә үзгәртеп кулланылуы — иҗтимагый тормышның табигый бер күренеше, тормышның табигый агымы. Ә менә аларны куллануцагы табигыйлекне бозарга, аларның шулай тормыш законнарына буйсынып үзгәртеп торуын тыярга тырышу, бу өч төрле тел күренешенең кайсы да булса берсенә генә өстенлекләр биреп, икенчеләренең кулланылыш сферасын ясалма рәвештә тарайтырга маташу җәмгыятьтә каршылыклар, милләтара ризасызлыклар китереп чыгара. Мондый каршылыклар төрле республикаларда тел

турында законнар кабул иткәндә аеруча күзгә ташлана. Әйтик, бер республика Югары Советы тота да, үз республикасындагы төрле тел күренешләре (дәүләт теле, милли аралашу теле, туган тел) яшәүне комплекслы рәвештә раслау яки яклау урынына, берберсеннән аерылгысыз әлеге өч тел күренешенең берсен генә аерып алып (әйтик дәүләт теле), шуны гына раслап указ кабул итә. Әлбәттә мондый указ республикада яшәүче башка милләт вәкилләрендә ризасызлык хисләре тудыра. Минемчә, Советлар Союзындагы һәр республика Югары Советы тел мәсьәләсендә берьяклы түгел, ә комплекслы указ кабул итәргә тиешләр. Татарстанда, мәсәлән, аның төп нигезе түбәндәгечәрәк була ала:

— Татарстан Югары Советы ТАССР территориясендә иҗтимагый кулланылыш ягыннан өч төрле тел күренеше булуынраслый: 1. Дәүләт теле (татар теле); 2. Милли аралашу телләре (рус теле, аралашучылар сайлап алган тел); 3. Туган тел (ТАССР территориясендә яшәүче һәр милләт вәкиленең үз туган теле).

Татарстан хөкүмәте шушы өч төрле тел күренешенең һәрберсенең үз хокуклары булуны расларга: һәр өч төрле тел күренеше сферасындагы телләрнең барысын да өйрәнүне, куллануны, мәктәптә шул телдә уку мөмкинлеге булдыруны гарантияләргә тиеш.

Әнә шулай илебездәге, шул исәптән республикабыздагы бөтен телләргә дә берберсенә дәгъвасыз тигез хокуклар булганда гына безнең бүгенге әдәби телебез, конституция хокукларын файдаланып, алга табан тагын да үсеп китәчәк.

## Рафаэль Мостафин:

— Бүгенге татар теле ике яктан кысылу кичерә. Бердән, аның яшәү даирәсе тарая. Соңгы елларда үткәрелгән социологик тикшеренүләр күрсәткәнчә, татар халкының яртысы диярлек әдәби телне белми, татарча укымый, радио тыңламый, телевизион тапшыруларны карамый. Икенче яктан, аның кулланыш сыйфаты түбәнәя. Тел чит сүзләр белән чуарлана: борынгы сүз байлыгын, әчке җегәрен, шулар белән бергә яшәү сәләтен дә югалта бара. Беренче чиратта бу газета телендә күренә. Әкренләп газетага хас соры төссез тел әдәби әсәрләргә дә үтеп керә.

## Гәрәй Рәхим:

— Бүген шунысы сөендерә: язучы кешегә тегеләй яз, болай яз, теге теманы язма, бу теманы яз дип вәгазь сөйләү чоры үтте. Югыйсә бит бездә шулай да була иде: Язучылар союзына җитәкче урыннардан берәр вәкил килә дә, җыелышта язучыларга нәрсә турында һәм ничек язарга күрсәтмәләр бирә. Яз булмаса Язучылар союзы идарәсе рәисе һәр җыелыш азагында тегене язмыйсыз, моны язмыйсыз, безгә тегенди әсәрләр кирәк, мондый әсәрләр кирәкми, дип, язучыларын „пешерә“. Бүгенге күзлектән караганда, бу бала-чага уены булып күренә. Әмма, кызганычка каршы, мондый «уен»ның шаукымы әле бүген дә үзен сиздергәләп куя. Минемчә, хәзерге татар әдәбиятын үстерү өчен язучыларны җыеп «өйрәтүләр»нең бер файдасы да юк. Дөрес, бездә талантсыз язучылар да юк түгел. Әлеге җитәкче, һичшиксез, теләсә кайсы мәсьәләдә, шул исәптән әдәби иҗат мәсьәләләрендә дә талантсыз язучыдан киңрәк фикер йөртә ала. Әмма шунысы кызганыч, җитәкче кешенең иң изге теләкләре, иң акыллы киңәшләре һәм иң дөрес фикерләре дә талантсыз язучыны талантлы итә алмый. Димәк, бу очракта үгет-нәсихәт нәтиҗәсез кала.

Хәзерге татар әдәбиятын үстерүдә, минемчә, түбәндәге чаралар конкрет ярдәм итә алыр иде: республикада әдәбият һәм сәнгать газетасы, «Язучы» китап нәшрияты булдыру (ләкин ул бүгенге Татарстан китап нәшриятының штаты, кәгазь һәм гонорар фонды исәбенә эшләнмәскә тиеш. Мондый итәк кисеп җиң ялгаудан беркемгә дә файда юк)— болар язучының иҗат активлыгын да арттырыр, алдагы иҗади планнарын тормышка ашыруда ныклы ышаныч та булдырыр иде; мәктәпләрдә татар теле һәм әдәбиятын укытуны сан ягыннан киңәйтү, сыйфат ягыннан яхшырту — бүгенге мәктәп укучысы ул киләчәктәге китап сөюче дә, яшь язучылар сафын арттыру өчен резерв та; Татарстанда татарча нәфис һәм мультипликацион фильмнар төшерүче киностудия булдыру — мең еллык тарихы булган татар әдәбиятына киносценарий жанрын үзләштерү зарури; Мәскәүдәге татар театрын яңадан торгызу, Казанда татарча яшь тамашачылар театры ачу — татар драматурглары бүгенге театрларыбыз белән генә бөтен иҗади потенциалларын тормышка ашырып бетерә алмыйлар.

Ә инде тормышыбызга аваздаш, халкыбыз озак еллар, хәтта гасырлар буе яратып укырлык яңа әсәрләр иҗат итү бүгенге язучыларыбызның төп бурычы булып кала килә.

## Рафаэль Мостафин:

— Әдәби мирасны халыкка кайтару буенча соңгы вакытта искиткеч күп эш эшләнде. Кол Галинең «Кыйссаи-Йосыф» әсәре яңадан басылды, берничә вариантта хәзерге әдәби телгә тәрҗемә ителде, аңа шактый тулы, тирән искәрмәләр бирелде, бу тема буенча берничә җитди фәнни хезмәт тә басылып чыкты. 1988 ел ахырында беренче мәртәбә «Идегәй» дастаны аерым китап булып басылды һәм бу искиткеч бай чыганакны яңача өйрәнергә юл ачылды. Ш. Мәрҗәни, Г. Исхакый әсәрләре, ниһаять, халыкка кайтарыла.

Чираттагы максат, минемчә — татар зыялыларының эмиграция шартларында иҗат ителгән әдәби һәм гыйльми мираслары белән танышу. Без бу турыда берни дә белмибез, моңача хәтта кызыксынырга да батырчылыгыбыз җитми иде...

Ә бүгенге әдәбиятыбызда жанрлар ничек үсә соң?

Илленче елларның икенче яртысында барган яңарыш шигърият байрагы астында үтте. Илдар Юзиев, Шәүкәт Галиев, Гамил Афзаллар көчле бер дулкын булып, әдәбиятыбызга дәррәү бәреп керде. Аларның шигырьләре яңа фикерләр, яңа тема һәм идеяләр, бер сүз белән әйткәндә яңарыш рухы алып килде. Хәзер исә эш башкачарак тора. Поэзия торгынлыкта калды, дип әйтәсем килми. Шагыйрьләребез осталыкларын да, профессиональ тапкырлыкларын да югалтмады. Әмма, шулай да, яңа чорның яңа мөмкинлекләре, шул ук яңарыш рухы поэзиядән бигрәк публицистикада һәм прозада чагыла. Шагыйрьләребез дә кыю-кыю фикерләр әйтергә омтылып карыйлар. Ләкин бу өлкәдә алар шулай да публицистлар белән ярыша алмый.

## Ркаил Зәйдулла:

— Жанрларны кайчагында бер-берсе белән чагыштыралар. Минемчә, бу бөтенләй дөрес түгел. Болай фикер йөртү профессионалларга килешми. Әдәбият турында сөйләшүне бу юнәлештә борып җибәрү безнең тәнкыйди фикернең бер каптырмалы, бер күзәнәкле булуыннан килә...

Һәр жанрда да яхшы әсәрләр, начар әсәрләр бар. Ә әдәби тәнкыйтьнең бурычы шуларны аера белүдә. Укучыларга әдәбият чытырманлыкларында адашмас өчен кирәк бу.

Шигърятнең «артка калуы» турында соңгы елларда күп сөйләнде. «Алгы позициясен» югалткан поэзия хакында искә алып үтү «яхшы зәвык» билгесе була башлады шикелле. Моңа, әлбәттә, Мансур Вәлиев, Рафаэль Мостафин мәкаләләре дә шактый өлеш керткәндер.

Дөресен әйтик: шигърятне шик астына алу — әдәбиятның үзен шик астына алу дигән сүз. Һәр әдәбиятның чишмә башы шигырь, аның асылын шигърилек билгели. Бездә бу фактор аерата көчле. Бу фикеремне биредә дәлилләп торасым килми, әдәбият әлифбасы белән бераз таныш кеше миңа каршы төшмәс...

Татар шигыренә ни өчен шулай һөҗүм итә башладылар соң әле? Иң өстә яткан сәбәп, миңа калса, аксакал — патриарх урынының буш калуында булса кирәк. Туфаннар, Хәкимнәр вафатыннан соң башланган бу бәхәсләр шул уйга этәрә.

Шигърятне бер төслелектә, сорылыкта, аморфлыкта гаепliләр. Әлбәттә, начар шигырьләр күп, мөтәшагыйрьләр күп... Ә кайчан алар аз булган? Әдәбиятнең кимәлен иң әйбәт әсәрләр буенча бәһалиләр.

Хәзер без бер-беребездән уздырып «торгынлык еллары» турында сөйли башладык. Янәсе, ул вакытта бастыра алмаган нинди әсәрләр бар? Белмим, бәлки мондый караш башка жанрларга ярыйдыр да, тик ул шигъриятькә бөтенләй туры килми. Укып карагыз сез утыз ел, егерме ел элек чыккан шигырьләрне! Андагы юл араларыннан әле бүгенге публицистика да әйтелмәгән фикерләр табып була. Ә поэзия шундый «астыртынлыгы» белән көчле бит ул.

Әйе, хәзер маңгайга бәреп язылган шигырьләр күбәйде. Мондый язык үземдә дә бар. Шлюзлар ачылганда, күңелдәгене турыдан әйтеп каласы килә. Табигый теләк. Ләкин шигърятнең көче мондый шигырьләрдә түгел. Маяковскийчылык болай да безнең шигърияткә бик күп зыян салды, аңнарны саташтырды. Бу турыда бездә әйтелгәне юк. Әмма, миңа калса, егерменче еллар шигърятенә әле өр-яңадан бәя бирәсе бар. Дәрдемәнд үлеменнән соң татар поэзиясе үзе өчен фаҗигале булган юлга кереп китә. Күрәсең, чыннан да, «җәмгыятьтә яшәп, аннан азат булу мөмкин түгелдер». Туфаннарның, Җәлилләрнең төрмәләрдән, концлагерьдан кайткан әсәрләре генә татар шигырен үз юлына, хак юлга кире алып чыкты, минемчә.

Шигърият турында сөйләгәндә боларның барысын да истә тотарга иде.

Бизмәннәр үзгәрә.

Соңгы елларда татар поэзиясендә бөтенләй яңа агымнар, юнәлешләр сизелә. «Яңа

дулкын» шәкелне вату, сындыру белән мавыкмый, киресенчә, аны камилләштерергә омтыла кебек. Бу — безнең иң әйбәт традицияләрне дәвам итү нәтиҗәсе. Ни генә әйтсәң дә, шигърият — сурәт һәм музыканың синтезы бит ул.

Бары тик күрә белергә, ишетә белергә генә кирәк. Ә моның өчен аз гына булса да бер-береңә игътибарлы булу зарури.

## Рафаэль Мостафин:

— Сиксәненче еллар башында драматургиябез үзенә күрә бер зур сикереш ясаган иде. Бу сикерешнең иң югары ноктасы, минемчә, Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәре булды. Хәзерге вакытта исә, драматургия икенче эшелонда калды кебек, ул да проза һәм публицистикадан калыша.

Балалар әдәбияты үз позициясен югалтмады. Ләкин алга китеш тә сизелми.

Тәнкыйтьнең башка жанрлардан артта калуына без инде күптән күнектек. Бу хәлнең шулай ук үзгәргәне юк. Бер генә мисал: алты томлык «Татар әдәбияты тарихы»на күпме өмет багладык, аңа күпме көч салынды, вакыт сарыф ителде! Әмма алты томлыгыбыз чыгып җиткәнче үк искерде. Егерменче йөз башы, совет чоры әдәбиятларына караган томнарны яңабаштан карап чыгып, бик җитди үзгәрешләр кертеп, яңадан язып чыгарга кирәк.

Яңа талантларга килгәндә, аларны колакларыннан тартып үстереп булмый. Әмма яшь талант үзен күрсәтсен өчен мәйданны киңәйтеп, тиешле шартлар тудырып була. Шундый шартларның кайберләрен генә санап китәм. Алар, дөресрәге, Татарстан язучыларының XI съезды резолюциясендә дә әйтелде:

**1. Татар телендә әдәбият-сәнгать буенча атналык газета чыгарырга. 2. Районнарда чыга торган дубляж газеталарны мөстәкыйль татар газеталарына әверелдерергә. 3. Татарлар яшәгән башка өлкә һәм республикаларда татарча газеталар чыгаруга ирешергә. 4. Радио һәм телевидение буенча татарча тапшыруларның вакытын шактый арттырырга (кимендә, ике-өч мәртәбә). 5. Татарстан Язучылар союзының аерым нәшриятын булдырырга.**

Мәйданы киң булса, әдәбият та үсәчәк! Шул чагында без дә чын-чыннан ярыш турында сөйли алачакбыз!

## Китап күзәтү

# ШАГЫЙРЬ ИМАНЫ

Хәсән Туфан поэзия турында: «Җан рәхәтем — шигъриятем»,— дия торган булган. «Иҗат — бәхет ул, иң матур, иң көчле бәхет ул! Иң бәхетле чагым — иҗади накалда яшәгән чак. Җанның-күңелнең-йөрәкнең-бәгырьнең дөрләгән, кайнаган чагы, уй һәм хиснең аера алмаслык булып кушылып, ташып торган чагы». Шагыйрьнең бу сүзләреннән аның иҗат иткәндәге халәтен ачык күз алдына китерү кыен түгел.

Классик шагыйребез Хәсән Туфан турындагы истәлекләрдән тупланган «Ак чәчәк атар иде» дигән китапны (Татарстан китап нәшрияты, 1989 ел) мин җыр укыган кебек, мавыгып, бер бөтен итеп кабул иттем. Нәтиҗәдә, татар совет поэзиясенең олы вәкиле Хәсән Туфан һәм кеше, һәм шагыйрь, һәм акыл иясе буларак өр-яңадан ачылгандай булды. Бигрәк тә аның яшәешкә, кешеләргә, шигъриятькә мөнәсәбәтен тагын да тирәнрәк һәм тулырак тойдым.

Хәсән Туфан 1981 елда вафат булды. Халкыбыз күңелендәге бу яра әле чагыштырмача яңа. Шуңа да карамастан, истәлекләр язу, аларны өйрәнү һәм тагын күп кенә чыганакларны барлау сигез ел вакытны алган. Х. Туфан турындагы кызыклы язмалар әнә шулай тупланган. Инде, алардагы мәгълүматларны бер эзлеклелеккә салып, мәктәп укучыларына, урта махсус һәм югары уку йортлары студентларына, гомумән, халкыбызга җиткерү — галимнәр, укытучылар, әдәбият сөючеләр эше.

Шунысы әйбәт, язмалар теләсә ничек түгел, хронологик тәртиптә урнашканнар. Без Х. Туфанны бала чагыннан алып соңгы сулышын алганга кадәр күзәтү мөмкинлегенә ия. Дөрес, төрле авторларның язмаларында бер үк вакыйга яки фактны кабатлаулар да очрый. Бу бик табигый. Ник дигәндә, берәү икенче авторның нәрсә язганыннан хәбәрләр түгел, үз белгәнен бәян итә. Аннан соң алардагы уртак күренеш төрлечә ялтырап ала, үзенчәлекле яңгыраш таба.

Мәсәлән, шундый бер кызыклы очрак. Шагыйрьнең мулла кушкан исеме Хизбулла булган. Фамилиясе тагын бер гыйбрәтле тарих. Көчләп чукындырылып та ислам диненә тугрылыклы калган Иске Кармәт авылы кешеләренең яңа туган балаларын ул еллардагы хакимият законсыз дип исәпли һәм аларга фамилияне дә ата-бабасы исеменнән түгел, ә бәлки ана исеменнән чыгып язылар. Әнисе Гөлзизә исеме буенча Хизбуллага да Гөлзизин фамилиясе бирелә. Читкә китәргә паспорт алганда исә бу хәлне төзәтергә, малайга фамилияне әтисе исеменнән ясарга уйлыйлар. Авыл халкы аның әтисен — укымышлы Фәхрулланы — хәзрәт дип йөртә. Хизбуллага да фамилияне Хәзрәтов дип куялар. Казакъ далаларында балалар укытып йөргәндә гамәлдән чыккан паспортын алыштырганда, патша властьларыннан эзне яшерү өчен, ул бер егеттән Хәсән Кусинов исем-фамилиясенә тутырылган документ ала һәм егерме җиденче елга кадәр аңа шулай йөрергә туры килә. Атаклы «Туфан» псевдонимын алуы да очраклы гына булмаган. Хәзерге вакытта пенсиядәге укытучы Г. Кудашев язуына караганда, Уфаның «Галия» мәдрәсәсендә укыган вакытта булачак шагыйрьнең шигырьләре белән танышкан бер укытучысы шәкертенең язмаларын көчле әсәрләр, хәтта «туфан» (җил-давыл мәгънәсендә) дип бәяли. «Яраткан укытучысы тарафыннан әйтелгән, Хәсәннең күңелендә шагыйрь булу өметен уяткан кыйммәтле сүз — «туфан»ны Хәсән үзенә фамилия итеп алды»,— ди Г. Кудашев.

Бу мәгълүматларның кайберләре әлегә кадәр дә билгеле иде. Әмма Г. Кашапов, Г. Кудашев, М. Таһировалар тарафыннан искә алынган әлеге мәгълүматлар мәсьәләгә төрле яклап ачыклык кертә һәм укучының Хәсән Туфан турындагы белемен арттыра. Алай гына да түгел, һәр атлаган саен исем алмаштырырга мәҗбүр булган Туфанның заманнан, халкыбыз тарихыннан аерылгысыз булуын яңа көч белән раслый. Халык кадәр халык бер буында өч мәртәбә язу алыштырырга мәҗбүр ителгән икән, безне башкасы белән шаккаттыру мөмкин дә түгелдер. Егерменче гасыр башының катлаулы тормыш дулкыннары халкыбызның бу талантлы егетен, әнә шулай Хәсән Туфан булып әверелгәнче, бер яктан икенчесенә ташлый-ташлый, бихисап

михнәтләр кичертә һәм милләтебезгә шагыйрь буларак бүләк итә. Истәлекләр җыентыгы безгә шушы процессны эзлекле рәвештә күзәтеп бару мөмкинлеген бирә.

Китап Х. Туфанның «Бәлки, шагыйрь булмас та идем...» дигән мәкаләсе белән ачыла. Бу — шагыйрьнең 1970 елда чыккан «Давыллы еллар лирикасы» китабына язган кереш язмасы икән. Беренче битләрдә үк шушы «бисмилла»ның бирелүе дә отышлы алым буларак кабул ителә. Ник дигәндә, күп кенә нәрсәләрне шагыйрьнең үзеннән дә яхшырак итеп белеп булмыйдыр. Чыннан да, Х. Туфан бу мәкаләдә үзенең шагыйрь булып китүенең алшартларын күрсәтә, әлеге юлда ярдәм кулы сузган остазларын яратып искә ала, поэзиянең үзенчәлегенә ачуга игътибар итә. Әмма укучы шулай да кереш сүздән генә үзенең кайбер сорауларына тулы җавап ала алмый. Ул күбрәкне көтә... Бигрәк тә шагыйрьнең 1940—1956 еллар арасындагы язмышы турында сүз дәшмәве канәгатьләндерми. Роберт Батулла шагыйрьнең мондый сүзләрен китерә: «Беләсезме, егетләр, мин бит артык күп сөйләшмәскә кул куеп, сүз биреп чыктым...» Шулайдыр, әнә Ибраһим Салахов та шулай иткәндер. Әмма күңелендәгеләрне язып, алмагач төбенә күмгән ләбаса. Хәсән абый да шулайрак итә алган булыр иде.

Болай да аз сүзле, табигате белән сабыр, тыйнак шагыйрь, аның каравы, шул еллардагы кичергәннәрен «Агыла да болыт, агыла...» кебек гүзәл әсәрләрендә әйтеп бирде. Шигъриятебезне сталинчыл террор чоры кешеләре кичерешләре белән сугарылган поэзия энҗеләренә баетты. Аларда белдерелгән хисләрне уйлап кына чыгарып булмый. Бер караганда табигый генә, җай гына барган сүз сөреше үзендә никадәр киеренкелек, кичереш тирәнлеге туплаган! Әйе, бер үк әйбер, күренеш турында берәү роман язса, икенчесе шигырь энҗеләре тезә. Һәркемнең үз осталыгы, үз мөмкинлеге. Ихтимал, алар без күрергә теләгән микъдарда түгелдер. Әмма эш күләмдә түгел. С. Хәким әйткәнчә, «Юллар озынайган саен шигырь тыгызланган. Юлда йөк авыр булмасын өчен хисләрнең иң кадерлеләрен генә үзе белән алган шагыйрь».

Шулай да Х. Туфанның әдәби мирасы зуррак булуы мөмкин иде. Мөмкин иде генә түгел, тәгаен ул колачлырак булган. Ләкин аның байтак әсәрләре — нинди үкенеч! — югалганнар. Мәсәлән, Р. Мостафин раславынча, 1948—1949 елларда ул шигырьләрне үзе торган баракның идән астында, яшерен урынында тота. Әмма искәрмәстән аны бу урыннан Себергә җибәрүләре сәбәпле, шагыйрь шигырьләрне алып китә алмый. Моңа кадәр дә кайбер әсәрләре завод цехындагы кеше күзе төшмәстәй җирдә калып юкка чыга. Алар арасында нинди генә шигырьләр булмагандыр!

М. Җәлил «Моабит дәфтәрләре»н бары тик әсирлек шартларында гына иҗат итә алган шикелле, Х. Туфанның байтак әсәрләре дә гадәттән тыш хәлләр эчендә туган. Әнә бит иҗат халәте турында ул үзе ниләр дигән: «Шигырьне язалармени? Шигырь белән яшиләр, дөресрәге, ул үзе җаныңда бер изге зат булып яши... Аңа бернинди аерым вакыт та, махсус шартлар да кирәкми».

Әсәрләрен шагыйрь ничек саклап калган соң? Сохари эчендә. Р. Мостафин язмаларын укыганда моңа сөенеп утырасың. «Егерме-утыз бит кәгазь җыелган, ул аларны түгәрәкләп төргән дә сохари эченә яшергән. Тишекләрне ике яктан да ипи белән ябыштырып, мич янында кыздырып киптергән. «Лагерьда нинди генә тентүләр булмады,— дип сөйли иде Хәсән абый.— Анадан тума чишендерәләр, бөтен әйберләреңне тикшереп чыгалар». Әнә шул сохари кисәкләре татар әдәбияты өчен әйтеп бетергесез игелек кыла, шигырьләрне саклап кала.

Җыентыкка тупланган истәлекләрне шартлы рәвештә өчкә бүлеп булыр иде: кырыгынчы елга кадәрге шагыйрь буларак өлгерү вакыты, тоткынлык чоры, ирекка кайткач булган уңъеллыклар. Әмма бу «бүлекләрнең» күләме төрлечә. Беренчесе — җиде, икенчесе — бары өч, соңгысы — егерме җиде истәлекне эченә алган. Димәк, Х. Туфан гомеренең әсирлек һәм сөргенлек чорлары шактый аз өйрәнелгән. Истәлекләрнең төрле юл белән язылган булуларына да игътибар итик. Р. Мостафин Хәсән аганың үз сөйләгәннәрен бәян итсә, Гарәфи Хәсәнов олы шагыйрьнең лагерьдагы язмышын бергә бүлешкән кеше буларак сөйли. Актык кыерчык ипине бүлешеп, бөтен байлыгы булган бишмәте белән бүреген Хәсән абыйсына биргән Гарәфи Хәсәновка китапны укыган һәркем рәхмәт сүзләре әйтәчәк.

Газиз Кашапов исә безнең әдәбият тарихын өйрәнүдә яңа сәхифә ачып җибәрә. Ул Себердә, Хәсән Туфан эзләреннән йөреп, шагыйрьнең яшь вакыттагы һәм сөрген елларындагы язмышын ачыкларга тырыша. Аның «Җырлый-җырлый үттем Барабаны...» дип исемләнгән очеркы китаптагы иң кызыклы сәхифәләрнең берседер. Автор анда шагыйрь сөргендә булган Новосибирск өлкәсе Усть-Тарка районы Покровка авылына баруын һәм шул төбәкләрдә ишеткән-күргәннәрен бәян итә. Шагыйрьне биредә һәркем зур хөрмәт белән искә ала. Үзе дә Идел буеннан бу якларга сөрелгән немец милләтле Бекк исә Х. Туфанны аеруча яратып искә төшерә: «Эчкерсез кеше иде Туфан. Акча сорамас, тегe кирәк, бу кирәк димәс, эшлисе эшне эшләп бирер. Кешеләрне аңлый торган кеше иде. Аңа

бөтен кешенең — яше-карты, олы-кечесенең сере сыядыр иде». Авыл хатыны Мария Деревягина сөйләгәннәр татар халкы, аның бер улы Хәсән Туфан өчен тагын бер тапкыр горурлык хисләре уята: «Ул бик пөхтә киенер иде. Чалбары чип-чиста булу өстенә, аны тагы да үтүкли иде. Чәчләре һәрвакыт тарап салынган булыр иде. Кайвакыт ул иртә белән көтүгә чыгып киткәндә ипи-сөт салынган сумкасын онытып калдырса калдырыр, әмма үзенең кәгазьләрен онытканын берәү дә хәтерләми. Безгә бик сәер иде бу хәл. «Шушы кәгазьләрдә — минем бөтен гомерем».— дия торган булган ул кешеләргә».

Әйе, Х. Туфан тормышын өйрәнү буенча әле эш җитәрлек. Иң әһәмиятлесе: документларга, сорау алу кәгазьләренә, төрле «эш»ләргә үтеп керү кирәк. Шуннан башка дөреслекне ачыклау мөмкин булмаячак. Х. Туфан башта үлемгә хөкем ителә, аннан соң бу җәза ун елга каты режимлы колониягә һәм биш ел сөргенгә алыштырыла. Кырыгынчы елның көзеннән алып 1942 елның 7 мартына кадәр судсыз-нисез, ә соңыннан, судсыман нәрсә оештырып, бер гонаһсызга каты җәзага хөкем ителгән шагыйрьнең трагик язмышы — шәхес культы чорының кара пәрдәсе ябылган бер сәхифә. Хәзер ул пәрдәне күтәреп, аның теге ягындагы хәл-әхвәлләрне халыкка күрсәтер чак җитте.

1956 елның 19 мартында СССРның Генераль прокуроры карары буенча акланган та, әле Хәсән Туфанга шактый күңелсезлекләр кичерергә туры килә. Мәсәлән, 1957 елда татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы көннәрендә аны, паспортындагы тамгасына карап, башкала кунак йортына урнаштырудан баш тартулары үзе генә дә нечкә күңелле шагыйрь йөрәген ничек тирән җәрәхәтләмәгәндер? Ш. Галиев язмасындагы менә бу юлларны кем генә тетрәнмичә укыр икән? «Хәсән абыйны юатып, урын юллап йөрделәр. Булмады бугай. Ахыр чиктә барыбер уртак бүлмәдә йоклап йөргәне истә калган».

Бу истәлекләрне укыганда мине иң гаҗәпләндергәне — Хәсән ага Туфанның сабырлыгы булды. Үз иленең явыз кешеләре тарафыннан хаксызга җәберләнгән бу шәхеснең ихтыяр көче, шигърият куәтенә ихлас инануы, киң күңеллеге кемдер уйлап чыгарган сыйфатлар гына түгел бит, чын дөресе шулай. Х. Туфан илгә, совет хакимиятенә үпкә сакламады. Ш. Галиев та шул якка игътибар итә: «Бу хакта үзегез ни уйлый идегез?»— дип сораганым бар. «Безнең монда булуыбыз партия өчен шулай кирәктер, без төшенеп җитмәгән серләре бардыр, дип уйлый идек».— дия иде. Мин үзем әлеге «усаллыкка көч белән каршы тормау» кебек толстойчылыкны кабул итә алмыйм. Әмма мондый кискен нәтиҗәне ясаганчы, утызынчы-кырыгынчы еллар кешеләренең күңел дөньясын аңларга тырышырга кирәктер. Ә бу аңлаудан шактый аяныч нәтиҗә килеп чыга: Сталин һәм аның чолганышы халыкны шулкадәр ышандырганнар ки, хәтта җәберләнүчеләр үзләре дә «шулай кирәктер» дип икеләнеп калганнар. Бу еллар терроры иң куркыныч ягы нәкъ шунда да — кешеләрдә коллык психологиясе тәрбияләү.

М. Кәрим шагыйрьнең пәйгамбәрләрчә киң күңеллелеген күрсәтә. «Озак яшәп китте, рәхәт тә, кыен да яшәп китте, ләкин ул дөньяга хәтере калып, язмышына зарланып китмәде». Төрле авыруларга каршы тору өчен тәнебездә әчке көч булган кебек, кешегә авырлыкларны җиңү өчен дә ныклы иман кирәк. М. Кәрим үз язмасында шагыйрьнең шушы иманын ачып салырлык сүзләр китерә: «Хәсән Туфанның ничәмә еллар аерылышудан соң үз өендә әйткән иң мөкатдәс сүзләрен кат-кат искә алам. Без аның «тегендә»ге хәл-әхвәлләрен сорашып, аңа кызгану, юату тойгылары белдерә башлагач, ул кырт кисте:

— Монысын куегыз әле, егетләр. Әйдәгез, үзебезнең анабыз Әдәбият, һәрберебезнең сөйгән яры Поэзия турында сөйләшик.

Авыр сәгатьләрдә, кыен елларда менә нәрсә коткарып калган икән аны — «анабыз Әдәбият, сөйгән ярыбыз Поэзия».

Шагыйрь шушы күңел ышанычын яшь буында да саклау турында кайгырта. Шигъри энекәше Кадыйр Сибгатуллинга язган хатында ул бу гүзәл гамен яшьләргә васыять итеп калдыра: «Безнең ышанычны, безнең өметләрне, шагыйрь хәлдә генә түгел, шәхес хәлендә дә акларга тиешлегеңне бик нык аңла, безне бервакытта да уңайсызлыкка калдырырга тиеш түгеллегеңне искә алып яшә. Бу көннәрдә генә түгел, иртәгәләрдә дә, иҗади гомереңнең иң соңгы елларына, чорларына кадәр дә, безнең кебек кенә түгел, бездән дә иманлырак хәлдә бул. Бу сиңа әмер дә һәм алдан ук әйтеп куелган васыять тә». Әлбәттә, аталарча бирелгән бу киңәш бер К. Сибгатуллинга гына төбәп әйтелмәгән, ул Зөлфәткә дә, Мөдәррис Әгъләмовка да, Равил Фәйзуллинга да, Ркаил Зәйдуллинга да — тагын бүгенге һәм килер буыннарның талантлы яшьләренә багышланган. Шагыйрь өчен (гомумән, кулында каләм тоткан һәркем өчен) иң мөһиме — гамәлең белән дә, язган әсәрләрең белән дә иң югары дәрәҗәдәге иманны раслый бару, һәрдаим шул иманыңны ныгыта төшү. Хәсән Туфан безгә үз мисалында шуның бөек үрнәген бирде. «Ак чәчәк атар иде» җыентыгының һәр җөмләсе безне шуңа инандыра.

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН,**
филология фәннәре кандидаты.

# РОМАН-ХРОНИКАДА НИЛӘР БАР?

Безнең татар әдәбиятында тарихи романнар юк дәрәҗәсендә аз. Ә андый әсәрләрнең кирәклеге һәркемгә дә аңлашыладыр. Аерым шәхес үзенең үткән тормышын белмичә яши алмаган кебек, милләт тә үз тарихын белмичә яши алмый. Шулай да соңгы елларда тарихи әсәрләребез күренә башлады. Без моны Нурихан Фәттах, Мөсәгыйт Хәбибуллин романнарын күздә тотып әйтәбез. Ләкин бу романнар укучыга нәрсә бирә, безнең культураны ни белән баета, тарихтагы ак тапларны никадәр җуя, милләт алдында торган проблемаларны чишәргә ничек ярдәм итә — бу турыда сөйләшү булганы юк әле. Андый сөйләшү алда дип уйлыйсы килә. Бүген без, шундый сөйләшүне башлау йөзеннән, тарихи романнарның берсе турында сүз алып барырга булдык. Сүз — Аяз Гыйләҗев һәм Алексей Литвинның «Алтынчы августка кадәр» дигән китабы турында.[1]

Роман 1918 елның җәендә Казанда булган вакыйгаларны сурәтләүгә багышланган. Әсәрнең төп геройлары итеп шул вакытта Чекада эшләгән кешеләр алынган. Бу — уңышлы алым. Чөнки Чекада эшләгән кеше тормышның төрле-төрле катламнарына бик җиңел үтеп керә. Мондый герой ярдәмендә тормышның төрле якларын, төрле полюсларын күрсәтеп була.

Ничек файдаланганнар соң авторлар әлеге мөмкинлектән? Күрсәтә алганнармы Казанның ул чактагы чуар, киеренке тормышын?

Әсәр төп геройның үз кулы белән язылу рәвешендә бирелгән. «Бардыр, гомерләре аккан су кебек эзсез-өнсез узган кешеләр дә бардыр,— дип башлап китә ул үзенең язмаларын.— Ә безнең гомернең атна-айлары гына түгел, көне, сәгатьләре дә тарих сукмакларында тирән эз калдырды. Чоры шундый иде».

Әлеге юлларны укыгач уйга каласың: бу юлларның авторы Чекада гомере буе эшләгәнме? Эшләмәгәндер, югыйсә ул үзенең Чекада эшләү фактына бу кадәр үк әһәмият бирмәс иде.

Чекада берничә мәртәбә кадрлар алышыну, төрле чистартулар булып узды. Ягоданы — Ежов, Ежовны — Берия алмаштырган вакытта элекке кадрлар юк ителде, алар урынына яңалары килде. Унсигезенче елда ук Чекада эшли башлаган герой боларны ничек кичергән, бүгенге көнгә кадәр ничек исән кала алган — романда бу турыда бер сүз дә юк. Әйтерсең лә бу гыйбрәтле вакыйгалар геройга, язмаларның авторына бөтенләй кагылмаган...

Романдагы вакыйгаларның үсенләнүе Мәскәүдә башлана. Анда кулга алынган фетнәчеләрдән сорау алганда билгеле була: зур һәм катлаулы фетнә көтелә, бүлекләре Казанда да бар икән. Өч чекист, фетнәчеләрдән алынган адрес һәм парольләргә таянып, шуларның эшләре арасына керер өчен, Казанга китәләр. Шуларның берсе — без укыган язмаларның авторы Сергей Сергеевич Фролов. «Ул вакытта безгә егерме яшь иде» (38 бит).

Казан вокзалына килеп төшү белән боларны танып та алалар. «Сергей Сергеевич!» дип кычкыра бер кыз. Бу аның белән бер йортта үскән Зоря булып чыга. (Ул чакта егерме яшьлек егетләргә кызлар «Сережа» дип түгел, «Сергей Сергеевич» дип дәшә торган булдылар микәнни?) Казан фетнәчеләре боларның киләсен беләләр һәм көтеп торалар — шуны әйтергә килгән Зоря.

Үзләренең кем икәнен белеп һәм көтеп торуга карамастан, безнең егетләр фетнәчеләр янына барырга булалар. Анда барып нәрсә эшләргә уйлаганнардыр — монысы укучыга әйтеп бетерелми. Дошманнар күп һәм кораллы, килеп керү белән боларның җилкәләренә пистолет китереп териләр. Шуннан китә атышу, үтерешү, ләкин гаҗәп хәл: безнең егетләрнең өчесе дә бу мәхшәрдән исән-сау килеш чыга! Укучыга моны аңлавы кыен. «Башыма пистолет белән суккаиннар, һушымны җуйганмын, бернәрсә дә хәтерләмим»,— дип, Сергей Сергеевич бу хәлне аңлатудан җиңел генә котыла (17 бит).

Шулай йомшак язылган бу эпизод. Офицер кешенең, кулында пистолет була торып, Сергей Сергеевичка атмыйча, аңа пистолет сабы белән сугып маташуын кузалдына китерү кыен.

Сергей Сергеевич икенче көнне госпитальдә һушына килә. һәм шундук торып, штабка офицерлардан сорау алырга китә. (Башына сугылып, бер тәүлек диярлек һушсыз яткан кеше шулай тиз генә торып китә алырмы?)

Офицерлардан Сергей Сергеевич сорау алып утырганда «бүлмәгә яшь тикшерүче Гайнулла Таһиров килеп керде» (21 бит). Шулай дип язылган романда. Ләкин Сергей Сергеевич әле Гайнулланы беренче тапкыр гына күрә, кайдан белә ул Гайнулла Таһиров икәнен дә, яшь тикшерүче икәнен? «Гайнулла Таһиров белән әлерәк кенә, мин госпитальдән чыккач, таныштык» диелгән. (Шунда ук). Шулай да булсын. Ләкин ничек шушы минутта ук Сергей Сергеевич аңа тулы характеристика биреп өлгерә, биографиясен дә сөйләп ташлый? Күрәзәче диярсең...

Күрәзә түгел, билгеле. Гайнулла белән алар озак вакыт бергә эшләгәннәр, шуңа күрә Сергей Сергеевич аны яхшы белә. Ләкин болар — киләчәктә буласы эшләр. Ә Сергей Сергеевичның бүген, танышуның беренче минутларында ук, Гайнулла турында шулай бар белгәнен сөйләве дөресме? Роман көндәлекләр нигезендә язылган икән, аның вакыйгаларны сөйләүдә көндәлеккә якынрак торуы яхшырак, ышанычлырак булыр иде, әсәр табигыйрәк яңгырар иде.

Сергей Сергеевич — Мәскәүдә үскән рус егете, укымышлы. Ә Гайнулла — Казанда үскән татар эшчесе. Аларның бер-берсе белән танышып китүләре, бер-берсен аңлау-

---

[1] Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ, Алексей ЛИТВИН. «Алтынчы августка кадәр». Татарстан китап нәшрияты. Казан, 1987 ел.

лары бик җиңел, шома гына булмагандыр, шуны процесс итеп күрсәтү сорала шикелле. Әмма әсәрдә бу юк. Сергей Сергеевич беренче күргән минутыннан ук Гайнулланы үтереп мактарга тотына. Ләкин моның белән генә Гайнулла укучының мәхәббәтен казана алмый.

Геройларны эшләре, сүзләре-хисләре аркылы ачасы урынга, аларга әзер характеристика биреп бару бу романга, гомумән, хас нәрсә. Матур әдәбият өчен мондый алымның ярамаганын әйтеп үтүдән тыш, тагы шуңа игътибар итәсе килә: Сергей Сергеевич үзенең язмаларын безнең көннәрдә, вакыйгалардан соң ярты гасыр чамасы вакыт үткәч язган. Бу вакыт эчендә ул үзе дә үзгәргәндер, кайбер вакыйгаларга, геройларга карашы да алышынгандыр, шәт. Романда аның ул чактагы карашлары белән бүгенге, бераз үзгәртелгән карашлары да күрсәтелсә, яхшы булыр иде. Бүген заманы да бүтән, Сергей Сергеевич та бүтәндер... Ләкин бүгенге Сергей Сергеевич белән ул чактагы Сергей Сергеевич арасындагы аерма романда бөтенләй сизелми диярлек.

Ольженицкийга да романда беренче битләрдә ук әзер, катгый характеристика биреп куелган. «Казан Чекасында мин олы шәхес, чын революционер белән очраштым» (29 бит). Ләкин Ольженицкийның моны аклырлык эшләрен дә, сөйләгән сүзләрен дә күрмибез.

Мондый юл белән бирелгән геройлар тере кеше булып китә алмыйлар, схема гына булып калалар. Фәридә белән дә эшләр шулай тора. Аны җайлап ачарга булыр иде роман барышында. Сергей Сергеевич белән, Гайнулла белән мөнәсәбәтләрен күрсәтү аша. Юк, Сергей Сергеевич беренче күрешүдә үк Фәридәне якын кешесе итеп кабул итә дә, аны мактарга тотына һәм романның буеннан буена «уңган кыз Фәридә» дип, аңа сокланып йөри.

Сокланмаслык та түгел шул Фәридәнең эшләре. Ниләр генә эшләми Фәридә романда! Казанда офицерлар кафе ачып, шуларны үзләренең очрашу урыннарына әйләндереп җибәргәннәр. Бу эшнең асылына Фәридә төшенә. Алай гына түгел, ул, кафеларга кереп, андагы офицерлар белән танышып, аларның кайсы контр икәнен ачыклап йөри. Үзеннән чекистлар сорау алганда Фликкель:

«— Остарып барасыз! Шундый сөйкемле Фәридәгә: «Кайчандыр Керенский белән таныш идем», дип әйтеп тә өлгермәдем, тәбе капкачы шапылдап ябылды да»,— дип куя (32 бит).

Кайда һәм кайчан әйтте икән Фликкель бу сүзләрне Фәридәгә? Кызларга үзең турында мондый сүзләрне бары тик ниндидер интим хәлләрдә, иркенләп сөйләшеп утырганда гына әйтеп була. Алай ук сөйләшеп утырыр дәрәҗәдә ничек танышкан Фәридә Фликкель белән? Аларның уртак танышлары юктыр. Фликкель — Петербургтан килгән интеллигент, Фәридә исә Казанда үскән татар кызы, эшче гаиләсеннән. Ничек алай җиңел таныша Фәридә офицерлар белән?

Ольженицкийны үтергән кешене дә Фәридә тота. Кафеда утырганда ул телдән бирелгән портрет буенча гына шул кешене таный һәм, Галимов белән бергә тотып, штабка алып кайта!

Гайнулланың эшләре исә алай мактанырлык түгел. Хәтта ул Фәридә тоткан офицердан сорау да ала алмый. Бары тик ярдәмгә Сергей Сергеевич килгәч кенә эшне башкарып чыгалар. Моның өчен Гайнулла Сергей Сергеевичка рәхмәт әйтә:

«— Миңа карышып маташкан иде, сезне күрүгә җебеп төште. Нинди сихерегез бардыр» (111 бит).

Ләкин бит, без күреп тордык, Сергей Сергеевич әллә нәрсә эшләмәде. «Сез Чекада утырасыз, шаярмагыз, аның председателе Ольженицкийны үтерүдә гаепләнәсез»,— диган иде, шул җитте (109 бит). Күрәсең, Гайнулла шундый сүзләрне дә әйтә алмый.

Гомумән, Гайнулланың рус офицерларыннан сорау алып йөрүе аңлашылмый. Чекага эләккән татарлардан сорау алып утырса да бик җиткән иде Гайнуллага. Ләкин ул моның белән канәгатьләнергә теләми, үзенә рус офицерларын чакыртып китерә дә, алардан сорау алырга тотына. Тик бер мәртәбә дә бу эшне ахырынача башкарып чыга алмый.

Һәм бу аңлашыла да. Чөнки сорау алу өчен тел белү генә җитми, алда утырган кешенең психологиясен дә тирәнтен аңларга кирәк, анык кадәр үк белем, культура кирәк, хәтта аларның ышанычын казана белергә кирәк. Гайнуллада боларның берсе дә юк. Бердән — яшь, егермедә генә, икенчедән культурасы түбән, белеме аз. Шуңа күрә офицерлар аңа бернәрсә дә әйтмиләр, көлеп кенә утыралар.

Романның икенче яртысында, инде тәҗрибә туплаган булса да, Гайнулла үзен барыбер күрсәтә алмый. Мулланур Вахитовны коткарырга дип бара да, аклар кулына эләгеп, романның ахырына кадәр төрмәдә утыра. Аның Сергей Сергеевичны ничек коткаруы турында язып тормыйбыз. Бу эпизодны пародия итеп кенә укырга була.

Шунысы гаҗәп — Сергей Сергеевич, аклар килгәч, кеше күзенә дә күренергә куркып, яшеренеп ята. Ә аның белән Чекада бергә эшләгән Гайнулла Казан буйлап рәхәтләнеп йөри. Нишләптер аны танымыйлар. Ә бит ул — Казанның үз кешесе! Хәтта төрмәгә эләккәч тә, Гайнулла анда башын тилегә салып йөри, аны беркем дә танымый, белмиләр аның чекист икәнен!

Гайнулла төрмәгә утыргач, сюжетны авторлар теләгән якка бору, Казандагы төрле кешеләрне романга алып керү бурычы Саҗидә апа өстенә төшә. Ничек үти ул моны?

«Кая барырга?

Шунда ул бик еракта яшәгән бер кешене, элгәрәк елларны йомыш-юлга әнисе кереп йөргән кешеләрне... Фатих Әмирханны хәтеренә төшерде. Менә аларда тынычтыр... Яулыгын кысыбрак бәйләп, Саҗидә Бишбалтадан Ботан бакчасы ягына барырга чыкты, вокзал тирәсенә барып җиткәч, туктады... вокзалга керде, шунда почмакта чүмәшеп төнен уздырды. Әмирханнарга иртәнге чәйдән соң гына барып әлекте» (236 бит).

Бу өзектән күренгәнчә, Саҗидә Фатих Әмирханнар белән яхшы таныш түгел, кайчандыр әнисе аларга кереп йөргән, шуның аркылы гына белә. Ничек каршы ала Фатих Әмирхан үзендә күптән булмаган кешене?

«Шул чагында иплән кенә ишек ачылды

һәм Саҗидә апа килеп керде.

— Менә үтенечне Ильяс Алкин комиссиясенә Саҗидә апа илтеп тапшырыр. Барасызмы, Саҗидә апа?»

Ерактан арып килгән, кичәдән бирле ашамаган, төнен вокзалда үткәргән Саҗидә, нишләсен: «Сез кушкач, нигә бармаска ди, Фатих улым!» — дип җавап кайтара (249 бит). Шулай каршы ала Фатих Әмирхан үзләрендә күптән булмаган, арып, ачыгып килгән кешене.

Мондый кытыршылыклар әсәргә ышануны киметә. Ә андый төгәлсезлекләр романда күп, аларны һәр биттән китерергә була.

Әсәрнең иң йомшак ягы — төп геройның, Сергей Сергеевичның, эшләнеп җитмәгән булуы. Сергей Сергеевичны тулы канлы образ итеп бирә алмаган авторлар.

Бердән, төп геройның биографиясе юк. Ул Мәскәүдә туып-үскән, ләкин нинди гаиләдән, нинди мохиттән, нинди тәрбия алган, революциягә ничек килгән, нинди максат белән Чекада эшли башлаган — болар романда күрсәтелми.

Сергей Сергеевич шигырьләр яза. Ләкин бу аның эчке дөньясын ачарга ярдәм итми. Шигырьләрен ул нәрсә белән илһамланып яза — моны белмибез. Сергей Сергеевичның яраткан шагыйрьләре Маяковский, Пастернак, Цветаева, Есенин дип бирелә. Болар бер-берсенә шулкадәр каршылыклы шагыйрьләр ки, аларның барсын берьюлы яратучы кешене күз алдына китерү кыен.

Ул чордагы татар интеллигентлары нәрсә уйлаганнар, халыкның алдагы язмышына ничек караганнар — шуны да беләсе килә. Ләкин, политик бәхәсләр романда бик күп булса да, анда әйтелгән карашлар эзлекле бер концепция булып оешмаган.

Культура буенча автономияме яки территориаль автономияме — революция алдындагы елларда бу турыда күп бәхәсләр булган иде. Татар зыялылары бу мәсьәләгә ничек караганнар? Безнең халык өчен, бәлки, культура автономиясе кулайрак булыр иде? Чөнки халык илнең төрле төбәкләрендә сибелеп яши, мондый халыкны бер территориаль автономия астына җыю кыен... «Казан җирендәге берничә өязне җыеп, автоном республика ясап куйдылар, ләкин татар халкының ихтыяҗларын үтәү өчен бу гына җитми. Республика үзәге Казан илдәге бөтен татарларның мәркәзе ролен үйный алмый».

Мондый һәм шуңа охшашлы мәсьәләләргә ул чакта татар халкының киләчәге турында уйлаучылар ничек караганнар? Татар халкының киләчәген алар ничегрәк күз алдына китергәннәр? Әйткәнемчә, романнан бу турыда бернәрсә дә белеп булмый. Андый карашларны күрсәтүне авторлар бурыч итеп тә куймаганнар. Ул чордагы татар әһелләре бары тик көлке объекты итеп кенә алынган шикелле (Муллануր Вахитов һәм Фатих Әмирханнан башкалары).

Торгынлык елларында Юрий Трифоновның «Старик» дигән романы басылып чыккан иде (1978 ел). Андагы төп герой Летунов үзенең 1920 елда Мигулинга ясалган судта катнашканы өчен картлык көннәрендә үкенеп йөри, бу турыда кат-кат уйлана. Герой уйлана, аның белән бергә укучы да уйлана; бу исә укучыларның күзен ачарга ярдәм итә. Ә безнең романда исә беркем дә бернәрсә турында уйламый. Романда бирелгән бәхәсләр дөреслекне күрсәтүгә түгел, апологетикага хезмәт итәләр. Большевиклар үзләренең эшләгән эшләрендә дә, сөйләгән сүзләрендә дә хаклылар. Вакыйгалар дөрес юнәлештә бара — бу турыда беркемдә дә шик юк.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: авторлар зур эш башкарганнар, байтак материал туплаганнар, ләкин ул материал романда әле хәрәкәткә килеп җитмәгән. Бәлки, ашыкмаска кирәк булгандыр? Бераз ятса, ул материал җайлап тулыланыр иде. Җанланып, үзе турында үзе сөйли башлар иде. Геройлар да чын, тере кешегә әверелерләр иде.

**Вахит ГАРИПОВ,**
Казан.

**Зәки Зәйнуллин**

# ЭСТӘРЛЕБАШ МӘДРӘСӘСЕ

Атаклы татар уку йортлары арасында Эстәрлебаш мәдрәсәсе дә үзенә лаеклы урын биләп торган. Безнең көннәрдә әлеге мәдрәсә, гадәттә, күренекле татар шагыйрьләре Ш. Зәки (1825—1865), Г. Чокрый (1826—1889), М. Акмулла (1831—1895) иҗатына нисбәтән искә алына. Әйе, әлеге талантлы шагыйрь-мәгърифәтчеләр укыган һәм хәлфәлек кылган вакытта Эстәрлебаш мәдрәсәсе атаклы һәм мәшһүр булып танылა.

Шуның белән бергә, ул вакытка кадәр дә аның инде гасырдан артыграк тарихы булган. «Уңсигезенче йөздә Казан, Оренбург янындагы Каргалы, Борындык, Кышкар, Бәрәскә, Минзәлә, Эстәрлебаш, Ура, Мәчкәрә, Тайсуган, Ташкичү, Саба, Әгерҗе, Шырдан мәдрәсәләре үз заманнары өчен зур һәм күренекле мәдрәсәләр булып исәпләнгәннәр»,— дип яза тарихчы С. Алишев. («Казан утлары», 1984, 4 сан, 179 б.).

Эстәрлебаш мәдрәсәсенең кайчан ачылып эшли башлавы һәм аның имам-мөдәррисләре турында шул мәдрәсәнең соңгы мөгаллиме булган Мөхәммәтшакир Тукаев үзенең «Тарихы Эстәрлебаш» (Казан, 1899) исемле кибатында язып калдырган.

Жанры буенча бу төр язмаларны галимнәр Х. Әмирхан, Ш. Мәрҗани, К. Насыйриларның тарихи хезмәтләре тәэсирендә язылган, күмәк җәмәгать шәҗәрәсе — аерым төбәк тарихы, ягъни региональ тарих жанры дип атыйлар.[1] «XIX гасыр ахырында һәм XX гасыр башында бу тарихларның кайберләре басылып та чыккан. Мисал төсендә М. Тукаевның «Тарихы Эстәрлебаш», М. Сүнчәләйнең «Иске Кыешкы тарихы» исемле хезмәтләрен, Р. Фәхретдиневнең Сәгыйт бистәсе, К. Насыйриның Зөя өязе, А. Бләшевның Әҗе авылын тасвир иткән китапларын күрсәтергә мөмкин. Бу төр язма истәлекләр тарих фәне, тел тарихы өчен кыйммәтле чыганак булулары белән бергә, «...халыкның рухи тормышыннан күп кенә хәбәрләр бирүләре ягыннан да әһәмиятлеләр»,— дип яза М. Әхмәтҗанов. («Казан утлары», 1978, 3 сан).

«Тарихы Эстәрлебаш» китабының авторы М. Тукаев — икенче һәм өченче чакырылыш Дәүләт Думасы әгъзасы булуы белән дә мәгълүм кеше. Дума депутатлары турында язылган китапта аның фоторәсеме һәм кыскача биографиясе урнаштырылган. Фоторәсемнән безгә түбәтәйле, сөнни мыек, җитү сакаллы, таза, мәһабәт ир уртасы кеше карап тора. Рәсем астына: «Шакир Тукаев кырык яшьләрдә» дип язып куелган. (Азад-Гайшә Рорлих «Идел буе татарлары тарихы». (Калифорния, 1986) дигән китабында, Ш. Тукаевны 1862 елда туган дип яза).

Биографик белешмә рәвешендә бирелгән язмадан Ш. Тукаевның тормышы, белеме, әлеге Думаларның дин комиссиясендәге эшчәнлеге хакында берникадәр мәгълүмат алабыз: «Эстәрлебашында җир хуҗасы, сәүдәгәр һәм мөдәррис. Казан учительская школасының Оренбургта вакытында ике сыйныфыны бетермеш, хәзердә авылында торадыр. Ике Думада да мөселман фракциясенә язылып, аның программасына муафикъ хәрәкәт итде. Дума мөнбәренә менеп сөйләрлек кадәр русча белми, шуңар күрә икенче Думада да, өченчесендә дә чыгып сөйләгәне юк. Ләкин Дума фракциясе мөселманларына һәм үзе әгъза булган дин комиссиясенә ихлас белән йөридер вә хәленнән килгән кадәр хезмәт итәдер. ...һәм мәсьәләдә мөселманнарның интересын сакларга тырышадыр». Автор үзенең язмасын түбәндәге җөмлә белән тәмамлый: «...Шакир әфәнде, әлбәттә, бик яхшы вә лаеклы депутат түгел, һәрхәлдә, мәхдүмлеге ачык беленеп торадыр, ләкин шулай да мөселман депутатлары арасында Шакир әфәнде иң эшлекле вә галиләрдән вә өченче Думадагы

[1] Усманов М. А. Татарские исторические источники XVII—XVIII вв.— Казань, 1972

Уфа мөселман депутатлары арасында беренчеләрдән саналырга тиешдер».[2] Ничек кенә булса да, Шакир Тукаев хакында, асылда, объектив мәгълүмат бирелгән дип уйларга нигез бар.

Әлеге китап турында үз вакытында Ф. Әмирхан да: «...Мәхмүд Фоад әфәнде шактый хиссәле бу җыентыгында «...өч Думада мөселман депутатларының тәрҗемәи хәлләрен, вә Думада эшләгән эшләрен вә үзе ия булган депутатлык исеменә никадәр хаклы булуын бик матур, ачык рәвештә бер дә тарафдарлык итмичә бәян иткән» — дип язып калдырган икән («Әл-Ислах», 1909, 26 февраль).

Мөхәммәтшакир Тукаевны үз заманы өчен укымышлы һәм прогрессив карашлы кеше булган дип әйтә алабыз. Ул Риза Фәхретдинев, Закир Рәмиевләр (Дәрдмәнд) белән аралашкан, авылга русча газета-журналлар алдырган, Казаннан Баишев Мирсәед дигән укытучы китертеп, бер төркем балаларны русча укытырга тырышкан.

М. Тукаев үзенең унтугыз битле китапчыгында да Эстәрлебаш авылы, андагы мәдрәсә һәм аның мөдәррисләре хакында байтак мәгълүмат туплап, аларның төгәл урынын һәм даталарын күрсәтеп, аларга карата үзенең мөнәсәбәтен белдерә барып, тәфсилләп язган.

Китабының беренче битләрендә автор Эстәрлебаш авылының кайда урнашуы, ничек оешуы, кешеләренең кайдан күченеп килүләре хакында бик җентекләп яза. Үзеннән үзе аңлашылганча, әлеге хезмәт, әлбәттә, үз чорының әдәби теле нормалары белән һәм аның да югары стиле кануннары таләбенә туры китерелеп язылган. Менә бер җөмлә: «...Эстәрлебаш карьясе губернасы улан Уфа шәһәреннән йөз илле чакрым йирдә, өйәзе улан Эстәрлетамак шәһәрендән илле чакрым кыйбла тарафында олуг Сибирия тимер йулында вакыйг улан Шафран стансасындан йитмеш биш чакрым йирдә тәкърибән 73 дәрәҗә тулда, 53 дәрәҗә гарыз бәйәнендә, Эстәрле суының башындан биш чакрым йирдә вакыйг улан бер мәшһүр карьядер...» Алга таба Эстәрлебаш авылын Казан тарафындагы Каргалыдан килгән кешеләрнең нигезләве, аларның үз тормышларын ничек итеп җайга салулары, җир-су мәсьәләсен хәл итү уңаендагы уй-фикер һәм шөгыльләре хакында укыйбыз. Автор, кешеләрнең бу якларга күчеп килүләренең сәбәбен «...сәүдә вә кәсебләре илә шөгыльләнмәк өчен»,— дип яза. Димәк, ул дәүләт политикасын түгел, бәлки халыкның үзара киңәш-табышларын гына күз алдында тота, бәлки бу хезмәтне цензурадан үткәрү өчен шулай эшләнгәндер. Тарихтан билгеле булганча, Иван Грозный Казан шәһәрен яулап алганнан соң, рус патшалары һәм христиан дине башлыклары мөселман динендә булган татарларны гасырлар буена көчләп чукындыру сәясәте алып барганнар. Күршеләрендәге башка халыклар кебек үк, татар халкы да үзләренчә яшәешен, динен яклап, күп тапкырлар шул көчләүләргә каршы баш күтәреп караган: көчләр тигез булмаган — баш күтәрүләр корал көче белән бастырыла барган. Патша хөкүмәтенең колониаль һәм дини яктан көчләү политикасы белән килешә алмаган татарларның кайберләре ирек эзләп, динен саклап, үзләренең туган-үскән якларыннан качып китәргә мәҗбүр булганнар. Шуларның бер өлеше башкорт, казах якларына күченеп киткән.[3] Бер төркеме хәзерге Башкортстан АССРның Оренбург өлкәсе белән чиктәш урынына, Эстәрле елгасы буена туктаганнар, авыл башта Каргалы дип йөртелсә дә, соңрак әлеге елга исемен алып, Эстәрлебаш булып киткән. (Бүгенге көндә район үзәге). М. Тукаев бу хәл 1680 еллар чамасында булган дип исәпләп чыгара.

Авыл табигать ягыннан да сәүдә, җир эше өчен дә бик уңайлы урында. Тирә-як урмансуга, кара туфраклы җиргә, ташка бай. Илле-алтмыш чакрым гына көньякта казакъ яклары. Ерак та түгел борынгы Болгар-Бохара сәүдә тракты. Җир мәсьәләсен дә күчеп килгән халык татарларга хас булган акыллылык һәм эшчәнлек белән хәл иткән.

М. Тукаев үзенең китабында авыл халкының нинди эшләр белән шөгыльләнүләрен дә бик җентекләп, яратып һәм тәфсилләп язып калдырган: «Эстәрлебашның халкы татар халкыдыр. Күбесе ашлык сачеп кәсеп итәләр вә азрак сәүдә итүчеләре дә бар. ...Халык арасында кайбер сәнагать вә һөнәр ияләре дә һәм вөҗүддер»,— дип, автор авылда ташчы вә миччеләр, читек-кәвеш тегүчеләр, балта осталары булуын, аларның эшләгән эшләрен санап үтә. Ләкин әлеге авылның мәшһүрлеге аның олуг мәдрәсәләрендә дип, горурланып болай дәвам итә: «Шәһрәте олуг мәдрәсәләрендә һәр елда ничәшәр йөз шәкердләр... гыйлем алдылар, Эстәрлебашыннан күп галим вә голәмә һәр тарафка таралып, гыйлем вә әхлак тараттылар...» (4 б.). Аннан соң инде М. Тукаев әлеге җирлектә кемнәрнең беренче булып мәчет-мәдрәсә коруы, уку-укытуны башлап җибәрүе һәм 1895 елларга кадәр шул мәдрәсәләрдә дәрес бирүче мөдәррисләрнең эшчәнлеге хакында ишеткән-белгәннәрен бик тә ихлаксык белән яза: «...Эстәрлебаш авылында әүвәл мәртәбә имам булган кеше Монасыйб мелла 1710—1720 еллар арасында булган. Шуннан соң Хөсәен мелла Габдрахман углы дәрес башлаган. ...Хөсәен мелла әүвәл мәртәбә мөфти булып килгән Мөхәммәт-

[2] Усал М.-Ф. Беренче, икенче вә өченче Думада мөселман депутатлары һәм аларның кылган эшләре.— Казан, 1909, 137-138 бб.

Сүзлек: тәкърибә — якынча, тул — озынлык, гарыз — киңлек, карья — авыл.

[3] Татарстан АССР тарихы. Казан, 1970, 103-104, 137-138 бб.

җан мөфти Хөсәеневнең атасыдыр. ... Имди Эстәрлебаш мәдрәсәсе тарихына 1720 еллардан хисап кылырга ярый».

Бу урында бер сорау туарга мөмкин. 1740 елда махсус оештырылган «Чукындыру эшләре буенча контора» эшчәнлеге нәтиҗәсендә, 1742—1744 елларда 536 мәчетнең 418 е юк ителгәне мәгълүм. Ни өчен Эстәрлебаш мәдрәсәсен патша хөкүмәте яптырмаган?

Берөзлексез колониаль политика алып барган патша хөкүмәте Урта Азия халыклары турында мәгълүмат алуда татар сәүдәгәрләрен һәм руханиларын файдаланырга тырышкан. Төрле истәлекләргә караганда, Эстәрлебаш сәүдәгәрләре XVIII гасыр урталарында Бохара, Сәмәрканд, Хива, Кашгарга кадәр барып җитә торган булганнар. Алар алып кайткан мәгълүматлар хөкүмәт өчен дә кирәкле булган, әлбәттә.

Ә инде халык өчен мәктәп-мәдрәсәләр уку-язарга өйрәнү, эчке һәм тышкы әхлак кагыйдәләрен үзләштерү, дин гыйлеме алу, «акыл фәннәре» белән танышу үзәге булган.

Шунысы да игътибарга лаек, соңгы йөз елдан артыграк вакыт эчендә Эстәрлебаш мәдрәсәсендә — мөдәррис, ә мәчетендә имам булып Тукаевлар эшләгән. Шуларның беренчесе — Нигъмәтулла Биктимер углы Тукаев (1773—1844). «Гаделша хәзрәттән соң Эстәрлебашында шәех Нигъмәтулла хәзрәт вәлид Биктимер, вәлид Тукай Әлмәшһүр Биктә хәзрәт улмышдыр»,— дип яза аның турында М. Тукаев. 1773 елда туган, 1801 елдан Бохара мәдрәсәсендә укый, аңа кадәр Мәчкәрә мәдрәсәсендә белем алган була, 1813 елдан указ алып, Эстәрлебаш мәдрәсәсенә мөдәррис вә мәчетендә имам булып тора. Нигъмәтулла Тукаев үз чорының шактый киң танылган шәхесе була. Аның хакында Ш. Мәрҗани һәм Р. Фәхретдинев хезмәтләреннән дә укый алабыз. Мена шушы язмаларны чагыштырып укыганда, «Тарихы Эстәрлебаш»ның авторы бабасының тормышын берникадәр тәфсилләбрәк язса да, ул аны гади кеше итеп кенә бирә алган, ә Ш. Мәрҗани белән Р. Фәхретдинев исә Нигъмәтулла хәзрәтнең социаль йөзен, үз заманында нинди фигура булуын күрсәтә алганнар, дигән тәэсир кала. Ш. Мәрҗани, мәсәлән, болай дип язган: «Мелла Нигъмәтулла бине Биктимер бине Тукай бине Урманай әл-Эстәрлебаш. Чыгышы белән Казан иленең Малмыж өязе Салавыч карьясеннән. Бабасы шуннан күчеп китеп башкортлар арасында «Башкорт» дип язылып, Эстәрлебашта урнашып кала. Мелла Нигъмәтулла Казанда Фазыл бине Сәйфулла әл-Кизләви һәм Мәчкәрәдә Мөхәммәдрәхим ахунд һәм мелла Гадеррахман әл-Каргалыйлардан гыйлем алгач, Бохарага сәфәр кыла һәм анда ишан хәлифә Ниязколый әт-Төрекмәни хозурында тәрбия ала. Үз ватанына кайткач, шәехлек белән шөгыльләнә. Дөньясы киң, шәкертләре күп була. Үз илендә чиктән тыш зур шөһрәт казана. Мелла Габденнасыйр әл-Курсави карашын яклаучылардан һәм аның дусларыннан була. Үз мәдрәсәсендә аңа карата кызыксыну уята. Атабыз мәрхүм һәм аның кебекләрнең сүзләренә карагандa, гыйлемдә дәрәҗәсе артык зурдан булмый».[4]

Сүзләренә берникадәр эмоциональ төсмер өстәп, Р. Фәхретдинев тә, нигездә, шушы ук фикерне кабатлый: «Нигъмәтулла хәзрәтнең дөньясы иркен, шәкердләре күп, ярыйакыннары хисабсыз, абруе югары, үзе чиксез диндар, аскет, дин юлындагы тугрылыгы белән көчле, данлыклы, атаклы, шөһрәтле булдыгыннан моның заманасында Эстәрлебаш карьясе дәр әл-гыйлем, ягъни югары белем бирү урыны булды. ...Балалары һәм халык арасында гыйлем вә гүзәл холык таратуы хакында булган тырышлыклары вә калдырган әсәрләре аз заманда онытылмас, искә алыныр».[5]

М. Тукаевның китабында әлеге фикерләр берникадәр конкретлаштырыла һәм Нигъмәтулла хәзрәт сөннәтне үтәүнең матурлыгы ахыр чиктә матур гамәлгә күчү белән бәяләнә дигән хәдис-девиз белән эш иткән, олуг кешеләр белән күп аралашкан, ярсу йөрәкле, гайрәтле кеше булган дигән нәтиҗә ясала. Китап авторы бабасының дөньяви тормыш өчен кылган гамәлләре турында да тәфсилләп яза: «Гыйлем алырга дип килгән шәкердләр күбәя башлагач, мәсҗед вә мәдрәсәләрне зурайтырга хаҗәт төшеп, күп акча вә химмәт, вә иҗтиһад сарыф кылынган. Мәсҗед авылның уртасына күчереп салынган. (1960 елларга кадәр район культура йорты булды.— 3.3.). Авылның бакчаларына агачлар утыртылган. ...1836 елларда булыр, Эстәрлебашыга фантал китертелгән. Суыннан бу көнгә кадәр ничә мең җан иясе файдаланып торалар».

Эстәрлебаш авылы утырган тау итәгеннән агып чыккан алты чишмәгә диаметры алты метрлы цилиндр формасындагы калын имән тактасыннан ясалган чаннар төшереп, диаметры җиде сантиметр куыш итеп борауланган имән торбалар ярдәмендә, авылның алты җиренә чишмә суы китертелгән. Суны яшел калай белән ябылган зур агач чаннардан кул насослары (пешкәк) ярдәмендә алалар иде. Халык менә шушы корылманы «фантал» дип атаган. Боларның икесе 1955 елларга кадәр авылны су белән тәэмин итеп торды. Әлеге «фантал»ны мактап, үз вакытында Г. Чокрый шигырь дә язган булган:

*Агар чишмәне таулардан ничә һөнәр ярдәмендә*
*Китерде йортына; һәрчак саф, тонык су килеп тора.*

---

[4] Мәрҗани Ш. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар.— Казан, 1989, 245-246 бб.

[5] Фәхретдинев Р. Асарь. 2 т., 9 җөзьә. Оренбург, 1904.

*Фәкыйрь, мескен, гарип, мохтаҗ дус-иш —*
*Бары аннан су ала, күңелләрен сафландыра.*[6]

Нигъмәтулла хәзрәт китап туплауга зур игътибар биргән, үзе дә күчереп язган, кешеләрдән дә яздырган, Бохарадан да алдырган: «китаплар хасил итү өчен, күп иҗтиһад вә маллар сарыф әйләгән». Эстәрлебаш мәдрәсәсе аның вакытында Казан, Оренбург, Уфа, Әстерхан, Урта Азия якларында үзенең кульязма һәм басма китапларының күплеге белән данлыклы булган.

Нәкъ менә шушы вакытларда Г. Утыз-Имәни әл-Болгариның (1754—1834) Эстәрлебашка берничә мәртәбә килүе, Нигъмәтулла Тукаев һәм аның уллары тарафыннан кунак булып каршы алынуы, мәдрәсәнең көтепханәсендә утыруы, аларны яратып китүе мәгълүм.[7]

Н. Тукаев тагын Мифтахетдин Акмулланың ата-аналары хакында мәгълүм берничә версиянең берсендә исеме телгә алына торган шәхес буларак та тарихка кереп калган кеше.

Нигъмәтулла Тукаевтан соң, 1844 елдан, Эстәрлебаш мәдрәсәләренең мөдәррисе булып аның улы Мөхәммәтхарис Тукаев (1810—1870) кала. Ул 1833 елдан 1841 елга кадәр Бохарада укып кайтканнан соң, Эстәрлебаш мәдрәсәсендә дәрес бирә башлый. Аның заманында әлеге мәдрәсәнең даны тагын да арта, шөһрәте тагын да ныграк тарала. «Тарихы Эстәрлебаш» китабында язылганча, бу вакытларда шәкертләр бик күбәяләр, «кыргыз тарафыннан, Минзәлә, Оренбург вә Казан тарафларыннан, нугайлар ягыннан байлыкка ия булучылар да, халык арасыннан да укыр өчен, белем алыр өчен, монда киләләр». Дүрт йөз кадәр кеше сыярлык тагын бер бина төзелә. Хәлфәләр дә күп була, шул ук вакытта, хәзрәтнең дәресләренә бергә җыелып, аны тыңлаганнан соң, үзләре дә «һәркем үз белдегенчә, сүзләшер булып, кайбер дәресләр ике-өч сәгать яисә аннан да озаграк була иде». 1860 елда Харис Тукаев хаҗ сәфәрендә булып кайта. 1869 елда тарханлык дәрәҗәсе ала, фәннәр өйрәнергә һәм телләр белергә өндәүче, дөнья хәлләреннән хәбәрдар кеше була, тирә-якта ул фәкыйрьләр өчен фәкыйрьханәләр ачкан кеше буларак та таныла.

Ш. Мәрҗани һәм Р. Фәхретдинев хезмәтләреннән дә әлеге шәхес хакында кыскача мәгълүмат алырга мөмкин: «Ярань-якыннары күп, заманының мәшһүр угыллары вә галимләре моның янына килерләр иде, шәкерт тәрбиясенә маһир, замана хәлләреннән хәбәрдар иде, «Русия исламлары өчен дәүләт телене белмәк мотлак лязем дия, мәдрәсәләре хозурында русча укырга аерым мөгаллим тотды вә шәкердләренә рус лисаны укырга әмер итде», газеталар укып торының зарурлыгын аңлаганда, шул вакытларда киң тарала торган «Голос» газетасына языла һәм аны тәрҗемә иттерә. Хаҗ сәфәреннән язылган хатларыннан Харис Тукаев улларын-кызларын сагына, ярата белә торган ата, тирә-юнен күзәтә һәм шул күргәннәрен оста итеп кәгазьгә төшерә белә торган кеше буларак күзаллана: «Аллаһы тәгалә насыйб итсә, шимбә көн Истанбулга ут кимәсе илә китәргә торамыз, 34 сәгать бара, диләр. Беренче нумерга керергә торамыз (беренче дәрәҗәне аңлатса кирәк).—З.З.). Түшәкләре сәхтияттан, пәрдәләре йифәк, таһарәтләнә торган урыннары мәрмәр ташыннан, самавар краны рәвешендә су киләдер. Хакы 28 таңкадер...»

Мәгълүм булганча, нәкъ шушы вакытларда әлеге мәдрәсәдә күренекле шагыйребез Шәмсетдин Зәки дә хәлфәлек кылган. «Эстәрлебаш мәдрәсәсендә философия, мантыйк, дин сабагы, гарәп-фарсы һәм татар телләреннән тыш, рус теле, тарих, табигать белеме һәм башка төгәл фәннәр дә укытылган»,— дип яза М. Рахимкулова Ш. Зәкинең оныгы Шамил Әбдрәшитовның Советлар Союзы Герое булуы турындагы мәкаләсендә («Совет мәктәбе», 1987, 2 сан).

«1849 елда шул заманда даны киң таралган Эстәрлебаш мәдрәсәсенә Гали Чокрый килә, «...атаклы Эстәрлебаш мәдрәсәсенә килеп, шагыйрь Ш. Зәкидән Акмулла дәрес ала».[8]

Мөхәммәтхарис хәзрәттән соң, Эстәрлебаш мәдрәсәләрендә мөдәррис, мәчетендә имам булып аның бертуган энесе Мөхәммәтхаррас (1814—1871), аңардан соң, бер-бер артлы алты улы хезмәт итәләр: исемнәре: Габдулла, Габидулла, Хәбибулла, Габделмәҗид, Габделкадыйр һәм Мөхәммәтшакир. «Тарихы Эстәрлебаш» китабында боларның һәрберсенең туган еллары, кайда укулары, мәдрәсәдә нинди фәннәрне укытуларын бәян итүче кыска-җыйнак мәгълүмат бирелә, авторы үзе хакында гына бер нәрсә дә язмый.

Гасыр башында Эстәрлебашның уналты мәдрәсәсендә алты йөздән артык шәкерт белем алган. Бу уңайдан Г. Ибраһимовның сүзләре искә төшә: «...Әнә Кышкарлар, Эстәрлебашлар бик кечкенә авыллар, ә үзләренә нинди зур мәдрәсәләр бар».[9] Әдип, әлбәттә инде, Нурмөхәммәт бабасының әлеге мәшһүр мәдрәсәдә белем алганлыгын бик яхшы белгән.

Мөдәррис-хәзрәтләр дин сабагы, дөньяви фәннәр, әхлак нормалары буенча белем

---

[6] Татар әдәбияты тарихы. 2 т. Казан, 1985, 421 б.

[7] Фәхретдинев. Асарь. 2 т. 15 җөзьә. Оренбург, 1909, 506.

[8] Татар әдәбияты тарихы. 2 т., Казан, 1985, 416, 445 б.

[9] Ибраһимов Г. Әсәрләр. 2 т., Казан, 1975, 34 б.

биру белән бергә, өзлексез диярлек, кульязма күчерү, китап туплау белән дә шөгыльләнгәннәр. Буыннан-буынга җыелып килгәнгә, Эстәрлебаш мәдрәсәсенең китап фонды заманасы өчен бик бай булган. Бу хакта академик В. В. Бартольдның Оренбург якларында сәяхәте хакында язылган мәкаләдә дә телгә алынып үтелә: «...Профессор җәнабләре Дума әгъзасы Шакир Тукаевка төшкән. Шакир мәхдүм русча вә мөселманча мәгърифәтле, кеше танучы мөгътәбәр зат булганга... дәресханә вә китапханәләрне күрсәткән. Профессор искедән бирле мәшһүр булып килгән бу Эстәрлебаш мәдрәсәләрен бик ләззәт илә карап һәр җәһәтдән тамаша иткән. Мәдрәсәнең китапханәләрендә 200, 300, хәтта 500 ел элек язылган кульязма китапларны диккать вә ләззәт белән караган» («Вакыт», 1913, 9 июнь).

Шушы ук мәкаләдән укыту ысулының нинди булуы турында да мәгълүмат алабыз. Эстәрлебашындагы мәктәпләрнең башлангыч классларында үз вакыты өчен яңа саналган «ысулы саутия», ягъни аваз методы белән укытылган икән. Академик шуңа да игътибар иткән: «...Ысулы саутия берлә укыла торган ибтидаи (башлангыч) мәктәпкә кереп, балаларның укый торган китапларын вә яза торган дәфтәрләрен караган».

Әлифба укытудан башланган әлеге методның барлык уку-укыту системасына да үтеп керүе, аны яңартуы мәгълүм.[10] Шушы вакытта татар имлясы-язуы, әдәби теленең нинди булырга тиешлеге турында озакка сузылган каты бәхәсләр башлана һәм шул нигездә берберсенә каршы куелган агымнар килеп чыга. Бу хакта телчеләребезнең хезмәтләрендә күп һәм җентекле язылган. Без фәкать әлеге уңайдан бер мәкаләдә Эстәрлебаш мәдрәсә әһелләренең телгә алынып үтелүенә игътибарны юнәлтәбез. Әлеге мәкаләнең авторы әдәби тел булып фәкать «гүзәл вә кагыйдәле төрек теле» генә саналырга тиешлеген бик эмоциональ аңлаткач («Исхакыйның «Инкыйраз»ы Истанбулда укылмазмы, файдасы улмазмы иде? Улур да әмма лисан, вай лисан!»), безнең галимләребезнең һәм шәкертләребезнең гүзәл вә әдәби лисан-тел белән генә гыйлем вә тәрбия вә әдәб алырга мөмкинлекләре булуын раслый. Соңыннан «Карт» псевдонимы белән язучы бу автор: «...Җаубаш, Эстәрлебаш, Түнтәр вә Кызылком җәмәгатьләре лисан вә әдәбият мәсләкыйле дәгъвәсенә тотынып йөресәләр, үле милләт булып калырлар, бу бер хакыйкатьдер ки...» — дип нәтиҗә ясый, үзенчә мыскыллап уза. («Шура», 1912, 1 сан).

XIX гасыр ахырында әлеге мәдрәсәдә берничә ел укыган әтием — Зәйнуллин Лотфулла Зәйнетдин улының сөйләвенә караганда, мәдрәсә китапханәсе авылның зур мәчете тирәсенә, махсус салынган алты йортта урнашкан булган. Китапханәдә ундүрт меңнән артык данә китап исәпләнелгән.

1921 елда Эстәрлебаш мәдрәсәсе эшләүдән туктагач, мәдрәсәнең соңгы мөдәррисе Мөхәммәтшакир Тукаев китапларны авылның укымышлы кешеләренә алырга рөхсәт иткән. 1923 елда Оренбургка күченгән вакытында, үзе дә әлеге китапларның күпмедер өлешен алып киткән булырга мөмкин. (Бик хәерчелектә яши. Утызынчы елларга кадәр авыл белән элемтәдә була).

Таратылган китапларның йөз илледән артыгы Эстәрлебашта яшәгән Габдерахман бабай Айдабуловта сакланган. Ул вафат булгач, әлеге китапларны Гайса Хөсәенов машинага төяп Уфага алып киткән.

Берничә китапханә һәм мәдрәсә урнашкан йортларның сызымнары Эстәрлебаш тарихына нигезләнеп авыл музее төзегән һәм шунда эшләгән Галиев Владимир Лотфрахман улында саклана.

Авылда 1922 елда оештырылган совет мәктәбендә татар телендә укыту башлана. Бу мәктәп 1938 елда ун сыйныф бетергән беренче чыгарыш ясый. Шул вакыттан бирле Стәрлебаш урта мәктәбе эшләп килә. Соңгы ун елда татар теле урынына башкорт теле укытылган иде, хәзер яңадан татар теленә күчтеләр.

Тагын шуны да әйтеп үтәргә кирәк, авыл халкы мәдрәсәгә зур ихтирам белән караган, кулыннан килгәнчә аның шәкертләренә һәрвакыт ярдәм итеп яшәгән. Мәчет һәм мәдрәсәләр өчен аерым урманы һәм җире булган. Ул урманнан авыл халкы үз кирәгенә агач кисмәгән, әлеге көндә дә аны Мәчет урманы дип йөртәләр.

Эстәрлебаш халкы бүгенге көндә дә үзләренең төбәгендә өч йөз еллар чамасы элек үк даны тирә-юньгә таралган атаклы мәдрәсәләр һәм аның китапханәләре булуын яхшы беләләр, туган якны өйрәнүчеләрнең бу хакта язмалары да күренгәли.[11]

Мәдрәсәләребез — мәгърифәт учаклары. Аларның тарихын белү дә мәгърифәтлелек билгесе ул. Хәзер безгә һәр мәдрәсә турында барлык булган мәгълүматларны тупларга һәм халыкка җиткерергә кирәк.

---

[10] Ибраһимов Ф. Белем әлифбадан башлана.— Казан, 1973, 51, 57 бб. Әмирханов Р. Дәресләкләребезнең тирән тамыры. «Казан утлары», 1989, 8 сан, 166-167 бб.

[11] Гомәров Г. Безнең якларда тәүге китапхана. «Ленин юлы» — Стәрлебаш район газетасы, 1975, 27 февраль.

# ТУГЫЗЫНЧЫ ДӘРЕС

*Киң болында һәр җәй саен*
*Чәчәкләр була.*
*Ал, сары, ак чәчәкләргә*
*Бал корты куна.*

*Тал куакларына кунып*
*Сайрый сандугач.*
*Без китәбез дачаларга*
*Матур җәй булгач.*

Нур Баян

Грамматик яктан катлаулырак, озынрак җөмләләр төзеп сөйләшә башлагач, без тагын шундый күренеш белән очрашабыз: безнең телебездә кушма җөмләләр күпчелек очракта аерым-аерым әйтелми, алар бик җайлы гына итеп бер-берсенә кушымчалар яки башка чаралар ярдәмендә кушылып китә. Бу кушымчалар, гадәттә хәбәргә ялгана.

Русча фикерләргә күнеккән балалар мондый җөмләләрне дә русча калыптарак төзергә омтылалар. Мәсәлән:

| | | |
|---|---|---|
| Без бакчага бардык бит әле, анда Ринат керпе күрде. | *дөресе:* | Без бакчага **баргач, анда Ринат керпе күрде.** |
| **Яңгыр туктый һәм (и) без су буена төшәбез.** | *дөресе:* | Яңгыр **туктагач**, без су буена төшәбез. |
| Минем тамагым авырта, чөнки (потому что) мин салкын сөт эчтем. | *дөресе:* | Салкын сөт **эчкәнгә** минем тамагым авырта. |
| Без барыйк аланга, кайда гөмбәләр үсә (Пойдем на поляну, где растут грибы). | *дөресе:* | Без гөмбәләр үсә торган аланга барыйк. |

**Сүзләрнең әйтелеш үзенчәлекләре.** Без телебездәге авазларның дөрес әйтелеше белән таныштык инде. Балаларның сөйләмендә аларның ничек әйтелешенә һәрчак игътибар итәргә, аларны төзәтергә һәм махсус артикуляция күнегүләрен дә ясый торырга кирәк. Авазларның сүз эчендә әйтелеше, аларның төрле үзгәрешләргә дучар булуы фонетика фәнендә икенче бер әһәмиятле өлкәне тәшкил итә. Болар телнең **фонетик закончалыклары** дип атала. Телебезнең үзенә генә хас фонетик закончалыклары бар. Без аларның әйтелеш һәм әдәби телдә дөрес сөйләү өчен мөһим булганнарына гына тукталып үтәбез.

1. Татар телендә сузык авазлар бер сүз эчендә йә калын гына, йә нечкә генә була (сингармонизм):

Бакчаларыбызда
тәрәзәләрегездә

2. Әйтелештә О, Ө сузыклары сүзнең икенче, өченче иҗекләрендә дә саклана:

| *Язылa:* | *Әйтелә:* |
|---|---|
| *болытлы* | *(болотлыо)* |
| *күзгеләр* | *(күзгөләр)* |
| *көлкеле* | *(көлкөлөө)* |

3. *Ике сүз арасында сузыклар кушылып китә. Һәм еш кына аларның берсе кыскара:*

| | |
|---|---|
| *алма ала* | *(алмала)* |
| *укы инде* | *(укинде)* |
| тәмле алма | (тәмлалма) |

4. Ике сүз арасында килгән кайбер саңгырау тартыклар йомшак әйтелә (яңгыраулаша):

| | |
|---|---|
| килеп ал | (килебал) |
| курчак ал | (курчагал) |

**Бүгенге дәреснең темасы:** «Безнең яшелчә бакчасы». Яңа сүзләр: чөгендер, кишер, кәбестә, суган, бәрәңге, җыялар, бакча, түтәл һ. б.

1. Рәсемнәр буенча әңгәмә.
— Бу нәрсә? — Яшелчә бакчасы.
— Биредә нинди яшелчәләр үсә? Бу нәрсә?
— Чөгендер (чө-чө-чө-ген-ген-ген-дер-дер-дер).
— Бу нәрсә? — кишер (сүз берничә тапкыр кабатлана).
— Бу нәрсә? — Помидор.
— Помидор нинди? — Түгәрәк, кызыл һ. б.
— Бу кемнәр? — Балалар.
— Балалар кайда эшлиләр? — Балалар бакчада эшлиләр. Алар яшелчә җыялар.

2. Картина эчтәлеге буенча кечкенә хикәя төзелә. Моны бала белән бергә эшләү яхшырак.

Бу яшелчә бакчасы. Биредә кишер, суган, помидор, кыяр, чөгендер үсә. Әнә теге түтәлдә малайлар помидор җыялар, аны кәрзиннәргә тутыралар. Помидор зур, кызыл, түм-түгәрәк булып өлгергән. Ә биредә балалар кишер йолкыйлар. Балалар яшелчә бакчасында зур уңыш үстергәннәр.

3. «Уңыш бәйрәме» уены:
(Уенны балалар бакчасында яки балалар өчен нинди дә булса бәйрәмдә оештырырга мөмкин).

*Уенны алып баручы:*

Дуслар бәйрәмгә килгәнсез,
Гөлдәй матур киенгәнсез,
Ниләр китердегез күзгә?
Сөйләп бирегезче безгә.

Яшелчә булып киенгән балалар:

*Кәбестә.*

*Безнең бакча балалары*
*Яшелчә дә үстерә.*

*Бакчадагы туптан да зур*
*Мәсәлән, мин — кәбестә.*

*Кабак.*
Карагыз әле бер генә
Минә миңа кабакка.
Турап куйсагыз, мин сыймыйм
Хәтта тугыз табакка.

*Кишер белән кыяр.*
Кишер дә бик күп булды,
Кыяр да бездә уңды.

*Бәрәңге.*
Ә бәрәңге, бәрәңге,
Бәрәңгене күр әле.
Сап-сары бәрәңге белән
Тирән базыбыз тулды.

*Алып баручы.* Рәхмәт, балалар. Сез бик булдыклы,
Бик тырыш, шуңа мул булган уңыш.

4. Яшелчәләр турында табышмаклар әйтешү.

Ишеге юк, тәрәзәсе юк, эче тулы халык.

*(Кыяр)*

Җир астында җиз бүкән.

*(Бәрәңге)*

Кат-кат тунлы карыш буйлы.

*(Кәбестә)*

Суярсың, тунарсың, тунаганда еларсың.

*(Суган)*

Җир астында алтын казык.

*(Кишер)*

Алма, дисәң дә алалар, нәрсә соң ул, балалар?

*(Алма)*

Минә сиңа тамаша:
Бер нәрсә ике төстә.
Кызыл гәүдәсе җирдә
Яшел койрыгы өстә.

*(Кишер).*

Фәһимә ХИСАМОВА,
филология фәннәре кандидаты,
Рәшидә БОРҺАНОВА,
методист.

*Гарәп әлифбасы нигезендә*
*татарча уку күнекмәләре*

## ТУРГАЙ МОҢЫ

Борынгы заманнарда безнең халкыбызның көе хәзерге вакыттагы кебек булмаган, ә бәлки азәрбайҗан, төрек халык көйләренә охшаш яңгыраган.

Бу бик күптән булган. Болгар иленә дошман явы һөҗүм иткән. Алар чәчәк аткан шәһәрләрне һәм авылларны җимергәннәр, ә барлык балаларны, яшь ирләрне һәм хатын-кызларны кырып бетергәннәр. «Болгарларның инде киләчәге юк!» — дип мыскыллап көлгәннәр дошманнар. «Бу кешеләр инде яңа токым үрчетә алмаслар»,— дип уйлаганнар алар исән калган карт-коры турында. Чөнки үзләре, күп микъдарда хәмер эчкәнгә күрә, олы яшькә җиткәнче үк эшкә яраксыз хәлгә киләләр икән. Әмма дошманнарның әшәке хыяллары эшкә ашмаган. Хезмәт сөючән, тырыш, таза һәм бөтенләй диярлек хәмер кулланмаган болгар халкы үрчеп, яңадан көчәеп киткән. Тик озак елларга халык күңелен караңгы кайгы баскан. Фаҗигале көннәрдә һәлак булган яшьләрнең хәтерен саклап, халык арасында җырлау һәм күңел ачу гөнаһ булып исәпләнгән. Әкренләп көйләр онытылган, уен кораллары югалган.

Еллар үткән. Яз көннәрендә җир сөрүче яшь болгар егетләре, кырларда тургай җырларын ишетеп, аларга кушылып көйли торган булганнар. Вакыт узу белән менә шул тургайлар моңы халкыбызның көенә әверелгән. Шуңа күрә халык җырларында тургайлар макталалар да инде.

## ШӘРИФКОЛ[1]

Русия таифәсе[2] тугыз йөз алтмыш беренче[3] елда татарларны җиңеп, Казан каласын тирә-ягы белән басып алганда, кала эчендә сигез манаралы бер җамигъ мәчете һәм Таҗик ермагы дип танылган мәхәлләдә янә бер мәчет вә мәдрәсә бар иде. Галимнәр, шул исәптән габбаси[4] изгеләр вә галәви сәедләр[5] күп иде. Аларның рәисе «Изгеләр җитәкчесе» дигән ат казанган Шәрифкол исемле, ислам ханнары вә шәһәр халкы алдында газиз вә мөхтәрәм бер кеше иде. Русия кинязьләре Казан ханнарына илче җибәреп хатлар күндергәндә, мулла Шәрифкол исеменә дә хатлар һәм бүләкләр җибәрәләр иде, диерләр. Соңында, русиялеләр Казанга һөҗүм иткән вакытта, ул үзенең яраннарын вә иярченнәрен янына җыеп, мәдрәсәгә кереп, аның түбәсе өстендә русиялеләр белән каты сугыш кылып, руслар тарафыннан мәдрәсә түбәсеннән чәнчеп төшерелеп, шәһид булды.

Татар халык иҗаты: риваятьләр һәм легендалар. Казан, 1987, 61, 217 бб.

---

*1. Шәрифкол (Колшәриф) — Казан ханлыгында зур сәяси көчкә ия булган шагыйрь, дин эшлеклесе һәм дипломат.*
*2. Таифәсе — халкы.*
*3. Тугыз йөз алтмыш бер — милади белән 1552 ел.*
*4. Габбасилар — гарәп хәлифәлегендә 750—1258 елларда идарә иткән династия.*
*5. Сәед — Мөхәммәд пәйгамбәр нәселеннән булган кешеләргә бирелә торган титул.*

بورونغی زمانلاردا بزنڭ حالقبزنڭ کویلری خاضرگی وقتاغی کبک بولماغان، ئه بلکه آذربیجان، تورك حالق کویلرینه اوحشاش یاڭغراغان.

بو بیك کوبته‌ن بولغان. بلغار ایلینه دوشمان یاوی هجوم ایتکه‌ن. آلار چه‌چه‌ك آتقان شهرلرنی هم آوللارنی جیمرگه‌نه‌ر، ئه بارلق بالالرنی، یه‌ش ایرلرنی هم حاتن-قز-لارنی قروب بترگه‌نه‌ر. «بلغارلرنڭ ایندی کیله‌چه‌گی یوق!» دیب مسقللاب کولگه‌نه‌ر دوشمانلار. «بو کشیلر ایندی یاڭا توقوم اورچیته آلماسلار»، - دیب اویلاغانلار آلار. ایسه‌ن قالغان قارت-قوری توروندا. چونکه اوزلری،کوب میقداردا حمر أچکه‌نگه کوره، اولی یه‌شکه جیتکه‌نچی اوك أشکه یاراقسز حالگه کیله‌لر ایکه‌ن. امّا دوشمانلارنڭ ئه‌شه‌کی حیاللاری أشکه آشماغان. حذمت سویوچه‌ن، ترش، تازا هم بتونله‌ی دیه‌رلك حمر قوللانماغان بلغار حالقی اورچپ یاڭادان کوچه‌یب کیتکه‌ن. تیك اوزاق یللارغا حالق کوڭلین قاراڭغی قایغی باسقان. فاجغه‌لی کونه‌رده هلاك بولغان یه‌شله‌رنڭ حه‌ترین ساقلاب. حالق آراسندا جرلاو هم کوڭل آچو گناه بولوب ایسه‌بله‌نگن. ئه‌کرنله‌ب کۇیلر اونوتلغان، اوین قوراللاری یوغالغان.

یللار اوتکه‌ن. یاز کوننه‌رنده جیر سوروچی یه‌ش بلغار یکتلری، قرلاردا طورغای جرلارین ایشتوب، آلارغا قوشو- لوب کویلی تورغان بولغاننار. وقت اوزو بله‌ن منه شول طورغایلار موگی حالقبزنك کوینه ئه‌ورلگه‌ن. شوگا کوره حالق جرلارندا طورغایلار ماقتالالر دا ایندی.

## شریف قل

روسیه طایفه‌سی توغز یوز آلتمش برنچی یلدا تاتار- لرنی جیگوب، قازان قالاسن تیره- یاغی بله‌ن باسوب آلغاندا قالا أچنده سیگز منارالی برجامع مَسْجدی هم تاجیك یر- ماغی دیب تانلغان مَحَلّه‌ده ینه بر مَسْجد و مَدْرَسه بار ایدی. عالمنر، شول ایسه‌بنه‌ن عَبّاسی ایذگیلر و علاوی سَیدلر کوب ایدی. آلارنك رائسی «ایذگیلر جیته‌کچسی» دیگه‌ن آت قازانغان شریف قل ایسملی. اِسلام حانناری و شهر حالقی آلدندا عزیز و مُحْتَرَم برکشی ایدی. روسیه کنه‌زلری قازان حاننارینا ایلچی جیبه‌روب حاتلار کوندر- گنده، مُلّا شریف قل ایسیمینه ده حاتلار هم بوله‌کلر جیبه‌ره‌لر ایدی، دیرلر. سوگندا، روسیه‌لیلر قازانغا هجوم ایتکه‌ن وقتا، اول اوزینك یاراننارین و ایه‌رچنه‌رین یانینا جیوب، مَدْرَسه‌گه کروب، آنك توبه‌سی اوستونده روسیه- لیلر بله‌ن قاتی سوغش قیلوب، روسلار تارافننان مَدْرَ- سه توبه‌سننه‌ن چه‌نچب تشورلوب، شهید بولدی.

Журнал өчен текстны Җәүдәт Миңнуллин һәм Раиф Мәрданов әзерләде.

## Мәрзия Фәйзуллинага 60 яшь



Балалар язучысы, шагыйрә Мәрзия Низам кызы Фәйзуллина (Тәрҗеманова) 1930 елның 11 июнендә Татарстан АССРның Арча районы Шушмабаш авылында туган.

1955 елда мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен беренче шигырьләр җыентыгы — «Салават күпере» китабы басылып чыга. 1956—1962 елларда балалар бакчасында эшләү чорында М. Фәйзуллинаның иҗаты бик нык активлаша, нәниләр өчен бер-бер артлы «Чәчәкләр сәгате», «Ике көрәк», «Зур дулкыннар» дигән шигырь китаплары дөнья күрә.

1958—1964 елларда ул М. Горький исемендәге Мәскәү Әдәбият институтында читтән торып укый. Шул елларда үзәк нәшриятларда (Детгиз, «Малыш») аның «Цветочные часы», «Стихи», «Пропала кошка» исемле өч китабы басылып чыга.

1985 елны дөнья күргән «Сугыш юлларының тузаны» (Солдат хатлары) китабы Мәрзия Фәйзуллина поэзиясендә бөтенләй яңа сәхифә: анда сугыш һәм тыл чынбарлыгының төрле күренешләре художестволы тасвирлана.

Бүгенге көндә М. Фәйзуллина — татар һәм рус телләрендә чыккан егерме китап авторы. Шагыйрәнең аерым әсәрләре, рус теленнән тыш, үзбәк, чуваш, украин һәм башка телләргә дә тәрҗемә ителгән.

1965 елдан СССР Язучылар берлеге союзы әгъзасы.

## Мансур Хәсәновка 60 яшь



Күренекле әдәбият галиме, тәнкыйтьче һәм дәүләт эшлеклесе Мансур Хәсән улы Хәсәнов 1930 елның 25 июнендә Татарстан АССРның хәзерге Зәй районы Бигеш авылында крестьян гаиләсендә туган. Җидееллык мәктәпне, аннары Алабуга китапханә техникумын тәмамлаганнан соң, ул туган ягында ике ел уку йорты мөдире булып эшли, Казан дәүләт университетын кызыл диплом белән тәмамлагач, аны аспирантурада укырга калдыралар. Аннан соң ул «Татарстан яшьләре» газетасының редакторы, университетта ассистент, тарих-филология факультеты деканы урынбасары хезмәтендә була. 1961 елда М. Хәсәнов КПССның Татарстан өлкә комитеты аппаратына эшкә күчерелә. 1971 елның маена кадәр лектор, аннары мәдәният бүлеге мөдире, идеология бүлеге мөдире урынбасары, фән һәм уку йортлары бүлеге мөдире вазифаларын башкара.

1971—1983 елларда М. Хәсәнов — Татарстан Министрлар Советы Рәисе урынбасары хезмәтендә, ә 1984 елның гыйнварында Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары итеп раслана. 1966 елдан ул КПССның Татарстан өлкә комитеты члены һәм күп мәртәбәләр Татарстан Югары Советы депутаты итеп сайланды. 1961 елда М. Хәсәнов кандидатлык, ә 1971 елда докторлык диссертациясен яклый, 1974 елда профессор исемен ала.

М. Хәсәнов — әдәбият, татар иҗтимагый фикере үсеше һәм мәдәнияте тарихына караган фәнни-теоретик хезмәтләр, монографияләр һәм бүгенге әдәби хәрәкәтнең җитди мәсьәләләренә багышланган тәнкыйть мәкаләләре авторы. Язучы революционер, җәмәгать эшлеклесе Г. Ибраһимовның тормышын һәм иҗатын өйрәнүгә ул аеруча күп көч куйды, классик әдип турында татар һәм рус телләрендә күләмле монографияләр язды. Ул урта мәктәпләр өчен татар әдәбияты буенча дәреслекләр төзү эшендә актив катнашып килә. М. Х. Хәсәнов ике мәртәбә Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы һәм Мактау орденнары белән бүләкләнгән.

1976 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

*Татарстан Язучылар союзы идарәсе һәм «Казан утлары» журналы редакциясе юбилярларны чын күңелдән котлый. Аларга яңа иҗат уңышлары, озын гомер тели!*

## ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

16 апрель көнне Татарстан Язучылар берлеге башлангыч партия оешмасының ачык җыелышы булып узды. Җыелышның көн тәртибенә өч мәсьәлә куелган иде. КПССның яңа уставы проекты турында фикер алышуларда әдипләрдән М. Хәбибуллин, Р. Мостафин, М. Насыйбуллин, М. Хуҗин һ. б. катнашты.

Татарстанның 42 нче өлкә партия конференциясенә делегатлыкка кандидат итеп Татарстан Язучылар берлеге рәисе Р. Мөхәммәдиев, ә КПССның 28 нче съездына делегатлыкка кандидат итеп тәнкыйтьче Р. Мостафин күрсәтелде.

Җыелышны Язучылар берлегенең партия оешмасы секретаре Р. Низамиев алып барды.

## ЯЗУЧЫЛАР — ХАЛЫК ДЕПУТАТЛАРЫ

Узган сайлауларда язучыларыбыз — Ринат Мөхәммәдиев 127 нче Лениногорск милли-территориаль сайлау округы буенча РСФСР халык депутаты булып сайланды; 123 нче Буа сайлау округыннан Ренат Харис, 233 нче Саба сайлау округы буенча Фәүзия Кадыйрова (Бәйрәмова), 48 нче Декабристлар сайлау округыннан Роберт Миңнуллин, 169 нчы Усали сайлау округы буенча Равил Фәйзуллин, 28 нче Измайлов сайлау округыннан Разил Вәлиев ТАССР халык депутатлары итеп сайландылар.

Татарстан АССРның уникенче чакырылыш Югары Советының беренче сессиясендә шагыйрь Роберт Миңнуллин ТАССР Югары Советы Президиумы әгъзасы итеп сайланды.

Халык депутатларының егерме беренче чакырылыш Казан шәһәр Советы сессиясендә шагыйрь Разил Вәлиев шәһәр Советы Президиумы члены итеп сайланды.

## ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕ

25 майда ТАССР Язучылар берлеге рәисе Ринат Мөхәммәдиев җитәкчелегендәге бер төркем язучылар, шагыйрьләр Г. Тукай туган Арча якларында, Тукай-Кырлай авылында булып, чыгышлар ясадылар, хезмәт ияләре, укучылар белән очраштылар.

26 майда шигырь бәйрәме Казанда үзенең йомгаклау ноктасына җитте. Г. Тукайның музей-йортында башланган шигъри сүз ташкын булып М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет академия театры янындагы шагыйрь һәйкәле алдында дәвам итте. Аны кереш сүз белән шигырь бәйрәмен уздыру комиссиясе рәисе шагыйрь З. Мансуров ачты. Ул сүзне 1990 ел өчен Татарстан АССРның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премияләренә лаек булган язучылар И. Салахов һәм М. Мәһдиевкә бирде. Алар үз чыгышларында моңа кадәр йокымсырап яткан халкыбызның уяна башлавына сөенүләрен белдерделәр.

Алардан соң сүз шагыйрьләргә бирелде. Тантанага җыелган тамашачылар алдында шагыйрьләребез Н. Арсланов, Р. Гатауллин, Р. Зәйдуллин, М. Хөсәен, Л. Шакирҗанова, Л. Леронов, К. Булатова, Г. Рәхим, Г. Моратов, Р. Миңнуллин, Р. Гәрәй, Ә. Рәшитов, К. Латыйпов, Зөлфәт, Р. Юнысов, Р. Вәлиев һәм башкалар чыгыш ясады.

## РӘССАМ ХӨРМӘТЕНӘ

СССРның халык рәссамы, СССР Художество академиясе член-корреспонденты, СССР, РСФСР, ТАССР Дәүләт премияләре лауреаты Харис Габдрахман улы Якуповның тууына 70 ел һәм иҗат эшчәнлегенә 50 ел тулуны 19 мартта җәмәгатьчелек тантаналы шартларда билгеләп үтте.

Татарстан Художниклар берлегенең күргәзмәләр залында ул иҗат иткән әсәрләрне туплаган зур күргәзмә ачылды. Кичен тантана Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында дәвам итте. Аны кереш сүз белән ТАССР Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов ачты.

Сынлы сәнгатьне үстерүдәге хезмәтләре өчен Х. Якупов КПСС өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советының Мактау грамотасына лаек булган иде. КПСС өлкә комитетының беренче секретаре М. Ш. Шәймиев тантаналы шартларда әлеге бүләкне тапшырды.

Юбилярның тормыш һәм иҗат юлы турында ТАССР мәдәният министры М. М. Таишев сөйләде.

## КОНКУРСКА ЙОМГАК

Илебездә барган киң сулышлы үзгәрешләр чорында төрле җитешсезлекләрне фаш итеп, тормышка якынайган әдәбиятыбызда сатира-юмор жанрын үстерүне күздә тотып, узган ел, Татарстан Язучылар берлеге, Татарстан мәдәният фонды, Татарстан Язучылар берлеге каршындагы «Туган як» җәмгыяте һәм «Чаян» журналы танылган татар язучысы — юмор-сатира остасы Фаил Шафигуллин истәлегенә шаян һәм көлкеле хикәяләргә ачык конкурс игълан иткән иде.

Жюри членнарының уртак фикеренчә, беренче махсус премия, иҗатына хөрмәт йөзеннән, мәрхүм әдип Фаил Шафигуллинга бирелде.

Икенче ике премияне Марсель Галиев

һәм Роберт Батулла бүлеште. Өченче өч премия хуҗалары итеп Камил Кәримов, Заһид Мәхмүти, Фәнзаман Баттал исемнәре аталды. Балалар тормышын чагылдырган көлкеле хикәяләр өчен бер махсус премиягә Рафис Гыйззәтуллин лаек булды.

### СӨЕКЛЕ ҖЫРЧЫБЫЗ КАЗАНДА

16—24 мартта Казан шәһәрендә РСФСРның һәм БАССРның халык артисткасы Фәридә Кудашева концертлары булып узды. Халкыбыз язмышын бүлешеп яшәгән атаклы җырчының иҗат кичәләре Казан тамашачылары өчен олы бәйрәмгә әйләнде. Халкыбыз ул көннәрдә тагын бер шатлык кичерде: совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен, Татарстан Югары Советының 1990 ел, 13 март Указы белән, Фәридә Кудашевага «Татарстан АССРның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

### ЛИТВАДАН ХӘБӘРЛӘР

Литва җирендә татарлар бик борынгы заманнардан бирле яшиләр.

Хәзерге вакытта, җитди үзгәрешләр нәтиҗәсендә, Литва ССРда яшәүче татарларга үз телен, культурасын, гореф-гадәтләрен торгызу өчен бөтен мөмкинлекләр тудырыла. Баштарак Вильнюста әрмәннәр, еврей һәм украиннар өчен мәктәпләр ачылган иде. Менә инде татарларга да нәүбәт җитте: тиздән тагын бер милли мәктәп ачылачак. Ташкент педагогия институтыннан килгән белгечләр моңа әзерлек эшләре алып баралар.

Литвада поляк телендә чыга торган «Червоны штандар» («Кызыл байрак») газетасының 12 январь санында Мечислав Яцкевичның Польшадан җибәргән мәкаләсе дә бар. Анда, Лукишкин дигән авылга нигез салучылар бирегә 1397 елда килеп утырган татарлар булганнар икән, диелә. Автор, борынгы тарихи материалларга таянып, болай дип тә яза: «Татарлар үзләренең намуслы булулары белән дан тотканнар, аларга карата бер генә дә җинаять эше кузгатылганы булмады».

Вакытлар узу белән Лукишкин үсә, монда шул төбәк халкы да урнаша бара. XIX гасырда бирегә татар өйләре күп калмый. Берничә дистә ел элек Лукишкин Вильнюс шәһәре составына кергән.

### ГЕРМАНИЯГӘ СӘЯХӘТ

«Ватан» җәмгыяте идарәсе әгъзасы язучы Тәүфикъ Әйди март-апрель айларында, милләттәшләребез чакыруы буенча, ГФРның Ной-Ульм, Мюнхен шәһәрләрендә булып кайтты. Ул анда татарларның Германиягә килеп төпләнүен һәм милли мәдәниятебезне саклау, үстерү хәрәкәтен өйрәнде. ГФР Язучыларының Бавария оешмасы җитәкчесе Аета Шайб белән күрешеп, немец-татар әдәбиятлары багланышын югга салу хакында әңгәмә ясады.

АКШ конгрессы карамагында эшләүче «Азатлык» радиостанциясе Мюнхен шәһәреннән СССР халыклары телләрендә тапшырулар алып бара. Т. Әйди шушы радиоүзәкнең төрки редакцияләре хезмәткәрләре белән очрашты һәм аларга халкыбызның рухи тормышы сәхифәләре, әдәби мөнәсәбәтләребез, Татарстанның чит илләрдәге милләттәшләребез белән бәйләнешен ныгыту өчен яңа корылган «Ватан» җәмгыяте турында сөйләде. Бу чыгыш һәм сорауларга бирелгән җаваплар соңыннан татар, казах, рус телләрендә радио тыңлаучыларга тәкъдим ителде.

«Азатлык» радиосы хезмәткәрләре белән очрашуда «Идел» журналы баш мөхәррире Римзил Вәлиев тә катнашты.

### МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Театр сәнгате өлкәсендәге зур уңышлары өчен М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрының балет солисты Рифат Әбелхановка, Татарстан АССР Югары Советы Президиумының 1990 ел, 9 январь Указы белән, «Татарстан АССРның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең эстрада бүлеге солист-вокалисты Искәндәр Биктаһировка, эстрада бүлеге солист-вокалисткасы Рабига Сибгатуллинага, Татарстан АССР Югары Советы Президиумының 1990 ел, 12 январь Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет культурасы өлкәсендәге хезмәтләре өчен Болгар дәүләт тарих-архитектура тыюлыгы директоры Мөхәммәтшин Җәмил Габдерәхимовичка, Татарстан АССР Югары Советы Президиумының, 1990 ел, 29 январь Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган культура хезмәткәре» дигән исем бирелде.

# СӨЕМБИКӘ МАНАРАСЫ

Сөембикә манарасы — Казандагы милли архитектурабыз һәйкәлләренең күркәме һәм, әйтергә кирәк, иң атаклысы. Аңардан башка шәһәребезне күз алдына китерү дә кыен. Калабызга килгән кунаклар аның мәһабәт һәм җиңелчә күккә ашып торган матур эшләнешенә сокланалар.

Сөембикә манарасы җиде кат (астагы өчесе — дүрткырлы, өстәге дүртесе — сигезкырлы) итеп кызыл кирпечтән төзелгән. Нигезенең тигез утырмавы сәбәпле, акрынлап көнчыгыш тарафына авышкан. Бу авышлык 1960 елларда 1 метр 69 сантиметр булса, хәзер инде 1 метр 84 сантиметрга җитте. Мондый манаралар дөньяда санаулы гына. Шулар җөмләсеннән Италиядәге Пиза манарасын «Егылучы манара» дип тә атыйлар.

Манараның биеклеге 58 метр, нигез мәйданы 140 квадрат метр, архитектурасы сирәк очрый торган алымнар белән эшләнгән. Тикшеренүчеләр өчен шунысы ачык: манараны төзүдә милли болгар-татар мотивлары һәм Шәрык үрнәкләре файдаланылган.

1520 елларда Россиядә булган австрияле илче, галим Герберштейн «Казан татарлары алдынгы халыклардан санала һәм алар белемлеләр» дип язып калдырган. Шул ук XVI йөз урыс язучысы Пересветов Казан ханлыгының җирләрен «Җәннәт янындагы җирләр» дип атаган. Явыз Иван Казан диварлары каршында тукталып, шәһәрнең матурлыгына шаккаткан. 1552 елда Казанны яулап алуда һәм 1552—57 еллардагы халык чуалышларын бастыруда катнашкан князь А. Курбский да шәһәрдәге биек таш манаралар барлыгын, авыллардагы бәкләрнең сарай-йортлары бик гүзәл эшләнгәнлеген сокланып язып калдырган. Мәшһүр галимебез Ш. Мәрҗани, үзенә билгеле булган чыганакларга таянып, Казан Кремлендә 8 манаралы Җәмигъ мәчет булуы турында язган.

Манара стеналарының эчке ягында каттан катка менү өчен тар һәм текә баскычлар ясалган. Нәфис итеп эшләнгән тәрәзә уемнарыннан шәһәр һәм аның тирә-ягындагы манзараны хозур иткәндә, ирексездән бабаларыбыз гомер кичергән ерак заманнар, Сөембикә ханша, аның аянычлы язмышы турында уйланасың.

Сөембикә Нугай князьләренең олысы Йосыф кызы булган. Тарихта атаклы Юсупов фамилиясен йөртүче урыс князьләре (соңгысы Распутинны үтерүне оештыручы), әнә шул Йосыф балаларыннан киләләр. Сөембикәне Мәскәү тарафыннан Казанга хан итеп куелган Җангалигә кияүгә бирәләр. Ләкин алар арасында мәхәббәт тойгылары булмый. Мәскәү сәясәтен генә үткәрүдә һәм милләт мәнфәгатьләрен кайгыртмауда гаепләнеп, 1536 елда Җангали Казан бәкләре тарафыннан үтерелә. Хан булып икенче мәртәбә кире Казанга кайткан Сафагәрәй Сөембикәгә өйләнә һәм алар бик тату яши башлыйлар. 1547 елда аларның уллары туа, аңа Үтәмешгәрәй дип исем куялар. Ләкин 1549 елда Сафагәрәй вафат була һәм Сөембикә баласы белән тол кала. Озакламый Үтәмешгәрәйне хан итеп игълан итәләр; ә анасы Сөембикә аның өчен дәүләт белән идарә итәргә тиеш була.

Тарихи әдәбиятта Сөембикә гүзәл, мөлаем, кешелекле һәм гакыллы хатын итеп сурәтләнә. Мәгълүм иҗтимагый-сәяси хәлләрнең үтә нык кискенләшүе сәбәпле, Казан ханлыгын саклап калу максатында, Казан бәкләре Сөембикәне улы белән бергә Мәскәү карамагына тапшырырга мәҗбүр булалар. Бу вакыйгадан соң Йосыф бәк һәм Нугайның башка морзалары Сөембикәне үзләренә кайтаруларын сорап Явыз Иванга берничә мәртәбә мөрәҗәгать итәләр. Ләкин, үз ватанына кайтарасы урынга, Сөембикәне Касыйм ханы Шаһгалигә хатынлыкка бирәләр. Биш яшьлек улы Үтәмешгәрәйне 1553 елның 5 гыйнварында чукындырып, асыл исемен Александрга үзгәртәләр һәм, анасыннан аерып, Мәскәүдә калдыралар.

Шуннан соң Сөембикә турында әлегә башка төгәл мәгълүматлар юк.

Халкыбыз арасында Сөембикә турында төрле риваятьләр йөри. Аларның берсендә Сөембикәнең, урыслар кулына бирелмәс өчен, шушы манарадан ташланып үлгәнлеге турында бәян ителә.

**Сәлам АЛИШЕВ,**
тарих фәннәре кандидаты.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** күренекле әдип Нурихан Фәттах.
**Юрий ФИЛИМОНОВ** фотолары.

# ИГЪТИБАР: ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ!

Татар Совет Энциклопедиясен булдыру турында сүз дистә еллар элек күтәрелгән иде. Ву гомер эчендә союздаш республикаларның үз телләрендә күптомлы энциклопедияләре басылып чыкты, ә Татар Энциклопедиясенә һаман да чират житмәде. Моңа безнең «автономияле республика» эшләпәсен күтәреп йөрүебез комачаулаганмы, әллә башка сәбәпләр булганмы — аны ачыклауның хәзер инде ул кадәр кирәге юктыр. Ниһаять, үткән елның көзендә Татарстан хөкүмәте Татар Совет Энциклопедиясен әзерләргә һәм чыгарырга дигән карар кабул итте. Мондый гаять катлаулы олы хезмәтнең Баш редколлегиясе төзелде (башлыгы — Татарстан АССР Министрлар Советы рәисенең беренче урынбасары профессор М. Х. Хәсәнов), Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында Гыйльми үзәк булдырылды.

Энциклопедия нинди принципка нигезләнәчәк соң? Шунысы көн кебек ачык: бу хезмәт Зур Совет Энциклопедиясенең дә, союздаш республикалар энциклопедияләренең дә модельләрен кабатламаячак, ул милли, шул ук вакытта региональ да булачак. Икенчерәк итеп әйткәндә, аның асылында «Барысы да — татарлар һәм Татарстан турында» дигән принцип ята. Димәк, ул татар халкының (милләттәшләребезне Татарстан чикләрендә яки чит өлкәләрдә һәм чит илләрдә яшәүчеләргә бүлгәләмичә) бай тарихын, гореф-гадәтләрен, бәйрәмнәрен, әдәби мирасын, музыка, рәсем һәм театр сәнгатенең үсешен һәм башка бик күп өлкәләрдәге казанышларын иңләячәк. Энциклопедиядә татарлар яшәгән барлык шәһәр-авыллар, төбәкләр турында мәгълүмат китereләчәк, күпкырлы тормышыбызның төрле өлкәләрендә шөһрәт казанган барлык шәхесләребезгә (язучыларга, галимнәргә, дәүләт эшлеклеләренә, рәссамнарга, уйлап табучыларга, спортчыларга, артистларга, хәрбиләргә һ. б.) урын биреләчәк. Энциклопедия битләрендә милли мәдәниятебезгә, сәяси һәм икътисади тормышыбызның үсешенә өлеш керткән башка милләт кешеләре өчен дә урын табылачак.

Татарстан җиренең файдалы казылмалары, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы, җир-су атамалары, күренекле археологик казылмалары, Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы истәлекләре, табылдыклары һәм башка бик күп нәрсәләр хезмәт битләрендә, һичшиксез, урын алачак.


Күренә ки, бу — бездә моңарчы булмаган катлаулы, күпкырлы хезмәт һәм аны йөзгә тап төшермәслек итеп әзерләү өчен милли горурлыкларын югалтмаган һәр кешенең катнашы зарури. Ул — галимнәр эше генә түгел, киң җәмәгатьчелекнең дә эше. Республикабызда, башка өлкәләрдә һәм шулай ук чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез, төрле оешмалар һәм предприятиеләр энциклопедиягә кирәрдәй материаллар җыюда катнашырлар, дип ышанасы килә. Сораулар һәм тәкъдимнәр булса, энциклопедияне әзерләүче махсус бүлеккә түбәндәге адрес буенча мөрәҗәгать итә аласыз: *420111. г. Казань, ул. Лобачевского, 2*/31. ИЯЛИ КНЦ АН *СССР. Отдел ТСЭ.*

Татар энциклопедиясен әзерләү һәм бастырып чыгаруның матди ягы да бар. Эшне башлап җибәрү өчен Татарстан хөкүмәте быел 100 мең сум акча бүлеп биргән иде. Республикабызның кайбер оешмалары һәм предприятиеләре дә булдыра алганча финанс ярдәме күрсәтә башладылар. Мәсәлән, «Нижнекамскнефтехим» белән Горбунов исемендәге авиация производство берләшмәләре, мәсәлән, 50 шәр мең, «Татпушнина» производство берләшмәсе 30 мең, Киров исемендәге синтетик каучук заводы 15 мең, РСФСР мәдәният фондының Татарстан бүлеге 10 мең сум акчаны энциклопедия фондына күчерделәр инде. Шул ук вакытта ни өчендер КамАЗ, АлАЗ, «Татагропром» кебек куәтле оешмалар ярдәм итә алмаулары турында белдерделәр. Финанс ярдәме күрсәтергә теләкләре булган оешмалар һәм аерым кешеләр өчен хисап исәбен күрсәтәбез: *Татарское РУ ЖСБ СССР МФО 265016, счет 142630. Главная редколлегия ТСЭ при Совете Министров ТАССР.*

**Фәрид ХӘКИМҖАНОВ,**
филология фәннәре кандидаты,
Татар Совет Энциклопедиясе бүлеге мөдире.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)